ISSN 0206—4

# Казан утлары

12. 1983



# «Авыл офыклары» конкурсы йомгаклары

Авыл хуҗалыгы эшчәннәренең Азык-төлек программасын үтәүдәге фидакарьлегенә багышланган «Авыл офыклары» конкурсы турында игълан журналның 1982 елгы 11 нче санында бирелгән иде. Конкурска 26 очерк килде һәм шуларның 15 е журналда басылырлык дип табылды, 11 е журналыбызның 1983 елгы саннарында дөнья күрде.

Жюри, конкурсның ел әйләнәсендәге торышы белән танышып, мондый нәтиҗәгә килде.

1. «Авыл офыклары» конкурсы язучыларның, журналистларның һәм авыл хәбәрчеләренең очерк-публицистика жанрындагы эшчәнлеген активлаштырырга сизелерлек этәргеч ясады.

2. Конкурс барышында редакциягә эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше һәрьяктан камил очерклар кермәгәнлектән, игъланда вәгъдә ителгән беренче бүләкне бирмәскә, башка бүләкләрне әсәрләре яхшы дип табылган түбәндәге авторларга тапшырырга карар кылынды:

II бүләк (100 сум) — Илдар НИЗАМОВКА («Күңел урталыгыннан», 1983, 5 нче сан);

III бүләк (75 сум)— Энҗе МӨЭМИНОВАГА («Бер остазның ике шәкерте», 1983, 10 нчы сан);

III бүләк (75 сум) — Мөнир ӘҺЛИУЛЛИНГА («Өр-яңа мәсьәләләрне чишкәндә», 1983, 4 нче сан);

III бүләк (75 сум) — Мәрди РАФИКОВКА («Урман хуҗасы», 1983, 12 нче сан).

Жюри җиңүчеләрне ихлас күңелдән котлый, конкурста катнашкан барлык авторларга тирән рәхмәт белдерә һәм иҗатларында яңадан-яңа уңышлар тели.

# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
СОЮЗЫ ОРГАНЫ

12

1983

## *Бу санда*

КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ЕЛ)
ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

**Яңа бурычлар.** Редакция анкетасына җаваплар . 3

**Р. КӘРАМИ.** Йөрәгемне ут алган. Повесть . . . 11
**РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВ.** Шигырьләр . . . . . . 56
**К. МОСТАФИН.** Шигырьләр . . . . . . . . . 59
**М. РАФИКОВ.** Хикәяләр . . . . . . . . . 62
**Д. СИРАЙ.** Шигырьләр . . . . . . . . . 70
**М. ХУҖИН.** Май кояшы — яшь кояш. Хикәя . . 72

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

**В. КОЧЕТКОВ, А. ВЕЯН, Н. НИКУЛИНА, А. БИК, М. КАЗАКОВ, С. ВИШНЕВСКИЙ, Б. ДАНИЛОВ, С. ӘЛИБАЕВ.** Шигырьләр . . . . . . . . 80
**Ә. ӘЙЛИСЛИ.** Офыктагы җылы урман. Повесть . 91
**С. ВОРОНИН.** Чигирикандра итәгендә. Хикәя . . 109

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

**М. ЗАРИПОВ.** Кемдер ота, кемдер оттыра . . . 113

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫНА

**М. РАФИКОВ.** Урман хуҗасы . . . . . . . . 129

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**М. ХӘСӘНОВ.** Олы язмышлар юксындыра . . . 135
**Ф. ДУНАЙ.** Дөрләп ала фикерләр . . . . . . 140

**ТӨХФӘТОВЛАР.** Тормыш мәсьәләләре булсын . 144

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

**Г. МУХАНОВ.** Әдәбиятыбызның күркәм сыйфаты . 145
**Т. НАСЫЙРОВ.** Д. Бедный Татарстанда . . . . . 149

БИБЛИОГРАФИЯ

**С. МАННАПОВ.** Без бик якынбыз . . . . . . . 152
**Р. БӘШӘРОВ.** Балаларга яңа китап . . . . . . 155

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

**Ә. ЕНИКИ. Хатлар укыганда** . . . . . . . . . . 158

БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**И. ЮЗЕЕВ** . . . . . . . . . . . . . . . 162

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН. Сәхнәдә Камал I дисәләр** . 164

ИСТӘЛЕКЛӘР

**С. ХӘКИМ. Аккош күлендә сагыш, моң** . . . . 167

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

**С. МУЛЛАГАЛИЕВ, Х. БАКИЕВ. Шигырьләр** . . . 179

**1983 елда басылган әсәрләр исемлеге** . . . . 182

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **САЛИХ МАННАПОВ, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*

Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза бүлеге — 53-07-61, поэзия бүлеге — 53-07-61, тәнкыйть бүлеге — 53-07-63, сәнгать бүлеге — 53-07-63, очерклар бүлеге — 53-07-61, хатлар бүлеге — 53-07-63, корректорлар — 53-07-65, техник редактор — 53-07-65, машинисткалар — 53-07-60.

Производствога бирелде 28.09.1983 ел. Басарга кул куелды 24.11.1983 ел. ПФ 07099. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8)
Тираж 65049. Заказ Я-383. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

# КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ел) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

## ЯҢА БУРЫЧЛАР

**КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы уңае белән журнал редакциясе язучыларга берничә сорау биргән иде. Түбәндә шул сорауларга алынган җавапларны урнаштырабыз.**

СОРАУ:

— Совет кешеләренә коммунистик тәрбия бирү буенча Сез бүгенге татар әдәбияты алдында нинди яңа бурычлар күрәсез?

АТИЛЛА РАСИХ:

— Халыкка коммунистик тәрбия бирүдә совет әдәбиятының һәм, шул җөмләдән, татар әдәбиятының зур роль уйнаганлыгы барыбызга да мәгълүм. Ә менә КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы карарлары яктылыгында без — язучылар алдында торган бурычлар тагын да җитдиләнә төшә. Без бу катлаулы дөньядагы бик җаваплы вазифабызны ачык аңларга һәм үз иҗатыбызга таләпчәнлекне нык арттырырга тиешбез.

Сер түгел, язучыларыбыз еш кына тиешеннән артык камерный әсәрләр, көнкүреш ваклыклары турында язгалый башладылар. Кайбер очракта бу эчке сыкрану, бәхетсезлек мотивларын да күпертүгә китерә. Ә укучыны мавыктырырлык көчле уңай образлар әдәбиятта шактый кимеде, я булмаса ул тонык кына, икенче пландагы персонаж рәвешендә гәүдәләнә башлады. Әсәрләребезнең эчтәлегенә күз салсак, без кайбер очракта персонажларыбызның ваклануын да чамалый алырбыз. Минем әйтәсе килгәнем шул: бездә бүгенге көн таләп иткән уңай образларның эре планда язылганнары бик аз. Безгә идея коралларыбызны тагын да ныграк чарларга, вакытның ифрат җаваплы икәнлеген, матур әдәбиятның коммунистик тәрбия бирүдә бик-бик мөһим роль уйнаганын истән чыгармаска, эмоциональ яктан көчле, ышандыра торган, онытылмый торган әсәрләр тудырырга кирәк.

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ:

— Әдәбият гомер буе шушы планетадагы кешеләр арасында гуманлылык булсын өчен көрәшкән. Калган бурычлар барысы да шул зур идеягә кайтып калалар. Планетада ни җитми? Гуманлылык. Бу инде кешелеклелек дигән сүз. Безнең авылда, мин бала вакытта мондый сүз бар иде: «кешлеккә кию». Бу — күлмәк, яулыкка, киемгә карата кулланыла. Мин бу термин турында күп уйландым. Хәзер үзем өчен ачыш ясадым кебек: ул кием күрше-күлән, ил алдында сине матур, әдәпле итеп күрсәтергә тиеш. Синең тышкы кыяфәтең башкаларда матур хис уятырга, аларны да кешелекле булырга өйрәтергә, тәрбияләргә тиеш.

Әдәбият — халыкның, аның яшәү рәвешенең «кешлеккә кия торган» күлмәге, киеме. Бу төшенчәгә, минемчә, барысы да сыеп бетә. Хәер, бөек Ленин «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән хезмәтендә әдәбиятның гуманистик бурычлары турында 1905 елда ук язган иде инде. Мин бу хезмәтне соклана-соклана гел укыйм. Бигрәк тә, Ленинның әдәбиятка «җанлы пролетар эшнең җанлы агынтысын кертергә, шулай итеп, Россиядәге: язучы языштыргалый, укучы укыштыргалый,

дигән иске, ярым обломовча, ярым сәүдәгәрчә принципның һәртөрле җирлеген калдырмаска» дигән сүзләре турында кат-кат уйланам.

ШАМИЛ БИКЧУРИН:

— Язучылар алдына баскан аеруча мөһим проблема — илгә матерйаль байлык җитештерүчеләрне күрсәтү, дип уйлыйм. Көндәлек матбугатка игътибар итсәк, газеталарның беренче битләрендә илдәге зур яңалыклар, хезмәт уңышлары язылган булыр, производство, авыл хуҗалыгы алдынгылары күрсәтелер, галимнәрнең яңа фәнни ачышлары бирелер. Көнләшәм: журналистлар бу яктан сизгеррәк тә, өлгеррәк тә. Мин моны һич тә язучыларга журналистларны каршы кую өчен сөйләмим. Аларның — үз эше, безнеке — үзебезнеке. Язу алымнарыбыз, сәнгать чараларыбыз белән дә аерылып торабыз.

Җыеп кына әйтәсе килгән сүзем шул: безгә көн кадагына суккан мәсьәләләр турында тирәнгәрәк кереп язарга кирәк.

СОРАУ:

— Июнь Пленумы уңае белән әдәби тәнкыйть алдында нинди яңа бурычлар күрәсез?

ФЛҮН МУСИН:

— Татар әдәби тәнкыйте мөстәкыйль жанр буларак әле формалашып кына килгән вакытта ук Тукай аның «кирәкле шәйдер» икәнен яхшы аңласа, безнең чорда бу жанрның гомум әдәби-эстетик хәрәкәттәге урыны һәм роле тагын да тирәнрәк күзаллана, киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә. Әлеге мәсьәлә партиянең программ документларында да идеология эшенең әһәмиятле тармагы рәвешендә мөһим урын ала. КПССның 1983 елгы июнь Пленумында да иҗатка йогынты ясауның төп методы булып марксистик-ленинчыл тәнкыйть торырга тиеш дип белдерелде, әдәбият-сәнгать үсешендә тәнкыйтьнең авангардлык роле, аның алдында торган гаять мөһим бурычлар тагын бер мәртәбә ассызымлап билгеләп үтелде.

Гомум әдәби хәрәкәтне һәм аерым әсәрне дөрес бәяләү, аларның идея сафлыгы һәм сәнгатьчә камиллеге өчен көрәш, әдәби үсешнең төп тенденцияләрен һәм казанышларын күрсәтү, шул нигездә социалистик реализм методының киң иҗат мөмкинлекләрен ачудан гыйбарәт бу бурычларны уңышлы хәл итү өчен, минемчә, ике моментка аеруча игътибар итү сорала. Аларның берсе—тәнкыйтьченең идея инанганлыгы, гражданлык җитлеккәнлеге һәм позициясе. Без гадәттә тәнкыйтьчедән әдәбиятны яхшы аңлавын таләп итәргә күнеккәнбез, ә менә ул тормышны ничек белә?— монысына еш кына дикъкать итмибез. Хәлбуки, тәнкыйть әдәби әсәрне тормыштан да чыгып тикшерергә һәм бәяләргә тиеш. Гомумән, әдәби иҗатның чынбарлык белән бәйләнешләрен ачу — тәнкыйтьнең мөһим бурычларыннан берсе ул. Тәнкыйтьче язучы кебек үк тормышны яхшы белергә тиеш. Бу максатта тәнкыйтьчеләрнең дә завод-фабрикаларда, төзелешләрдә һәм авылларда еш-рак булуларына, хезмәт кешеләренең ничек эшләүләрен һәм яшәүләрен үз күзләре белән күрүләренә ирешәсе иде. Дөрес, соңгы вакытта бездә бу юнәлештә кайбер омтылышлар бар. Әмма халык тормышы белән даими бәйләнештә тору аерым тәнкыйтьчеләрнең шәхси энтузиазмы җимеше генә булып калмасын, гомум күренешкә, уртак ихтыяҗга әверелсен иде.

Аннан соң, безнең тәнкыйтькә еш кына агымдагы әдәби хәрәкәткә актив мөнәсәбәт, аны оператив төстә өйрәнү һәм бәяләү җитми. Биредә без кайвакыт гафу ителмәслек сүлпәнлек һәм пассивлык күрсәтәбез. Бу юнәлештә бәлки газета-журнал редакцияләренә дә тәнкыйтьчеләр белән активрак эшләргә, аларга тынгылык бирмәскә кирәктер.

Тәнкыйтьченең иҗат активлыгына кире йогынты ясый торган тагын бер момент бар. Ул — язучыларның тәнкыйтькә мөнәсәбәте. Соңгы

вакытта без бу хакта шактый сөйлибез, тәнкыйтькә дөрес караш тәрбияләргә кирәк дип тәкрарлыйбыз. Әмма әдәби даирәләрдә генә түгел, партия тарафыннан да куела торган бу мәсьәлә үзенең актуальлеген һич тә югалтмый. Чөнки үз иҗатыңа карата әйтелгән тәнкыйть фикерен кабул итмәү мисаллары язучылар арасында кимеми, бәлки арта гына бара. Кайбер авторлар (алар күбрәк урта һәм яшь буын язучылары арасында очрый) сүздә тәнкыйтьне хупласалар да, үзләренә кагыла калса, аңа теш-тырнак белән каршы торалар. Бары үз иҗатларына мөнәсәбәттән генә чыгып, алар тәнкыйтьчеләрне ике төркемгә бүлеп карыйлар кебек. Сине мактаганнары әйбәт, акыллы, уңганнар. Язучы андыйларга ашка аш белән җавап бирергә, ягъни үзе дә аларны төрлечә мактарга, күтәрергә тырыша. Ә инде сиңа игътибар итмәгәннәре яки тәнкыйтьләргә җөрьәт иткәннәре бары хурлауга лаеклылар. Алары тәнкыйтьләнгән автордан мәрхәмәт көтмәсеннәр. Бу хәлләрдә тәнкыйтьнең үзенең дә беркадәр гаебе бар. Чөнки урынсыз мактау сүзләре күбәйгәндә, иҗатны бәяләүдә объективлык, таләпчәнлек кимегәндә, аерым авторлар һаваланып китәләр, аларның «серкәсе су күтәрми» башлый. Тәнкыйтькә мондый субъектив караш үзенең тиешле бәясен алырга тиеш.

Хәзерге тәнкыйть алдындагы тагын бер мөһим бурыч аның сыйфатын күтәрүдән, фәннилегенә ирешүдән гыйбарәт. Бередә бигрәк тә анализ алымнарын төрләндерү һәм камилләштерү сорала. Безнең агымдагы тәнкыйть гадәттә әсәрне үзалдына гына карый, әдәби хәрәкәт яки аерым язучы турында субъектив-эмоциональ фикер йөртү белән чикләнә. Бу принцип кайвакыт бигүк объектив һәм нигезле булмаган нәтиҗәләргә китерә. Мондый хәлләрдән котылуда чагыштырма анализның файдасы зур булыр иде. Бердән, инде әйтелгәнчә, әдәби үсешне һәм аерым әсәрне тормыш белән бәйләп карау (язучы иҗатының никадәр тормышчан булуын, реаль актуальлеген һәм мәгънәсен ачыклау), икенчедән, әсәрне, язучы иҗатын, әдәби күренешләрне гомум әдәби процесста тикшерү бик мөһим. Шундый анализ булганда, без кайчак бик оригиналь дип бәяләнгән әсәрләрнең чынлыкта проблематик яктан да, әдәби чишелеш буенча да шактый кабатланганын күрер идек. Мәсәлән, бездә авыл картлары һәм карчыклары хакында байтак язылды. Әмма Ә. Еники, Ш. Хөсәенов, Т. Миңнуллин, Х. Сарьян әсәрләреннән соңгыларында инде бу персонажларны сурәтләүдә әллә ни яңалык күренми, киресенчә, алар икенчеллек тәэсирен калдыралар.

Әдәбиятлар арасындагы иҗади бәйләнешләр гаять көчәйгән, әдәби үсешнең хәлиткеч факторларыннан берсенә әверелгән безнең чорда милли әдәбият күренешләрен гомум фонда карау заман таләбенә һәм ихтыяҗына әйләнде. Чөнки шул тәкъдирдә генә теге яки бу әдәбиятның үсешен, казанышларын һәм кимчелекләрен, аның уртак хәзинәгә керткән өлешен конкрет һәм дөрес күзалларга мөмкин. Чагыштырма-типологик анализ, моннан тыш, аерым әдәбиятта миллилек белән интернациональлекнең үзара мөнәсәбәтләрен, бу әдәбиятның гомум әдәби процесста ничек катнашуын, үзендә аның нинди тенденцияләрен чагылдыруын, гомумән, бөтенсоюз һәм дөнья әдәби хәрәкәтенә ничек килеп кушылуын ачыкларга булышыр иде. Әдәбиятны шушы яссылыкта өйрәнү бер үк вакытта хәзерге тәнкыйтьнең идея-эстетик җитлеккәнлеген, эрудициясен, колачын билгеләр иде.

Мондый анализ татар тәнкыйтенә әле бик тә җитми. Шунлыктан ул бөтенсоюз аренасына да бик сирәк чыга, милли әдәби хәрәкәтне үзәк матбугатта яктыртуда кыюсызлык һәм пассивлык күрсәтә. Хәзерге әдәбиятыбызның күпмилләтле әдәби процесста бик аз яки бөтенләй диярлек күзгә чалынмавы, үзәк матбугатта һәм тикшеренүләрдә лаеклы урын ала алмавы, минемчә, байтак дәрәҗәдә шушы хәл белән бәйлән-

гән. Әгәр ул шулай ясалма рәвештә гомум процесстан читтә калдырылып киленсә, тәнкыйть язучыларны киң игътибарга лаеклы эзләнүләргә рухландырмаса, бу хәлнең тора-бара әдәбиятыбызда провинциальлекнең көчәюенә китерү ихтималы бар.

Безнең тәнкыйть партия, заман алга куйган таләпләргә җавап бирсен өчен, аның киң колачлы һәм тирән фикерле, иҗади актив һәм принципиаль булуына, нечкә идея-эстетик анализны җитди гомумиләштерүләр белән бәйли алуына ирешергә кирәк.

СОРАУ:

— Бүгенге татар шигърияте укучы күңеленә тагын да эчкәрәк үтү өчен нәрсәләр эшли ала?

РӘДИФ ГАТАУЛЛИН:

— Шигърияткә сусаган һәм үзен борчыган сорауларга нәкъ менә бүгенгедән җавап эзләгән укучы күңеленә үтү — шактый катлаулы бурыч.

Моның өчен безгә иң беренче чиратта, заман алга куйган проблемаларга, сорауларга кыюрак алынырга, тормышның нәкъ үзе белән йөзгә-йөз килеп, кешеләр белән ачыктан-ачык сөйләшеп, аңлашып, аларның рухи дөньясын тагын да тулырак аңлап язарга кирәктер. Укучыбыз әнә шундый әсәрләрне, шагыйрьнең тынгысыз рухлы бай шәхесе, кызыклы биографиясе, яшәү рәвеше белән расланган, ягъни тирәнтен ышандыра, уйландыра, иярткә, тәрбияли ала торган әсәрләрне якын күрә. Бүген без күрергә теләгән шигъри уңай герой да әнә шул нигездә генә укучыны җәлеп итә алачак. Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан әсәрләренең үрнәгендә без олы язмышлар, геройлар, мәңгелек һәм актуаль мәсьәләләрнең яңгырашын күрәбез. Сибгат ага Хәкимнең «Эзлиләр Европа буйлап» поэмасы әнә шул зур традицияләрнең дәвамы, үстерелеше ул. Бу әсәрдә иң зур мәсьәләләр хакында ачыктан-ачык сөйләшү, аңлашу, халкыбызның зур юллары турында, киләчәк турында җитди уйлану бар.

Соңгы елларда язылган поэмаларыбызда тагын мөһим бер яңалык— төрле жанрларның шигырьгә үрелеп, яңалык тудыруы. Биредә мин И. Юзеевның «Соңгы төн», «Очты дөнья читлегеннән» һәм «Мәңгелек белән очрашу» шигъри трагедияләрен, Ә. Баяновның «Һәйкәл» шигъри драмасын күз алдында тотам. Алар минем күз алдымда шигъри театр булып гәүдәләнә: драматик элементлар, трагедия алымнары югары шигърилек белән үрелә, үсә алган. Зөлфәтнең «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасы исә публицистик кайнарлыгы һәм образлылыгы белән җәлеп итә.

Ләкин җитди проблемаларны Такташча гади юмор, гражданлык пафосы һәм темперамент, халыкчан һәм садә, матур образлар белән укучыга җиткерү турында да уйланасы бар әле безгә. Бу җәһәттән Ш. Галиев, Г. Афзалларның бәхәссез уңышларын искә алабыз. Ә менә шигъри публицистика, югары накаллы гражданлык пафосы белән чын шигърилек кушылган политик лирика турында әле хыялланырга кала. Соңгы елларда Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис, Ә. Давыдов традицияләрен онытып барабыз. Бу, бигрәк тә, политик сатира өлкәсенә карый.

Лирикада шагыйрьләребез һәрвакыт актив булдылар. Ләкин югары идеялелек һәм чын сәнгатьчәлек турында безгә һәрчак уйланырга кирәк!

СОРАУ: КПССның июнь Пленумы карарлары яктылыгында әдәбиятыбыз алдында барыннан да элек нинди проблемалар көн тәртибенә куелды?

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре:

— Татар совет әдәбиятын туган илебез тарихыннан аерып карау, халкыбыз үткән катлаулы да, данлы да көрәш юлыннан башка күз алдына китерү, гомумән, мөмкин түгел. Үз язмышын ил язмышы белән аерылгысыз бәйләп, Ватанга һәм туган илгә бирелгәнлекнең үрнәге булып торган олы талантларга бай безнең әдәбият. Иҗат ялкыннарын гына түгел, халык бәхете, ил иминлеге өчен кирәк булса гомерләрен дә кызганмаган каһарман-әдипләр язмыны? Җәлил, Ф. Кәрим, А. Алиш, Г. Кутуй... һәммәсенең язмышы легендаларга тиң!

Сораудан читләшеп, сүземнең башында ук тарих сәхифәләренә тагы бер мәртәбә мөрәҗәгать итүем бер дә юкка гына түгел. Заман мәҗбүр итә! Йөрәкләрне кысып, күңелләрне сагайтып торган халыкара киеренкелек мәҗбүр итә! Тарихта гыйбрәт бар. Җанында кешелеклелек һәм игелек нуры булган, җирдә яшәүнең матурлыгын тойган, мәхәббәт кебек гүзәл хискә ия булган бер генә кеше дә бүген битараф була алмый. Җирнең иминлеген, озак гасырлар дәвамында ирешкән цивилизацияне саклау бөтен прогрессив кешелекне борчыган беренчел проблемага әверелде. Партиябез һәм дәүләтебез җитәкчесе Ю. В. Андроповның шул уңайдан ясалган мөрәҗәгате һәр кешене Җир язмышы өчен җаваплылыкка чакырып, илләрне, материкларны иңләп узды.

Мондый шартларда әдәбиятыбыз алдында торган иң җитди бурыч ул, әлбәттә, әлеге гаять әһәмиятле һәм кичектергесез проблемаларны уңай хәл итүгә мөмкин булган кадәр өлеш кертү. Бу көрәштә язучының миссиясе нидән гыйбарәт булырга тиеш соң дигән урынлы сорау туа. Һәм ул сорауга өздереп кенә җавап бирү бер карашка җиңел түгел.

Дөнья тыныч түгел, борчулы. Аның төрле почмакларыннан әле дә булса кан һәм күз яшьләре саркып тора. Америка Кушма Штатлары империализмы расист һәм реакцион режимнарны явызлыкка өндәп, рухландырып торуы белән генә чикләнмичә, планетабызның әле бер, әле икенче почмагында барган прогрессив үзгәрү һәм хәрәкәткә үзенең канга буялган корыч тешләрен китереп батыра. Никарагуа, Сальвадор, Әфганстан, Ливан кебек илләрдән ишетелеп торган борчулы хәбәрләр, бернинди гаепсезгә өзелгән гомер, ата-ана һәм сабыйлар күз яше шуңа дәлил түгелмени... Кариб диңгезе почмагында урнашкан нәни утраудәүләт Гренаданың шул ук Кушма Штатлар солдатларының канлы итекләре астында калып тапталуы, таплануы дәлил түгелмени... Алай гына да түгел, шул ук держава туган илебезгә, кешелек язмышына кизәнә, котырынып кораллану арбасы тәгәрмәчен тагы да зуррак тизлек белән әйләндерергә омтыла. Шундый чорда, шундый көннәрдә кем күңелендә тынгылык булсын... Язучы һәм әдип күңелендә бигрәк тә!

Шуңа күрә дә әдәбият һәм сәнгать алдындагы кичектергесез бурычлар бүгенге шартларда яңа эчтәлек белән байый, яңа төсмерләр ала. Кайчандыр кеше үз-үзен, ыруын саклауны бар нәрсәдән өстен күрсә, тора-бара туган ил һәм Ватан төшенчәләре формалашып, иң изге эчтәлек-мәгънәгә ия булган. Ватан азатлыгын саклап бабайлар гражданнар сугышы чорында ак интервентларга каршы көрәшкән булса, икенче бөтендөнья сугышында данлы Совет Армиясе солдатлары булып безнең әтиләр, туган ил белән бергә, Европа халыкларын фашизм афәтеннән йолып калдылар. Ә бүген исә Ватаныбыз, тагы да зуррак миссияне үз өстенә алып, планетаны, кешелекне һәлакәттән саклау өчен көрәшнең алгы сафында бара. Миңа калса, бүген һәр кеше, һәр совет гражданы әлеге миссияне һәм җаваплылыкны яхшы тоеп һәм тирәнтен аңлап яшәргә тиеш. Көн тәртибендә торган мәсьәлә һәм проблемаларны киңрәк масштабта күрә һәм аңлый белергә бурычлы. Ә әдәбият исә

әлеге гуманистик көрәш-хәрәкәтнең алгы сафында, авангардында булырга тиеш.

КПСС Үзәк Комитеты идеология, масса-политик эшнең актуаль мәсьәләләрен көн тәртибенә куеп, шул уңайдан безнең һәммәбезне тирән уйландырган җитди документлар кабул иткәндә, барыннан да элек, прогрессив кешелек алдында торган әлеге киеренкелек һәм җаваплы миссияне күз уңында тота. Шуңа күрә июнь Пленумында кабул ителгән Карар ул заман таләбе буларак кабул ителә. Әдәбият һәм сәнгатьтә дә ирешелгән уңышлар белән генә канәгатьләнеп калмыйча, чорыбызга лаек яңа проблемалар белән рухланып, шуларны чорыбызга лаек масштабларда хәл итү кирәк дигән сүз бу. Шуңа күрә дә бу көннәрдә ирешелгән уңышлардан, үтелгән юллардан бигрәк, алда торган бурычлар, хәл ителергә тиешле принципиаль мәсьәләләр хакында уйлану урынлырак булыр.

Әйтик, Пленум әдәбият һәм сәнгатьнең коммунистик төзелеш практикасы белән элементләрен тагы да ныгытуны көн тәртибендә торган иң җитди бурычлардан берсе буларак күрсәтте. Чынлап та, аерым казанышлары булуга да карамастан, безнең татар совет әдәбиятына да әлеге юнәлештә шактый эзләнергә һәм табарга кирәк булачак. Чорыбызга лаек масштаблы уңай геройларны, рухы белән көр, хезмәте белән зур, якты идеаллары белән гүзәл булган замандашыбызны оныту яисә икенче планда калдыру мөмкин түгел. Рахметов һәм Павел Корчагиндай, яшь гвардиячеләр һәм Мересьев кебек батырлыклары, олы омтылышларга бирелгәнлекләре белән рухландырып торган геройларыбыз белән, яшерен-батырын түгел ич, без әллә ни горурлана алмыйбыз. Әлбәттә, сүз әдәбиятыбызга зур өлеш керткән, үз вакытында аны илебез әдәбиятлары арасында мәртәбәле тоткан әдипләребез иҗаты турында түгел. Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал, һ. Такташ, М. Җәлил һәм Х. Туфан, К. Тинчурин һәм Ф. Бурнаш әсәрләрендә тасвирланган масштаблы заман тормышы һәм геройларны хәтердән чыгару мөмкин түгел. Г. Бәшировның «Намус» һәм К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романнарын, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Г. Гобәй, Ш. Маннур әсәрләрендә сурәтләнгән Гаяз, Сөләйман Уразмәтов, маякчы кызы Илсөяр һәм Гайҗан карт кебек образларны онытү ярамас. Дөресрәге, аларны оныту мөмкин түгел, бер укуда ук күңелгә кереп, җанга сеңеп калган һәм гомер буена рухландырып торырлык рухи җегәргә ия булган әдәби җәүһәрләр халык хәтерендә җуела алмый.

Әлбәттә, соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләр арасында да заман тормышын һәм замандашыбызны тасвирлау юлында уңыш саналырлыклары юк түгел. Г. Бәширов прозасы, Ә. Еники әсәрләре, аерым алганда, аның «Тынычлану» хикәясе, А. Расихның «Сынау» романы, Г. Ахуновның «Хәзинә»се, Ш. Бикчуринның «Каты токым»ы, А. Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән»е, һичшиксез, соңгы еллар прозабызның төп үсеш юнәлешен билгеләп торалар.

Драматургиядә Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»е һәм «Монда тудык, монда үстек» пьесасы шулай ук бүгенге театр сәнгатебезнең генә түгел, әдәбиятыбызның да зур казанышы саналырга лаеклы. Шунда ук И. Юзеевның аерым сәхнә әсәрләрен, яшь драматург Р. Хәмиднең «Синең урыныңа кайттым» һәм «Китәм инде» пьесаларын игътибарга лаек күренеш буларак билгеләп узарга мөмкин. Моңарчы күләгәдәрәк калып килгән драматург Кашаф Әмировның бүгенге халыкара хәлгә турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, Әфган һәм Совет иле халыклары арасындагы интернациональ дуслыкны чагылдырган сәхнә әсәре язып тәмамлавын да аерым искә алу урынлы булыр.

Заман тормышын әдәбиятта чагылдыру һәм уңай герой образын тудыру хакында сүз кузгалганда, без гадәттә сүзне проза хакындагы

сөйләшүгә кайтарып калдырырга күнеккән. Әлбәттә, прозаның мөмкинлекләре бу юнәлештә чиксез зур, һәм алга таба да бу юнәлештәге таләпләр, барыннан да элек, шул жанр алдында куелыр. Шулай да поэзиябезнең дә заман тормышын сәнгатьле чагылдыруда тоткан урынын искә алмасак, дөрес булмас иде. Әйтик, С. Хәкимнең «Эзлиләр Европа буйлап», И. Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән», Р. Харисның «Ат иярләү», Р. Мингалимовның «Ике авыл арасы», Зөлфәтнең «Йөрәкләрдә — үлмәс дастан» поэмалары чор рухын чагылдыруга һәм замандашыбызны борчып торган вакыйгаларны тасвирлауга, масштаблы уңай образ тудыруга шулай ук зур өлеш керттеләр. Дистәләгән шагыйрьләребезнең фәлсәфи һәм лирик әсәрләреннән башка да әлеге юнәлештә җитди эзләнүләрне күз алдына китерү һәм аңлату тулы булмас иде. Исемнәр һәм әдәбиятыбыз барышында уңышлы дип кабул ителгән әдәби әсәрләрне алга таба да шул рәвешле санау мөмкин, әлбәттә. Әмма бу очракта максат башка. Уңышлы әсәрләрне күпме генә санасак та, күңел канәгатьләнмәс. Инде искә алынганча, үткәндәге уңышлар белән генә куанып яшәр чак түгел. һәр көн яңа таләпләр куя, әдәбиятның яңа идея һәм эстетик биеклекләргә күтәрелү ихтыяҗын булдыра. Әдәбият һәм сәнгать исә, шул таләп һәм ихтыяҗлардан бер генә көн, бер генә адымга да калышмаска тиеш. Калыша икән, димәк, ул үз миссиясен тулысынча үтәп җиткерми дигән сүз.

Заман һәм әдәбият арасындагы бу бәйләнеш, багланышны күзәтеп, анализлап, кирәк вакытта күрсәтеп һәм юнәлеш биргә бару, барыннан да элек, әдәби тәнкыйть алдындагы бурыч. Нәкъ менә шуңа күрә дә июнь Пленумындагы чыгышында Ю. В. Андропов әдәби тәнкыйтьнең ролен һәм авторитетын күтәрү мәсьәләсенә аерым игътибар биреп узды. Әдәби тәнкыйтебез һәм тәнкыйтьчеләребезнең соңгы елларда бермә-бер активлашуын, нәтиҗәлерәк эшләвен, әдәби процесска торган саен сизелерлек тәэсир итә килүен билгеләп узсак та, әдәби процессны әйдәп барырга тиешле тәнкыйтебез әлегә үзе дә заман таләпләре артыннан җитешер-җитешмәсрәк бара. Н. Юзиев, И. Нуруллин, Р. Мостафин, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин, Т. Галиуллин, М. Вәлиев, С. Маннапов, Р. Кукушкин һәм Ф. Галимуллин кебек хәзерлекле тәнкыйтьчеләре булган әдәбият өчен бу һич гафу ителмәслек хәл. Җитешсезлекләрне вакытында күреп алып, аларны барлыкка китергән, мәйданга чыгарган факторларны билгеләүдә генә түгел, уңышлы әдәби күренешләрне үз вакытында һәм кичекмәстән бәяли килүдә дә әле өзеклекләр очрап тора, кабатлана килә. Әле бүгенгәчә акны — ак, караны — кара дип әйтергә күнеккәнебез юк.

Соңгы вакытта әдәбиятта, аның һәр жанрында уртакуллык өстенлек итә бара, дип расларга күнегеп китте безнең тәнкыйть. Бу хак, моның белән килешми мөмкин түгел. Әмма әлеге уртакуллыкканиләр сәбәпче соң, аны мәйданга китергән шартлар нидән гыйбарәт? Бу хакта исә, кагыйдә буларак, тәнкыйтебез артык баш ватарга яратмый. Уйланып карыйк әле, әлеге уртакуллыкка китергән сәбәпләр арасында әдәби тәнкыйтебезнең күпчелек әсәрләрне бер чама, гадәткә кергәнчә анализлый һәм бәяли килүе дә юк микән. Рецензияләребезне, тәнкыйть мәкаләләребезне тагын бер күздән кичерик һәм игътибар итик — нигездә бер үк төрле бәя даими кабатлана килә түгелме аларда? Менә дигән ак төсне дә «акка охшаган», «акка тартым», дип, аклы-каралыны да шулай ук дип, шул ук сүзләр белән бәяли килмибезме соң? Миндә шундый фикер туды: әдәбиятта, гомумән, уртакуллык дигән нәрсә юк, аны без — тәнкыйтьчеләр тудырганбыз. Әдәбиятта яхшы әсәрләр бар, һәм өлгереп җитмәгән, зәгыйфь туган начар әсәрләр бар. Яхшыны — яхшы, яманны — яман дип бәяләргә тартынган, кыймаган тәнкыйтьче-

ләр генә тудырды ахры ул уртакуллыкны. Хәзер үзләре үк шуннан зарланып, шуннан ничек котылырга белми иза чигәләр.

Мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Мин бары тик бер әсәргә тукталып үтүне кирәк санpark. Моннан бер ел чамасы элек кенә дөньяга чыккан «Исәнме, Кәшфи абзый» повесте (авторы М. Мәһдиев) хакында матур-матур гына фикерләр йөрсә дә, тәнкыйть өздереп үз сүзен, үз хөкемен әйтә алмый калды. Үзеннән-үзе аңлашыла инде, димәк, ул да «уртакуллар» арасында теркәлеп калды. Ә бит әлеге повестьта нәкъ менә безне бүген борчыган, уйландырган проблемалар сәнгатьчә камиллеккә җиткереп тасвирланган иде. Әсәрнең үзәгендә безнең замандашыбыз, иген үстерүче механизатор образы тасвирланган. Ул, тормыш рәвеше һәм холык-фигыле белән гади һәм гадәти генә булып тоелса да, чын герой, замандашларыбызны, бигрәк тә яшь буынны туган җиргә, игенче хезмәтенә, авылга бирелгәнлек рухында тәрбияләүче уңай герой иң. Партия һәм хөкүмәтебез авыл яшьләрен нәкъ менә шул рухта, Кәшфи сыман ук игенче хезмәтенә җаны-тәне белән бирелгән итеп тәрбияләргә чакыра да бит инде. Шуның өстенә әсәрнең һәм әлеге образның сәнгатьчә камиллеген дә инкарь итү мөмкин түгел. Ни җитми соң? Булганны лаеклы рәвештә күрсәтә, бәяли һәм пропагандалый белү җитми!

Шул ук хәл үз вакытында Ш. Бикчуринның «Каты токым», Э. Касыймовның «Чулман — оныклар елгасы» белән кабатланмадымы? Бу әсәрләр һәр икесе ил күләмендә абруйлы бүләккә лаек булды. Әмма безнең тәнкыйть бу уңышның нигезен әсәрләрнең үзләрендә күреп җиткермичә, аны бары тик тәрҗемә сыйфатына гына кайтарып калдыра язды. Гәрчә, һәр ике роман республикабызда барган җитди социаль һәм рухи үсеш-үзгәрешләрне аеруча тулы чагылдырган киң планлы проза әсәрләре иде. Игътибар белән карасаң, шундый мисаллар безнең һәр жанрда очрап, кабатланып тормыймы икән?! Гомумән, безнең тәнкыйтькә вакыт-вакыт үзенең критерийлары хакында да уйлангалап алу зыян итмәс иде.

Әдәбиятыбызның һәр жанрыннан оперативлыкны, сугышчанлыкны бермә-бер арттыру таләп ителә. Чөнки болардан башка заманчалыкны күз алдына китерү кыен. Мисал өчен, шигърияттә Такташ иҗатына хас публицистик ялкын, Җәлил әсәрләрендәге туган илгә бирелгәнлек рухы бүген дә дәвам иттерелергә, үстерелергә, заманча яңа формаларда гәүдәләнергә тиешле. Шигърият һәм әдәбият кешеләрне бердәмлеккә, уртак һәм олы максатлар белән рухланып яшәргә чакырсын. Кешелекләлек һәм интернациональ дуслык, туганлык хисләренең һәр нәрсәдән көчлерәк, олырак булуын күрсәтү — әдәбиятның изге бурычы. Бүгенге киеренке шартларда, тынычлыкны яклап бөтен прогрессив кешелек бердәм сафларга омтылганда бу аеруча әһәмиятле.

## Рәфкать Кәрами

# ЙӨРӘГЕМНЕ УТ АЛГАН

ПОВЕСТЬ

### I



Кешенең җайга салынган тормышы шул рәвешчә атналар, айлар, хәтта еллар буена дәвам итәргә мөмкин. Ләкин килә бер көн: кеше я нинди дә булса шатлык-куаныч кичерә, ә кайгы-хәсрәткә дучар була, я үзендәниндидер үзгәреш сизә, я табигатьтә аңа билгеле булмаган берәр яңалык ача. Шуннан ул инде тормыш-яшәеш, аны чолгап алган мохит, бүтәннәр һәм... үзе турында уйлана башлый. Әйе, кеше үзенең ни өчен дөньяга килүе, ни өчен яшәве һәм нигә үлүе турында уйлана башлый. Кешенең сөю-сөелүе, кылган гамәлләре хакындагы уйлары тышка бәреп чыга.

Флүр Сәхбиевич тә еш кына әнә шул халәтне кичерә һәм үзенең язмышы, тормыш юлында очраган кешеләр, бигрәк тә хатын-кызлар турында уйланырга ярата. Аларның кайберләре күңелендә тирән эз калдырган — тиз генә искә төшәләр, ә бер ишләре исә шундук онытылган, кабат ул аларның йөзләрен дә күз алдына китерә алмый. Әгәр хәтерендә нык сакланган берәүгә карата гаделсезлек эшләгән булса, ул кайчагында борчылып, үкенеп тә куйгалый, ләкин күпчелек вакыт, тормыш-яшәеш шулай булырга тиештер, барысы да аныңча эшлидер, дип уйлый һәм шулай уйлавы белән үз-үзен юата. Флүр Сәхбиевич еш уйлана. Билгеле, бу уйлануларга нинди дә булса этәргеч сәбәп була.

Бүген дә, иртән торгач, Флүр Сәхбиевич бик шәплэп, бөтен шартын китереп гимнастик күнегүләр ясады, салкын су белән юынды, «сәламәт тәндә — сәламәт акыл», дип авыз эченнән көйли-көйли тәне кызарганчы сөлге белән сөртенде һәм, көзге каршына килеп, чәчен тарый башлады. Шулвакыт ул маңгай өстендә бер озын ак чәч күрде. Утызны тутырган буйдак егет өчен бу искитәрлек яңалык түгел, әлбәттә, ләкин ул аксыл җепләр әле чигәләрдә генә иде бит. Ә хәзер әнә кая үрмәләгәннәр. Әйе, гомер йомгагы сүтелә бара... Флүр Сәхбиевич кара чәчләре арасыннан юан бармаклары белән аралап, маңгай өстендәге әлеге чәчне йолкып алды. Барыбер ак чәч үзе генә эләкмәде, бер бөртек кара чәч тә ияреп чыккан иде. Ир-атның андый нечкә эшләргә маһирлыгы чамалы шул. Бәлки шуңа күрәдер туку фабрикаларында, сәгать һәм төгәл прибор заводларында күпчелек эшче — хатын-кыз. Аларда тумыштан килә торган нәфислек, төгәллек, пөхтәлек була, куллары-бармаклары андый эшкә ятып тора. Һәм Флүр Сәхбиевич кинәт Гөлмира турында уйлап алды. Ул кызның да бармаклары нәзек, җитез һәм...

йомшак иде. Гөлмира соңгы вакытта әнә шул бармаклары белән Флүр Сәхбиевичның чәчләрен тузгытырга, аларны иркәләп сыйпарга, тарарга һәм чигәсендә күренгән сирәк ак чәчләрне чүпләргә ярата иде. Әйе, соңгы вакытта шулай булды. Ә баштарак аңа да оялчанлык, читенсенү, ятсыну хас иде. «Гөлмира, Гөлмира,ниләр уйлап, ничек яшисең икән син? Мин укып чыккан кызыклы китап булып хәтеремдә калган кыз»,— дип уйлады Флүр Сәхбиевич һәм ул кыз белән ничек, кайда танышуын рәхәтләнеп исенә төшерде. Аның күңеле йомшап, нечкәреп киткәндәй булды. Югыйсә, бу арада никтер күңеле буш иде. Бу хәл берәр кыз белән йөреп, ташлашкач була һәм ул яңасы белән танышканчы шулай дәвам итә... Әйе, Гөлмира исенә төшкән иде бит.

Флүр Сәхбиевич узган ел, июнь ахырында, кичке профилакторийга путевка алды. Әлегә сәламәтлегенә зарланмаса да, табибларга күренеп, бераз ял итеп кайтырга иде нияте. Чөнки ул ревматизм эләгүдән шикләнә, төзелештә эшләгәч, моның әз-мәз билгеләре дә юк түгел. Аннары ялгызак кеше өчен ул профилакторий-санаторий дигәннәре бик кулай нәрсә: көндез эшлисең, кич кайтып дәваланасың һәм кунып та каласың. Сирәк-мирәк ял кичәләре дә була анда. Кыскасы, ашау — байдан, үлем — ходайдан, дип түшәмгә төкереп кенә ятасы.

Флүр Сәхбиевич ул кызны профилакторийга килүнең икенче көнендә очратты. Эштән кайткач, аскы катта чишенеп, берьюлы палата ачкычлары эленгән кечкенә шкафка да күз салып, ул башта ашханәгә кереп, көндезге ашын капкалап чыкты. Аннан, йомшак башмаклары белән салмак кына атлап, үз бүлмәсенә — дүртенче катка юнәлде. Коридордан өске катка менә торган баскычка, уңга борылган гына иде, биш-алты шешә кочаклап, подвалдан менеп килүче дулкынланып торган коңгырт чәчле бер кызга юлыкты. Кыз шешәләрне җайсыз итеп күтәргән һәм берсе менә-менә төшеп чәлпәрәмә килер төсле.

Флүр Сәхбиевич кызны көтеп алды да:

— Бирегез, ярдәм итим үзегезгә, юкса шулкадәр байлыкны әрәм итүегез бар,— диде.

Кыз аңа күтәрелеп карады һәм көлемсерәп әйтте:

— Моннан да кыйммәтле байлык булмас шул.

Флүр Сәхбиевич ипләп кенә кыз кулыннан дүрт шешәне алды да икешәрләп тотты.

— Шулаймыни? Алайса мин дә төшеп сорыйм әле,— дигән булды егет шаяртып.

— Әллә кайчан алгансыздыр инде. Бушка килгәнне хәзерге егетләр ычкындырмый. Элек кенә...

— Ялгышасыз. Урта гасырларда, мәсәлән, рыцарьлар хәтта сугыш коралларын һәм атларын да сөяркәләре хисабына юнәткәннәр.

— Димәк, минем сүзләр сезгә кагылмый?

— Әлбәттә.

— Алайса — гафу итегез.

Флүр Сәхбиевич кызны алдан уздырып җибәрде, һәм алар көлешә-көлешә баскычтан менеп киттеләр. Кыска җиңле зәңгәр күлмәк кигән кызның иңнәренә таралган, дулкынланып торган коңгырт чәчләренә, зифа буйлы гәүдәсенә сокланып карамыйча түзә алмады егет. Бигрәк тә күзенә нык ташланганы — кызның кояшта янган тыгыз балтырлы, килешле матур аяклары иде. Моны ул кызга сиздермәде, әлбәттә, һаман сөйләнүендә булды.

— Ничәнче катта? Өченчеме?

— Әйе. Каян беләсез?

— Хатын-кызлар гадәттә шунда яши.

— Димәк, сез монда...

— Икенче тапкыр. Ә сез?

— Беренче.

— Ошап китсә, килгәләрсез әле. Безнең кебек ялгызакларга бик шәп урын бу. Ялгызак дип дөрес әйттемме?

— Әйе.

Өченче катка күтәрелгәч, кыз алтмышынчы палатаны (егет моны күңеленә беркетеп куйды) ачып керде һәм, урындык башыннан нәрсәнедер җәлт кенә эләктереп, ишек янындагы кием шкафына элеп куйды да Флүр Сәхбиевичны бүлмәгә чакырды.

— Рәхим итегез.

— Уңайсыз булмасмы?

— Юк,— диде кыз һәм шешәләрне аның кулыннан алып, тәрәзә төбенә тезеп куйды.— Утырыгыз.

Флүр Сәхбиевич кыз тәкъдим иткән урындыкка, өстәл янына утырды. Бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Вагон кебек озынча зур бүлмәдә өстәл һәм кием шкафыннан тыш тагын пөхтә итеп җыештырылган өч агач караватбар иде. Алар янәшәсендәге тәбәнәк тумбочкалар өстендә китаплар, газета-журналлар. Стенага кечерәк кенә бер картина — җәйге пейзаж эленгән. Түшәмнән идәнгә кадәр төшеп торган калын тәрәзә пәрдәләре җыерып куелган.

Флүр Сәхбиевич чисталыгы, иркен һавасы белән рәхәтлек биреп торучы бүлмәне мактамыйча булдыра алмады.

— Бик матур икән бүлмәгез,— дип куйды ул, як-ягына каранып.

— Ярый инде,— диде кыз тыйнак кына.— Әле һаман ныклап урнашып, тәртипкә китерә алмыйбыз.

— Болай да бик яхшы. Безнеке шыксызрак.

Кыз дәшмәде. Чөнки егет күзләрен тутырып, текәлеп аңа караган. Бу минутта кыз Флүр Сәхбиевич тарафыннан бәя ала иде. Кыз озынча тулы йөзле, артка төшеп торган озын коңгырт чәчле, төс-бите әллә ни күзгә бәрелерлек түгел. Әмма аның тәненә сыланган юка күлмәкле гәүдәсе бик сылу, бик күркәм. Кояшта янган муены озынча, ләкин нечкә түгел, беләкләре дә тотсаң өзелергә тормый, шул ук вакытта алар нәфис һәм сыйпыйсын китереп, күңелне кытыклап, вәсвәсә салып торалар. Кызның тулы балтырларының тыгызлыгына, төз һәм таза аякларына Флүр Сәхбиевич әле баскычта ук күз төшергән һәм кыз шешәләрен тәрәзә төбенә илтеп куйганда да карап сокланган иде. Аның йөреше дә бик килешле. Аяк очларын читкә каратыбрак баса һәм, гомумән, бөтен килеш-килбәте белән бераз гына балериналарга тартым. Дәшмәгәндә кызның йөзе тыныч, табигый матурлык сирпеп тора, әгәр тигез ак тешләрен күрсәтеп сөйләшә башласа, бөтен йөзе нурланып китә, көләчләнә һәм озын керфекле коңгырт күзләре җылылык бөрки.

— Сезне кечкенә чакта әнигез ничек дип сөя иде?

Флүр Сәхбиевич каршына, өстәл янына утырган кыз гаҗәпләнеп, аптырашта калды, шоколад төсендәге нурлы күзләрен тутырып егеткә карады. Аннары көлеп җибәрде.

— Кызым, и-и минем олы кызым, дип.

— Нишләп олы кызым, дип? Сез туганда ук шушылай зур, чибәр идегезмени?

Бит алмалары кызарып, йөзе тагын да яктырып китте кызның.

— Юк, билгеле. Беренче бала булганга.

— Ә исемегез белән әйткәне булмадымы? Миңа әни һәрвакыт, ах, минем бу усал Флүрем, дия иде.

Кыз бары хәзер генә сүзнең кай якка баруын һәм аннан нәрсә таләп ителүен аңлады.

— Гөлмира кызым, дип.

Менә шулай уен-көлке сөйләшкән арада танышып, берничә минут утыргач, Флүр Сәхбиевич урыныннан кузгалды һәм саубуллашып чыгып китте. Кыз аңа булышуы өчен рәхмәт әйтеп калды.

Егет үзе чыгып киткәч тә әле таза, озын буйлы гәүдәсе белән бүлмәне тутырып торгандай тоелды. Бая, үзе барында, Гөлмира аңа ятсынып, оялып кына караган иде, шулай да егетнең бөтен килеш-килбәте, шома таралган кап-кара чәче, текә маңгае һәм калын кара кашлары да, һәрчак елмаюлы киңчә йөзенә үзенә бертөрле асыл сыйфат биреп торучы, ирен читләтеп ике якка салынып төшкән кара мыегы да, көлгәндә ялтырап киткән тигез ак тешләре дә — барысы да кызның хәтеренә уелып калды. Егетнең яңаклары гына түгел, уртасы чокырлы ияге дә хуҗасының көчле ихтыярга ия булуын раслый шикелле иде.

Флүр Сәхбиевич палатасына кайтып, өс-башын алыштырды һәм зәңгәр төстәге спорт костюмы — «олимпийка» киеп куйды. Аның бүлмәдәшләре шар сугарга җыеналар иде, дүртесе дә икенче катка, бильярд бүлмәсенә төшеп киттеләр.

Үз нәүбәте җиткәч, Флүр Сәхбиевич та уенга кушылды һәм ике кешене отты. Ләкин җиңүгә бик җиңел ирешүенә карамастан, уенын дәвам итмәде, хәзер аңа каршы уйнаячак кешене ул әле узган ел ук хәтерләп калган иде. Аңа оттырачагын ачык белгәнгә күрә, шарлар тезеп, сугарга әзерләнгәндә генә кинәт сәгатенә карап алды.

— Егетләр, гафу итәсез, баш врач чакырган иде, истән чыккан,— дип таягын өстәлгә куйды һәм бильярд бүлмәсеннән чыгып китте.

Һич йомышы булмаса да һәм баш врач үзен дәшмәсә дә, ул, врач белән яхшы ук таныш булуыннан файдаланып, аска төшеп, берничә минут аның кабинетында утырып чыкты.

Бераздан Флүр Сәхбиевич кызыл почмакка керде, газеталар караштырды, китапханәдән Голсуорсиның бер романын яздырып алды.

Түгәрәк йөзле, сары чәчле китапханәче хатын көлеп:

— Әле берәрсе белән танышырга өлгермәдеңме соң?— дип сорады.

— Юк. Әллә ярдәм итәсезме?— дип шаяртты.

Үзе шулай диде, ә үзе баядан бирле я күңеле күтәрелеп, я кәефе кырылып китүенең, я эче пошып йөрүенең сәбәбен белә алмыйча аптырады.

Бу халәт кичен кызыл почмакта Гөлмираны ерактан гына күреп калгач, иртәгесен ашханәдә исәнләшеп узгач, тагын яңарды. Менә шулай иләс-миләс йөреп, ике көн узды. «Җитте!»— диде Флүр Сәхбиевич үз-үзенә һәм, ныклы бер карарга килеп, өченче катка менеп китте. Чөнки ул тәҗрибәсе буенча белә: әгәр беренче караштан ук кызга ошасаң, бераз гына аңа тын алырга ирек бирергә кирәк. Ул уйлансын, уйлары белән генә булса да сиңа якынайсын, аның сине күрәсе, синең белән сөйләшәсе килсен һәм берме-икеме көннән соң аның белән яңадан очрашырга, болай да әйләнгән башын бөтенләй иләсләндереп җибәрергә кирәк. Бу юлы инде булган байлыкны әкренләп күрсәтергә, сүз байлыгы, тапкырлык, акыллы булып күренү, тышкы кыяфәт белән ялтырау — барысы да бер максатка — кызга ошарга тырышуга юнәлгән булырга тиеш. Кыскасы, менә шул мөһим вакытны — кызның уйлары чуалган мизгелне ычкындырырга ярамый. Әгәр беразга гына соңга калсаң да, бөтенесе дә бетте дигән сүз. Я аны башка берәү эләктерәчәк, я аның күңелендә бөреләнә башлаган хисләр ачылып җитмичә мәңге йомылачак.

Палатада Гөлмира берүзе. Песи кебек йомарланып, аякларын бөкләп менеп утырган да бирелеп китап укый. Ишек шакыган тавышка ул башын күтәрми генә, керегез, диде һәм, Флүр Сәхбиевичны күргәч, башта бераз гына каушап калды, ләкин шул секундта ук йөзе яктырып та китте.

— Рәхим итегез.

Гөлмира итәген җай гына тотып, аякларын җылы чүәгенә шудырып төшерде дә, күлмәген сыпыргалап, торып басты. Караватына кул тидереп, тигезләп алды.

— Хәерле көн,— диде Флүр.
— Сезгә дә. Утырыгыз.
— Рәхмәт. Ниләр җимерәсез?
— Җимерсә, егетләр җимерә инде, безнең — вак-төяк.
— Миңа да җимерергә туры килми шул, киресенчә — төзим.
— Шулаймыни? Алайса без коллегалар.

Гөлмира үзенең төзү оешмасында бухгалтер булып эшләвен әйтте. Сораша торгач, икесенең дә бер үк трестта эшләве, бары төзү идарәләре генә аерым булуы ачыкланды. Флүр Сәхбиевич үзенең прораб булып эшләвен һәм хәзерге вакытта нинди объект коруын бик үк озынга суҙмыйча, бераз гына горурлык һәм шулай булырга тиешле икәнен аңлаткан кыяфәт белән сөйләп бирде. Ул институт бетерүен һәм ике ел чит илдә командировкада булуын да әйтеп үтте. Тулай торакта яшим, диде. Соңгысы дөреслеккә туры килмәсә дә, ул башта ук бер кызга да үзенең бүлмәсе барын әйтми иде.

— Ә кайсы илдә булдыгыз?— дип сорады кыз җанланып.
— Монголиядә.
— Шулаймыни?— диде Гөлмира туганын күргәндәй сөенеп, чөнки ул үзе Бурят республикасының башкаласы Улан-Удэ шәһәреннән иде. Шул хакта әңгәмәдәшенә дә әйтте.
— Ә ничек монда килеп чыктыгыз?
— Техникум бетергәч. Берничә шәһәр арасыннан Казанны сайладым. Бабайлар җире үзенә тартты, ахры.

Гөлмира Улан-Удэда әнисе белән үги әтисе, сеңелесе яшәвен, ә энесенең хәрби хезмәттә — флотта икәнен әйтте.

Аннары Флүр Сәхбиевич тумбочка өстендәге китапларга ишарәләп, Гөлмираның нәрсәләр укуы белән кызыксынды, һәм бераздан сүз әдәбият, сәнгать тирәсенә күчте. Гөлмираның бу өлкәдәге фикере егетнең игътибарын җәлеп итте һәм әңгәмәгә азык булды.

— Минемчә, хәзер әсәрләр ашык-пошык языла.
— Заманы шундый.
— Сәбәп ул гына микән...
— Шулай да элекке стильдә эшләүче әдипләр дә юк түгел. Миңа калса, бу ашыгычлык әдәбиятта әле әллә ни күренми, ә сынлы сәнгатьтә, музыкада күбрәк сизелә. Әнә стенадагы пейзажны карагыз: Шишкин моны шулай ясар идеме?
— Шишкин — талант.
— Барыбер. Хәзерге рәссамнарның картиналары бертөсле кебек, дөресрәге, төссез сыман. Кешеләрнең йөзе аерылып тормый.
— Ашыгалар. Элек бер картинаны унар-унбишәр ел язганнар. Васнецов үзенең «Өч баһадир»ын егерме ел язган.
— Сезнең белән килешәм. Ләкин бер нәрсәне истән чыгармагыз: элек тә рәссамнар күп булган, картиналар күп язылган, осталык, эшләнеш ягыннан да төрле-төрле... Ләкин безгә килеп җиткәннәре, дөресрәге, вакыт сынавы аша узганнары санаулы гына. Әлбәттә, хәзерге рәссамнардан да күпмеседер тарихка кереп калачак, һәм алар ясаган сурәтләр киләчәк буыннарга барып ирешәчәк.
— Моның белән нәрсә әйтмәкче буласыз?
— Элек әдәбият-сәнгать белән әз кеше шөгыльләнгән һәм алар профессиональ осталыкның иң югары баскычына күтәрелгәннәр.
— Ә хәзер алай түгелме? Минемчә, моңа ирешү өчен хәзер мөмкинлекләр тагын да күбрәк.
— Әйе, хәзер бездә мәктәпләр дә, укытучылар да күп. Ләкин бу үзешчәнлеккә китермәсме? Чөнки барысы да нидер дәгъва итә бит. Элек әгәр авылда җырчы, гармунчы булган икән, ул аның белән төп хезмәтеннән бушаган арада шөгыльләнгән.

— Бу хәзер дә шулай.
— Белмим. Нишләптер смотрлар, эштән азат итүләр күбәйде. Ә ул ВИА дигәннәре белән буа буарлык. Аннары, тагын бер әйбер бар: элекке олы әдипләрнең, сәнгать кешеләренең балалары аталары юлыннан китмәгән. Дөрес, тарихта бар шундый очраклар, ләкин сирәк, һәм дәвам итүчеләр талантлы кешеләр. Шулай да аларны көчләп ул юлга этәрмәгәннәр. Хәзер исә әгәр берәү артист икән, баласы да җырларга, язучы икән — иҗат кешесе булырга тиеш дип карыйлар. Фән өлкәсендә бу ялгыш караш тагын да еш очрый. Шуңа күрә урта кул әсәрләр, картиналар, көйләр, һөнәр иярләре күбәйде. Ә югыйсә, иҗат эше белән табигый сәләте булган кешеләр генә шөгыльләнергә тиеш бит.
— Кызык фикер,— диде Гөлмира елмаеп.
— Дөрес түгелме әллә?
— Алай димим. Нигәдер бу турыда уйлаганым юк иде.
— Мин дә гел уйланып йөрмим, сүз иярә сүз чыгып кына әйтүем.
— Шулай да бу фикерләрегез бик үк дөрес түгел шикелле.
Ләкин Флүр Сәхбиевич бәхәс куертып тормады. Ул хәтта кайчагында логик эзлеклелеген дә саклап тормый, әле генә әйткән бер фикерен сөйләп бетерәсе урында башына килгән икенчесен шартлатып китереп сала һәм, үзе кебек үк, әңгәмәдәше дә кайчагында җепнең очын чуалта иде. Моны ул ачык белеп эш итә, чөнки мондый бәхәсләр, беренчедән, аның турында яхшы фикер калдыра, икенчедән, ул тыңлаучысын, бигрәк тә хатын-кызны, һәрчак авызына каратып тора ала. Моңа ул озак күнегүләр нәтиҗәсендә иреште. Флүр Сәхбиевич тагын бер сыналган ысулын куллана, ул да булса — әңгәмәне ярты юлда кырт өзү. Һәм Гөлмира белән сөйләшкәндә дә ул бәхәснең иң куерган чагында сүзне икенчегә борып:
— Сезнең кәеф ничегрәк?— дип сорады.— Бакчада йөреп керергә исәп юкмы?
— Әйдәгез,— диде кыз, риза булып, чөнки бүлмәдәшләре процедура алырга төшеп киттеләр һәм тиздән аларның кайтып керү ихтималы бар иде.

## II

Алар профилакторийга терәлеп үк торган матур гына бакчага — паркка чыктылар. Парк уртасындагы яшь каеннар, сирәк озын нарат-лар, яшел тупыл һәм өрәңге агачлары, күл буендагы таллар тымызык җилдә шаулый.
Асфальт аллеяларны тутырып, шак-шок басып, биек үкчәле түфли кигән кызлар килә. Аларга ышкылып диярлек, велосипедка атланган малай-шалай, үсмерләр выжлап үтә. Юлдан эчкәрәк кертеп куелган буяулы киң утыргычларда салам эшләпәле агайлар, ак яулыклы, пар-чалы озын күлмәк кигән әби-апалар тыныч кына ял итә. Кочаклашкан бәхетле яшьләр көлешә-көлешә сукмаклардан әкрен генә атлый...
Гөлмира белән Флүр Сәхбиевич парк уртасындагы күл янына килеп туктадылар. Дистәләгән нәзек торбалардан су фонтаны өскә ургыла, һәм аклы-яшелле су өстендә, күзне иркәләп, берөзлексез ак күбекләр, кечкенә көмеш дулкыннар хасил була.
Бераздан культура сараеның ишеге ачылып, урамга халык агыла башлады һәм кинодан чыгучылар икегә аерылып, күл тирәли атлады-лар.
— Нинди кино икән?— диде Флүр Сәхбиевич кызны култыклап.
— Юк, керәсе килми, карап кына үтик.
Күл буеннан киткәч, Флүр Сәхбиевич белән Гөлмира бераз вакыт култыклашып паркта йөрделәр, культура сарае каршына барып кил-

деләр, игъланнар укыдылар. Аннары күл читләтеп уңга таба борылдылар һәм сирәк-мирәк үскән төз наратлар арасыннан әкрен генә атлап киттеләр.

Культура сараенда репетиция ясаучы тынлы оркестрның быргы, трамбон тавышлары ишетелгәләп куя.

Гөлмираның колак төбендә Флүр Сәхбиевичның ягымлы тавышы. Егет берөзлексез сөйли. Кыз дикъкать белән аны тыңлый, ләкин бер үк вакытта тирә-юнен, түбәнтен очкан кошларны да күзәтергә өлгерә. Чөнки тирә-юньнең матурлыгы, кичке табигатьнең гүзәллеге аның кәефенә тәңгәл килә. Хәер, алай гына да түгел, кызның күңелен тагын да күтәреп, җилкендереп җибәрә.

Салкынча җил исеп үтте, болытлар арасыннан, жылысын биткә бәреп, сүрән кояш чыкты. Ул бик түбән, агачлар башында гына кебек. Ә агачлардан озын-озын күләгәләр сузылды. Егетнең дә сүзләре, әйтергә җыенган фикерләре әнә шул күләгәләрдәй озын; тоташ агым кебек агыла да агыла. Хәзер ул кызга, дәртләнеп-илһамланып, күптән түгел үзе караган спектакль турындагы уйларын җиткерә иде. Гөлмира, оятына каршы, ул спектакльне күрмәгән һәм егет белән әңгәмә корырлык хәлдә түгел иде. Ләкин Флүр Сәхбиевич, кызның уңайсызлануын күргәч, моңа әһәмият бирмәскә тырышып, җайлап кына сүзне икенче темага борып җибәрде. Бу да кызның игътибарыннан читтә калмады, һәм Гөлмира шуның өчен аңа рәхмәт хисләре белән тулы күзләрен төбәде.

Юлдан борылып, ямь-яшел чирәмне һәм нарат күркәләрен таптап бераз баргач, куш наратка тап булдылар.

Флүр Сәхбиевич әңгәмәсен бүлде һәм:

— Карагыз әле боларны, туганда ук кавышканнар,— дип, әлеге агачка күрсәтте.— Адәм балаларына үз ишен табу өчен күпме эзләргә, көтәргә кирәк!

— Ярый ла таба алсалар!

— Әйе. Әмма тапкан кеше — иң бәхетле, әлбәттә.

Флүр Сәхбиевич, үрелеп, җирдән ак чәчәкләр өзде.

— Онытмагыз: куш нарат төбеннән алдык,— диде ул аларны кызга биргәндә.— Бәлки безнең бәхет чәчкәләредер алар!

— Рәхмәт,— диде кыз балкып.

Алар кайту ягына борылдылар. Ләкин килгән юлдан түгел, ә тар сукмактан киттеләр.

Кояш баер якта болытлар таралып, күк йөзе ачылган иде.

Гөлмира баш өстеннән агылган болытларга, аннан агачларга карый. Наратлар өскә ава кебек. Ул тагын елмая.

Бер хатын бала арбасы этеп бара, ә янында ире, аның кулында транзистор. Аннан тирә-юньгә моң агыла.

Алар яныннан үткәндә Флүр Сәхбиевич бала арбасына күз салды һәм берничә адым киткәч:

— Баласы матур,— диде.— Яратам соң нәниләрне!

Бераздан куе, ямь-яшел үлән үсеп утырган сазлык сыманрак урынга килеп чыктылар. Бер төштә челтерәп аккан су аркылы тар гына басма-такта салынган иде. Флүр Сәхбиевич кызны искәрмәстән җиңел генә күтәреп, ерганакның теге ягына алып чыкты. Гөлмира үзе дә сизмәстән аны муеныннан кочаклап алды һәм җиргә баскач көлеп әйтә куйды:

— Очып китәм дип торам.

Флүр Сәхбиевич ягымлы елмаеп аңа карады, ләкин бер сүз дә әйтмәде һәм җай гына иңеннән кочты. Бераз баргач, туктап, кызның күзләренә туры караган хәлдә аны үзенә тартты.

— Ярамый,— диде кыз һәм бөтен гәүдәсе белән артка тартылды.

«Ярамый икән, димәк, ярамый,— дип куйды эчтән генә Флүр Сәхбиевич һәм артык сагызланып тормады, кызны иңбашыннан кочаклаган килеш ары китте.— Ашыкмаска. Сабыр, егет. Яхшы ат соңыннан алдыра».

## III

Икенче көнне Флүр Сәхбиевич, соңгы вакытта халык теленә кереп, кулдан-кулга йөри башлаган бер «Роман-газета» алды да тагын Гөлмира янына менде. Кызның сөенечтән йөзе балкып китте.

— Каян таптыгыз?

— Мин үзем алдырам.

— Чынмы? Алайса сезнең танышларыгыз күптер.

— Ничек дип әйтим, әзрәк бар.

Бераз утыргач, кыз, нидер исенә төшеп, җәһәт кенә торды да тәрәзә төбеннән трестның бер генә битле күптиражлы газетасын алып килеп өстәлгә, Флүр Сәхбиевич каршына җәеп салды.

— Миндә дә сезгә сөенечле хәбәр бар. Хәер, сез аны беләсездер инде.

Флүр Сәхбиевич аптырап, газетага күз салды. Анда, ярты битне тутырып, ул төзегән объект турында мәкалә басылган иде. Шунда ук сурәт: алгы планда ул ике бригадир белән бик җанлы сөйләшеп тора, ә артта — төзелеш объекты.

Флүр Сәхбиевич әлеге фоторәсемне күрүдән һәм бигрәк тә газетаны Гөлмира алып кайтып, аңа күрсәтүдән күңеле булып, горурлык һәм шатлык хисе тоеп, кызга карады.

— Рәхмәт,— диде ул.— Әле күрмәгән идем.

Кыз исә аның үзенә караганда да бәхетлерәк иде шикелле.

— Молодец!— дип, Гөлмира аңа сокланып карады һәм сәгатенә күз төшереп, читенсенеп кенә әйтте:— Сез үпкәләмәсәгез, мин душка төшеп менәр идем. Укыштырып утырыгыз.

— Нинди сүз булуы мөмкин! Мин дә чыгам...

— Юк, юк, сез монда гына утырыгыз. Мин хәзер. Ярыймы?

— Яхшы,— диде Флүр Сәхбиевич риза булып.

Бая ул кергәндә Гөлмира, полиэтилен капчыкка әйберләрен тутырып, бүлмәдән чыгарга җыена иде.

— Мин озак тормам. Әнә мода журналларын карый торыгыз,— диде Гөлмира ягымлы елмаеп һәм өстәлгә берничә журнал куйды да, Флүр Сәхбиевичны өстеннән бикләп, юынырга төшеп китте.

Күп тә үтмәде, кемдер ишекне тартып карады, бер-ике тапкыр каты гына шакылдатты. Флүр Сәхбиевич, уңайсыз хәлгә калып, дәшәргәме, юкмы, кем булыр икән бу, дип уйлап, аптырап утырды. Шакылдатучының аяк тавышлары ераклашкач: «Бүлмәдәшләреннән берәрседер»,— дип фараз кылды һәм үз-үзен тынычландырды. Ләкин бераздан баягы аяк тавышы яңадан ишетелде, ишектә шалтыр-шылтыр ачкыч борылды. Ишектә озын халатлы бер хатын чәрелдәде.

— Бу нәрсә?! Бүлмәдә ир-ат?!

— Гафу итегез, мин...

— Чыгыгыз! Минем кием алыштырасым бар!

— Ихтыярыгыз.

Флүр Сәхбиевич коридорга чыгып, баскычта Гөлмираны көтеп тора башлады.

Кыз озак көттермәде, ашык-пошык кына юынып, душтан менде.

— Ой, сез мондамыни? Гафу итегез инде мине,— диде башына чалма кебек итеп сөлге ураган, эсседән алсуланган Гөлмира оялып кына.—

Ул сезне куып чыгардымы? Ачкыч сорарга төшкәч, мин аңа әйткән идем бит югыйсә...

— Ярый, зыян юк. Җиңел пар белән.

— Рәхмәт.

— Барыгыз, керегез инде.

Гөлмира читенсенеп кенә баскычтан менеп китте, Флүр Сәхбиевич та үз палатасына юнәлде.

## IV

Ял көннәрдә санаторий-профилакторийда дәваланучыларның күбесе, гаилә җылысын сагынып, өенә кайтып китә, монда яшь-җилкенчәк һәм бала-чага тавышын өнәмәүче карт-коры гына кала.

Шимбә көнне иртән Флүр Сәхбиевич бер-ике партия биллиард уйнады. Аннары, буш палатасына кереп бераз утыргач, гитарасын алды да кызыл почмак каршындагы ял итү урынына — фойега төшеп китте.

Билгеле, кайда музыка — анда яшьләр. Берникадәр вакыттан Гөлмира да бер кыз белән нәкъ Флүр Сәхбиевич каршына килеп утырды. Башта егет аны күрмәде, фойе шактый зур һәм кызны киң яфраклы пальма каплый иде. Башын күтәреп карагач кына Флүр Сәхбиевич аны күреп алды. Бу вакытта егетнең уйнавы ничектер сүлпәнрәк иде. Ә кыз белән очрашкач һәм аның күзләрендәге соклануны күргәч, әйтерсең лә егетнең бармакларына җитезлек өстәлде, йөрәгендә дәрт артты. Ул гел югары тотып йөргән горур башын чак кына кырын салып, дәртләнеп, бервзлексез уйнады да уйнады.

Гөлмира аның һәр хәрәкәтен — шома итеп таралган кара чәчле зур башының көй уңаена селкенеп-селкенеп куюын да, уң кулының гитара кылларына чирткәннән соң хәле беткәндәй кисәк кенә аска таба төшеп китүен дә, уң аягы белән бервзлексез такт биреп торуын да — барысын да йотылып карап утырды. Егетнең кояшта янган чиста йөзе дә һәм ирен тирәли салынып төшкән кара мыегы да бик килешле, кызга якын иде. Башын күтәреп, кызга карап елмайганда аның тигез, эре тешләре күренеп китә, күз читләрендә беленер-беленмәс вак җыерчыклар хасил була. Ләкин ул җыерчыклар аны картайтып күрсәтми, чөнки алар шунда ук юкка да чыгалар.

Гөлмира иптәш кызы белән гитарага кушылып җырлап та алды. «Тавышы ярыйсы гына икән»,— дип уйлап куйды Флүр Сәхбиевич, кызга сокланып. Чама дигән нәрсәне һәрчак сизеп торучы кеше булларак, ул, күпмедер утыргач, яңа көйне уйнап бетерде дә каты итеп аккорд бирде һәм, гитарасын сул кулына тотып, урыныннан кузгалды. Аңа, тагын уйнагыз, дип ялына башладылар. Ләкин егетнең карары катгый иде, һәм ул сәгатенә карап алды да, баш иеп, китеп барды. Монысы да эрелек билгесе дип түгел, ә нәзакатлелек һәм шулай тиешле дип кабул ителде. Һәрхәлдә, Гөлмира каршында егет бермә-бер үсеп китте...

Көндезен дүртәү — Флүр Сәхбиевич, Гөлмира, аның иптәш кызы һәм кызның егете — Казанка елгасы буена пляжга бардылар. Нзрәпизрәп, тирли-пешә кайнар комда кызындылар, беләкләре талганчы туп суктылар, салкынча суда уйный-шаяра коендылар, ярыша-ярыша йөзделәр, аннан чыккач, тагын тәнне пешерердәй эссе комга аудылар...

Якында гына буфетлар — су, сыра, тәм-том, ә янда — асыл егет. Гөлмира аның сокланулы әрсез карашын һәрдаим, тәненең һәр күзәнәге белән сизеп тора. Ләкин бу кызның ачуын китерми, киресенчә, шуны белү, күрү бөтен җанын эретеп җибәрә. Уен-көлке, с[illegible]п булды. Ләкин арада егетнең бер фикере кызның хә[illegible] [illegible]ңеләнә берегеп калды.

Алар янында гына ике салмыш адәм бар иде. Монда да шыпырт кына өстәделәр булса кирәк, берсе шактый кәефле күренде һәм шуны раслагандай, башта әкрен, ә соңрак тирә-юньгә ишетелерлек итеп җырлап та җибәрде: «...Уң кулымны сузамын, кыз дигәнем хатын булса, кырын карап узамын».

Көчле, таза беләкләрен як-якка җәеп, чалкан яткан Флүр Сәхбиевич, иренеп кенә бер кулы белән кара күзлеген төзәтеп, җырчыдан көлеп әйтте:

— Аекның уенда, исерекнең телендә. Мөгаен, бу кайчандыр авылдан качкан агайдыр.

— Нигә алай уйлыйсыз?— диде Гөлмира йокы аралаш дәшкән кебек ялкау гына һәм, борылып, йөзтүбән ятты да, үзе кырын күз белән егетне күзәтә башлады.

Флүр Сәхбиевич кызның карашын сизеп, чак кына аңа таба борылды.

— Аңа карап кына кешеләр бәхетле булса икән! Юк сүз ул! Кыз баланы да аңларга кирәк. Аның да ялгышкан, онытылып киткән чаклары була. Ул да тере җан иясе бит...

Билгеле, Флүр Сәхбиевич, тәҗрибәле егет буларак, кем белән эш итүен белә һәм әйткәннәренең кыз күңеленә хуш киләчәген яхшы аңлый иде. Хәлбуки, моны кыз да аз-маз сиземли, кемгә аталганын төшенә, шулай да ул бу сүзләрнең ихластан әйтелүенә ышанырга тели иде.

## V

Тагын бер көн узды. Кич белән Флүр Сәхбиевич кызыл почмакка төште. Янәшәдә генә китапханә урнашкан иде. Флүр Сәхбиевич китапханәче хатынга хәерле кич теләде.

— Исәнме, исәнме,— диде китапханәче аңа үз кеше итеп һәм, читкә борылып, кемгәдер, китапханә эчендәге берәүгә дәште.— Үзеңә кара, кызый, миңа калса — кирәк түгел.

Флүр Сәхбиевич, үзе дә сизмәстән, чак кына үрелеп караган иде, ишек янында басып торучы Гөлмираны күрде. Кыз да аны абайлап алды, комачтай кызарып исәнләште һәм шул минутта ашыгып чыгып та китте. Флүр Сәхбиевич аны әллә кызыл почмакка керер микән дип уйлаган иде, ләкин кызый ишектә күренмәде.

Флүр Сәхбиевич әлеге сүзнең үзе турында баруын аңлады, һәм шуны раслагандай:

— Флүр,— диде китапханәче хатын, аның чыгарга җыенуын күреп,— нигә син Гөлмираның башын әйләндерәсең? Барыбер өйләнмисең бит.

Шуннан китапханәче хатын Флүр Сәхбиевичка узган ел да профилакторийда чакта аңа гашыйк булган бер кызның ничек газаплануын, елавын, телефоннан шалтыратуын, хәтта артыннан йөрүен исенә төшерде.

— Шулай булгач...

Ләкин Флүр Сәхбиевич аның сүзен уенга алды.

— Алайса, монысын да ташлармын дип, миңа кызлар белән бөтенләй йөрмәскәме?

— Бер белән генә йөр.

— Ә минем ничәү?

— Беләсеңме нәрсә...

Китапханәче хатынның тел чарларга исәбе юк түгел иде, ахры, ләкин шулвакыт ишектә кулына китап тоткан берәү күренде.

— Ярый, калдырыйк,— диде Флүр Сәхбиевич һәм кызыл почмактан чыгып китте.

«Монысына ни кирәк тагын?— дип аптырады ул китапханәче хакында уйлап. Чөнки аны да бер тапкыр озатканы бар иде. Ләкин ул хатын Флүр Сәхбиевичның үзе кебек карт чыпчык булып чыкты.— Ни кирәк аңа? Әллә шуның үчен кайтарамы?»

Флүр Сәхбиевич палатасына менеп китте. Ләкин бераздан, үз-үзенә урын тапмыйча, Гөлмираларга сугылды. Кыз өйдә юк иде. Егет яңадан кызыл почмакка төште. Бу вакытта анда халык шактый җыелган, кино карыйлар иде. Гөлмираны танып, Флүр Сәхбиевич аның артына, буш урынга барып утырды һәм иңенә җиңелчә генә кагылып, үз янына чакырды. Гөлмира күченеп утырды.

— Мондый характеристикадан соң мин синең янына да килергә читенсенәм инде,— диде егет, кызның колагына пышылдап.

— Миңа да әллә ничек,— диде кыз, башын иеп, һәм аңа иңбашы белән орынды.— Әйтәсе калмаган!

Ул шулай өзгәләнсә дә, монда Гөлмира гаепле түгел иде, сүзне китапханәче үзе башлады. Әллә үзе күргән, әллә ишетеп кенә белгән, ә шулай да аңа барысы да билгеле кеше сыман үз-үзенә ышанып, якын итеп сораштырырга тотынды. Гөлмира Флүр Сәхбиевич белән танышуын сөйләми булдыра алмады, дөресрәге, сүз иярә сүз чыкты. Менә хәзер шуңа үкенеп бетә алмый кыз, егет алдында үзен гаепле сизә һәм аның күңеле борчулы.

Бераз утыргач, Гөлмира:

— Әйдә чыгабыз,— дип торып китте.

Кино чекистлар турында һәм мавыктыргыч булса да, аларның үз хәлләре хәл, икесенә дә ничектер уңайсыз, бер-берсеннән тартынып торалар иде.

Бакчада караңгы, аллеяларда гына тоныкутлар яна, алар яктысында агач кәүсәләренең күләгәләре ниндидер шомлы күренә, аларны аермачык шәйләп тә булмый. Әз генә яңгыр сибәләп үткән, Гөлмира белән Флүр Сәхбиевич атлап барган асфальт сукмак юешләнеп тора.

— Синең монда нәрсә булды соң?— дип сорады Гөлмира бераздан.

— Кызлар инде. Мин үзем дә сөйләгән булыр идем.

Сүз тагын өзелде.

— Циркка барабызмы?

— Белмим.

— Мин ике билет алдым,— диде Гөлмира, ул ничектер юашланып калган сыман иде.

— Ярый алайса.

Флүр Сәхбиевич ялындырып кына риза булды, чөнки аның кәефе кырылган иде. Кыз да моны сизде.

— Ярар инде, борчылма, миңа да кыен бит,— диде ул, егетне култыклап алып.— Бер-беребезгә ияләнә генә башладык... Әллә ничек килеп чыкты. Минем үз бүлмәмә дә кеше алып кайтканым юк, ә монда, палатага егетләр чакырасың, дип бүлмәдәш хатын әрли. Җитмәсә, китапханәче тыкшына...

Флүр Сәхбиевич туктап, кызның яңакларыннан сак кына тотты да күзләренә карады. Гөлмираның мөлдерәмә күзләре ташып, бите буйлап ике тамчы сызылып төште. Флүр Сәхбиевич аның яшьле күзләрен үбеп алды, кыз егеткә сыенды һәм үзе дә аны кочаклады.

— Ярар, борчылма.

— Бетте инде,— диде Гөлмира, яшь аралаш елмаерга тырышып.

Якында гына поезд шаулап узганы, машиналар йөргәне ишетелә, әле шау-шуы басылмаган шәһәр үз тормышы белән яши. Ә Гөлмира белән Флүр Сәхбиевичның күңеле инде тынычланып, борчулары басыла төшкән. Аларның икесенә дә рәхәт, әйтерсең бөтен дөньясында бары икәве генә, башка беркем дә, берни дә юк — тирә-юньдәге әшәке телле кешеләр дә, гайбәт, ваклыклар да, дөнья ихлас гүзәл, нурлы һәм түгә-

рәк иде. Флүр Сәхбиевич кызның йомшак чәчләрен сыйпап, күпереп торган тулы, назлы иреннәреннән үбеп алды.

Каядыр ашыгып йөзгән карасу болытлар арасыннан саргылт ай күренде. Кызның да йөрәге әнә шул болытлар кебек каядыр ашкына, билгесезлеккә омтыла иде. Ни көтә аны алда? Мәхәббәтме, әллә мавыгу гынамы? Бәхетме, әллә сагышмы? Моны кем белә дә, кем аңа алда ни буласын әйтеп бирә? Гөлмира Флүр Сәхбиевичка сыенган хәлдә әкрен генә кузгалып китте. Аңа күптән инде болай рәхәт булганы, күңеленә ошаган берәрсе белән менә шулай иңгә иң куеп барганы юк иде. Ә булган иде андый минутлар, барысы да булган иде, ләкин бүген Гөлмираның ул турыда уйлыйсы килми. Аның бары тик киләчәк, янәшә атлаучы Флүр Сәхбиевич турында гына уйлыйсы, алдагы тормышын бәхетле, ә егетне яхшы, үзенә тиң кеше итеп күрәсе килде.

## VI

Соңгы вакытта Гөлмираның өс-башына, килеш-килбәтенә игътибары артты. Дөрес, аны элек тә зәвыксызлыкта гаепләп булмый иде. Ул заманча һәм гәүдәсенә ятышлы киемнәр кияргә ярата. Берәүләр кемдә дә булса яңа кием күрсә, килешәме ул, юкмы — аны уйламыйча, чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, хәзер шундыйны ук тектерәләр. Бигрәк тә затлы кием яратучылар шулай. Ләкин алар моның белән үзләрен көлке кыяфәттә калдыруларын абайламыйлар. Ә Гөлмира бу мәсьәләдә бик сак. Шуңа күрә аның һәр әйберсе — иң затлысыннан алып, өйдә кия торган халатына кадәр — бары үзенә генә атап тегелгәндәй ыспай, килешле. Шулай булса да, Флүр Сәхбиевич белән танышканнан соң ул үзенең күп кенә киемнәреннән гаеп таба башлады, көненә икешәр мәртәбә күлмәк алыштырды, уч төбе кадәр генә көзгесе кулыннан төшми диярлек.

Циркка Гөлмира соңгы вакытта модага кергән кыска җиңле ак күлмәк киеп барды. Төз, артык ябык та түгел, сыгылмалы зифа гәүдәгә ни кисә дә килешә, ә бу киеме белән ул бигрәк тә сылу. Чәче, гадәтенчә дулкынланып, таралып иңнәренә яткан.

Флүр Сәхбиевичка Гөлмира барча хатын-кызлар арасында иң гүзәледер сыман тоела. Ул тамаша башланыр алдыннан һәм тәнәфес вакытында кызны җиңелчә култыклап йөргәндә шатлыклы, рәхәт бер тойгы кичерде. Кыз-кыркынны шактый күргән кеше булса да, Флүр Сәхбиевич үзенең Гөлмира кебек сылуны култыклап баруы, бик күп ир-атларның аңа көнләшеп каравы белән горурлана. Ул бу халәтнең кызга да күчәчәген белә, чөнки үзе дә энәдән-җептән киенгән, һәр нәрсәсе затлы, бары тик «Березка» магазиннарыннан гына алына торган киемнәр — аксыл вельвет чалбар, озын якалы, тәненә сыланып торган кыска җиңле зәңгәрсу күлмәк һәм платформалы ботинка. Кыскасы, Флүр Сәхбиевич яныннан да хатын-кыз тыныч кына үтеп китә алмый, һәрберсе аңа үзенчә бәя бирә. Ә бу бәянең нинди икәнен аларның сокланудан зур ачылган күзләре, елмаюлы иреннәре, үтеп барганда керфек арасыннан кыйгачлап ташланган карашлары сиздерә иде.

Флүр Сәхбиевич башта фойеда цирк бинасын карап, Гөлмирага аның кайбер үзенчәлекле якларын, төзүче-инженер күзлегеннән чыгып, сөйләп-аңлатып йөрде. Шул арада ул зыялы гына берничә кеше белән исәнләшеп, бер-ике генә сүз белән булса да хәл-әхвәл сорашып алырга да өлгерде. Бу да кызның игътибарыннан читтә калмады. Икенче мәртәбә кыңгырау шалтырагач, алар буфет янына килделәр. Тәнәфес игълан ителү белән дәррәү ябырылып буфетка сырылган халык инде таралышкан, өч аяклы биек өстәлләр берәм-берәм бушаган иде.

Флүр Сәхбиевич, гомерендә беренче мәртәбә күрсә дә, якын таны-

шына дәшкәндәй, биек ак башлык кигән буфетчы кыз белән нәзакәтле генә исәнләште.

— Хәерле кич, сеңелем. Кәефләрегез ничек?

— Яхшы. Рәхмәт. Сезгә ни бирим?

— Шоколад һәм сок.

...Өстәл янынннан кузгалып киткәндә Гөлмира кәефе тагын да күтәрелүен һәм үзен бик әйбәт хис итүен тойды. Флүр Сәхбиевичны үзе култыклап алды.

Программаның икенче бүлегендә чегәннәр чыгышы — билгеле бер сюжетка корылган, җыр һәм биюләрдән гыйбарәт булган театраль тамаша күрсәтелде. Чегән кызлары иңбашларын калтыратып, бөгеләсыгыла биегәндә Гөлмираның да биеп китәсе килде, үзен көчкә тыеп утырды. Аннары җырлар агылды... Күрәсең, чегән халкы юкка гына шулай моңлы булмыйдыр — алар бит гомер-гомергә дөнья гизә. Ни өчен алар һаман урын күченә? Кайберәүләр моны өнәп җиткерми, утрак тормышка ияләшмәүләре өчен тирги. Бәлки бу аларның фаҗигасыдыр? Бәлки кайчан да булса бу халыкны яшәгән төбәкләреннән куып җибәргәннәрдер, бөтен дөньяга таратканнардыр һәм алар, хәзер әнә шулай илләр гизеп, ата-баба җирен эзлиләрдер? Кем аңлый ул горур халыкның йөрәк сагышын?.. Гөлмира, күңеле нечкәреп, әнә шундый уйларга бирелеп утырды. Бөтен бер халыкның язмышын түгел, ул әле хәтта үз күңелендә ни барын да белеп җиткерми, үз язмышының кай якка борыласын да төшенми. Югыйсә, барысы да ачык кебек: менә ул — Гөлмира, менә аның янында сөлек кебек егет. Төс-бит дисәң, буйсын дисәң — һәммәсе дә килгән. Кыз үзенең дә төшеп калганнардан түгеллеген белә. Бер-беренә пар килгән тагын башка икәү бар микән бу дөнья йөзендә?! Ә шулай да кызның уйлары борчулы, күңеле гасабилана.

Аренадан җыр агыла: «Очи черные, очи жгучие...» Әйе, бары да дөрес: ул аның күзләрен ярата да, алардан курка да һәм... очратуы хәерлегә микән? Гөлмира моңсу гына үз-үзенә елмаеп куйды.

Халык шаулашып, кысыла-этелә, ишекләргә сыеша алмыйча цирк бинасыннан чыкты да, ауган капчыктан түгелгән бәрәңгеләр кебек, төрле якка таралды.

Егет, юл читенә чыгып, якынаеп килүче яшел утка кул күтәрә башлагач, Гөлмира:

— Кирәкми, такси тиз алып кайта,— диде һәм кузгалып та китте.

Гөлмираның әлеге сүзләре аның күңеленә хуш килде, аннан соң аның бүген үз планы бар. Кызның трамвай юлы өстендәге бер урамда, аерым бүлмәдә торуын белә ул.

— Ярар, алайса,— диде ул, Гөлмираның тәкъдиме белән килешеп, һәм, сүзне уенга борырга теләп, өстәде:— Әйдә, бер утыргач, төшеп тормабыз, берочтан сезнең якларны да әйләнеп кайтырбыз.

Кыз егетнең тел төбе кая ишарә кылганны чамалый.

— Юк, бүген түгел,— диде ул.

Флүр Сәхбиевичның кинаясе дәвам итә.

— Безгә анда аяк басу насыйп булмас микәнни?

Әз генә үпкә дә, үкенеч тә бар шикелле бу сүзләрдә, фәкать ялынуялвару гына юк. Егетнең менә шушы горурлыгы җиңә дә, ахры, кызны.

— Нигә алай дисең?

— Мин әле һаман синең алда үземне гаепле кешедәй сизәм.

Флүр Сәхбиевичның бер кулы трамвай түшәменә беркетелгән шома тоткага ябышкан, ә икенчесе Гөлмираның билендә. Кыз аңа сыенып, дамба кырыендагы утларга карап бара. Аннан ул карашын еракка, сул якта калучы Киров дамбасына күчерә. Кызның карашы читтә, ә күңеле биредә.

— Әгәр кешене яратсаң, аның турында начар уйлыйсы килми.

Флүр Сәхбиевич өчен күптән кителгән, ә хәзер тантана итәрдәй кадерле сүзләр иде бу. Гөлмира аларны ничек әйткәнен абайламый да калды. Хәер, ул бит егет белән башта ук ачыктан-ачык мөгамәләдә булырга тели, шуңа күрә барысын да әйтеп сөйләшү яхшырак.

— Ә син мине ярата алыр идеңме?

Гөлмира Флүр Сәхбиевичның бу соравына да үзе әйтергә теләгән һәм егет көткән җавапны бирде.

— Әйе.

— Син бит әле минем турыда бик аз беләсең. Әгәр мин сиңа барысын да сөйләсәм, синең күңелең кайтачак.

— Кирәкми,— диде Гөлмира һәм трамвай кисәк сулга таба борылганда егеткә тагын да ныграк сыенды.— Якын кешең булу нинди рәхәт! Ялгызыңа — кыен.

Флүр Сәхбиевич кызны беленнән ныграк кысып, иелә төшеп, колагына:

— Мин дә синең белән булганда үзгәрәм төсле,— диде.— Мин усал бит. Танышканда ук әнинең мине ничек дип йөрткәнен әйттем. Ә синең янында юашланам, йомшак күңелле булам.

Гөлмира елмаеп әйтте:

— Минем әни миһербанлы, дияр иде.

— Ихтимал шулайдыр. Син үзең яхшы кеше, ахры, бәлки бу хәл шуның нәтиҗәседер.— Егет бераз дәшми торды, аннан авыр сулап:— Гөлмира, безнең икебезгә дә соңыннан кыен булыр, без барыбер аерылышырбыз,— диде.

Кыз сискәнеп китте. Күтәрелеп егетнең йөзенә карады. Аның кояшта янган карасу чырае җитди, ә авыз читеннән салынып төшкән кара мыегы һәм киң, очлы ияге хәтта бертөрле кырыслык билгесе булып күренде кызга.

Гөлмираның сораулы карашына Флүр Сәхбиевич:

— Синең барыбер күңелең суыначак,— диде.— Синең миңа карата булган ышанычың әкренләп бетәчәк.

Гөлмира дәшмәде.

Трамвайдан төшеп, шыксызланып калган шәрә алма агачлары утырган төнге бакча эченнән атлаганда да, сүрән яктыртылган аллеялардагы сирәк эскәмияләрдә күренгән парлылар янынннан узганда да һәм, Гагарин урамына чыгып, урамның караңгы тротуарыннан салмак атлап киткәндә дә тын гына барды да барды. Гөлмираның үз уйлары. Флүр әнә нәрсә ди бит. Ул үзен, кайберәүләр кебек, мактамый, һаман яманларга тырыша. Әйе, ул үзен хурлый, ә киресе килеп чыга: аның саен Гөлмираның егет турындагы уйлары, караңгылык пәрдәсен сизелер-сизелмәс ерткан таң балкышы кебек, яктыра бара. Күңелендә кара яткан кеше үзенең яманатын сата димени?

Биек койма өстеннән тротуарга салынып төшкән алма агачлары турысында Флүр Сәхбиевич кызны каты, ләкин назлы куллары белән кочып алды, чәчләрен сыйпап, күзләрен, кулларын һәм бармакларын берәм-берәм үбә башлады. Гөлмира карышмады. Әле генә башына килгән каршылыклы, пошаманлы уйлардан соң, егетнең көчен, җылысын, назын тою аңа рәхәт иде. Ул үзе дә бөтен кайнарлыгы белән аның иреннәреннән үпте, күзен йомып, егетнең ихтыярына буйсынып, аның кочагында торды. Гөлмира шушы асыл егетне яратуы, якын күрүе, аны бәхетле итүе өчен соңыннан үзен тиргәмәсме, яисә үкенмәсме?..

Профилакторийга кайткач, алар ашханәгә кереп, кефир эчтеләр дә, бер-берәнә хәерле төн, тәмле йокы, матур төшләр теләп, бер-берсенең кулларын җибәрә алмыйча торганнан соң, баскычта аерылыштылар.

## VII

Кич белән Флүр Сәхбиевич килеп кергәндә Гөлмира китап-дәфтәрләр сибелеп яткан өстәл артында башын иеп нидер язып утыра иде. Ул җиләс һавалы, тәрәзәсе ачык бүлмәдә берүзе; эре парчалы, түше ачыграк кыска җиңле халаттан, дулкынланып торган йомшак коңгырт чәчләре алдына — өстәлгә үк салынып төшкән. Ул керүчегә күтәрелеп караганда башын селкеп, аларны җәлт кенә артка чөеп җибәрде, елмаеп исәнләшкәч, егеткә урын күрсәтеп, тагын яза башлады. Ә тыңлаусыз чәчләре янадан күкрәгенә шуып төштеләр.

Флүр Сәхбиевич утырмады, бүлмәгә күз йөртеп чыкты һәм юри генә:

— Сәлам хатлары язабызмы?— дип сорады, чөнки өстәлдә ул биргән роман-газета, кыз шуннан нидер күчерә иде.

— Менә кайбер фикерләрен язып алам. Яратам шундый нәрсәләрне,— диде Гөлмира язуыннан туктап һәм тагын ак, тигез тешләрен күрсәтеп, егеткә елмаеп карады.— Баягынак Рабиндранат Тагордан да күчереп алдым.

Флүр Сәхбиевич буялган шома идәнгә сак кына басып, кызның артына чыкты һәм иелебрәк дәфтәренә күз салды, тигез хәрефләр белән язылган бер-ике юлны укыгач, тагын да иелә төшеп, иреннәрен кызның чәченә тидереп алды. Хуш исле чәчләр егеткә аңын томалар дәрәҗәдә рәхәтлек бирде, ирексездән сулышы киңәеп, күзләре йомылды.

Аннан ул Гөлмираның язарга комачаулап, түшенә ишелеп төшкән коңгырт чәчләрен җайлап кына ике учына җыеп алды һәм иңенә таратып салды, иелеп, янә кызның чәчләрен, битен һәм муенын үпте. Бөтен тәне ут янган Гөлмира, язуыннан туктап, ручкасын өстәлгә куйды, борылып, кулларын югары күтәрде, егетнең башын кочаклап алды.

Алар шулай беркавым торгач, Гөлмира пышылдап:

— Бүлмәдәшләрем керүе бар, миңа тагын кыен булыр,— диде.

— Әйдә безгә.

— Ярамас бит.

— Кәгазьләреңне ал, шунда язарсың.

— Килешерме соң? Әллә ничек, читен...

Флүр Сәхбиевич ачкычны бер генә борып, кызны үз бүлмәсенә үткәрде һәм ишекне ябуга ук аны арттан кочаклап алды.

— Безнең хан сараена рәхим итегез, туташ, төкле аякларың белән.

Бөтен тәненә таралган талгын назны тоеп, башын артка ташлабрак утырган Гөлмираның ирен читләрендә моңсу елмаю пәйда булды. Сүз әйтергә теле әйләнмәде. Ул китап-дәфтәрен һәм хәлсез кулларын өстәлгә куеп, сулышсыз утырды.

Флүр Сәхбиевич ишекне бикләде, утны сүндерде һәм кызны кулына күтәрде.

— Юк, кирәкми...

— Ундүрт яшьлек кызлар кебек гөнаһсызмы әллә син?

— Мыскыл итмә,— диде Гөлмира, урамнан төшкән ут яктысында егетнең кырыс булып күренгән йөзенә карап.— Җибәр, беләгемне авырттырдың.

Флүр Сәхбиевич кызны аягына бастырды, соңгы сүзенә игътибар итмәстән, аңа арты белән борылып, тәрәзәгә, караңгылы-яктылы урамга карап тора башлады. Ул кәефсез иде. Ике арада ниндидер салкынлык барлыкка килде һәм аларны бер-беренә бәйли башлаган җеп менә-менә өзелер кебек. Флүр Сәхбиевич кашларын җыерып, яңак мускулларын кыймылдатып, әкрен генә борылды һәм башын иеп карават

читендә утырган кыз алдына килеп басты. Икесе дә сүзсез калдылар. Бераздан Гөлмира калкынды.

— Мин чыгам.

Флүр Сәхбиевич ут кабызды, ачкычны уңга борды, ләкин Гөлмира кузгалмады. Егет аның янына килде, кочаклап алды.

— Гафу ит. Мин сине рәнҗеттем.

Гөлмира аны гафу итте һәм бераздан үзенең элеккеге егете турында сөйли башлады. Кыз аны бик яраткан икән.

— Мин үкенмим дә. Мин аннан бала табарга теләдем, ләкин булмый калды.

Флүр Сәхбиевич, үз күзләренә ышанасы килмәгәндәй, кызга күтәрелеп карады. Аңа менә шулай ачыктан-ачык сөйләгән кызлар очрамады. Күбесе соңыннан сөйли, акланырга тотына, ә бер ишеләре үзен гөнаһсыз дип күрсәтергә тырыша иде. Шуңа күрә Гөлмира аңа бермә-бер якынаеп китте. Ул өзгәләнеп, үкенеп, кызның яшьле күзләрен, йомшак чәчләрен үпте.

— Мин — начар кеше. Ә бит кайчандыр андый түгел идем.

— Моңа без — хатын-кызлар гаепле,— диде Гөлмира аның куенынннан чыкмыйча.

— Мин сиңа бәлки төгәл генә аңлата да алмам, син шуны төшен: безнең күңелләребез якын. Сөеклем минем!

Гөлмира башын Флүр Сәхбиевичның күкрәгенә куеп, бик озак рәхәт бер талгынлык тоеп, радиодан агылган симфоник музыка тыңлады. Әүвәл Бах, аннан Бетховен әсәрләре яңгырады.

— «Айлы соната»ны сәгатьләр буе тыңлар идем,— диде кыз һәм, тәрәзә каршына килеп, уйга чумды.

— Ә миңа Лист ошый,— диде Флүр Сәхбиевич, әкрен генә кыз янына килеп.— Аның «Ярәшү» дигән сонатасы бар. Ул аны Рафаэльнең шул исемдәге картинасын карагач язган. Менә шуны тыңлаганда әллә нинди тойгылар кичерәм. Башта музыка бөтен барлыгыңны били, тәннәр кымырҗый. Ә бераздан ул хисләрнең иң нечкә кылларына кагыла кебек. Ә тагын берникадәр вакыт утыргач, күңел тугайларын айкый, синең яшәешең, тормышның тоташы белән күз алдына килә һәм үтеп китә төсле. Озаграк тыңласаң, дөньяда фәкать музыка гына калган сыман.

Гөлмира бернichә минут тын гына торды.

— Листны мин Бетховеннан аерып карамыйм. Ул аңа якын. Юкка гына бервакыт: «Әгәр дә кайчан да булса Бетховен симфонияләрен эчке бер тетрәнү белән тыңлаучы булса, ул — мин!» — димәгәндер бит.

— Аның укучылары, аңа иярүчеләр күп булган.

— Әйе. Ләкин Бетховен бер генә.

— Ничек дигән әле ул князь Лихновскийга: «Князьлар меңләп булды һәм булачак, ә Бетховен бер генә» — дигәнме?

— Анысын ишеткәнем юк.

Флүр Сәхбиевич көлемсерәп:

— Без нишләптер бик югарыга менеп киттек әле,— диде.— Түбәнрәк төшик.

Гөлмира башта көлде, аннан җитди итеп сорады:

— Иртәгә культура сараена барабызмы?

— Бик барасың киләме?— дип сорады егет һәм, тәрәзәдән күзен алып, кызга карады.

— Син барсаң...

Иртәгә Урицкий исемендәге культура сараенда мәшһүр бер кино артисты белән очрашу булырга тора иде. Сүз шул хакта барды. Шактый вакыт кино, артистлар турында сөйләшеп утырдылар. Әлеге комик

артист уйнаган фильмнарны искә төшерделәр, көлешеп алдылар. Аннары сүз тагын үзара мөнәсәбәткә әйләнеп кайтты.

— Гөлмира, миңа һаман уңайсыз. Мин сиңа үземнең ничек һәм ни өчен яратканымны аңлата алсам иде!.. Ә безнең аралар хәзер бик тә якын булырга тиеш. Бу — бер-беребезгә булган ышанычны гына арттырыр иде.

Кызның тавышы калтырап чыкты.

— Син мине ташларсың бит.

— Нигә шундый сүзләр әйтәсең? Мин исбат итәрмен.

— Ничек?

— Без бергә булырбыз. Минем сине югалтасым килми. Син минем өчен бик кадерле кешегә әйләнеп барасың.

Егет бу сүзләрне әйткәндә әле хисләренең агышын төгәл белми, шулай да кызны ышандырырга тырыша һәм бер үк вакытта үзе дә шуңа ышанырга тели. Ул Гөлмираны кулына күтәреп, күкрәгенә кысты, үпте. Кыз оялып башын яшерде. Бу минутта алар бәхетле иде.

## VIII

Санаулы көн тиз үтә диләр һәм, моның шулай икәнен искә төшереп, профилакторий белән саубуллашу сәгатьләре дә житте. Гадәттә хушлашу — кайда гына, кем белән генә булмасын — жанны сөендерми. Ләкин Гөлмира белән Флүр Сәхбиевич йөзендә моңсулык юк, чөнки моннан иртәрәк китү аларны тизрәк кавыштырыр төсле. Шуңа күрә ямансуларга сәбәп юк. Егет белән кыз бу йорттан башларын иеп, моңсу караш белән артка каерыла-каерыла әкрен генә атлап китмәделәр, ә киресенчә, йөрәк тулы ялкын, шашкын дәрт белән бирегә үткәргән көннәрнең якты хатирәсен һәм якын киләчәктә кавышу өметен дә алып киттеләр. Хәтта бакчадагы агачлар да аларга бәхет теләп, сыек ботаклары, хуш исле, йомшак яфраклары белән аларны иркәләргә теләгәндәй жилфердәп, шыбырдап, нидер пышылдап калдылар сыман.

Алар тагын бик күп мәртәбәләр күрештеләр, иркәләү-назлау да булды. Бу вакытта Гөлмира Флүр Сәхбиевич турында барысын да белә иде инде. Ләкин ул аның фатирына барырга теләмәде. «Анда мин язылышкач кына, килен булып кына төшәм»,— диде ул, авыр елмаеп. Чөнки Гөлмира моның беркайчан да булмаячагын, фәкать тормышка ашмастай хыял гына икәнен яхшы аңлый, ә шулай да бу егеттән башка, бигрәк тә менә соңгы көннәрне аннан башка яшәү мөмкин түгел икәнен белә иде. Ул Гөлмира өчен бик кирәкле кешегә әйләнде, ансыз кызның тормышы тулы түгел, күңеле һаман нидер эзли, аны юксына, кайда гына йөрсә дә, ни генә кылса да, уйларында — ул, күз алдында — ул... Гөлмира аны һәрдаим көтә, бөтен жаны-тәне белән зарыгып көтә, аңа тартыла, ансыз үткән көннәре — бәхетсез.

...Флүр Сәхбиевич үтә күренмәле кыштырдавык кәгазьгә төрелгән чәчәкне уң кулыннан портфель тоткан сулына авыштырып, ишек янындагы кыңгырау төймәсенә басмакчы иде, ишек ачык икәнне күреп, аны эчкә этәрде. Бу яңа өйләнешүчеләр өчен дип төзелгән, ганлә саен бер бүлмәсе һәм биш-алты семьяга бер кухнясы булган йорт иде. Якты гомуми коридорга кергәч, егет дүртенче бүлмә ишеген шакыды.

Гөлмира йөгереп килеп, елмаеп ишек ачты һәм кунакны кулыннан тотып ук алды.

— Хәерле кич!

Флүр Сәхбиевичның бераз ятсынып калуына һәм шуңа күрә житди тонда әйтелгән сәламенә каршы Гөлмира балкып, үз итеп:

— Исәнме,— диде һәм урын күрсәтте.— Уз, уз.

Ул кыска җиңле, эре бизәкле, аяк йөзенә үк төшеп торган озын чуар халаттан, аягында бизәкле чүәк, башын горур тотып, җиңел атлап йөри, үзеннән хуш ис бөркелә. Аның киләсе кунакны көткәне һәм бу көннең кыз өчен тантана икәне күренеп тора: йөзендә елмаю, күзләрендә шатлык-куаныч.

Флүр Сәхбиевич чәчәген Гөлмирага бирде, кызның елык-елык килеп торган кызыл тырнаклы нәфис бармакларына игътибар итте, кулларының йомшак кагылуын тойгандай булды. Беленер-беленмәс кенә иннек сөрткән иреннәренә, сөрмә тарткан күз-керфекләренә сокланып, әйтмичә булдыра алмады.

— Син бүген королева кебек!

— Оялтма инде.

Флүр Сәхбиевич портфелен палас җәелгән идәнгә, стена буена сөяп куйды. Ул арада Гөлмира аның ботинкасын, идәнгә газета җәеп, ишек катына куйды. Флүр Сәхбиевич килеп кергәч тә лимон кабыгы кебек ачык сарыга буялган, эре яшел имән яфраклары төшерелгән стенага игътибар итте. Ихтимал, бүлмәсенә хуҗа үзе ремонт ясагандыр, тәҗрибәле төзүченең үткер күзе бераз гаеп-кыек та күрде. Шулай да, мактагандай итеп:

— Барысын да булдырасың икән,— диде һәм, бүлмә эченә баш иэәп алганнан соң, стенага бармагын тидереп карады.

— Әй,— диде кыз кулын селтәгәндәй итеп, аннан елмайды.— Эшләмәгән эшем юк, эш майтарган төшем юк.

Ләкин бүлмәнең башка җиһазларына — пөхтә итеп җыештырылган караватка һәм күпертеп кабартылган, ак челтәр япма белән каплаган зур мендәргә, аңа аркасын терәп утырган озын борынлы кечкенә Буратинога карагач, Флүр Сәхбиевич ирексездән елмаеп куйды, үзенең прораб икәнен онытты һәм кунак кына булып калды. Бүлмәнең зур тәрәзәсе бар, пәрдәсе стенага тартым — соргылт, аңа төрле савыт-саба, кувшин кебек әйберләр төшерелгән; тәрәзә төбендә сырлы-бизәкле балчык чүлмәкләрдә ачык кызыл чәчәкле яран, чәнечкеле яшел кыяклы алоэ һәм Флүр Сәхбиевич белмәгән ак гөлләр тезелешеп утырган, алар арасында бизәнү әйберләре, балчыктан әвәләп ясалган кечкенә матрос сыны. «Энесе моряк бит»,— дип уйлады кунак. Тәрәзә төбендә шулай ук агач бөркет статуясы. Ул сәләтле, тәҗрибәле оста тарафыннан эшләнгән, ахры, аның һәр сызыгы төгәл, бар төше дә камил, күрер күзгә бик нәфис һәм куелуы да урынлы кебек. Ләкин аның үтә нечкә һәм менә-менә сынарга торган агач ботагына кунып, аңа батырган үткен тырнакларын күргәч, бу кошның тәрәзә төбендәге гөлләр арасына ялгыш килеп эләгүен тоясың. Бәлки бу Флүр Сәхбиевичка гына шулай тоелгандыр һәм үзенең бу уйларыннан аңа нигәдер уңайсыз булып китте. Күңел нечкәрүенә бирелмәскә тырышып һәм, вөҗдан тынычлыгына кагылучы бу уйларыннан арыныр өчен таяныч эзләгәндәй, ул бүлмәне ахырынача күзәтеп чыгарга булды. Кеше тынгысыз, тәшвишле уйлардан арыну өчен игътибарын шулай бүтән нәрсәгә юнәлтә бит. Шуңа күрә Флүр Сәхбиевич кнопка белән ишеккә беркетелгән рәсемне — дулкынланып маңгаена ук төшеп торучы саргылт чәчле, зәп-зәңгәр күзле, ирен читләре белән генә елмайган һәм шул ук вакытта уйчан карашлы Есенин сурәтен күреп, шатланып диярлек сорап куйды:

— Егетеңме?

Гөлмира моның юри әйтелүен аңлады, әлбәттә.

— Әйе,— диде ул, башын кыңгыр салып, һәм елмайды.— Чибәрме?

— Ярыйсы.

— Хәлләрең ничек? Әниең килмәгән икән.

— Килеп җитми әле. Ул күптән җыена инде. Син ниләр эшләдең?

— Шәхси планда — үзгәрешсез. Эштә — бүген-иртәгә кирпеч өюне бетерәм, отделкага тотынам.

— Молодец!

Флүр Сәхбиевич бая ук стенада эленеп торган скрипкага игътибар иткән иде. Ул Гөлмираның нинди дә булса уен коралында уйнарга тиеш икәнен белә, ләкин бу турыда әлегә сүз булганы юк иде. Кайсыбер фатирларда, Флүр Сәхбиевичның белүенчә, андый әйберләрне я экзотика, яисә күзгә төтен җибәрү өчен генә дә элеп куялар. Шуңа күрә дә ул, скрипкага ымлап, шаярткан булып кына әйтте:

— Әллә бер сыздырып җибәрәсеңме?

— Сирәк тотам, онтылып бетә инде,— диде кыз тыйнак кына.— Алай кешегә күрсәтерлек осталыгым да юк.

Егетнең тиз генә бирешәсе килмәде.

— Шулай да, бик тырышсак...

— Кешесенә күрә генә,— диде кыз.

Гөлмира торып скрипканы алды, бераз вакыт көйләп-җайлап маташты, ияк астына кулъяулыгын кыстырды, башын кыңгыр салды. Башта ул нindидер пьеса уйнады. Бу әсәр Флүр Сәхбиевичка таныш түгел иде. Аннары бүлмә эченә моң агылды, бүлмәдә борынгы татар көе яңгырады. Бәләкәй генә инструменттан шундый аһәңле авазлар чыгуына ышануы да кыен иде. Кыз егеткә тагын бер ягы белән ачылды. Гөлмираның уң кулы смычокны я салмак кына тарта, я кинәт кискен бер хәрәкәт ясап ала, ә сул кулының нәфис бармаклары кыллар өстендә өзлексез бии...

Флүр Сәхбиевич гаҗәеп бер могҗиза эчендә калгандай сихерләнеп, скрипканың тылсымлы авазлары тәэсиренә бирелде һәм тын алырга да куркып диярлек утыра башлады. Аның күзләре йомылды һәм... каршында янә Гөлмира пәйда булды. Тик ул хәзер кысан бүлмәдә түгел, ә зур концерт залында, имеш; озын ак күлмәк кигән һәм йөзләгән тамашачы алдында имтихан тота, үзенең һөнәрен күрсәтә. Көчле ут яктысында кыз тагын да зифарак, тагын да гүзәлрәк... Менә ул уйнап бетерә. Зал аны алкышлар белән күмә, төрле яктан «Браво!» «Афәрин!» дигән сүзләр ишетелә. Ә Флүр Сәхбиевич, сүз әйтергә түгел, урыныннан кымшанырга да базмыйча, хәйран калып утыра бирә...

Флүр Сәхбиевич күзләрен ачты. Гөлмира уйнаудан туктаган һәм аңа карап тора иде. Егет кыз янына килде дә аның кулын тотып бармакларын үпте.

— Рәхмәт. Кайда болай матур итеп уйнарга өйрәндең?

— Мин җиде ел музыка мәктәбенә йөрдем.

— Ә нигә тагын да укымадың?

— Дөресен әйткәндә, мин эти кушканга гына йөрдем. Ул музыка мәктәбендә укыта, бер фанатик инде менә: көнен-төнен диярлек шунда уздыра, бала-чага белән оркестр оештырып, концертлар куеп мәш килә. Мине дә укытты. Ләкин минем башта ук теләгем булмады. Дөрес, соңга таба, күңел үсепме, көнчелек кузгалыпмы, кызлардан калышасым килмичә ярыйсы гына тырышып шөгыльләндем. Ләкин ул юлдан китмәдем.

— Кызганыч!— диде Флүр Сәхбиевич, башын селкеп.— Начар музыкант чыкмас иде.

— Комплиментыңа рәхмәт,— диде кыз елмаеп.— Ләкин... болай искитәрлек булмас иде.

— Нигә?

— Миңа соңыннан эти дә әйтте. Ул миннән музыкант чыкмасын белгән, шулай да, зыяны тимәс, дип йөрткән.

— Дөрес эшләгән.

— Утыр,— диде Гөлмира, скрипкасын элеп куйгач, һәм үзе дә өстәл янына килде.— Ә син музыканы каян беләсең?

— Самоучка.

— Ничек?

— Мин музыкантлар турында китаплар күп укыдым. Институтта бер дус егет бар иде. Ул бик шәп җырлый һәм сәнгатькә гашыйк кеше иде. Аның белән төрле кичәләргә, концертларга йөрдем. Хәзер сирәкләдем, билгеле. Ә ул барыбер үзенекен итте, институт бетергәч, ике ел мастер булып эшләде дә, төзелешне калдырып, консерваториягә керде. Хәзер филармониядә эшли. Без аның белән һаман да очрашабыз, гастрольдән кайтса, миңа килми калмый.

— Нинди генә язмышлар юк,— диде кыз бераз дәшми утыргач, аннан кисәк кенә башын күтәреп, егеткә карады.— Чәй куйыйммы?

— Онытып торам икән. Мәле ал боларны.

Флүр Сәхбиевич портфеленнән әйберләр чыгарды.

— Син мине һаман коньяк та шоколад белән сыйлап, тәмлегә өйрәтеп бетерәсең бит.

Егет бу сүзне игътибарсыз калдырды һәм Гөлмира кухняга чыккан арада түр почмакка терәп куелган өстәлдәге китап-журналларны караштырды. Кыз да өстәл янына килеп, аның каршына утыргач, китабын бер читкә куеп, кызга карап тора башлады.

— Берәр яры барабызмы?— дип сорады.

— Кая?

— Киногамы...

— Барасы килми. Өйдә генә утырыйк. Яңгыр да төшкәли, ахры. Иртәгә барырбыз, яме?

— Даманың теләге — джентельмен өчен закон,— диде егет, кулларын күтәреп. Аннан кызның күзләренә туры карады:— Сагындыңмы?

— Әйе.

Гөлмира оялып башын яшерде. Бераз шул рәвешле утыргач, ул кухнядан чәйнек тотып керде, өстәл хәзерләде. Флүр Сәхбиевич портфеленнән кечкенә магнитофон алып өстәлгә куйды. Бер рюмка эчкәч, икесенең дә кәефләре тагын да күтәрелде, гәүдәләрен боргалап биеп тә алдылар. Янә өстәл артына утыргач, Гөлмира әнисе, туганнары турында сөйләде. Күрәсең, ул аларны бик ярата һәм сагына иде. Гөлмира, өлкән бала буларак, энесе белән сеңелесен үзе карап үстергән. Энесе хәзер су асты көймәсендә хезмәт итә икән.

— Башта бик кыен, дип хатлар язды. Төшенкелеккә бирелгән чаклары да булгалады. Тора-бара өйрәнде, хатлары ешайды һәм күңелле итеп яза. Кунакка кайтырга җыена, Казаннан бер мичман бар, бик дуслашып киттек әле, дигән. «Мичман синең карточканы күреп, әллә гашыйк булды инде, бу арада гел сораштыра»,— дип тә өстәгән.

Гөлмираның йөзенә кызыллык йөгерде, оялып башын түбән иде дә сеңелесе турында сөйләргә кереште:

— Анысы кияүдә, тату гына торалар, хатларыннан моң-зар сизелми.

Флүр Сәхбиевичка Гөлмираның туганнары өчен көенеп, борчылып торуы бераз гына сәер һәм аңлашылып та җитми торган ят тойгы иде. Ләкин ул моны кызга әйтмәде.

Ул, җәһәт кенә торып, кызны биленнән алды һәм аның белән бүлмә буйлап бөтерелә, очынып вальс әйләнә башлады.

Гөлмира утның сүнгәнен абайламый калды.

— Кирәкми.

— Без барыбер бергә булырбыз!— диде Флүр Сәхбиевич кызның колагын пешерердәй кайнар сулышы белән.

Кыз бөтен тәне белән егеткә сыенды һәм хисләрен тыя алмыйча үзе дә аны кочаклады.

— Нәрсә өчен яраттың соң син мине?!

— Минем өчен синнән дә гүзәл кыз юк!

Стенада ут яктысы тирбәлә. Урамнан дөбердәп-выжылдап трамвай уза. Гүя ул кызның бөтен шик-шөбһәләрен үзенә ияртеп алып китә. Тышкы яктагы калайга шык-шык яңгыр ява, ул тәрәзә пыялаларына

бәрелеп шыбырдый, әкрен генә шаулый. Әйтерсең, үзенең гел бертөрле авазы белән кызны йоклатырга тели. Нәзек агачка үткен тырнакларын батырган бөркет, корбанына ташланырга әзерләнеп, тәрәзә төбендә канат җәйгән. Ә Гөлмира колагына талгын аккан елга суы кебек салмак кына серле сүзләр иңә.

— Син минем белән бәхетле булырсың! Мин сине сөям. Бу миңа шатлык, бәхет, рәхәтлек китерә. Киләчәк тормышымның тагын да тулырак, мәгънәлерәк булачагын вәгъдә итә, аңа хәзер үк яңа эчтәлек өсти. Мин шулай ярата алуыма үзем дә гаҗәпләнәм. Мин сине яраткан кебек берәүне дә яратмадым шикелле.

Гөлмира әллә ачынып, әллә сөенеп пышылдый:

— Каян очраштык соң без?!

— Син үкенәсеңме әллә?

— Юк!— диде кыз һәм кайнар куллары белән егетнең көчле, таза муенын урап алды.

## IX

...Флүр Сәхбиевич ул көннәрне, әле кичә генә булып үткәндәй, бөтен ваклыклары белән кабат исенә төшерде, әйтерсең назлы кичләрне яңадан бер күңеленнән кичерде. Һәм хәтерендә тагын теге бөркет сыны пәйда булды. Нишләптер бик озак вакытлар аның хәтереннән китмәде ул кош... Шуңа карамастан, егет өчен татлы да, газаплы да иде бу, чөнки ул Гөлмираны тиз генә оныта алмады.

Эшкә китәр алдыннан Флүр Сәхбиевич Гөлмираның соңгы хатын китап киштәсеннән алып укыды да, күңелен бимазалап тормасын, йөрәгенә тоз салмасын өчен аны ерткалап ташлады. Ә хатның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт иде.

«Төнлә ява башлаган яңгыр әле һаман чиләкләп коя, шыбыр-шыбыр тәрәзә пыялаларына бәрә дә ачуланып орынып алгалый. Ул миңа нәкъ теге кичне хәтерләтә. Урамда көн сүрән, өйдә салкын, җылырак гөренеп, сиңа хат язарга утырдым.

Синең шалтыратуыңны нинди түземсезлек белән көткәнемне белсәң иде! Менә бүген дә кәефем күтәренке — синең тавышыңны, гәрчә сөйләшүең теләр-теләмәс кенә булса да, ишеттем.

Соңгы тапкыр килгәндә шулай үзеңне тәкәббер тотып, миңа карата салкын карашыңны сиздереп китүең һәм үткән юлы телефоннан шундый тонда сөйләшүең — болар барысы да чишелеш якын икәнлеген сөйли иде. Мин инде күптән аңладым: гөлләрнең чәчкәсе өзелде һәм алар белән бергә безнең мәхәббәтебезнең шатлык-сөенечләре дә чәчкәләрен койды; алар бик авыр һәм тирән җәрәхәт калдырса да, хәтеремнән чыкмыйча, миңа татлы минутлар бүләк итә иде.

Әйе, мин дөресен әйтәм, нәкъ шулай: татлы минутлар... Мин синең белән таныш булуыма үкенмим. Мин бит моңа, кайберәүләр кебек, үз-үземне белештермичә, минутлык хискә бирелеп кенә бармадым. Мин көчле икәнемне, әгәр теләмәсәм, мине бу адымга беркем дә этәрә, мәҗбүр итә алмаячагын яхшы белә идем. Ләкин мин барысына да риза булдым һәм күңелемнән синең белән болай сөйләштем: «Ярар, карап карыйк синең кемлегеңне». Һәм син үзеңне күрсәттең... Ялгыш аңлый күрмә, мин кылган эшемә үкенәчәк түгелмен.

Кадерлем, аңла: минем бер генә теләгем бар — яхшы дуслар булып калыйк. Үзең әйтә идең бит: хатын-кыз ир-атның башта танышы була, аннары — сөяркәсе, бары шуннан соң гына дусты, дип. Мин шуңа риза. Бу бит гөнаһ та, әхлаксызлык та, минем тарафтан түбәнлеккә төшү дә түгел. Безнең арада туган иң изге хисләр беркайчан да онытылмас. Аларны беркем дә юк итә алмый. Мине дөрес аңларга тырыш.

Флүр, сөеклем! Синең белән тагын бер генә мәртәбә очрашасым, назлы сүзеңне ишетәсем килә... Бик, бик очрашасым килә! Әгәр теләмисең икән — көчләмим. Кавышулар насыйп булмады, дип уйларбыз. Хуш».

Флүр Сәхбиевичка Гөлмира бик кызганыч тоелса да, ул кабат аның белән очрашмаска, аңа шалтыратмаска, хатларына җавап язмаска һәм аны онытырга кирәк дигән нәтиҗәгә килгән иде. Нәрсәсе белән кыз аның гайрәтен чигерде соң? Берни белән дә түгел. Чөнки ул буй-сыны, тәсе-бите, холкы-фигыле белән Флүр Сәхбиевичка ярамаслык кыз түгел, киресенчә, аның зәвыкларына һәрьяклап җавап бирердәй, уй-фикерләре дә аныкына тәңгәл килердәй кеше иде. Гомумән, заманча киенә һәм яши белүче, тугрылыклы хатын, балаларына яхшы ана булырдай итагатьле кыз иде Гөлмира. Әмма ул да Флүр Сәхбиевичның тормыш сукмагыннан читкә тибәрелде. Күрәсең, эш монда Гөлмирада түгел, ә егетнең үзендәдер. Әлбәттә, ул моны чит кешегә түгел, үзүзенә дә икърар итәргә базмый. Ә чынлыкта исә ул әле үзен хатынкызлар белән йөреп туймаган дип исәпли һәм гаилә камытын муенына салудан ерак тора иде. Шуңа күрә бөтен ягы килгән Гөлмира да аңа юлдаш була алмады.

Кайчагында Флүр Сәхбиевич үзе елаткан кызларның күз яше, каргышы төшүдән курка башлый, ләкин ул үзенең бу тойгысын да йөгәнли, намусына тиярдәй андый уйларны читкә алып ташлый һәм иркенле тормышын дәвам иттерергә ниятли иде. Ләкин вакыйгалар Флүр Сәхбиевич көтмәгән, ул һич күз алдына китермәгән юнәлеш алды.

...Флүр Сәхбиевич төзегән объект — биек катлы таш йорт тәгълләнү алдында тора. Бу чор прораб өчен игенчегә урак өсте белән бербөтен уйлаганы, борчылганы, сулаган һавасы шул. Көнне төнгә ялгап эшли, көн озын чатыр чаба. Андый чакларда гел югары тоткан горур башы да түбән иелә кебек.

Бүген дә эшкә килеп, объектны карап чыккач һәм бригадирларны җыеп сөйләшкәч, Флүр Сәхбиевич прораб будкасыннан — үзенең эш кабинетыннан — чыкты да, башын ия төшеп, төзелешне әйләндереп алган тәбәнәк койма буйлап капкага юнәлде. Капка төбендә аны төзү идарәсенә барырга машина көтә иде. Ләкин ул, капкага якынлашкач, башын күтәрсә, гаҗәпләнүдән туктап калды: кызу-кызу атлап, каршына Гөлмира килә иде. Үзе яланбаш, чәче дулкынланып, җилдә таралыптаралып китә.

— Исәнме,— диде ул килә-килешкә һәм кинәт туктады да, егеткә сүз әйтергә ирек бирмичә, дәвам итте.— Синең белән хушлашырга килдем.

— Кая барасың?— дип сорады Флүр Сәхбиевич салкын гына.

Ул кыз әйткән сүзнең асылына төшенеп җитмәгәндәй, үзен тыныч тотты, ләкин күңеле нидер сизенде, аңгәмә вакытында нәрсәнедер хәтеренә төшерергә теләгәндәй, кашлары җыерылды, ә үзе текәлеп кызның җитди, хәтта кырыслык билгеләре чагылган йөзенә карады.

— Кияүгә чыгам. Энем хезмәтен тутырып кайтты. Теге мичман да кунакка кайткан. Мине алып китә.

Гөлмира, поезд кузгалып киткәндә соңгы сүзләрен ашыгып әйтеп бетерергә теләгән кешедәй, кызу-кызу сөйләде. Аның дулкынлануын, эчке тетрәнүен яшерергә тырышуы нык сизелә иде.

Флүр Сәхбиевич тыныч кына:

— Бәхет телим,— диде.

Ләкин ул кинәт тавышының юкка чыгуын тойды. Үз сүзен үзе ишетмәде. Тамак төбенә нидер килеп утырды сыман. Ул тагын нәрсә дә

булса әйтергә кирәген сизсә дә һәм әйтергә бик теләсә дә, хәленнән килмәде. Авыр газаптан аны кыз үзе коткарды.

— Рәхмәт. Бик ашыгасыңмы?

— Йортны тапшырабыз. Эш тыгыз чак. Ә нәрсә?

— Синең белән сөйләшәсем килгән иде.

— Сөйләшик соң...

Флүр Сәхбиевичның сүзен теләр-теләмәс кенә теш арасыннан сөзеп чыгаруын күргәч, Гөлмираның сабыры төкәнде. Ул, бәреп чыккан күз яшьләрен тыя алмыйча, томырылып егеткә карады да, өзгәләнеп:

— Их, син! — диде һәм, кырт борылып, кызу-кызу атлап китеп барды.

Флүр Сәхбиевичның тез буыннары йомшады, урыныннан кузгала алмыйча торды. Үзен күрмәгәнгә генә түзгән икән, кыз аңа шундый якын, кадерле булып тоелды ки, ул аның һәр чалымын ачык хәтерләвен, аны бик нык сагынуын аңлады. Билгеле, әгәр дә яшьрәк чагы булса, икенче төрлерәк эш иткән булыр иде. Ә хәзер, бөтен теләкләренә каршы килеп, егетнең акылы өстен чыкты һәм ул кыз артыннан торып йөгермәде, сабыр гына үз урынында басып калды. Билгеле, бу тынычлык тышкы тынычлык кына иде. Күңелендә исә давыл кубарга тора, бу — яшенле яңгыр алдыннан була торган шомлы тынлык иде.

Гөлмираның кара оек-сапожки кигән тулы балтырлы төз аяклары, нечкә билле, әле кайчан гына Флүр Сәхбиевич назлаган сылу гәүдәсе — бөтен барлыгы белән күңеленә якын һәм таныш гәүдәсе — ерагайганнан-ерагая... Ул шулай барыр-барыр да, башта Химиклар сарае янындагы наратлыкка кереп югалыр, аннан күктәге авыр, карасу болытларга ашар кебек. Һәм нинди дә булса киек казга, ялгыз торнага әйләнеп, мәңге болытлар арасыннан сөйгәнен — аны эзләп каңгырып йөрер сыман. Яисә ул бәләкәй генә бер кошка, әйтик, сабан тургаена әверелер һәм һәр язда, Флүр Сәхбиевичның эшләгән җиренә килеп, баш түбәсендә өзелеп-өзелеп сайрар, үзенең мәхәббәте турында сөйләр. Яки ул берәр болытка әйләнеп, җәйләрен, кояшлы көннәрне күз яшьләрен кояр, ә кешеләр аны ләйсән яңгыры диярләр. Барча тереклек шатланыр, сөенер, тик бер генә кеше — Флүр Сәхбиевич кына моның артык яратудан болытка ашкан Гөлмира күз яшьләре икәнен аңлар һәм шул вакыт...

— Флүр Сәхбиевич, китәбезме?

— Нәрсә? Кая китәбез? Ә, гафу ит. Әйдә.

Прораб каршында торган шофер егет бераз аптырап, аңа шикләнеп карап куйды һәм машинасына кереп утырды.

Машина, гүя әле генә кимсетелгән кыз баланы куып җитәргә һәм гафу үтенергә теләгәндәй, кинәт урыныннан кузгалды, асфальт юлга ыргылды. Ләкин Гөлмираның — рәнҗетелгән гүзәлнең зифа буе инде күренми иде.

## X

Олысы-кечесе белән бик теләп аралашучан, тапкыр сүзле Флүр Сәхбиевич, авызына су капкандай, ләм-мим дәшмичә машинада утыруын белде, ярты шәһәрне диярлек урап, төзү идарәсенә барып җиткәнче авыз ачып сүз әйтмәде.

Прорабның холкын яхшы белгән шофер егет бераз аптырый калды. Ләкин бу дәшми-тынмый баруның ни сәбәптән икәнен үз күзләре белән күрүче шаһит буларак, ул да сүз катарга җөрьәт итмәде. Кайбер түрәләр һавалырак була, үзеннән түбәннәр белән сүз куертуны кирәксенми. Ә Флүр Сәхбиевич андый түгел. Шуңа күрә шофер егет бу юлы дәш-

мәүне, прорабны борчымауны мәгъкуль күрде. Дөрес, ул сирәк-мирәк аның ягына күз салгалый иде. Кәефе күтәрелмәсме, ни дә булса әйтмәсме, дип уйлады. Чөнки беренче карашка прорабның йөзе тыныч, хәтта ваемсыз һәм гамьсез кебек иде. Ләкин аның уенда ни барын, күңелендә ниләр тулгануын шофер егет белә алмый иде шул. Чынлыкта исә...

Әйе, чынлыкта исә Флүр Сәхбиевичның йөрәге давылдай ярсый, күңеле ашкынулы, уйлары — диңгез дулкыннары кебек асты өстенә килеп кенә тора — берөзлексез агыла иде. Уйланмаслык та түгел шул. Аның күңеленә бик каты бәрелде Гөлмира. Китте, ташлап китте. Мичманга кияүгә чыга, имеш. Мичманга... Дөрес, начар партия түгел. Ләкин әле монда мин бар бит! Тукта, Флүр, төптәнрәк уйла. Син күпме йөреп тә Гөлмирага, егермесен тутырган кызлар ишетәсе килгән, бигрәк тә яраткан кешеләреннән ишетәсе килгән кадерле, көтеп алган сүзне әйтмәдең, язмышларны уртак итү, бергә булу хакында тәкъдим ясамадың. Ул аны бик көткәндер... Ә хәзер... Азмы андый очраклар: хатын-кыз, үзенең сөйгәненә ачу итеп, кемгә дә булса башка бераүгә ашык-пошык кына кияүгә чыгып куя. Әлбәттә, моңа ниндидер сәбәп этәргеч була. Әйтик, ачуланышу, үпкәләшү... Ә бу очракта синең суынуың түгел микән? Әйе, ул аны күтәрә алмаган. Чөнки бу — хаксызга рәнҗетелү. Аның бер генә гаебе бар: ул сине ярата иде. Әйе, бу хак. Ә мичман? Мичман һәм Гөлмира арасында нинди якынлык, бәйләнеш бар соң? Берни дә юк шикелле.

...Узган ел Гөлмираның моряк энесе кыска сроклы ялга кайтты. Кайтышлый ул Казанда берне генә кунып, әти-әнисе янына Улан-Удэга очты. Киткәндә ул сугылырга вагъдә итте һәм сүзендә торды. Ул көнне Гөлмира бәләкәй генә мәҗлес җыйды.

— Энем теге мичманны алырга китте, син дә кил,— дип шалтыратты ул төштән соң.

— Танышыргамы? Бик атлыгып тормыйм. Мичман да шулайдыр дип уйлыйм. Ашыгызга таракан булып та төшәсем килми. Минемчә, синең белән генә танышуны кулайрак күрер мичман.

— Флүр, юкны сөйләмә. Син бит акылсыз кеше түгел. Аны мин чакырмыйм, Азатның бергә утырасы килә.

— Белмим, карт боцман белән яшь юнга арасында нинди уртак сүз бардыр,— диде Флүр Сәхбиевич төксе генә.

Гөлмира сөйләшүнең тонын үзгәртеп, шаяруга күчте.

— Бәлки ул син уйлаганча ук карт түгелдер! Я, киләсеңме?— Ахырда кыз түзмәде, назлы тавышы белән тагын бер чакырды:— Кил, яме!

— Көт.

Бу очрашуда ни өчен өчесе дә катнашу кирәген Флүр Сәхбиевич та, Гөлмира да бик яхшы төшенәләр иде. Чөнки Флүр Сәхбиевич, Гөлмира сөйләве буенча, мичманның кызга чын-чынлап гашыйк булуын белә. Соңгы вакытта Гөлмираның энесе Азат моны ачыктан-ачык яза башлады. Флүр Сәхбиевич инде хәзер үк мичманнан көнләшә, ләкин моны кызга гына сиздермәскә тырыша. Бәлки төксе сөйләшүе эчтән януын, көнләшүен яшерергә теләүдән дә килеп чыккандыр. Ул мичман Гөлмирага чынлап торып бәйләнмәсен тагы дип тә курка. Кызның да йөрәге урынында түгел. Гөлмира шуңа күрә дә бу очрашуга Флүр Сәхбиевичның килүен тели. Әгәр сөйгәне янында икән, вәсвәсәләнергә урын калмаячак, күңеле алгысып йөдәтмәс һәм, гомумән, мичман белән ике арада сөйләшү булмаячак дип уйлый иде. Чөнки ул Флүр Сәхбиевичның үзенә әләккәнне чит-ятка бирмәүче каты куллы кеше икәнен белә. Ләкин монда әле дүртенче кеше — энесе дә барын Гөлмира уеннан чыгарган иде.

Флүр Сәхбиевич әйтелгән вакыттан ярты сәгатькә соң килде. Өстәлдә бар нәрсә әзер, музыка уйный, Азат белән мичман тәрәзә янында сөйләшеп торалар.

— Рөхсәтме? Исәнмесез.

— Рәхим итегез,— диде Гөлмираның энесе.

Флүр Сәхбиевич артыннан ук Гөлмира да кухнядан кереп җитте.

— Хәерле кич.

— Уз, уз, тартынма. Чит кеше юк, барысы да үзебезнекеләр,— диде Гөлмира балкып.— Танышыгыз.

Хәрбиләр тәрәзә каршыннан бүлмә уртасына килделәр, кул кысышып, исемнәрен әйтеп күрештеләр. Әлбәттә, бу очрашуны иң нык көткән (бәлки бөтенләй теләмәгән) һәм бер-беренә сынап караган кешеләр Флүр Сәхбиевич белән мичман иде.

Флүр Сәхбиевич башта ук шуны искәрде: мичман буйга аннан бераз кайтыш булса да, төскә-биткә чибәр, тик чигәсендә чәче генә сирәкләнгән, түбәсендә дә артык калын түгел. Базыграк гәүдәле, әмма чын ирләрчә каты куллы. Кием-салымы бик пөхтә, кара төс килешеп тора үзенә.

Шома күн пальтосын, тар читле күн эшләпәсен салып чөйгә элгән Флүр Сәхбиевичка мичман читтән генә сынап карап торды. Кара күн куртка, зәңгәр джинси кигән бу егетне мичман башта бик өнәп бетермәде: артык фырт киенгән һәм үзе дә киемнәре кебек шомадыр төсле күренде ул аңа. Кунакка гитара күтәреп килүе дә аның яшендәге кешегә бер дә килешми иде сыман. Портфеленнән ике бармагы белән чеметеп кенә әрмән коньягы чыгарып өстәлгә куюы да шаккатырырга корылган кебек тоелды. «Эффектлы жестларны шәп үзләштергән бу»,— дип уйлады мичман. Дөрес, азмы-күпме дөнья күргән кеше буларак, ул боларның тышкы кабык кына икәнен яхшы аңлый, кеше турында алдан фикер йөртеп, аңа кара мөһер сугарга һәм начар нәтиҗә чыгарырга ашыкмый иде.

— Утырыгыз, егетләр.

Хатын-кызның иң тыйнагы да җай чыкса чытлыкланырга, үзен җиңүче итеп тоярга, бик аз гына вакытка булса да үзенең өстенлеген күрсәтергә ярата. Гөлмира да шул изге, ләкин көчсез затларның берсе. Димәк, әгәр ул өстәлнең бер ягына мичман белән Флүр Сәхбиевичны утыртып,ә энесе белән үзе алар каршында икән, монда аны әллә ни гаепләп тә булмый. Гомерендә бер генә көн аның да тантана итәргә, бер генә мәртәбә Флүр Сәхбиевичны көнләштерергә хакы бардыр лабаса.

— Кара диңгездә хезмәт итүчеләр Кавказ халкының гадәтен яхшы беләдер,— диде Флүр Сәхбиевич, кулына рюмка алып.— Алар тост әйтмичә эчми. Бу гадәт безгә дә кереп бара. Беренче тост сезгә багышлана, егетләр. Илнең иминлеген, безне саклаучы батыр моряклар, аларның исәнлеге, уяулыгы өчен күтәрик!

— Минемчә, беренче тост бу күркәм табынның ягымлы хуҗасы Гөлмира өчен булырга тиеш.

Флүр Сәхбиевич мичманның бу сүзләрен үзенчә бәйгегә чакыру дип кабул итте һәм сүзен бирәсе килмичә:

— Мансур иптәш, сез — кунак,— диде.— Бездә әле кунак сыйлау гадәтен онытып бетермәгәннәр. Гөлмира, килешәсеңме?

— Әлбәттә. Сезнең исәнлеккә.

Ул аерым-аерым энесенә һәм мичманга карап алды.

Хатын-кыз синең исәнлегеңә чәркә күтәргәч, монда инде ниндидер вак сәбәп тапкан булып кәҗәләнеп тә, үгез кебек аяк терәп карышып та, юк-бардан фәлсәфә корып та булмый. Биредә бер генә юл кала — күтәреп эчеп җибәрү.

Флүр Сәхбиевичның бүресе улады — ул тантана итә. Хәзер тезген аның кулында, кая теләсә, шунда бора. Ләкин ул киң күңелле кеше. Көндәшне дә ихтирам итә, чөнки мичман көндәш кенә түгел, ә кунак та.

— Хәзер Мансур әйткән тост үз көченә керә. Гөлмира, синең алтын кулларың, якты киләчәгең, бәхетле тормышың өчен!

— Дөрес, күпчелек вакыт хатын-кыз бәхете ир-атка бәйләнгән...

«Ах, мичман, бик тешләк кеше булып чыктың син,— дип уйлады Флүр Сәхбиевич һәм егеткә карап елмайды.— Син үзеңне аңа бәхет китерәчәк кеше дип уйламыйсыңдыр бит?»

Ләкин Флүр Сәхбиевич теленә килгәнне түгел, ә хәзерге моментта нәрсә кирәк булса, шуны әйтергә өйрәнгән. Бер күнеккән гадәтеннән тайпылырга яратмый ул.

— Минемчә, безнең беребез дә Гөлмираны бәхетсез итәргә җыенмый?!

«Әһә, телеңне тешләдеңме! Кызарып чыкты егеткәй, мунча чабынамыни. Сиздек эшеңне, коярбыз тешеңне! Минем файдага бер дә ноль».

— Мин гомумән хатын-кыз турында әйткән идем.

«Аклану кирәкми, мичман, мин — прокурор, син — гаепләнүче түгел. Монда мәҗлес, җырның ертыгы юк дигәндәй, мәҗлестә сүздән гаеп эзләү килешми. Монда һәркем өчен төп шарт — шат күңелле булу».

Яшь морякның колак тырпаюлы — җил каян искәнне тиз чамалый, зиһен җитез эшли, үзе сизгер һәм ярдәмчел.

— Апа, синең исәнлеккә.

Ул рюмкасын ирененә тидереп кенә алды да, торып, Флүр Сәхбиевичның ишек катына сөяп куйган гитарасына үрелде. Аны алып килүне Гөлмира үтенгән иде.

Азатның тавышы матур гына, уйнавы — уртача. Мичман да кыстаганны көтеп тормады, гитарага кушылды.

...И все-таки море
Останется морем,
И кто-то тревожиться
Должен за нас.

Хәрбиләр тагын бер-икене җырлагач, Гөлмира кухня тирәсен урап килде, өстәлгә икенче ризык — тавык ите белән бәрәңге куйды. Аннан ул гитараны Флүр Сәхбиевичка сузды.

— Хәзер син үз һөнәреңне күрсәт.

— Олуг барда — телең тый, остаз барда — кулың, дигән картлар.

— Не прибедняйся. Уйна әйдә.

Гөлмираның күзләре бик күп нәрсә әйтергә, аңлатырга тели иде. Ул мичман белән Флүр Сәхбиевич арасындагы яшерен көрәшнең сөеклесе файдасына тәмам булуын көтә. Моның өчен кыз кулыннан килгәннең барысын да эшләячәк. Шуңа күрә ул үзенең кемне тиң итүен табындагыларга да сиздерергә телидер. Аның сөйгәне үзенә лаек. Артык булмаса әле.

Флүр Сәхбиевич Гөлмираны дөрес аңлады шикелле. Билгеле, кыз үтенеп сорагач, ялындырып тормады. Димәк, шулай кирәк. Димәк, хәзерге минутта аннан шул таләп ителә, фәкать шул гына. Димәк, Гөлмира дустының үз һөнәрен күрсәтүен тели, аның йөзгә кызыллык китермәячәгенә ышана. Аның күпшы киемле тәти егет кенә түгел, ә һәрьяклап та булдыклы кеше икәнен күрсәтәсе, моны барысына да исбат итәсе килә. Эшләр алайга киткән икән, рәхим итеп тыңлагыз... Егетнең уйнавы Гөлмираның да, Флүр Сәхбиевичның үзенең дә абруе төшәрлек булмады, ул дәртләнеп, ашкынып уйнады. Алар икесе дә канәгать калдылар.

Аннары, Флүр Сәхбиевичның тәкъдиме белән, Гөлмираны скрипкада уйнаттылар. Бераздан егетләр урамга, тәмәке пыскытырга чыктылар.

Көзге салкынча һавада, тымызык кына искән җилдә бераз торгач, башлары җиңеләеп киткәндәй булды. Һава хәленә кагылышлы, шәһәрнең матурлыгына соклanудан туган, тирә-юньдәге яңа төзелешләр турындагы әңгәмәдән соң, Азат кинәт сорап куйды.

— Флүр, сезнең машинагыз бармы?

Кинәт бирелгән бу сорауга аптырабрак калса да, Флүр Сәхбиевич яшь егетне рәнҗетмәде, апасына хөрмәт йөзеннән әңгәмәне өзмәде. Бераз гына фәлсәфәгә бирелеп алды.

— Машина — үзең теләп алган чир, җәфа ул, мәшәкатьләре күп. Әйтик, мәҗлестә рәхәтләнеп кешечә ял итә алмыйсың. Әгәр йөз грамм эчсәң, ГАИ яныннан үткәндә дер калтырап төшәсең. Аннары ул яңа чакта гына сине утыртып йөртә, бары ике-өч ел рәхәтен күрәсең, ә аннан ремонттан башың чыкмый, астында ятып чиләнәсең. Мин чутлап чыгардым: машина акчасына ун ел буе таксида йөрергә мөмкин. Көн саен түгел, әлбәттә, кирәк чакта гына утырасың. Ватылса, ташлап китәсең, икенчесенә күчәсең. Ә үз машинаң... башка бәла.

Аннары сүз чит-ят җирләр, дөнья гизүгә күчте. Мичман да дуслык визиты ясаган хәрби кораблар составында бер-ике тугандаш илгә барып кайткан икән. Аларның табигате, холкы, гореф-гадәтләре хакында матур гына итеп сөйләп бирде. Кыскасы, әңгәмә җанлы барды.

Флүр Сәхбиевич Азатның, сүзгә бик теләп кушылмаса да, һаман нидер әйтергә җыенуын сизеп торды. Һәм аның фараз итүе дөрескә чыкты. Тәмәкеләр сүнеп, сөйләшер сүз бетеп, керергә генә җыенганда, Азат яшьләргә хас тәвәккәллек белән әйтеп салды:

— Иптәш мичман, сез керә торыгыз. Ә без Флүр абый белән тагын бераз саф һава сулыйк әле.

«Ах син, мут егет, менә ничек эш йөртәсең икән! Баядан бирле әнә нәрсә сине борчып торган икән. Ярый, ярый, бу юлы исәп синең файдага булсын. Тик белмим, апаң мичман белән сайрашырга бик ашкынып тормый шикелле».

— Серләрегез бармыни? — дигән булды мичман елмаеп. Ә үзе мондый форсат чыгуга ифрат куанган иде.

«Монысы да артистланып маташа. Бар инде, бар, йөгер».

Мичман кереп китте. Аның артыннан ишек ябылу белән Азат чатнатып әйтеп салды:

— Флүр, апаны калдырыгыз сез.

— Мичмангамы?

— Әйе. Ул бик әйбәт кеше. — Аннары, Флүр Сәхбиевичның мыскыллы елмаюын күреп, әйтә куйды. — Белмим, бәлки сез дә яхшы кешедер, ләкин мин сезне белмим. Ә мичманны беләм. Ул батыр йөрәкле, апага лаек кеше.

— Сезне үлемнән коткарып калмагандыр бит? Бер романда шундыйрак ситуация укыганым бар. Сез аңа рәхмәт йөзеннән апагызны бүләк итәргә җыенасыз. Шулаймы?

— Көләсез? Әгәр аның кемлеген беләсегез килсә, сөйлим. Ул мине түгел, ә срочный хезмәттә чагында бөтен су асты көймәсен шартлаудан коткарган. Аның ике иптәше үлгән, ә мичман һәм тагын бер өлкән матрос аз гына үлми калалар. Моны для сведения әйтүем. Ә сезнең көлүегез урынсыз. Шулай булгач...

— Яхшы, алай да булсын, ди. Ә сез апагыздан сорадыгызмы соң? Аңа кем кирәген ул үзе сайларга тиеш түгел микән?

Яшь егет бу сорауга әзер түгел иде. Ул мондый сөйләшүнең ахыры булмаячагын, дөресрәге, аны бөтенләй башкаларга тиеш түгел икәнне аңлады һәм сүзне икенче темага борды. Флүр Сәхбиевичның эше турында сорашты. Ләкин болар икесе өчен дә кызыксыз иде инде. Бу — вакытны сузу гына иде. Әгәр Азатка мичман белән апасы сөйлә-



*Т. Хажиәхмәтов рәсеме.*

шер өчен вакыт кирәк булса, Флүр Сәхбиевичка исә мичман артыннан ук бүлмәгә бастырып керүе уңайсыз, хәзер алар икесе дә, уен бетәр алдыннан тупны читкә типкәләп вакытны сузган футболчылар кебек, юк-бар сүз белән мавыгырга мәҗбүр булдылар.

Бераздан алар өйгә керделәр.

— Сез кая югалдыгыз? — дип сорады Гөлмира ашыгып.

Аның бөтен уй-борчулары йөзендә чагыла. Күрәсең, мичман вакытны бушка уздырмаган, ике арада җитди сөйләшү булган, Гөлмира гүя Флүр Сәхбиевичка аны мичман белән ялгыз калдырганы өчен үпкәли дә иде шикелле.

Мичманның чырае караңгы, кәефе төшенке булудан Флүр Сәхбиевич сөйләшүнең үз файдасына бетүен аңлады. Кинәт аның күңеле күтәрелде, үзендә җиңеллек сизде. Ул кызга рәхмәт әйткән төсле яратып карады, энесенә булган ачуы да юкка чыкты, мичман да аңа бик сөйкемле, ләкин үзеннән көчсез һәм бәләкәй, әз-мәз шуклыкларын гафу итәрлек бала булып күренде. Флүр Сәхбиевич, Гөлмираның алар килеп кергәч тә биргән соравын җавапсыз калдырып, егетләрне өстәлгә дәште.

— Нишләптер суытып җибәрде, әллә җылынып алабызмы?! Ягез, моряк дуслар, кыюрак!

...Дәшми-тынмый машинада барган Флүр Сәхбиевич әлеге очрашуны энәсеннән җебенә кадәр дигәндәй исенә төшерсә дә, бер нәрсәгә тукталырга теләмәде. Ә ул бик мөһим иде. Ул — мичманның Гөлмирага гашыйк күзләре. Әйе, Мансур аңа гашыйк иде. Гөлмира скрипкада уйнаганда мичманның аңа томырылып каравын күргән һәр кеше моны ачык аңлар иде. Ә Флүр Сәхбиевич аны күрде. Ул хәтта Мәҗнүн күзләре белән Гөлмирага төбәлгән мичманны җәлләп тә куйды. Ләкин аңа карап кына кызын егеткә бирергә җыенмый иде ул. Кыз аның үзенә дә әлегә бик кирәк.

Билгеле, мичманның карашын Гөлмира да тойгандыр, чөнки моны сизмәү мөмкин түгел иде. Ләкин кыз моңа игътибар итмәскә тырыша иде. «Әйе, тырышкан иде. Тик түземе озакка җитмәгән, ахры, тегесе яңадан кайтып, үз янына чакыргач, берсүзсез ияреп киткән. Ә мин калдым. Бер ялгызым утырып калдым».

Флүр Сәхбиевич, машина кинәт туктагач, айнып киткәндәй булды, күзләрен зур ачып алга карады. Алар төзү идарәсе каршына килеп туктаганнар иде. «Ярар. Җитте». Флүр Сәхбиевич хәзер бөтен зиһенен бер төенгә туплап эшкә җикте. Чөнки бу арада аның эшләре бик җитди һәм көйсезрәк бара иде.

## XI

Гөлмира китеп барганнан соң Флүр Сәхбиевич газаплы көннәр һәм төннәр кичерә башлады.

Андый вакытта төрле кеше үзен төрлечә тота: берәүләр эчүгә сабыша, икенчеләр эшендә сүлпәнләнә. Ләкин Флүр Сәхбиевичка болар ят нәрсә. Ул, билгеле бер тәртипкә өйрәнгән кеше буларак, моңа юл куймады, җебеп-мәлҗерәеп төшмәде. Тышкы яктан аңарда әллә ни үзгәреш сизелмәде дә шикелле. Ул эчү белән артык мавыкмады, ә эшендә, киресенчә, кырысрак холыклы булып китте, таләпчәнлеге артты.

Хезмәттә ярыйсы: һәрчак кешеләр арасында, ыгы-зыгы белән көннең үткәне дә сизелми, ә өендә... ул җәфа чигә, газаплана иде. Аны ялгызлык борчый, интектерә; ул музыка тыңларга әвәсләнеп китте. Хәтта бер-ике мәртәбә астагы күршеләре кереп ризасызлык та белдерделәр. Чөнки кайвакыт магнитофон уйнаткан килеш йоклап та китколәде. Тик бу кисәтүне ул шундук онытты, аның күңелендә башка уй: егет өчен көн Гөлмира белән башлана һәм шул кыз белән тәмамлана.

Ара-тирә Флүр Сәхбиевич үзен орышып та куйгалый. Әмма берни эшләр әмәле юк — Гөлмира күз алдыннан китми. Кызның озынча нурлы йөзе, дулкын-дулкын чәчләре, шоколад төсендәге ягымлы күзләре, кигән киемнәре һәм нинди кием кисә дә килешле буй-сыны, балериналар кебек аяк башларын читкә каратыбрак атлаучы тыгыз балтырлы матур аяклары — барысы да күз алдына килә дә тора. Төннәрен ул Гөлмираның буйсынучан, кайнар тәнен төшендә күреп уянып китә... Кайчагында Гөлмира белән бергә йөргән бакчага килә, кичләрен анда берүзе озаклап каңгырып тын аллеялар буйлап атлый.

Беркөнне Флүр Сәхбиевич бакчадагы күл янында ярты сәгать чамасы уйларга бирелеп басып торды.

Флүр Сәхбиевич күл яныннан йөрәге әрнеп, бөтен күңелен ризасызлык, канәгатьсезлек биләп алган хәлдә, арып-талып китеп барды.

Шәһәр бакчаларында сентябрь ае үзенә бер төрле яме белән күңелгә якын. Әле җәй дә бетеп җитмәгән, көз дә яңа гына башланган. Ниндидер урталыктагы халәт. Түгәрәк клумбаларда, озынча түтәлләрдә әле һаман ямен җуймаган чәчәкләр үсеп утыра, агачлар берән-сәрән генә сарыга манылa, яфраклары коелып, куаклар сирәгәя башлый. Асфальт тротуарларга, чирәмсез сукмакларга, хәлсезләнгән кошлар кебек, теләр-теләмәс кенә яфраклар төшеп куна.

Каңгырап йөрүче Сәхбиевичка бакчаның матурлыгы күренми. Әнә шулай талгын гына коелган сары яфракларны да ул тыныч кына күзәтә алмый, чөнки әлеге хәлсез яфракларның берсе үзедер кебек тоела. Ул да хәлсез, аның да кемгә дә булса кирәге беткән һәм ул кешеләрне күрми, белми торган берәр җиргә китеп олагырга тиештер сыман.

Кайчак ул үз-үзенә кызганыч булып тоела башлый. Ләкин аңа үзеннән битәр шәфкать күрсәтүче, юатучы юк. Ә бит әле кайчан гына хәл киресенчә — ул ташлаган кызлар шундый хәлгә дучар булалар иде.

Флүр Сәхбиевич, караңгы уйларга бирелеп, кайчандыр Гөлмира белән янәшә атлаган сукмаклардан ары китә. Аның кайчандыр мондый тойгы кичергәне бар иде: яратып йөргән хатын-кызың кулдан-кулга китсә, күңел әрни, нигәдер аның өчен көенәсең, борчыласың, аңа карата булган ихтирамың бетмәсә дә, әкренләп кими шикелле. Аннан ул хатын-кыз онытыла, күңел чоңгылларында юкка чыга. Әгәр Гөлмира белән дә шундый хәл булса... Юк, бу Гөлмирага кагылмый шул. Ул үзенең законлы ире куенында. Монысы Флүр Сәхбиевичка икеләтә авыр, менә шул законлы ирендә булганга күрә Гөлмирадан аның күңеле кайтмый, ә аны ярату хисе арткаңнан-арта бара шикелле. Еpактагы ТЭЦның биек торбаларыннан, аның уйларыдай, кара төтен ургый. Бераздан ажгырып поезд үткәне һәм, Флүр Сәхбиевичның йөрәген әрнетеп, әче итеп тепловоз кычкыртканы ишетелде.

Кайчандыр Гөлмира белән икәү йөргән бакчаны, сукмакларны әйләнгәч, тынычлану урынына җан газабы көчәюен генә тоеп, Флүр Сәхбиевич өенә кайтып китте.

## XII

Ул, тәмам башы каткан, болай яши алмаячагын һәм ярамаганын ачык тойган хәлдә, ләкин әле ни дә булса кылырга ныклы бер карарга килә алмыйча, шыксыз фатирына кайтып керде. Чишенде, ашап-эчте, йомшак кәнәфигә утырды һәм радионы ачты. Концерт бара иде. Җыр үзенең моңы һәм сүзләре белән дә Флүр Сәхбиевичның бүгенге халә-

тенә бик тәңгәл килә иде. Җырчысы да ул яраткан кеше. Иөрәкләрне өздереп, бәгырьләрне айкап, моңы агыла.

Яшьлегемә йөгереп кайтыр идем,
Йөгереп кайта торган юл булса...

Әйе, бик күпләр яшьлегенә әйләнеп кайтыр иде, тормышын икенче төрле башлар иде, ләкин бу мөмкин эш түгел. Ә шулай да Гөлмира янына йөгереп барырга бәлки әле соң түгелдер? Ә? Нигә йөгерергә? Ул бит малай-шалай түгел. Юлдан чабарга кирәк. Утыр да кит поездга. Юлы да сикәлтәле, урман-чатырлар аша түгел, ә тап-такыр. Самолет та бар... Нигә соң әле китеп бармый? Ә кая барырга?

Башы тубалдай булды Флүр Сәхбиевичның. Йомшак келәмгә басып, коңгырт төстәге ялтыравык стенка янына килде. Бер китап алды. Уртасын ачты да укый башлады.

Наз итәр кемнәргә гөл,
Каршында былбыл булмаса?

Ачуы килеп, китапны өстәлгә ташлады, икенчесенә үрелде. Нидер эзләнгәндәй, каударланып, битләрен актарырга кереште, бер урында озаграк текәлеп торды, кычкырып укыды. «...Григорий күзен йомса да, Аксиньяның яшел кофтасы һаман күз алдында тора. Нindидер тылсымлы бер көч Григорийның башын Степаннар ындыры ягына бора». Флүр Сәхбиевич китабын куйды, күзгә каршында тукталып, үз-үзе белән сөйләшергә кереште: «Болай булмый, егет, нидер эшләргә кирәк. Я, нишлибез, тәти егет? Белмисең. Бел! Ә бәлки онытыргадыр? Дөнья киң, кызлар да буа буарлык. Тагын Гөлмира кебекләр, хәтта аннан да чибәррәкләр, назлыраклар очрамас дип куркасыңмы әллә?

Синең бит апрель аенда Казанка елгасында язгы ташу карарга чыга торган гадәтең бар. Хәтерлисеңме, боз киткәч, кайбер сай урыннарда, кечкенә утрауларда калын-калын бозлар утырып кала. Алар берничә көннән кояш җылысында эреп, юкка чыгалар, я су тиз артканда суга агып китәләр. Ә синең күңелдәге бу юшкын бетмәс, тормыш сулары — айлар, еллар аны юып алып китмәс дисеңме? Юшкын гынамы соң ул? Әгәр син моңарчы татымаган һәм, вак-вак кисәкләргә бүлеп өләшеп тә, әле һаман бетмәгән олы хис булса? Әгәр Гөлмира белән бергә син аны мәңгегә югалтсаң? Ул чагында ничек яшәргә? Белмисең. Әйдә, бергәләп уйлашыйк. Әһә, беләсең. Мин дә беләм...»

Һәм ул, ныклы бер карарга килеп, өстәл артына утырды, каләмкәгазь алды, хат яза башлады.

«Сөеклем!

Гомеремдә беренче тапкыр чын мәхәббәт шатлыгын татыган кеше бәхетсез була аламыни?! Ышанасыңмы, мин синең белән бервакытта да бәхетсез булмадым, хәзер дә, син мине калдырып киткәч тә, мин бәхетле, чөнки мин чын сөюнең, чын ләззәтнең, олы тойгыларның һәм бөек бәхетнең ни икәнен белдем. Синең белән мин үземне чынындагыга караганда югарырак, көчлерәк итеп тойдым. Мин сине беркайчан да онытмам. Син һәрвакыт минем йөрәгемдә булырсың, күңелемне тулыландырып торырсың. Шулай икән, димәк, син һәрчак, соңгы сулышыма кадәр, минем белән булырсың!»

Флүр Сәхбиевич кинәт туктады, уйга калды. Зиһене, чуалган фикерләрен җыя алмыйча азапланды. Суыткычтан башланган шешә алып, бер рюмка коньяк эчте, лимон тешләде һәм авызына сигарет кабып, ишекле-түрле йөренә башлады. Җеп очын таба алмый изаланган тегүче кебек, хатын дәвам итәргә сүзләр эзләде.

Ул урамга карады. Әче җил шыксыз-ямьсез йортлар арасында бутала, шәрә агачларны бөгә, соңгы яфракларны туздыра. Егет балконга

чыкты, бераз вакыт шунда басып торды, аннан бүлмәсенә керде, өстәл артына утырды. Кемдер ишек шакыган кебек булды. Ул сикереп торды. Барып ишек ачты. Коридорда беркем дә юк иде. Янә килеп утырды. Һәм кинәт буа ерылып киткәндәй тоелды, хисләр аны күмеп китте, алар сүзгә әйләнде.

«Сиңа нәрсә теләр идем мин, сөеклем? Фәкать бәхет кенә, тормышыңда шатлык кына, бер генә минутың да хәсрәтле узмасын, һичкайчан башыңа кайгы килмәсен. Яшә һәм бәхетле бул! Яшә һәм исеңдә тот: сине дөньяда бар нәрсәдән дә артыграк күреп яратучы кеше бар. Әгәр син шуны онытсаң, мин мәңге бәхетсез булырмын. Әгәр синең йөрәгеңдә минем турыдагы истәлек яши икән — мин бәхетле кеше.

Шатлыгым минем, карлыгачым минем! Минем белән узган көннәреңне беркайчан да кызганып искә алма!»

Болай газапланырлык булгач, нигә ташлады соң ул аны? Монысын да үзе аңлатып бетерә алмас иде. Ул шулай күбәләк кебек чәчәктән-чәчәккә кунып йөрергә күнеккән. Ел буе матур гына йөргәч, Флүр койрыкны сыртка салды. Менә шул. Әгәр егетләрчә, чын ирләрчә матур итеп, яхшылап хушлашса иде. Юк бит, юк. Салкынаюымны үзе дә аңлар әле дип, ул башта килүен сирәкләтте, шалтыратуы да айга берикегә калды. Ә бичара кыз аны ничек өзелеп көткәндер... Юк, ул вакытта Флүр боларны уйламады шул. Менә хәзер үзе каңгырып йөргәч кенә ул барысын да аңлады. Ә теге чакта тагын әллә кемнәрне табар һәм әле бик күпләрнең назында коеныр сыман иде, югыйсә. «Әйе, тәти егет, сиңа гына җитмәде инде,— дип орышты үзен Флүр.— Туймас тамак, ач бугаз. Я, хәзер нишлибез?..»
Ул Гөлмирага багышланган хатын янә дәвам итте.

«Мин җир йөзендә яшәдем һәм ни өчен икәнен белмәдем. Ә хәзер беләм: мин сине очратып, сине яратып һәм синең сөеклең булыр өчен яшәгәнмен икән. Мин шушы очрашу мизгеле өчен яшәгәнмен. Мизгел, дим. Ә аны башкача ничек атыйсың, чөнки безнең куллар бер-берен иркәләп туя алмый, иреннәребез, тагын, тагын берничә генә минут, дип пышылдый иде. Әйе, без ул минутларны озайта идек. Ә күпкәме? Кабат без аерылыша идек. Ләкин ул вакыт без яңадан очрашыр өчен аерылыша идек, без әле бик күп мәртәбәләр очрашачагыбызны, бер-беребезнең күзләренә сәгатьләр буе карап торачагыбызны белә идек. Без күп сөйләшми идек, әмма безнең карашларыбыз никадәр күп нәрсә аңлата иде: сокланубызны, мәхәббәтебезне һәм куанычыбызны. Без янә очрашырга дип аерылыша идек. Ә хәзер... Я хода, без шулай яңадан күрешмәскә дип аерылыштыкмыни?!»

Флүр йөрәк ярсуына чыдый алмыйча язды да язды. Бераз яза да ручкасын өстәлгә атып бәреп, исерек кешедәй алпан-тилпән килеп, хәле бетеп, киселгән багана кебек гөрселдәп диванга ава. Аның күзләре әчетә, колагы шаулый, сулык-сулык башына кан бәрә, күзен йомса, күз аллары әлҗе-мөлҗе килә иде. Көне буе авыр физик эш эшләгәндәй бөтен тәне ватылган, арыган... Ул тиз генә йоклап китә алмады, уйланып ятты. Йокыга киткәч, озак та үтмәде, куркыныч төшләр күреп, саташып-бастырылып, шабыр тиргә батып уянды. Ул төш күрде. Гөлмира болында, чәчәкләр арасында, имеш. Флүр Сәхбиевич аңа таба йөгерә башлый. Кинәт җир ярыла һәм ул аска төшеп китә. Төшә, төшә... Ә үзе берөзлексез кычкыра: «Гөлмира! Гөлмира!» Бераздан җир әкрен генә кушыла һәм аны, бөтен тәнен шытырдатып, кыса башлый. Флүр Сәхбиевичка Гөлмираны яңадан күрмәс кебек тоела. Ул җан ачысы белән кычкырып җибәрә: «Гөлмира-а!» һәм, үз тавышыннан куркып, шабыр тиргә батып уянып китә. Үзе еш-еш сулый...
Ул фәкать таң беленә башлагач кына, тигез сулап, йокыга талды.

## XIII

Флүр Сәхбиевич гомерендә беренче мәртәбә сәгать сигездә уянды һәм беренче тапкыр эшкә соңга калды. Беренче тапкыр... Соңгы вакытта мондый беренче тапкырлар аның тормышында еш кабатлана башлады шикелле. Ул беренче мәртәбә чын-чынлап гашыйк булды... Әллә элегрәк тә булды микән? Һәрхәлдә, кисәк кенә хәтерли алмады Флүр Сәхбиевич. Аның өчен бөтен тормыш дәрьясын кабат кичәргә, утыз еллык гомерен күз алдыннан үткәзергә кирәктер. Бәлки гашыйк булуы да беренче мәртәбә генә түгелдер. Төгәл әйтүе кыен.

Берәр хатәр хәлгә юлыкса, кеше үзенең үткәнендә актарынучан була бит, елъязмаларын хәтер җебеннән үткәрә. Чокчына торгач, шунда ул үзенең кемлеген күрә, битендәге пәрдәсе ертылып, аның чын йөзе ачыла, теге яки бу очракларда кылган гамәлләрен, үзенең дөньяга килеп ни эшләр майтарганын исенә төшерә.

...Флүр Сәхбиевич авылда туып үсте. Авыл малае укырга кергәнче нишли? Табигать кочагында үсә — болында, урманда йөри, су коена, үз ишләре белән сугыша-кыйнаша, чана-чаңгы шуа, җәен-кышын уеннан туймый. Флүр дә шулай үсте. Ул заманда әле шәмәйле уйнау гадәте бар иде. Елга буендагы биек яр кардан арчылуга, анда малай-шалай хуҗа булып ала да шәмәйле уйнарга тотына. Шәмәйләрне җиргә тезеп куялар да, берничә адым читкә китеп, тимер аткыйлар белән чәки башлыйлар. Берәрсе хәрәмләшсә, я аягына аткый тисә, якалашу китә. Флүрнең үзенең дә, иптәш малайларының да бияләй эченә тыккан аткый белән бәреп, башлары бер генә тишелмәгәндер, аякларына уч төбе кадәр тимер бер генә бәрелмәгәндер. Аңа гына түзә авыл малае. Ләкин шул чордан Флүр төннәрен сискәнеп-куркып уяна, саташа торган булып калды. Чөнки ул бер малайның башын тишкәч, тегенең абыйсы аны дулап куып китте. Флүр өенә качып котылды, ләкин төне буе саташып чыкты. Икенче вакыт ул шәрә килеш көне буе кычыткан арасында ятты. Монысы су коенганда башланган чәкәләшүнең азагы иде. Шушы хәлләрдән соң Флүрнең саташуы еш кабатлана торган булды...

Флүрнең әтисе колхоз председателе, әнисе укытучы иде. Шуңа күрә әллә ни кытлык-мохтаҗлык күрмичә, михнәтнең ни икәнен белмичә үсте ул, үзен белә белгәннән бирле аның тамагы тук, өсте бөтен булды. Кечкенәдән үк сәламәтлеге яхшы, укуы да әйбәт иде. Ул табигый сәләтенә ышанып, артык зур тырышлык куймыйча гына яхшы билгеләр белән унны бетерде. Җәмәгать эшләрендә булсын, үзешчән сәнгатьтә булсын — бик теләп катнашты, активлар рәтендә йөрде, алдынгылардан саналды, җыелышларда макталды. Үз-үзенә артык ышану, гел беренче булу — аның канына сеңде. Һәм бу гомер буе шулай дәвам итәр төсле иде.

Флүр документларын төзүче-инженерлар институтына җибәрде, зур авырлык белән студент булу бәхетенә иреште. Авылда ул үзен гадәттән тыш шәхес дип, күпне белүче, теләсә нинди эшләр башкарырга көчкуәте җитәрдәй кеше дип йөри иде. Ә менә имтихан биргәндә хыялында төзегән бина көчкә җимерелмичә калды. Егет үзенең гади һәм гадәти кеше икәнен күрде. Укуының исә беренче көненнән үк ул үзенең икенче дөньяга килеп эләгүен, ирегә, теләкләре һәм мөмкинлекләре чикләнүен танырга мәҗбүр булды. Ул үзен староста яки комсорг итеп сайларлар, баш-аягы белән тагын җәмәгать эшләренә чумар, бүтәннәрдән бер карыш өстен торыр дип өметләнгән иде. Ләкин ялгышты. Аны хәтта стена газетасы редколлегиясенә член итеп тә сайламадылар.

Беренче айларны егеткә уку да авыр бирелде. Моңа кадәрге гомерен татар авылында үткәргән, әллә нидә бер генә якын-тирәдәге бәләкәй шәһәрләргә барып кайткалаган егетнең тел белмәве юлында би-

ек киртәдәй калкып чыкты. Студентларның күбесе шәһәрдән булып, Флүрдән күп алга киткән егетләр, аңа караганда өстен, эрудицияләре зур. Флүр хәтта исемен дә ишетмәгән китапларны алар әллә кайчан укып онытканнар икән. Ә кызлары... Тик тормаган аякта бәла бар дигәндәй, ике атна укып, ниндидер бер кичәдән соң Флүр озатырга теләгән кыз аны якын да җибәрмәде. Ул егетнең килеш-килбәтенә, киемнәренә кырын күз белән генә карап, мыскыллы елмайды да:

— Син мине озатмакчы буласыңмы? — дип сорады.

— Әйе.

— Ә таксида алып кайтырга акчаң бармы? Дәшмисең. Димәк, юк. Ә үзең кызлар озатмакчы... Син авылда беренче егет булгансыңдыр, шәт, ә авылыгыз — бер йорттыр. Әйеме? Ха-ха-ха!

Флүр урам уртасында басып калды, ә кыз артларын уйнатып китеп барды. Гарьлегеннән ни чара кылырга белмичә егет бик озак урам ташларын таптады. Аның горур йөрәгендә тәкәббер шәһәр кызларына карата мәңге бетмәстәй үч уты дөрли иде.

Аннан соң да Флүр белән бик күп хәлләр булды. Бер кичне, юктан гына бәйләнеп, ниндидер үсмерләр үзен канга батырып тәпәләп ташладылар. Шуннан соң Флүр, аны барысы да хөрмәт итсен өчен нишләргә кирәген уйлап, төрле планнар корып баш ватты. Моның өчен тормышның җаен аңларга, көчле булырга кирәк шикелле тоелды аңа. Күбесенә ул үз башы белән иреште, белмәгәнен дусларыннан сорады. Һәм шундый нәтиҗәгә килде: тормышта барысын да үз җилкәсе белән күтәрергә, ягъни, тормыш бинасының һәр ташын үзе табып, үзе төзәргә, булыр-булмас ярдәмне читтән көтмәскә, һәр нәрсәне үзенә табарга, иң мөһиме, тырышып укырга, әти-әнисенә бәйле булмас өчен төнге эшкә керергә, хезмәт семестрында, күбрәк акча төшәрдәй урын булса, җәһәннәм читенә китеп олагырга, ә кышын берәр спорт секциясенә язылырга. Әлбәттә, соңгысы аның тормышта үзалдына куйган максаты түгел. Бу — юл уңаенда, узып барышлый гына эшләнәчәк.

Егет барлык уйларын тормышка ашырды. Соңгы этапта хәтта чак кына арттырып та җибәрде, ахры. Чөнки беркөнне тренеры аны тырышлыгы өчен мактады һәм:

— Сиңа зур өметләр баглыйм,— диде.— Синнән яхшы боксер чыгачак, физик көчеңне тагын да арттыра төш.

Ләкин Флүргә дөнья чемпионы булу кирәк түгел, күпме көчәнсә дә, ул аңа ирешә алмаячагын яхшы аңлады. Чөнки моның өчен шәһәрдә туып, шәһәрдә үсәргә, бик кечкенәдән үк спорт белән шөгыльләнергә, аның серләренә төшенергә кирәк иде. Флүргә исә икенче разряд тирәсендә сикергәләсә, бәйләнгән үсмерләргә тешләрен учларына тоттырып җибәрерлек булса, шул бик җиткән. Дөрес, бергә-бер булса, ул хәзер дә кемгәдер баш бирерлек түгел. Ләкин шәһәр малайлары беркайчан да ялгыз гына килеп ябышмыйлар шул.

Флүр монысына да ирешә һәм дүртенче курста чакта бер кызны озата барганда килеп бәйләнгән өч егетне юлга аркылы-торкылы өеп калдырды. Бу хәл кызлар теленнән өч ай төшмәде.

Шуның өстенә Флүр гитарада уйнарга өйрәнде. Ярты ел буе вакытын жәлләмичә, түләүле дәресләргә йөрде. Ул моңа бары тик кызларга ошар өчен генә язылды. Походларда шәһәр егетләре учак янында гитара чиерткәндә ул бик кимсенеп утыра иде. Моннан ары Флүр дә кеше кыланганны кыланачак, гитара кылларын чиртәчәк. Ә гитараның җаен белгән егет, билгеле, кызларның күңел кылына да ачкычны тиз табар...

Институтны тәмамлаганда ул факультетта иң асыл егетләрнең берсе иде. Аның үсәргә омтылуы, тырышлыгы, үз-үзенә катгый таләпчәнлеге бушка китмәде. Буй-сын килгән, өс-баш заманча, перспектива әйбәт.

Аны Казандагы төзелеш трестларының берсенә билгеләделәр. Ул эшнең җаена тиз төшенде, икенче елны ук мастердан прораб булып күтәрелде. Тагын ике-өч елдан участок башлыгы булу ихтималы да юк түгел иде. Ләкин бер елдан Флүр Сәхбиевич чит илгә командировкага китте. Ят җирләрдә экзотика эзләп, дөнья күрәсе килгәннән китмәде ул. Бу хәл болай булды.

Бервакыт аны үзенең начальнигы — өлкән прораб өенә чакырды. Флүр Сәхбиевич шаккатты. Ул җиһаз, кием-салым дисеңме — барысы да затлыдан. Участок башлыгы чит илдә эшләп кайткан икән.

— Бөтен әйберне сертификатка алдым. Ә монда җыелган процентлар запас тора,— диде ул, кунакның соклануын күреп, һәм өстәп куйды: — Яшь чагында әйләнеп кайт. Хәзерге заманда машина да кирәк нәрсә...

Кайтып барганда Флүр Сәхбиевичның башына уй килде: «Җай чыкса, миңа да шул тарафларга юл тотарга кирәк». Дөрес, ул машина, мебель, келәм-палас дип хыялланмады, аны кием кызыксындыра иде. «Шәһәр җирендә кешене ни бизи? Кием. Агач күрке — яфрак, адәм күрке — чүпрәк. Бу бигрәк тә безгә, егет-җиләнгә кагыла».

Бөтен юлларын белеште Флүр Сәхбиевич һәм озакламый теләгенә иреште. Әйткән сүзендә дә торды: сертификатын бары киемгә генә тотты, ел саен Мәскәүгә барып, «Березка» магазинында киенеп кайта торган булды.

Мәскәүгә барып киенеп кайтуны ул шаяртып, елан кебек кабык алыштыру, дип атый. Чөнки искерәк кием киенеп бара да, магазиннан чыккач, берәр аулак урында, я агачлар арасына, я чокырга искеләрен ташлап калдыра иде.

Менә шулай итеп ул фәкать үзенең өлгерлеге, ифрат эшчәнлеге аркасында бүгенге көндә әзме-күпме дәрәҗәгә иреште, үзен заманга лаек, аягында нык торучы кеше итеп сизде.

Эш дәверендә Флүр Сәхбиевич тагын бер нәрсәне яхшы төшенде. Идарәдә белемле, перспективалы инженерлардан саналса да, бу урыннан китәргә аңа әле иртәрәк иде. Берәүләр үз өстенә җаваплылык аласы килмичә зуррак урынга утырудан курка, бигрәк тә хезмәт хакында әллә ни аерма булмаса да. Флүр Сәхбиевич исә икенче төрлерәк фикер йөртте. Прораб булып тагын берничә ел эшләсә, ул пенсиягә алданрак чыгачак. Дөрес, бу турыда уйларга әле иртәрәк, ләкин гомер үтә бит... Шуңа күрә Флүр Сәхбиевич әлегә югарырак урыннарга кызыкмады. Өлгерер, барысына да өлгерер. Иң әһәмиятлесе — шушы йөкне авырыксынмыйча тартырга, баш-күзеңне тондырып чапмаска, җай гына алып барырга, тупланган абруйны төшермәскә. Кем белә, бәлки тагын берникадәр вакыттан соң ул участок дилбегәсенә тотынмас та, аны читләтеп үтәр һәм туп-туры я техник бүлек башлыгы булыр, я баш инженер креслосына утырыр. Чөнки аның тәҗрибәсе җитәрлек: участок башлыгы ялга китсә, ул гел аның урынына кала, эше майлагандай шома бара, гөрләп тора. Моны барысы да беләләр, күрәләр. Ул тресттагыларның да үзе турында әйбәт фикердә торуларын ишеткәли.

Кыскасы, Флүр Сәхбиевичның тормышы моңарчы борып куелган сәгать кебек көйле барды. Кыз-кыркын, яшь хатыннар аның кулыннан күп үтте. Теге вакытта борынын җыерып, аңа мыскыллы караш «бүләк иткән» чибәрне дә ул бермәлне кулына төшерде. Флүр Сәхбиевичның бу вакытта таксига түләрлек кенә акчасы бар иде инде, һәм ул шулай итте дә, бер квартал кайтасы юлга да такси яллады. Машинаның ишеген каерып ачып, урам яңгыратып әйтеп салды:

— Рәхим итегез, ханым, карета әзер. Ул сезне бик озак көтте.

Ә бичара чибәркәй бу ачы юморны аңламады, ул күп нәрсәне оныткан иде. Флүр Сәхбиевич кына яхшы хәтерле кеше булып чыкты.

Флүр Сәхбиевич авыл белән арасын өзмәде, туганнары килсә, кунак итте, үзе дә ике-өч елга бер кайткалады. Әтисе моннан биш ел элек дөнья куйды, әнисе бер бәләкәй шәһәрдәге кызында, ягъни Флүр Сәхбиевичның бертуган апасы тәрбиясендә. Шулай итеп хәзер авылга кайтуның да хаҗәте калмады. Ә әнисен үз карамагына алырга ул бик ашыкмады.

Кайбер кешеләр ялгызлыктан интегүе хакында зарланса, Флүр Сәхбиевич көлә иде. Моңарчы аның үз янында кемнедер даими тоеп яшәргә мохтаҗлыгы булмады. Аңа иреге кадерлерәк иде. Әйе, моңарчы. Тик менә соңгы вакытта гына аның көйләнеп куелган яшәү механизмында бер шөреп бушады, кайсыдыр пружинасы ычкынды. Аны нинди генә оста да хәзер үз урынына беркетеп куя алмый иде инде. «Нишләргә? — Менә шул сорау аның каршына килеп басты.— Нишләргә? Хәзер ничек яшәргә?»

Ул Гөлмирага язган хатын кат-кат укыды. Әгәр беркөнне ул хат аңа мәгънәсез сүзләр тезмәсе булып күренсә, икенче көнне ул иң каты бәгырьле кешене дә эретерлек, әйтеп бирергә мөмкин булганның барысын да үз эченә сыйдырган язма — эч сереңне бушату булып тоела һәм аның күңелендә ул хатны тизрәк Гөлмирага ирештерү теләге туа. Ләкин кая җибәрәсең? Авылга — бабайгамы? Гөлмира яшәгән йортка барып сораштырсаң, бәлки адресын белүче табылыр иде; әле хезмәт урыны да бар бит. Ләкин бу — Флүр Сәхбиевич өчен түбәнлек.

Шулай аңлы-миңле йөреп, бер ай узды. Бер көнне Флүр Сәхбиевич, Казанда сезон ябылуын, бүген соңгы уен икәнен белгәч, футбол карарга барды. Аннан трамвайга утырып кайтты. Ләкин уйланып кайта торгач, үз тукталышын узып китте. Ә икенчесендә төшәргә җыенгач, нигәдер аны китәргә һәм Гөлмира яшәгән йортка күз салып кына булса да узарга ниятләде. Шул ук трамвайдан төшмичә, кире әйләнеп кайтырга иде исәбе.

Менә трамвай, тукталышларны саный-саный, пар рельстан шуыша. Соцгородта трамвай кисәк уңга борылды. Ялтырап яткан рельслар күренде. Алар Флүр Сәхбиевичка бумерангны хәтерләтте. Китәсең дә шул ук юлдан әйләнеп кайтасың... Хәер, трамвай рельслары гына түгел, поезд юллары һәм асфальт борылмалары да бумерангка охшаган. Китәсең дә кире кайтасың... әгәр берәрсе сине озатып калса һәм кайтуыңны бик зарыгып көтсә.

Трамвай китеп барды. Флүр Сәхбиевичның йөрәге исә тибүдән туктагандай булды. Чөнки Гөлмира яшәгән бүлмәдә ут яна, кеше шәүләсе чагыла иде. Әйе, кемдер бар иде бүлмәдә. Егет Гөлмира тәрәзәсенә күз салып, йорт каршыннан үтте. Кинәт Флүр Сәхбиевич адымын туктатты. Бүлмәдә Азат йөренә иде. Аның кулында китап: нидер укыймы, ятлыймы. Сөйгән ярын юксынып тилмергән гашыйкның башына килгән беренче уй шул булды: «Әллә Гөлмира да кайтканмы?»

Флүр Сәхбиевич, Азат үземне күрмәгәе тагы дип, тизрәк китеп барды. Берничә адым атлагач, кире килде һәм янадан туктап торды. Тельняшкасының җиңнәрен сызганып куйган егет чыннан да Азат иде. Азат хуҗаларча нык атлап йөри. Бик бирелеп укый. Хәтта тәрәзә пәрдәсен тартып куярга да оныткан. Димәк, ул монда кайткан булып чыга түгелме соң? Әйе, шулайдыр. Нишләп Гөлмира шушы фатирларга кытлык заманда үз бүлмәсен чит-ятка калдырып китсен. Анысына гына башы җиткәндер. Димәк, әле бар нәрсә дә югалмаган. Азат, ни әйтсәң дә, күргән-белгән кеше...

Флүр Сәхбиевич трамвай тукталышына юнәлде. Бу юлы да трамвайдан чыгардай булып, әлеге кадерле тәрәзәне карап китте. Аның күңелен сөенеч биләп алды, әйтерсең ул Гөлмираны очратты. Юк, хатны ертмас ул хәзер, ничек тә Гөлмирага җибәрер.

Иртәгесен кичкырын Флүр Сәхбиевич әлеге изге җиргә, аңа күп наз биргән, аны күп мәртәбәләр бәхетле иткән йортка килде.

Барып җитәрәк аны, бизгәк тоткандай, ниндидер курку-каушау биләп алды. Ул калтыранган кулын пальто кесәсенә яшерде. Өй янына җитәрәк хәтта туктап калды. «Азат мине аңлармы? Мыскыл итеп куып чыгармасмы? Болай түбәнсенү, аның алдында мескенләнү кирәкме, мәсхәрәгә калмаммы? Бәлки Гөлмираның адресын бөтенләй сорамаска, болай гына, юл уңаеннан гына, хәл белергә генә кердем дияргәдер? Ярый, ни булса — шул. Тәвәккәллә, егет. Ә ничек инде адрес сорамыйча чыгып китәсең? Бәлки бераз салгач, этләшеп тормас, бирер. Бар, кер, егет, нык бул!»

Азат Флүр Сәхбиевичны колач җәеп каршы алмады, әллә ни гаҗәпләнмәде дә. Ул башта: «Егет салмыш килеш иске юлны таптап кергәндер, апаның киткәнен оныткандыр»,— дип уйлады. Ләкин егетнең аек икәнен күргәч, сагая төште. Урын тәкъдим итте.

— Утырыгыз.

— Рәхмәт. Нәрсә, хезмәтне тутырып кайттыкмы?

— Әйе.

— Әллә Казанда төпләнергә исәп?

— Күрәсез.

— Эш ягы ничек соң? Ярдәм кирәкмиме? Югыйсә...

— Заводка урнаштым. Юл аркылы гына.

— Яхшы булган.

Флүр Сәхбиевич пальто изүен ычкындырып җибәрде. Моны Азатның өнәмәвен күреп, кире төймәләмәкче иде дә, ул уеннан баш тартты.

Флүр Сәхбиевич Азатның йөзенә текәлеп карады. Егет олыгая төшкәнме, әллә мыегы шулай күрсәтәме, ул үзгәргән сыман. Ә бүлмәдә берниндә үзгәреш юк. Бар да искечә, нәкъ Гөлмира яшәгәнчә. Һәр нәрсә үз урынында: стенага эленгән скрипка да, озын борынлы кечкенә Буратино да, матрос һәм бөркет сыннары да... Тик Гөлмира гына юк. Шулай да Флүр Сәхбиевич күңеленә бер тиле уй килә: менә хәзер елмаеп, моңарчы кухняда кайнашкан Гөлмира килеп керер. Һәм Флүр Сәхбиевич аның газиз, нурлы йөзен, балериналарныкына тартым нәфис аякларын күрер...

— Әшегез ничек бара?

— Әйбәт. Рәхмәт. Сиңа берәр институтка әзерләнергә кирәктер инде.

— Әйе, менә китап кулда бит.

— Вакытны бушка уздырмыйсың. Молодец. Ничек уйлыйсың, синең кайту хөрмәтенә әллә берәр йөз грамм тотып куйыйкмы?

«Я хода, мин дә бу кадәр мескенлеккә төшәрмен икән,— дип үз-үзен орышты Флүр Сәхбиевич.— Элек мин, бу егет мичманны алып килгән чакта, болай сөйләшә идемме? Нишлисең, туры килә. Иелгән башны кылыч кисми, дип юанырга, еландай боргаланырга, юхаланырга гына кала».

— Минем алып куйган юк. Бик шаярмыйм да...

Флүр Сәхбиевич ашыгып кесәсенә, баядан бирле бимазалап торган шешәгә үрелде.

— Юл уңаенда мин бер ак башлы малайны ияртә килгән идем. Әгәр каршы булмасаң...

— Ихтыярыгыз.

Азат теләр-теләмәс кенә рюмкалар чыгарды, кабарга әзерләде.

Чакырылмаган кунак күн пальтосын салып элде, утырып аракы бүлде. Ул рюмкасын кулына тотуга, Азат мәкерле елмаеп:

— Кавказ гадәте буенча тост әйтәсезме?— дип сорады.

— Кирәк инде. Сезнең исән-сау кайту хөрмәтенә.

Шулай төчеләнүе Флүр Сәхбиевичның үзенә дә охшамады. «Шушының алдында тәлинкә тотып утыр инде, адәм тәганәсе».

Эчтеләр. Капкалап алдылар. Азат дәшми. Флүр Сәхбиевич та сүзне нидән башларга белми. Ахырда моряк егет, аңа туп-туры карап, тагын зәһәр елмайды.

— Сезнең ни өчен килүегезне әйтимме?

— Тырышып кара.

— Сезгә апа кирәк.

— Адресы.

— Әлегә адресы гына, билгеле.

— Дөрес.

— Юк, бирмим мин аны сезгә. Комачауламагыз. Алар — бәхетле.

— Мин аның бәхетен җимерергә җыенмыйм. Мин...

— Ялынмагыз. Барыбер бирмим. Әйе, сезнең бөтенесе дә алдан әзерләнгән, уйланылган. Аракы эчкәч егет юмартланыр, ни сорасам да отказ бирмәс, дип уйлагансыздыр. Бигрәк тә сезнекен эчкәч... Алай да бирмәсәм?

— Шаярма, Азат. Без бит ирләр. Син мине аңларга тиеш.

— Әгәр барыбер бирмәсәм? Иртәгә әрмән коньягы алып килегез дисәм?

Флүр Сәхбиевич егеткә карап, түзеп-түзеп утырды да, бөтен ачуы — монда килергә мәҗбүр булуы, ялынып утыру — барысы да бергә җыелды, тышка бәреп чыкты һәм ул каршында утырган Азатны кулыннан эләктереп алды.

— Мальчишка! Мин сиңа ирләрчә, изге ният белән килдем. Апаңны ятратканга, аннан башка яши алмаганга шулай түбәнсенәм! Әгәр миңа бирергә теләмәсең, апаң хакына бир! Ул да мине ярата!

— Сез аны каян беләсез?

— Беләм!

— Ул сезне онытткандыр...

— Юк, синең апаң алай ук хәтерсез түгел. Ул — алтын кеше! Әгәр ул яратса, ике генә көнгә дип яратмый. Яшьли сөйгән егетен ул минем белән йөргәндә дә искә ала иде. Мин аннан көнләшми идем, чөнки апаң бу вакытта инде мине ярата башлаган иде.

— Мин андый сүзне тыңларга хурланыр идем.

— Ә мин — юк. Чөнки мин үзем дә аны яраттым. Йөргән хатын-кызлар арасында иң кадерлесе — ул.

— Апа хәзер мичман хатыны. Аны да ярата...

— Юк, ул аңа миңа ачу итеп кенә чыкты. Ул мине генә ярата! Азат, егет бул, бир апаңның адресын!

Ни хикмәттер, Азат торып апасыннан килгән хатның конвертын Флүр Сәхбиевичка сузды.

— Бирәм. Ләкин намуслы эш итсәң генә... Чөнки мин һаман да мичман яклы. Мин аны күбрәк беләм, ә сезне бик аз һәм... артыгын белергә теләгем дә юк. Хушыгыз.

Флүр Сәхбиевич юлда конвертны кулыннан төшермәде, Гөлмираның язуын танып, үзен күргәндәй булды, подъезд төбендә яшереп кенә конвертны үбеп алды... Әйтерсең лә бу конверт гадәти кәгазь кисәге түгел, ә Гөлмираның йомшак, назлы куллары иде.

## XIV

Флүр Сәхбиевич хатны иртүк почта әрҗәсенә илтеп салды. Аннан егет сәгатенә күз төшерде. Кайчанрак алырлар икән дә, кайчанрак озатырлар, янәсе. Дөрес, анда зәңгәргә ак белән, хатлар көненә өч тапкыр алына, дип язылган иде. Ярый ла онытмасалар.

Ул, беренче баласы туган эти кеше кебек, кая басканын да белмичә, шатлыклы тойгы кичереп йөрде, хыялында Гөлмираны күрде. Менә бернинчә көннән аңа барып ирешкән хатны Гөлмира почта тартмасыннан сак кына ала һәм... аптырап китә. Юк, ул сөенә! Әйе, әйе, шатлыктан йөзе яктырып китә, сабый баладай кулларын чәбәкләп куя, ярышта кадерле бүләк алган спортчыдай, аны күкрәгенә кыса. Юк, алай гына да түгел. Флүр Сәхбиевич аермачык күрә: Гөлмира куанычыннан кычкырып җибәрә, йөзендә нур, күзендә шатлык яшьләре... Ул атылып өенә керә, хатны укып чыга һәм шундук сөйгәненә җавап язарга утыра...

Ләкин Флүр Сәхбиевич төшенке уйларга да бирелә. Я аның хаты мичман кулына эләгер, дип фараз кыла, я Гөлмира бу хатка бер дә шатланмас, дип уйлый. Алай итсә дә гаҗәп түгел. Чөнки Флүр Сәхбиевич үзе гаепле. Нигә? Моны егет бары үзе генә белә. Һәм берәмберәм Гөлмира белән йөргән чактагы эпизодлар исенә төшә, күз алдына килә.

Флүр Сәхбиевич Гөлмираны кайвакытларда икеләнү-шикләнүләр биләп алганын сизә иде. Сизү генә түгел, ул моны күрә иде. Менә Гөлмира аның белән бер җан, бер тән булып яши. Егетне белә дә кебек. Ләкин ул моны чит кешегә түгел, үзенә дә икърар итә алмый, чөнки егетнең рухын ахырынача аңлап бетерә алганы юк. Ә моны исә Флүр Сәхбиевич юри шулай эшли иде. Ул Гөлмираны ишеге ачык, ләкин ишек турысына пәрдә эленгән бүлмә каршында тота шикелле. Ләкин кайбер сөйләшүләрдә, үз-үзен тотышында сирәк-мирәк Флүр Сәхбиевич үзенең чын йөзе ачылып китүне дә күрергә, танырга мәҗбүр иде.

Бервакыт, опера театрына баргач, Флүр Сәхбиевич институттагы сабакташын очратты. Алар бик җылы күрештеләр, мондый очракларда бирелә торган гадәти сораулар китте.

— Сине нинди җилләр ташлады?

— БАМнан. Ялга. Ә син Казандамы?

— Әйе.

— Әйдә минем белән.

— Рәхмәт.

— Хәер, гаилә ишле, җыйналып-төйнәлеп китүе, кузгалуы авырдыр.

— Юк, мин ялгызак.

— Кит аннан! Шушы яшькә кадәр... Мин сине инде өч бала атасыдыр дип уйлаган идем.

— Өлгерербез. Руслар әйтмешли, дурное дело — не хитрое.

— Алай димә. Минем урыннан-урынга күчеп йөреп тә ике бала! Олы кызым быел укырга керде, кечесенә — өч яшь. Алар белән бик күңелле. Эштән шуларны сагынып кайтасың, шулар өчен дип тырышасың, дөнья көтәсең...

Сабакташы бик озак балалары турында сөйләде. Аларның нинди гадәтләре барын, нинди уен уйнаулары, хәтта кигән киемнәренә кадәр тасвирлап бирде. Өч көн күрмичә торса, өзелеп сагынуын әйтте.

Сабакташ белән аерылышкач, Флүр Сәхбиевич:

— Тинтәк, тапкан мактаныр нәрсә,— диде.— Әллә шул балаларыннан рәхәт күрермен ди микән картаймыш көнендә?!

Әйе, шулайрак ычкындырган иде Гөлмирага. Ул кызның дәшмәвеннән, егетнең бу сүзләрен, бала шатлыгы кичерүче, аларны уйлап сөенүче ата кешедән көлүен хупламавын да сизгән иде.

Ә икенче юлы, якшәмбе көн — тулы мәгънәсендә ял иткән сирәк көннәренең берсе иде. Алар шугалакка бардылар. Анда ике хәл булды. Катокта юлга аркылы килеп, аларга бәрелгән бер малайның башына сукты Флүр Сәхбиевич.

— Күзең чыкканмы әллә?!

Гөлмира моны күреп шаккатты. Флүр Сәхбиевичның беренче очрашкач та, бакчада йөргәндә әйткән сүзләре исенә төште. Димәк, ул кыланган. Кыз егетне шелтәләмичә түзә алмады. Үзенең ризасызлыгын белдерде.

— Ничек син балага кул күтәрә аласың?

— Йөрмәсен буталып.

— Барыбер. Бала яраткан кеше алай итә алмый.

— Ә кем әйтте мине бала ярата дип?

— Үзең. Бервакыт, бакчада. Хәтерлисеңме? Бер хатын бала арбасы этеп бара иде. Янында, ире, аның кулында транзистор да бар иде. Алар яныннан үткәндә син арбага күз салдың һәм берничә адым киткәч: «Баласы матур. Яратам да соң нәниләрне!» — дидең.

Флүр Сәхбиевичның кылт итеп исенә төште ул көн һәм ул чагында әйткән сүзләре. Ләкин хәленең җитдиләшүеннән куркып, сүзне уенга борды.

— Булмас. Мин, әниләре яшь атасыз балаларны яратам, дип әйткәнмендер.

Гөлмира моңа ышанырга да, ышанмаска да белмичә аптырашта калды. Үзенең абайламыйчарак ычкындырып җибәрүен сизгән Флүр Сәхбиевич, судан коры чыкмакчы булып, сүзне шундук икенче темага борды. Ләкин чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, шушы ук көнне Флүр Сәхбиевич тагын бер хата җибәрде. Катокта ул бер чибәр кыз күрде. Кыз, күрәсең, фигуристка иде. Аның бөтерчек кебек бөтерелүе, аягы бозга да тимәгәндәй җиңел шууы, сылу гәүдәсе — болар барысы да Флүр Сәхбиевичның күз алдында торды, атналар буе уеннан китмәде, онытылмас бер төш кебек күңеленә сеңеп калды. Унҗиде-унсигез яшьлек бу кызның салкыннан алсуланып торган битләре, дугайланып килгән нечкә кара кашлары һәм чиядәй иреннәре дә — барысы да гаҗәеп гүзәл, хәтта аның чәчләренә дә ниндидер сихри матурлык яшеренгән төсле иде. Ул чакта Флүр Сәхбиевич үзе Гөлмира белән шуа, сөйләшә, көлә-шаяра, ә күзләре һаман әлеге сылу ягына карый, башы ирексездән шул якка борыла иде. Моны Гөлмира да сизде, ләкин бер сүз дә әйтмәде. Шунда ул егетнең үзенә өйләнмәячәгенә тагын бер кат инанды.

Менә хәзер, шул хәлләрне зиһенендә барлап, искә төшереп чыккач, Флүр Сәхбиевич уйланырга мәҗбүр. «Кызлар күрмәгән егетме мин? Ә шулай да түзә алмадым, сабырлыгым җитмәде. Шайтан алгыры, бигрәк чибәр иде шул кызы, һушны алырлык иде. Эх!.. Әйе, Гөлмира сизенгәндер, минем аңа өйләнергә җыенмавымны аңлагандыр. Ишек төбендә генә урын барда түргә үтмә, дия иде әни. Ә мин һаман түргә омтылдым... Бу кечкенә вакыйгалар эзсез үтмәгәндер, Гөлмираның күңеленә авыр таш булып яткандыр».

...Ниһаять, Флүр Сәхбиевичка зарыгып көткән җавап хаты килде. Бик газиз иде бу хат егет өчен. Ул аның эчтәлеген белгәнче үк, тулып ашкан бу шатлыкка үз-үзен әзерләргә тырышып, игътибар белән конвертына күз салды. Әйе, бу гадәти хат булмаска тиеш. Чөнки конвертына хәтле гадәти түгел бит. Рәсеме дә нинди диген: зәп-зәңгәр диңгез һәм күк, ә алар арасында, җирдә, яшел пальмалар:. Әйтерсең лә Гөлмираның егетне сагынган куллары...

Эре хәрефләрдән җыелган тип-тигез юллар. Хәтта адресы да бар. Ләкин өенеке түгел, ә почта бүлеге номеры, димәк, «До востребования» булып чыга.

Шатлыктан исереп, Флүр Сәхбиевич бүлмәсенә күтәрелде, ишеген дә япмыйча, өстен дә чишенмичә, кабаланып конвертны ачты һәм кадерле кәгазь кисәген кулына алды. Хатка тиз генә күз йөгертеп чыкты. Ләкин... хат егеткә ул уйлаган, хыялында тудырган, өметләнеп көткән шатлыкны китермәде. Киресенчә, бөтен өметләрен челпәрәмә китерде,

яралы йөрәгенә тоз сипкәннән ким булмады. Әйе, хат аңа бернинди дә сөенеч вәгъдә итми иде.

Ике-өч сүз белән генә Гөлмира аның хатын алуын һәм исенә төшерүе өчен егеткә рәхмәтен әйткән. Кабат хат язмаска кушкан.

Флүр Сәхбиевич үз күзләренә ышанмыйча, хатны яңабаштан укып чыкты, Гөлмира кулы белән язылуына күңелендә шик туды. Әмма... хатны чыннан да Гөлмира язган иде. Шулай күпме бергә йөреп, нинди татлы уйлар-хыяллар белән яшәп, бары шушы өч җөмләдән торган хат кына калдымыни?! Егет хатны конверт эченә тыкканда конвертта-гы рәсемгә күз төшерде. Бу юлы теге яшел кыяклы пальмалар Гөлмираның кулларын түгел, ә хәлсезләнгән акчарлакларның салынып төшкән канатларын хәтерләтә иде.

Флүр Сәхбиевич уйлана башлады. «Ә нигә ул бүтән эчтәлекле хат язарга тиеш иде соң? Нигә кыз һаман колач җәеп аны көтәргә тиеш? Юк, булмас. Ничек җырлыйлар әле: үзең ничек, мин дә шулай, ялыныр дип уйлама... Нәкъ дөресе. Чөнки син үзең шуны теләдең, хәзер генә суфыйга әйләнгәч тә...»

...Флүр Сәхбиевич өчен тагын газаплы көннәр башланды. Төннәр утырып Гөлмирага хатлар язды. Кыз аның бер-ике хатына бөтенләй җавап бирмәде, ә аннан... түзмәде, һәм егетнең озын-озын хатларына кыска гына җаваплар кил҆ә башлады.

Флүр Сәхбиевичның эченә җылы керде, көннәре кояш нурына, төннәре ай яктысына чумды, күңелендә, таң йолдызыдай, өмет чаткысы кабынды: «Бәлки?..» Аһ, бу «бәлки»! Күпләрнең рухын җылытып, йөрәген ымсындырып, күңелен җилкендереп торучы татлы, мәрхәмәтле сүз! Тылсымлы сүз!

Флүр Сәхбиевичка да әнә шул «бәлки» көч-куәт өстәде, йөрәгенә дәрт биреп торды; тормышка ышанычын арттырып, мәхәббәт ялкынына сүрелергә, ә үзенә сыгылып төшәргә ирек бирмәде.

## XV

Хат алышу, сөйгәнеңнән килгән җылы сүзләрне уку — әйбәт. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул кәгазь кисәкләре җанлы кешене алыштыра алмый, аның сокланулы карашын, кайнар назын сиңа китереп җиткерә алмый. Иртәме-соңмы, бер-берен яраткан кешеләр очрашырга тиеш. Бары шулай булганда гына хат язышуның мәгънәсе бар.

Флүр Сәхбиевич тә берничә мәртәбә моны Гөлмирага сиздерергә тырышты. Кыз, төрле сәбәпләр табып, егетнең чакыруын кабул итмәде. Шуннан соң Флүр Сәхбиевич, түземе бетеп, путевка юнәтеп, июнь ахырында Кара диңгез буена, Гөлмира яшәгән якларга китеп барды.

Беренче көн урнашу мәшәкатьләре белән узып китте. Флүр Сәхбиевич Гөлмираның эшенә шалтыратты, ләкин көрәшергә ният тотмады. Чөнки бу көрәшү ничектер ашык-пошык кына булыр шикелле иде. Ә егетнең күптән көтеп алынган бу кавышуның бәһасен төшерәсе, кадерен җибәрәсе килми иде. Аннары ул озын юлдан соң талчыккан кыяфәттә сөйгәне күзенә күренергә теләми. Аның ялы әле башлана гына, өлгерер. Ни дисәң дә, бу очрашу элекке кебек җиңел генә узмаячак, ул бик күп нәрсәне хәл итәчәк, шуңа күрә аңа ниндидер нәзге йолага җыенган кебек җентекләп әзерләнергә, тынычланырга, һәр сүзенең, гамәленең алдын-артын ныклап уйларга кирәк иде. Кыскасы, мөһим, бик мөһим иде бу көрәшү.

Флүр Сәхбиевич кичен диңгездә коенып, бик соңламыйча йокларга ятты. Нияте — сәгать җиде-сигезләргә кадәр уянмаска иде. Ләкин яшь, таза тәнгә күп кирәкме — сәгать бишләрдә уянды һәм кинәт, Гөлмира янына килеп, аны күрмичә, шулай тыныч кына йоклап ятуы өчен оя-

лып куйды. Әмма барыбер кичә дөрес эшләвен уйлап алды. Бүген — бүтән. Ул ял иткән, кәефе күтәренке, көчле иде.

Флүр Сәхбиевич балконга чыгып басты. Көн яктырып беткән. Җиләс һава рәхәт. Берөзлексез кошлар сайрый. Гүя алар егетнең шатлыгын уртаклаша, аны бу якларга килүе белән тәбрик итә, якты таң атуы белән котлый. Кайбер кошлар, аның үзен күрергә теләгәндәй, тыз-быз, әрле-бирле очыналар. Еракта этәчләр кычкырганы ишетелә. Якындагы юлдан сирәк-мирәк үткән машина тавышлары аларны кыска гына вакытка күмеп китә, аннары тагын табигатьнең бу матур почмагы үзенең гүзәллеге белән игътибарыңны җәлеп итә, хәйран калдыра, шушы могҗизаны карап туя алмыйсың. Зәңгәр күк йөзе алсу нурлар белән өртелгән. Еракта таулар, әйтерсең, зәңгәр томан эчендә, тигезле-тигезсез тау сыртларының кайберләре шома, ә беришесе — тарак теше кебек тырпаеп тора, күрәсең, алар чыршы агачлары белән каплангандыр. Таулар артында, Флүрнең туган җире калган якларда, күк йөзе аксыл, чиста.

Монда килгәнче булган ашкынуы сүрелә төште Флүр Сәхбиевичның, ул тынычланып калгандай булды. Бүлмәгә кермәкче иде, уеннан кире кайтты. Ничектер бу табигать күренешеннән күзен алалмыйча, сокланып-сихерләнеп, бик озак карап торды.

...Кояш өтеп алырдай нык кыздыра. Кайнар җил исә. Ком аяк табаннарын пешерә. Диңгездә дулкыннар йөгерешә, су өстендә бихисап көзгеләр, пыялалар елтыр-елтыр килә — дулкын сыртларында кояш нурлары уйный.

Флүр Сәхбиевич сәгатенә карап алды. Унике тулып киткән. Ә Гөлмира юк. Тукта, әнә кыз килә түгелме?

Флүр Сәхбиевич сикереп торды, йөгерә-атлый Гөлмирага таба китте. Гөлмира! Нинди килешле аның аяк атлаулары, никадәр якын бу сылу гәүдәсе! Ничек сагынган ул аны!

Гөлмираның да адымнары ешайды.

...Карап күзләре талмас, сөйләп сүзләре бетмәс шикелле. Менә инде күрешкәннәренә сәгатьтән артык, ә сүзләрнең иге-чиге күренми.

— Әйе, мин башта үземә генә түгел, сиңа да ышанмадым. Яшеренбатырын түгел, дөньяда төрлесен күрергә туры килде. Ләкин тора-бара мин сиңа ышана башладым, ә инде теге көнне син минем янга төзелешкә килгәч, синең өчен үземнең бик кадерле, ә синең минем өчен иң кирәкле кеше икәнне аңладым.

— Соң булса да...

— Әйе, ләкин аңладым. Син минем өчен изге, илаһи бер кадерле җанга әверелдең. Мин кайчакта аптырап та куям: ничек инде кешене шулай яратырга мөмкин?! Башта мин сиңа аптырый идем, хәзер — үземә. Әйе, ышансаң — ышан, ышанмасаң — юк.

— Бу — мәхәббәт, изге нәрсә.

— Мин сиңа бервакытта да үземнең хисләремне көчләп такмадым һәм такмам да. Ул алда да шулай булып калсын. Нинди генә хәлдә булсак та, без бер-беребез өчен янып-көюебезне белеп, сизеп яшик.

— Ләкин безнең юллар аерылган...

— Юк, мин хәзер синнән башка яши алмыйм! Мин монда сине алып китәр өчен килдем!

— Ашыкма. Әле вакыт бар. Уйлашыйк, аңлашыйк.

— Соң барысы да ачык бит инде.

— Белмим.

— Гөлмира, кадерлем, минем синең алдыңа тезләнәсем килә, синең кайнар кулларыңны үбәсем килә... Никадәрле ләззәт бирдең син миңа, күпме изге минутлар бүләк иттең! Синең назларыңны мин кара гүргә

кергәндә дә онытa алмамдыр. Гомеремнең иң соңгы сулышында да сине искә алырмын кебек.

— Кирәкми! Мин болай да...

— Юк, кирәк! Мин барысын да әйтергә тиеш.

— Флүр... Баштарак ничек көттем мин сине! Ә хәзер...

— Сине сагынып, синең күзләреңне үбәр өчен килдем мин. Кума мине, мәхәббәтемне рәнҗетмә!

— Мескенләнмә. Мин сине — горур егетне яраттым. Күтәр башыңны!

Гөлмира ике кулы белән яңакларыннан тотып Флүр Сәхбиевичның башын күтәрде. Аның яшьле күзләренә карады.

— Мин сиңа ышанам, ышанам, бәгырем! Мин үзем дә сине яратам! Ләкин... соң инде, соң!

— Ничек?

— Шулай.

— Туктале...

Яр буена, причалга ап-ак катер килеп туктады. Гөлмира, аны күреп алды да, сүзне икенчегә борырга җай чыгуына куанып:

— Әйдә, мине бер җилдертеп әйләндереп кил! — диде.

Егет теләр-теләмәс кенә риза булды.

Утырдылар. Ярдан егерме биш-утыз метр ераклыктагы кызыл буй янышнан выжлап үтеп тә киттеләр. Яшел камышлары, чуклы-бизәкле зонтлары, ком гарәбедәй каралган тәнле йөзләгән кешеләре белән сөзәк яр бик тиз артта калды.

Катер, Гөлмира белән Флүр Сәхбиевичның йөзләренә су бөртекләре чәчрәтә-чәчрәтә, аларның чәчләрен тузгыта-тузгыта, дулкыннар өстеннән алга ургый.

«Аһ, нигә бу катер!? Нигә ул түбәсенә ике балдак беркетелгән туй машинасы булмады икән?!» — дип уйлый Гөлмира.

## XVI

Берничә көннән алар тагын очраштылар. Гөлмира белән су буена килделәр. Ятаклар алып, җайлап урнаштылар.

Яр тулы кеше. Коенырга ярамый, диңгездә — дулкын. Су коенырга ярамаса да, кайбер кыюрак егетләрнең җаны түзми. Җиңнәренә кызыл тасма бәйләгән коткаручылар күрмәгәндә алар суга ташланалар. Флүр Сәхбиевич та алар артыннан иярде. Ул әчкәрәк йөзеп кергән иде, башы бер күренә, бер югала башлады. Бераздан коткаручылар бу кыю башларны, дөресрәге, бу башсызларны судан куып чыгардылар.

«Көчле дулкын вакытында диңгез белән шаярырга ярамый. Ләкин кайберәүләр шуннан тәм таба. Дулкын белән генә түгел, кайберәүләр мәхәббәт белән дә шаяра, икенчеләр аны чын дип кабул итә. Син дә шулайрак идең бит», — дип уйлады Гөлмира коенган егеткә карап.

Ләкин егет судан чыгып, аның янына килеп яткач:

— Салкынмы? — дип кызыксынды.

— Юк. Суы җылы.

— Саксыз кыланасың.— Гөлмира Флүр Сәхбиевичның чәчләреннән сыйпап алды.

Флүр Сәхбиевич хатынның тәләгенә буйсынып күзләрен йомды, бармакларының сизелер-сизелмәс кенә дерелдәвен тойды. Гөлмира басынкы тавыш белән, үз алдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Кайчандыр син минеке идең.

— Син дә...

— Әйе, мин дә синеке идем. Син әле хәзер дә минеке була аласың.

— Син дә...

— Юк. Мин хәзер синеке була алмыйм. Мин — ир хатыны. Иремнән аерылмыйча мин синеке була алмыйм.

— Бу...

— Дәшмә... Син килдең дә зиһенемне тараттың, бөтен дөньямны бутадың. Ул — бүгенге диңгез кебек.

— Без аны икәү тынычландырырбыз.

— Юк. Син минем дөньямны бары тик бутый гына беләсең. Синең бар белгәнең шул. Ә калганы — миңа. Теләсә нишләсен Гөлмира...

Хатынның күзләре читкә, еракка, диңгезгә төбәлделәр.

— Мин яратуыңның чынлыгына ышандым. Ләкин син мине бик нык рәнҗеттең. Кайчагында менә шулай диңгез ярына килеп, суга карап, мин синең белән сөйләшә идем. Ә диңгез барысын да аңлый һәм минем сүзләрне сиңа җиткерәдер кебек иде.

— Әйе, ул миңа барысын да әйтте. Синең мине көтүеңне, сагынуыңны... һәм менә мин килдем. Мин — синеке.

— Әйе. Тик мин генә синеке түгел.

«Кешеләр гел шулай: кемнеке дә булса берәүнеке булырга тиешләр, я булырга тырышалар,— дип уйлады Гөлмира.— Нигә алай икән? Ә диңгез беркемнеке дә түгел. Ул — бөтен кешенеке. Ул барысын да тигез күрә. Ләкин ул да бүген тыныч түгел».

Ә диңгез һаман чайкала, чайкала... Комлы ярга ак күбек тарала, күк күкрәгән тавышлар чыгарып, дулкын яр буйлап бара.

Гөлмира диңгезгә карап, уйга баткан: «Кешенең дә мәхәббәте шулай дулкын кебек бер көчәя, бер сүрелә микән? Белмим. Ләкин минеке нигәдер һаман бер килеш».

Хатын түзмәде, торып, яр читенә килде, тез тиңентен суга керде. Ул аягында көчкә тора иде. Дулкын шулкадәр көчле бәрә, ян белән бассаң гына аңа каршы торырга мөмкин. «Мин тормыш дулкыннарына да каршы торырга, җиңеп чыгарга тиеш. Менә шул чагында гына мин — кеше, чын мәгънәсендә кеше!»

Гөлмира көлеп куйды. Гаҗәп бу диңгез дигәнең: төрле уйлар уйлата, сине иләсләндерә, әллә нинди хисләр уята, зиһенеңне чуалта, ләкин акыл һәрчак аек — күңелгә олы тормыш турында уйлар килә.

Байтак вакыт тын утыргач, Флүр Сәхбиевич Гөлмирага бер кәгазь сузды.

— Менә сиңа расписание, безнең экскурсия көннәре.

Гөлмира кәгазьне кулына да алмады.

— Гафу ит, мин синең белән беркая да бармыйм,— диде.

## XVII

Флүр Сәхбиевичның ялы инде тәгәлләнеп килә. Ул Гөлмира белән бары берничә генә тапкыр очрашты. Ә хәзер... тагын аерылышу. Күпмегә? Бу — Гөлмирадан тора. Шуңа күрә егет соңгы көннәрен бик тынгысыз, төннәрен йокысыз диярлек уздырды. Менә өч көн рәттән инде иртүк балконга чыга да, уйларына бирелеп, сәгатьләр буе тик басып тора.

Гөлмира белән очрашкач, Флүр Сәхбиевич шундый сүз башлады:

— Кем ничектер, мин үзем туган ягымнан читтә яшәүне күз алдына да китерә алмыйм,— диде.— Әллә олыгая башладым инде. Әйтәләр бит, гомер буе читтә йөргән кешеләр дә, картайгач, үз илләренә әйләнеп кайталар, дип. Менә бу табигатьне,— егет кулларын җәеп, тирә-ягына ишарә кылды,— башта шулкадәр яраттым. Оҗмах дигәннәре булса, шушыдыр кебек тоелды. Ләкин хәзер туйдыра башлады. Гел бертөрле — яшел, яшел...

— Әйе, мин дә баштарак шулай уйлый идем. Бездә бит елның һәр дүрт фасылы бар. Ничек дигән әле шагыйрь: җәең — җәй, кышың — кыш...

Бераз вакыт тыныч кына утыргач, Флүр Сәхбиевич әйтә куйды:

— Мин иртәгә китәм.

— Беләм.

— Әйдә минем белән.

— Иртәгә Мансур йөздән кайта... Мин сине озатырга килермен. Хәзер — киттем. Мә, укы.

Гөлмира китеп баргач, егет ул калдырган кәгазьне эчке бер дулкынлану белән укырга хәзерләнде. Ләкин анда каяндыр күчереп алынган (Гөлмираның андый гадәте егетнең исенә төште) бер генә җөмлә язылган иде: «Теряя любовь женщины, можно обвинить только самого себя за неумение сохранить эту любовь».

...Икенче көнне Флүр Сәхбиевич аэропортта ут йотып йөрде. Тормыш мәшәкатьләре, дөнья ыгы-зыгысы икенче планга күчте. Алгы планда бары Гөлмира гына иде. «Үзе генә килерме? Әллә мичман беләнме? Әгәр икәү килсәләр, димәк, барысы да бетте, дигән сүз. Әгәр ялгызы гына килсә... Хәер, алай булган сурәттә дә, Гөлмира күңелендә ни барын тәгаен гына белеп булмас. Ул миннән чакрымнар белән генә түгел, рухы белән дә ераклашкан, ахры».

Флүр Сәхбиевич аэропортта утырганда, куе яшел яфраклы, зур магнолия агачына игътибар итте. Тармаклы, ап-ак зур чәчәкле бу биек агач тормыш, яшәешнең бер символы булып күз алдында үсеп утыра иде.

Аэропорт каршындагы асфальт мәйданга бер такси килеп туктады. Аннан Гөлмира килеп чыкты. Ул ерактан ук Флүр Сәхбиевичны күреп алды, йөзе балкып китте. Егетнең дә эченә җылы йөгерде, күңелендә өмет чаткысы кабынды, бөтен шик-шөбһәләре таралды, сөйгәненә таба атлады... Ләкин Гөлмира артыннан ук машинадан кап-кара киемле, янтыгына кортик аскан мичман да килеп чыкты. Флүр Сәхбиевич, йөрәгенә пуля китереп бәргәндәй, кинәт тукталып калды. Ә Гөлмира, берни булмагандай, аңа таба атлавын дәвам итте.

Мичман Флүр Сәхбиевичка честь биргән шикелле ерактан кул изәп алды да читтәрәк торган магнолия агачына таба китте.

...Әле дә ярый түгәрәк тәрәзә-иллюминатор куя белгәннәр самолет гәүдәсенә. Аңа бөтен дөнья сыя кебек. Аннан барысын да күреп була. Ә бүген дөнья егеткә кул болгап калучы Гөлмирадан гына тора. Бүген бөтен дөньяны ул — Гөлмира тәшкил итә.

*1981*

Роберт Әхмәтҗанов

# ГОМЕР ТИРӘГЕ

●

*Аh, тау юклыклар...*
Р. Ф.

Таулар да бар монда —
болытларга тигән,
упкыннар да,
кыялар да менә дигән —
җайлы урын бөркетләргә
ояларга!

Монда көн-төн диңгез актарыла,
шаша диңгез көне-төне...
Тавышында акчарлакмы үкси,
бөркетнеңме өне?

Ул тауларның түбәләре төнен
тиеп тора Айга...
Әмма — «тавы биек, даны сыек» икән —
бөркетләре кайда?

## Вәхшәт

Хәрабәләр арасында
буш нигездән
ниләр эзли ялгыз Ана?..

Бөтен җир буена —
көнчыгыштан көнбатышка —
нәни малай
елап бара.
Як-ягында кырлар яна...

Яңагыннан, өндәү булып,
күз яшьләре тама!

●

Мәхәббәтсез, утсыз һәм сөюсез
үткән көннәр — кысыр хыяллар...
Салам белән суга язган антлар,
китек бәхет — бәллүр-пыяла;

зәңгәр мираж, алтын пәрәвезләр,
чибәр гарип,
җәннәт төрмәсе,
татлы сагыз,
канатсыз җыр, өмет...
Тормыш-туйның чүпрәк бирнәсе...

Ком өстенә салган идеал-сарай,
шәрә табын,
көләч дивана,
муляж алма,
йолдыз күләгәсе...
Үрелеп кара, яле, син аңа!..

Барына да бүген хисап бирәм,
гомернең нәкъ исәп вакыты.
Сөю китер миңа! Кызыктырмый
фиргавеннең алтын табуты!

## Хәвеф

*Офыкта болытлар онытылган...*

Дөнья
нинди хәбәр көтеп тынган?
Шундый тынлык!

— Офык сызыгында ни тетенли?
— Олы юлларда ул —
машиналардан гына туза тузан...

## Олы юл

*...Олы юл ул — бик күп халыкларның олаулары, ямщиклары йөри торган, гасырлар буе үскән каеннар утырган баганалы юл.*
*Ул юл озын, озак...*
Бакый Урманче

Ул юл озын, озак — ай-һай, түзәр микән арбаң тәгәрмәче?
Юл читендә шайтан таяклары, әрем, убыр табагачы...

Уза ул юл — соргылт тузан тузган айлы кырлар аша,
даңгыр-доңгыр! — гомер олаулары сузыла чорлар аша...

Карурманнар шаулап каршы ала, атлар өркә куркып.
Юлаучылар алдан бара, атның тезгененнән тотып.

Сикереп төшеп, бураннарда төнен юл катысын таптың,
Әйдәдең син, ак башыннан тотып, Тормыш дигән атның.

Тәвәккәлләр юлы бу олы юл. Һәлакәтләр тулы...
Бара торгач килеп коя аңа Киек Казлар юлы.

Йолдызлар аша үтә юл — ул юл озын, озак...
Мин — бер юлчың. Каршыладың, Тормыш, фатихаң бир, озат!

●

Уң колагы чыңлап куйды аның:
исемен кычкырдылар өч тапкыр.
«Гомере буе онытылмаслык булсын».
Оныту кая? Яле, чыдап тор!..

Ул онытмас аны! Ышаныгыз,
рәхмәт сезгә аның исеменнән!
Исеме аның, үзенә барып җитеп,
Әлфиракка китеп ишетелгән!

Йолдызларга барып җиткән, хәтта
шул исемдә йолдыз кабынган!
Шуның нуры, галәм юлын үтеп,
сабый күзләрендә чагылган...

Исеме бар аның! Түгел хәзер
улы гына ата-ананың:
исемен аның теркәп куйды инде
улы итеп олы Ватаны.

«Исемең матур, озак яшә!» диләр,
кабатлыйлар янә тагы бер:
иң беренче булып калкыр өскә
«Кеше» дигән исемең барыбер.

●

*Мәхәббәт алиһәсе*

Син ерак язда, нур кебек,
калдың болын фонында...
Күксел күзләр тора көлеп
бәхетле офыгында!..

Барысы да якын иде —
калдымы ятка бары —
ап-ак иңендәге миңе,
бриллиант алкалары?

Төннәрен ялкын сулаган
ул кайнар вәгъдәләре?
Сөюдән сулыгып елаган
ул сылу гәүдәләре?..

Шул елда калдың, яшисең
бары шул чакта гына.
Гүя шаярып дәшмисең,
күмелеп чатка гына...

Тор әле шунда, кузгалма,
язгы болын фонында.
Күзләрең көлсен, кыз бала,
азатлык офыгында.

Тор әле шунда, шунда тор,
Мәхәббәт алиһәсе!
Җанымның килә җаныңа
сыенып ял итәсе!

●

*«Якты юраулар» циклына*

Озак әле үсәргә!
Ишек яңагында киртләр —
Яңакларын үлчәргә.

Озак килә хатлары...
Сагындырып төшкә керә
Инде сабый чаклары!..

Хәбәр килми оныктан.

Матчасында бишеге калган
Туган өен оныткан...

Җылың тора бишектә.
Әниеңнең соңгы җәе —
Бер кайтып кил ничек тә.

Кичекмә, син, кичекмә!
Күпмегә үстең, балакай,—
Киртләр кетә ишектә.

## Сиңа мәдхия

Мәхәббәтнең юмарт алиһәсе,
көләч көннәремнең алтын таҗы!
Ярты җаным, рухым хәзинәсе,
яшәү кыйбласының якты Хаҗы —
син идең ул...

●

Нигә уйчан? — диләр.
Тыңлыйм
гомер шаулап акканын.
Хәтер елгаларын кичеп,
хатирәләр кайтканын;

Баш очында Кояш җырын,
Моңын бөек Заманның;
Бик тирәндә — Вөҗдан тавышын,
Намус сулкылдаганын;

Бүгенгедән киләчәккә
очып барган хатларның
сәламнәрен... җилпенешен
мәңгелек канатларның...

Нигә уйчан? — диләр.
Тыңлыйм...
Вакыт шаулап акканын.

## Камил Мостафин

### Охшамаганнарга гимн

Без күпләргә охшаганбыз:
эшләребез охшап куя
башкаларның эшләренә,
сүзләребез охшап куя
башкаларның сүзләренә.

Бөтен җирдә — охшашлыклар:
бер-берсенә охшый өйләр,
бер-берсенә охшый көйләр,
хәтта кайчак — көлүләр дә,
сөелү һәм сөюләр дә.

Юллар ерак, дөнья чиксез,—
ничек адашмыйбыз соң без
охшаш өйләр арасында,
охшаш эшләр арасында,
охшаш хисләр арасында!
Ә бит охшамаганнар да
яшәп килә бу дөньяда,
бигрәк сәер адымнары,
бигрәк гаҗәп сораулары,
сөйләүләре, җырлаулары,
һава белән сулаулары!

Хыяллары, тойгылары
танышлардан кояшлырак,
сагышлардан сагышлырак,
башкалардан канатлырак,
башкалардан талантлырак.

Яшиләр һәм яктырталар
юлларны да, уйларны да,—
яктырталар уйлар белән,
яктырталар җырлар белән,
дошманнарга юнәлдергән
янган самолетлар белән.

һәм,— әйдәгез,— бер минутка
оркестрлар яңгырасын,
дөнья барабаннар каксын:
охшамаганнарны уйлыйк,
охшамаганнарны барлыйк,
охшамаганнарны җырлыйк!

●

Син шәһәргә киткән чакта, хыял төяп,
карап калды әнкәң, изге теләк теләп,
басу капкасыннан чыгып, күз карашын,—
юк, аркаңа түгел — йөрәгеңә төбәп.

Вакыт узгач кына, дустым, аңлап алдың:
шул караштa булган икән өмете дә,
сагышы да, сөюе дә, көюе дә,
әйтелмәгән үтенече, үгете дә.

Аннан өйдән эшкә чыгып киткән чакта
бусагага басып калды сөйгән ярың,
менә бит әй: сөюе дә, сагышы да,
өмете дә синдә генә икән аның.

Ә аннары, тотып тәти уенчыгын,
улың калды, син чыкканда ерак юлга,—

кул болгады,— сиңа гына бүләк итте
хыялын да, серләрен дә, шатлыгын да.

Син яшисең тырышып һәм онытылып,—
нинди кызык! Җилләр исә төрле яктан.
Чү! Ашыгып барган чакта, азга гына
туктап тор да, бер әйләнеп кара артка.

Тибәлгәннәр сиңа күзләр өметләнеп,—
әйдә, дустым, бу дөньяның ямен яңарт,—
әниең булып, иркәң булып, улың булып,
Туган илең һаман тора сиңа карап!

●

Шәһәрләрдән күчеп авылларга
һәм төннәргә ялгап көннәрен,
күз яшьләрен кушып гимннарга,
даны йөри әллә кемнәрнең.

Кем даны ул? Белсә, туктар иде,
исем биреп сүзсез моңнарга,
иске окопларга төшәр иде
намустай ак ташлар куярга.

Әллә кемнәр яшьләй очраштырган
дөрләп янган җәйге даланы,
җирне капшап килгән танкларны,
соңгы чикне, актык чаманы,
ә даны... юк, очратмаган аны.

Тагын кемдер аны очратмаган,
узган чакта дәһшәт читеннән,—
кыен елны «бронь» ала алган,
качып калган, исемен алыштырып,
чит җирләргә киткән иленнән...

Даны йөри җирдә кешеләрнең
ак көннәргә ялгап төннәрен,
һәм — оятсыз, җырсыз, моңсыз —
йоклый
намуслары әллә кемнәрнең...

●

Була минут: әллә кай тарафтан
кайткан чакта газиз төбәккә,
таныш юлга килеп чыгу белән,
бер кыл чыңлый башлый йөрәктә.

Әйтерсең, моң, туып ерак көнне,
иңгән монда ялгыз куакка,
тар инешкә, көтү йөргән кырга,
сукмак илткән якка — еракка.

Инде менә күптән киткән кеше
килеп чыккач шушы урынга,
гүя ул моң кабат күтәрелә
һәм җәелә җәйге болынга...

Кичке тугайларның кочагында
тынган тавышларны саклый ул,
ул таң булып сызыла, көтүченең
чыбыркысы булып шартлый ул.

Якты бу моң! Кое төбендә ул
ай шәүләсе булып калтырый,
таныш өйнең калай түбәсендә
яшькелт яшен булып ялтырый.

Туган якка кайтып табылган моң!
Бу дөньяга нинди җыр белән,
нинди моңнар белән килсәк тә без,
китәбездер шушы моң белән!

●

Синең төндәй кара чәчләреңдә
ап-ак көмеш китә чагылып:
баш очыңнан аккош очып узган,—
күңелеңә киткән кагылып.

## Карчык

Менә карчык... Иңбашлары иңгән,
киемнәре — иске, киелгән,
ә ул шундый... — ул Тукайны күргән,—
балачакта, туган өендә...
Яңакларын усал җилләр өткән,
аның күген каплап очканнар,
сискәндереп аңын — самолетлар,
моңландырып җанын,— торналар.
Күзләре дә үзгәргәннәр инде —
әллә моңнан, әллә кояштан,
Тукай гына аның күңелендә
сулмас шатлык булып урнашкан.
Тасвирламый карчык аның йөзен,
хатирәсен саклый, сөйләми,
сорасалар,— ул елмая гына,
елмая да уйлый әллә ни.
Кайчагында гына телгә килә:
— Әйткән иде, монда кил диеп...
Өстәп куя:— Ул сораган иде,
сеңелкәем, исемең кем диеп...
Ябык бармаклары сыйпап куя
өстәл өстен... Әллә капшыймы
кыз чагының нәни ак калфагын,
я... күзлеген эзләп тапмыймы?
Юк! Кирәкми күзлек, атса атсын
алсу таңнарының актыгы,—
һаман күрә аның күңел күзе
гомер буе килгән яктыны!..

## Кешесез табигать фәкыйрь

Кешесез табигать фәкыйрь.
Кешесез учак янмый.
Ә кешегә кеше кирәк,
кешене кеше аңлый.

Алдымда—юллар, басулар...—
аңлыймын барсын да мин,
ә үзем... уйда, фикердә —
дусларым каршында мин.

Күрделәр: юлда барганда
җилпенде ак күлмәгем.
Ә елмайган күзләремне
күрделәрме,— белмәдем...

Ә үзем... соң аңладыммы
хисләрен, шатлыкларын?..
Без күрәбез кайчагында
гел дөнья ваклыкларын.

Анда бит биек очу бар,
еракларны күрү бар,
иң кадерле кешеләргә
кулларыңны бирү бар.

Анда бит атауларны һәм
тойгыларны ачу бар,
Ватан кушкач, күтәрелеп,
аягүрә басу бар...

Анда, һай, зур җиңүләр бар —
замана баш иярлек,
анда шундый бәхетләр бар,—
башлар күккә тиярлек.

Белмәгәннәр, хәтерләгез,—
күк балкыса чамасыз,—
кояш диеп уйламагыз —
шулай без елмаябыз!

# Мәҗит Рафиков

## ХИКӘЯЛӘР

### Айрат

Кама суының урманлы биек яр битендә урнашкан санаторий. Июль ае. Кояш ялт иткән. Агач корпуслар, бормалы асфальт сукмаклар урыны-урыны белән куе ябалдашлы каеннар өрәңгеләрнең кап-кара күләгәсендә югалалар. Лоджиягә чыксаң, күккә томырылып үскән ялбыр каеннар арасыннан олы суның агымы күренеп ята. Җилкәсенә куәтле ГЭС плотиналары күтәреп торган кодрәт иясе кебек бу Кама! Алгы ярлары томансыл зәңгәрлеккә чумган — утраулармы анда, ярлармы, күз аерырлык түгел. Бетмәс-төкәнмәс вак дулкыннар өстендә күзләрне чагылдырып кояш каурыйлары җемелдәшә, кәрван-кәрван үзйөрешле авыр баржалар, аккоштай җиңел «метеорлар», «ракеталар» уза, шөпшәдәй җитез катерлар чуала, иртәнге сәгатьтә чакрым ярым буйлы саллар күренә. Ә һавасы бу җирләрнең, һавасы! Күкрәп үскән урман исләре дә, киң агым өсләреннән килгән җиләслек тә...

Кайсыдыр куакта кызылтүш сайрый, куышлы карт өрәңгенең шәрә ботагында әле яңа мамык кундырып оядан чыккан кошчыклар пырылдаша — әллә очып китәргә куркалар инде...

Ял итүчеләр таралыша. Кайсы процедура алырга китә, кайсы яңа җирләрне күреп әйләнмәкче, кайсы үзенә компания эзли.

Минем күрше дә чыгып китте. Мин палатага кердем дә яңа газеталарга тотындым. Озак та үтмәде, әкрен генә ишек ачылды, ярыгыннан бер чырай күренде — малайлар чырае. Мине күрү белән малай ишекне тиз генә кире ябып та өлгерде. Мин аңа, ни эшләгәнемне уйлап та тормастан:

— Мальчик, мальчик! Зайди-ка сюда, зайди! — дип кычкырдым.

Ул ишекне яңадан ачты, әчкәре атлады һәм шунда ук елдам бер караш белән өстәлдәге транзистор белән кул сәгатен капшап та алды.

— Әйдә, уз, утыр,— дидем, газетаны кулдан төшермичә генә.— Исемең ничек синең?

— Айрат.

Таза гына малай үзе. Унберләрдә булыр. Озынча тулы битенә җәйге тут кунган, күлмәк-чалбарлары пөхтә.

— Ә фамилияң?

— Сәлиев.

— Әтиең бармы соң?

— Бар.

— Эшлидер бит кайда да булса?

— Эшли. Төзелештә ул, яңа корпуста.

— Ә әниең?

— Әни биредә, санаторийда. Конторда ул.
— Нинди эштә?
— Кассир.
— Исеме ничек?
— Фаня.
— Ә үзең биредә кем булып эшлисең?
Малай көлемсерәп куйды:
— Беркем дә түгел.
— Алай булгач, бу корпуста нишләп йөрисең?
— Бер абзыйны эзли идем...— Аның тавышы тоныклана төште, кашлары кыймылдый башлады.
— Кайсы палатада тора ул абзыең! Исеме кем?
— Белмим.
— Кызык икән. Ничек эзлисең инде аны, белмәгәч?
— Болай таный идем...
Мин аның ачык күрән күзләренә туры карадым.
— Таный идең?.. Ә хәзер инде таный да алмыйсың, шулаймы?
Малай өнсез калды, ике бите гөлт итеп кызарып чыкты. Ул башын игән килеш шыпырт кына:
— Шулай-а-ай,— диде.
— Менә бит ничек. Ә нәрсәгә кирәк соң сиңа ул абзый?
— Сорарга...
— Нәрсә сорарга?
Малай кулын кулга алып, бармакларын сындырыр дәрәҗәдә катыкаты уа башлады. Аның алсу тәнле бармаклары ни хәл итәргә, кая яшеренергә белмичә газапланалар иде.
— Кара әле, Айрат, син ничек карыйсың? Әйдә хәзер үк барыйк әниең янына. Әйтик, менә син безнең корпуска үзең дә белмәгән ниндидер абзыкайны эзли килгән идең, диик.
Аның күз керфекләре челт-челт килеп, ирен очлары тартыша башлады.
— Бармыйк...— Малайның тавышында зинһарлап ялвару сизелде.
— И Айрат, Айрат! Нишләргә кала инде безгә болай булгач?
— Белмим...
— Бәлки, син үзең генә барып әйтерсең? Әниеңә, дим. Кая бардың, кемне эзләдең, нигә кирәк булды сиңа ул абзый...
Малай башын иеп, җилкәләрен калкытып тора, гүя ки менә хәзер кемдер аның башына кусәк белән тондырырга тиеш.
— Мин лутчы өйдән качам...— диде ул.
Икебезнең дә баш катты. Нишләргә?!
— Алайса, Айрат, без болай итик. Син миңа хәзер үк чын күңелеңнән сүз бирәсең: моннан соң болай беркайчан да, бернинди дә ят абзыйларны эзләп йөрмисең! Буламы?
— Була! Чын пионерлар сүзе: моннан болай беркайчан да алай йөрисем юк! — диде ул, коточкыч хәлдән тизрәк котылырга ашыккандай, һәм шунда ук җиңел сулап та куйды. Яктырып киткән күз карашы эчкерсез саф иде. И беркатлы җан!
— Синең бит, Айрат, үз әтиең бар. Төзүче дә әле үзе. Мөгаен, бөтен ят абзыйлардан да яхшырактыр.
— Яхшырак шул! — Малайның чыраенда көтелмәгән бер куаныч чагылып китте.
— Яратамы соң ул сине?
— Ярата!
— Әниең дә яратамы?
— Ул да.
— Соң шулай булгач, сиңа тагын кем кирәк булсын, ди?

— Транзистор тотып йөрисе килә иде...— Моны ул үзе дә абайламастан ычкындырып җибәрде... Һәм шунда ук, гаебендә тотылганын аңлап, куркынып, агарынып китте.

Мин моны күрмәмешкә салыштым.

— Өегездә транзистор юкмыни?

— Бар да ул, алып чыгарга кушмыйлар...

— Алай икә-ә-ән.— Бу әчкерсез бала миңа бик якын кебек тоелып китте.— Я, ярый, менә минекен алып чык,— дидем мин аңа, күз карашы белән үземнең иске «Меридиан»га күрсәтеп. Җыйнак, җиңел, тотмаган дулкыны юк.

Малай кинәт сагаеп калды. Ике күзен тутырып миңа карап тора. Ышаныргамы, ышанмаскамы? Янәсе, мин алыйм дип үрелгәндә генә, кулдан эләктереп, мине әни янына сөйрәмәсме!..

Көтелмәгән бу хәлдән мин шаркылдап көлеп җибәрдем. Көлүдән тыелгач, янә транзистор ягына ияк кагып, малайга шаян, хәйләкәр бер елмаю белән күз кыстым: «Ал!— янәсе.— Курыкма. Бөтенесе ал да гөл!..» Имештер, ул да мин — икебез генә белә торган серле бер кызык ясарга сүз берләштерәбез...

Малайның авызы ерылды, үзе бөтен кыяфәте белән елмаеп, балкып китте, транзисторны алды. Дөньясы түгәрәк, түбәсе күктә!..

Бер ярты сәгать үтте микән, ишек шакыдылар. Бу янә шул ук Айрат иде. Ни күзләрем белән күрим, тез башлары, туфлиләре тузанга буялып беткән, чырае сытык, күз төпләре шешенгән, яшьләре дә кибеп җитмәгән, ә кулында — минем «Меридиан».

Мин сикереп тордым:

— Айрат! Сиңа ни булды?

— Менә... сабын сындыра язды...— диде ул, сулкылдавыннан тыела алмыйча, транзисторны миңа сузып. «Меридиан»ның сабы сынып ук чыкмаган, чатнаган гына, почмакларына балчык, яшел яфрак кисәкләре тулган иде.— Көчкә куып җиттем,— диде малай, сүзләрен өзек-өзек әйтеп.— Бирми... Кулдан тартып алды да чапты... Моныса минеке булды, ди...

— Кем ул?

— «Ярканат». Чын исеме Ярулла. Зур малай. Гел шулай ул... Кемдә нәрсә күрсә...

Мин каршымдагы бу балага сокланмыйча булдыра алмадым.

— Кара әле, Айрат, син бит менә дигән әйбәт малай икәнсең лә! Герой син!

Айрат бераз тынычлангач, мин аны асфальт сукмакка кадәр озата чыктым.

Көн аяз. Кояш ялт иткән. Карт өрәңге ботагында оядан яңа чыккан кошчыклар пырылдаша — әллә очып китәргә куркалар инде...

## Балта, пычкы, струклары...

Һәр эшне бик җентекләп, килештереп, тәмләп эшләү гадәте канында ук булгандыр аның. Бер йортта күрше булып яшәгән Сафа абзыйны әйтәм. Бал ачыткан ул бер вакытны. Ачыткач, кранлы савыты белән баш очына, тумбочка өстенә утыртып куйган да шлангысының бер очын шуның кранына кидергән, кыскычлы икенче очын баш куеп йоклый торган мендәре астына яшергән. Җәннәт түгел, диген!..

Базык, калын, нык бәдәнле ир иде ул. Эштән кайтышлый бераз гына салмыш булса, ачу тулы карашларын калын күз кабаклары астына

яшергән килеш, таш сындай төп-төз, туп-туры атларга тырыша иде — юан-юан ике аягы гына кыймылдый. Янәсе, айныклардан-айнык!

Дөньяда җене сөймәгәне кем дисәң,— әлеге дә баягы подъезд төбендә үткән-сүткәнгә үзләренең аяусыз хөкемнәрен чыгарып утыручы карчыклар иде. Тегеләре дә Сафа абзыйны күрү белән тынып калалар. Кая ул телгә алу, күрмиләр дә, янәсе!

Ишегалдында ир-ат белән гәпләшеп утырганда Сафа абзый кайчак бик уфтанып:

— И-их, егетлә-ә-әр, авылда торсаммы! Бөтен өйләрен рәттән сырлап-челтәрләп чыгар идем, валлаһи... Дачада инструментлар ята минем. Сандыгы белән. Балта, пычкы, струклар. Кулыңа бер тотсаң, уйнатып туймассың! — дип, фатир алмаштырып килгән яңа күршесенә дәшә иде: — Сезнең андый-мондый балта әшегез юкмы соң? Кирәксә, әйтегез. Китап шүрлекләреме, тумбочка-фәләнме... Эшкә тотардай агач юктыр инде үзегезнең?..

Тумышы белән Арча ягыннан иде үзе. Кайсыдыр Атыдан дип истә калган. Уртасыннандырмы, Утарыннанмы...

Бер кичне караңгы төшкәндә яфрак коеп утырган чаган астында кинәт үтә дә нечкә тавыш белән ишетелер-ишетелмәс кенә «Иске Карурман»ны сузып җибәрде бит бу. Гәптәшләре, барыбыз да шаккаттык. Бу кадәрле дә моң булыр икән шушы аю кыяфәтле агайда! Иң нечкә борылышларына кадәр өздереп кенә сала...

— Әткәй мәрхүмнең җырлаган җырлары,— дип бер-бер артлы кыскаларын да тезә башлады:

> Байлар кайтты мәкәрҗәдин
> Артка тагып туры атын,
> Безнең нише моңлы-зарлы
> Салып сайрый канатын...

Язып алучысы табылса, берүзе әллә ни кадәр фольклор үрнәкләре яудырыр иде ул. Кайберләрен мин дәфтәргә тырнаштырып алган идем.

Авиационный заводта эшләде ул үзе. Стропальщик. Эшен яраткан-нар. Инде күптәннән бирле өч бүлмәле фатирда яшәде.

Соңыннан хезмәттәшләре дә сөйләп торды: «Эшлисе эшенә чат ябыша иде менә! Бөтен ягын алдан уйлап, туры китереп, әйбәтләп башкара торган абзыкай иде...»

Пенсиягә чыкты — пенсиясе иң югарысына ике сум гына тулмаган.

Кайчакларын өендә хатыны, козгын тавышлары чыгарып ташлана иде аңа: «Кая куйдың өч сумын? Отдай! Отдай!..» Стена аркылы ишетелә бит ул.

Явызлык дигән нәрсә адәм тавышын бу кадәр дә бозар икән! Ишегалдында ул апакай юкса менә дигән нечкә, йомшак тавыш белән, бик ягымлы итеп тә сөйләшә белә иде...

Үзе зур бер заводның тулай торагында төн аралаш вахтер булып торды ул. Хатынын әйтәм. Кайбер көннәрне эштән кайтышлый, кабул итү пунктына сугылып, кара сумкасына җыеп алган буш шешәләрен тапшырып чыга иде.

Сафа абзый белән икесе бер авылда туып үскәннәр алар. Бик яратышып кавышкан булганнардыр. Казанга Сафа абзый сугыштан кайткач килеп урнашканнар. Гаилә ишәйтә башлаганнар. Тормышлары түгәрәкләнгән саен бәхетләре арта гына барасы иде дә бит!

Өйләрендә үзара туган телдә сөйләшәләр иде алар, татарча. Бәйләнер минутында гына хатыны яман да ватып-сындырып русчага күчә иде. Кайвакытны күрше бүлмәдән анасына ярдәмгә уллары да килеп чыга иде, студент, классик көрәштән разрядник. Атасыннан ике баш калку. Сафа абзыкай келәм җәйгән идәннәренә тулы капчыктай «лып» итеп төшкәли иде. Моны ул эчтән генә кичерде, кешегә сөйләп, үз дә-

рәҗәсен төшереп йөрмәде. Алай да соңрак ишегалдында бер күршесенең колагына гына әйткән:

— Тәкатем калмады, аерылам, китәм!..

Якындагы бер төзелешкә төнге каравылга урнашкач, үзе дә бераз ирек алгандай булды. Әмма бераз вакыт узу белән ишегалдында да күренми башлады. Тамагыннан аш үтми икән, диештеләр.

Күп тә үтмәде, Сафа абзый вафат булды.

Аларның көрәшче улларыннан зуррак тагын ике балалары булган икән әле. Җирләгән көнне Куйбышевтан ярты гына көнгә олы уллары кайтып төште. Бик зур инженер икән, диештеләр. Кызлары да югары белемле икән — педагог. Таза, пөхтә, чибәрләр.

Автобуслар килеп туктады — заводныкылар төялешеп тулган. Хезмәттәшләре. Веноклар, веноклар, медальле кызыл күпчекләр тезелеп китте. Таш өйләргә кадәр сискәндереп, оркестр уйнап җибәрде...

Әле ярый мәрхүм Сафа абзый, якты дөнья белән хушлашканчы, кечкенә оныгын сөеп-уйнатып, күңелен кинәндереп өлгерде. Көрәшче уллары институтны бетереп диплом алу белән нечкә генә бер баскетболисткага өйләнгән иде.

Гаҗәп икән бу кеше дигәнең! Аңлы гомеренең күп өлешен шаулы шәһәрдә үткәргән, зур бер заводның алдынгы эшчесе булып танылган. Ә күңеленең иң түр бер җирендә татар авылының менә дигән бер балта остасы һаман яши килгән, һаман өзелеп-өзелеп үзенекен тансыклаган!..

Әтиләренең еллыгы мәҗлесендә магнитофоннан мәрхүмнең тере тавышын тыңлап утырдылар:

И-и-и-и-и-и,
Исемең матур, кемнәр куйга-а-а-ан,
Сине күреп кем туйга-а-а-н!..

Икенче елында көрәшче улы экспорт вариантта чыгарылган «москвич» машинасы сатып алды да, баскетболисткасы белән икәүләп, Кырым-Кавказ якларына чыгып китте.

Ишегалдында аның турында бер сүз булып алды:

— Ничек алай дүртесенә дә языла алган соң ул? Шолоховка да, Гринга да, өстәвенә тагын Серафимович белән Толстойга да...

— Ничекме? Үзе алып барган көрәш секциясенә йөрүче малайның әнисе аша. Җаен тапкан.

— Барыбер укымаячак инде ул аларны!

— Таптың укыр кеше! Ярышлардан кайтып керми бит ул. Әле Уфага китеп бара, әле Горькийга, әле яшьләрне өйрәтә...

...Әтисенең инструментларын да кемгә дә булса сандыгы-ние белән сатып җибәргәннәрдер инде.

Тутыгып, эштән чыгып ятмасалар ярый ла!

## Шеланга — Теньки — Ташовка

Моннан бер унбиш еллар элек язучыларның иҗат йорты Малеевкадан кайтып килә идем. «Дорохово» станциясеннән электричкага утырып Мәскәүгә киләбез. Вагонда яныма озын буйлы чандыр бер карт туры килде. Рус. Үз гомерендә бик кыю, тәвәккәл кеше булган булса кирәк, бит җыерчыклары кискен-кискен уелган, үзе әле дә шактый тере, гәпчел, кызыксынучан булып чыкты ул.

Мин, Казанга кайтып барам, дигәч, кинәт шундый җанланып китте ки, әйтерсең лә куанычлы бер ачыш ясаган.

— Казаннан дисезме? Әә беләсезме, күптәннән бирле Мәскәүдә торсам да, тумышым белән мин дә бит Казанныкы! Казан, Идел буйлары — кадерле җирләр! — диде ул, дулкынлануын яшермичә һәм бөтенләй көтмәгән бер сорау бирде миңа: — Ә беләсезме, нинди такмаклар такмаклый иде ул элеккеге пароходлар, көпчәкләре белән суны шап-шоп кыйнап барган чакларында, ә? Беләсезме? А-а-а, ю-ук шул.— диде ул, миңа бераз карап торгач.— Сез яшь шул әле моны хәтерләр өчен... Элек бит Казанда шундый бер пароход ширкәте бар иде — «Меркурий», шәһәр тирәсендәге линияләр барысы да аның карамагында иде... Революциягә кадәр әле бу. И ул пароходларда йөргән чуар халык! Чабаталылар, цилиндрлылар, ә күбесе — үзебезнең яланаяк, яланбашлар. Эскимослар белән папуаслардан кала барысы да бар. Һәркем үзенчә яшәргә, җан асрарга тырыша. Пристань саен базар, палуба саен базар, чат саен, адым саен базар. Ул кәрҗин-кәрҗин виктория, чия, алма, редис, суган, ул сумса, пәрәннекләр, ул балыкның кипкәне, катканы, тозлысы, каклаганы, ыслаганы, тересе, кытай фонарьләре, сызгы, чабата, чыпта, мунчала, каен себеркесе, ул чүлмәкләр, мөгез тараклар... Кая карама кызыл битле юан бабалар, очлы күз малай-шалай, веерлы дама белән монокльле мыек, төрле шантрапа. Анда исерек компания гармун тартып бәйрәм итә, тегендә угырыны кыйныйлар, кайсы үзенең товарын мактый, кайсы сүгенә... Ю-у-ук, туганкай, сез боларны күргәнегез юк... Сәлам әйтегез миннән туган якларга! Минем дә, кайда туры килсә шунда, стаканлап көнбагыш сатып йөргән чаклар бар иде... Ә соң беләсезме, нәрсә дип такмаклый иде ул көпчәкле пароходчыклар? Юктыр шул. Менә тыңлагыз:

Шел-ланга — Теньки — Ташовка,
Шел-ланга — Теньки — Ташовка,
Шел-ланга — Теньки — Ташовка,
Груши, яблоки — дешевка,
Чулки, варежки, носки-и-и-и-и!..

Соңгы авазын ул көтелмәгән бер наянлык белән ерактан ишетелгән нечкә, озын һәм бераз гына карлыккан тавышлы пароход гудогына әйләндереп җибәрде — әллә кайларда калган малайчакларыннан килгән татлы аваз, янәсе... Җыен яшьләр арасында берүзе, урындык аркасына ята биреп, бу шаян такмакны картайган чыраенда, күзләрендә дә шундый илһам чаткылары, шундый да ләззәт билгеләре чыгарып көйләп торып такмаклавын, ул гудокны шундый да җан рәхәтләре белән кычкыртуын, «Шеланга»ның «л» авазын шундый да сузып икеләндереп җибәрүләрен кара син аның!..

Беренче ишетүемдә бу «көпчәкләр такмагы» миңа кайгыны кайгы дип белмәс хөр күңелле халыкның гаҗәеп бер авыз иҗаты җимеше булып кына тоелган иде. Инде хәзер, еллар узу белән, уйланам: үзе кем булган соң ул — олы үзәктә, олы эшләр эчендә кайный-кайный генераллыкмы, профессорлыкмы дәрәҗәсенә ирешкән бу карт? Ник Казан исемен ишетү белән иң әүвәл туып үскән өен, хәтта әти-әниләрен дә түгел, нәкъ менә Иделне, аның иркен агымын, пристаньнәрен, шәфкатьсез тормышта бәреләсугыла көн күргән чуар халкын, тау ягы, болын ягы ярларын, саф җилләрен, баш өстендәге юмарт кояшын һәм — барыннан да элек! — пароход көпчәкләренең, суны шап-шоп кыйнап, нәрсә такмаклаганнарын исенә төшергән ул?

Нинди васыять итеп сөйләгән ул моны миңа?

# Контрамарка

Гәптәшем — палатадаш күрше Нияз ага Ибраһимов. Казанда туып-үскән кеше икән. Бөек Ватан сугышында танкист идем, ди. Соңыннан «Спартак» фабрикасында эшләгән. Солдат итекләре теккәннәр, җылы-җылы унтылар. Шуннан ук пенсиягә чыккан. Җиңел сөякле какча абзыкай. Түгәрәк зәңгәр күзләре сабыр да, сынаучан да карыйлар.

Беренче танышканда үзенең сабый чагына кагылышлы хәлләрдән кызык кына бер вакыйга сөйләп алды ул:

— Тумышыммы? Унҗиденче елның утызынчы октябрендә туганмын мин. Октябрь революциясенә нәкъ бер атна кала. Әни сөйли торган иде: «Казанга аклар килеп керсә дә, кызыллар килеп керсә дә, сине тиз генә бишектән эләктереп ала идем дә, базга төшеп китә торган идем, дип. Утыра идек шунда, караңгыда икәүләп, шәһәрдә атыш тавышлары тәмам туктаганчы...»

Минем аны бик бирелеп тыңлавыма, хәтта кәгазьгә дә теркәштереп алуыма кызыгыптырмы, Нияз ага миннән:

— Сезнең Гадел Кутуй белән очрашканыгыз булмадымы? — дип сорады.

Аның бу соравы гәп куерту өчен сылтау гына иде, ахрысы. Очрашканым булмавын болай да күреп-чамалап тора бит, югыйсә. Бәлки ул шулай сүзне ерактан башлап, читтән уратып, челтәрләп-чуклап йөртергә ярата торгандыр. Миңа калса, алай кызыграк та әле ул.

— Мин бит, Нияз ага, сугыш чыкканда үсмер малай гына идем, андый затлар белән аралашырга. Казаннан читтә дә идем.

— Шулайдыр шул,— диде ул һәм, бераз тынып торгач, тавышын күтәрә төшеп әйтте: — Ә мин аны белә идем.— Ләкин сүзен шунда ук читкә борды: — Бу Рөстәм Кутуй дигән язучы шул Гаделнең улы түгелме ул?

Монысын да белә торып сорый иде.

— Әйе, улы,— дидем мин, аның сүз җаена буйсынып.

— Ничек соң, әйбәт язамы, этисенең йөзенә кызыллык китермиме?

— Бик әйбәт яза. Менә дигән художник. Кайбер әйберләрен укыйм да сокланып бетә алмыйм.

— Хәтерлим мин аның этисен, Гаделша Нурмөхәммәтовичны. Яраткан укытучыбыз иде! Авиатехникумда укып алдым мин бераз. Сугышка хәтле әле. Подготовительный бүлегендә. Ул техникум хәзер дә шул ук урында тора, Муса Җәлил урамында. Бәлки беләсездер?.. Рус теленнән укытты ул безне. Әйбәт тә кеше иде! Кара чәч, кара тутлы көләч йөз. Гел елмаеп-көлеп кенә сөйләшә иде кеше белән. Өс-башлары чиста-пөхтә. Костюмнан. Галстугын хәтерләмим. Кырынмаган-төзәтенмәгән килеш күрмәссең. Безне укыткач, тагын каядыр эшкә китә иде. Укытырга булса кирәк. Э-э-э... Обаятельный — безнеңчә ничек була әле? Әйе, әйе, нәкъ шулай, мәхәббәтле, сөйкемле кеше. Яңа гына танышкан кешесе белән дә бик якыннарча, күптәнге дусларча сөйләшә торган иде. Шундый эчкерсез, саф күңелле.

Минем Идрис Якупов дигән бер иптәш бар иде. Бер группада укыдык. Ул кичләрен театрга барып, кечерәк рольләр уйнап йөрде. Подрабатывать итеп. Ә Кутуй бит пьесалар да яза иде. Үзе дә чын артист. Купшы, зәвыклы. Идрисне белә. Бер көнне тәнәфестә Идрис белән мине очратты да, икебезгә ике контрамарка бирде:

— Егетләр, минем премьераны барып карагыз әле, сез нәрсә әйтерсез икән? — ди.

Ул чакларның театры хәзерге күчмә кебек булгандырмы инде, спектакльләре элеккеге Печән базары мәчете бинасында куела торган иде. Сәхнә пәрдәсе кул белән тартып ябыла торган иде. Ике яктан. Хәзер анда — телсезләр-чукраклар клубы. Киров белән Париж коммунасы урамнары чатында. Беләсездер? Тукай торган «Болгар» номерлары да шунда рәдем генә. Кайсы пьесасы буенча куйганнардыр, истән чыккан инде, әмма яратып, куанып карадык. Ә, әйе, ул елларны ике комик та бар иде! Берсе Камай, берсе Мамай. Баш рольне Кутуй үзе уйнады түгелме икән әле...

Икенче көнне бездән сорый:

— Я, егетләр, ничек?

Ниләр әйткәнебез истә калмаган, әмма безнең авызлар колакка житкән иде! Карап чыккач та бик канәгать булып, шаулаша-көлешә кайткан идек. Үзебезнең укытучы премьерасы лабаса!.. Аның бит төп әсәре «Тапшырылмаган хатлар»мы әле? Беренче басылып чыгуы да шул безне укытып йөргән елга туры килә шикелле...

Ул кайда, полевой госпитальдә үлгәнме әле? Польшада бугай? Үкенечен әйт, ә! Жиңүдән соң бит... Ничә ел узды әле жиңүдән соң? Утыз сигезме? Үзе юк, китабы калган. Укый башласаң, аерыла алмыйсың... Рөстәм барып кайтты бугай этисенең каберен күрергә?.. Әнисе беләнме?

— Алар кайткач, Тукай клубында бер кичә дә оештырылды. Гадел Кутуйның туган көненә багышлап,— дидем мин.— Рөстәм шунда Польшада ничек каршылауларын, ниләр күргәннәрен сөйләде.

— Үкенеч. Бергәләшеп карточкага да төшә белмәгәнбез. Китабына кул куйдырып алырга да башка килмәгән. Менә илткән булыр идем музеена. Исемен зурлап. Безнең язучылар музее бардыр бит ул?

— Булмыйча.

— Контрамаркасы да сакланмаган, ичмасам. Бер дә уйлый белмәгәнбез инде менә шушындый нәрсәләрне...

## Нәшрият баскычында

Кулъязмалы папка тотып, киң өсле култыксага таяна-таяна, баш редакторга менеп бара идем. Күрәм, каршыма, шул ук култыксага ябыша-ябыша, Мәхмүт ага төшеп килә. Галиев. Физикадан укыткан пенсионер. Буфетка юл тота булыр. Нәшриятка техник терминнар сүзлеге чыгаруда ярдәм иткән көннәре иде. Озын буйлы, озынча битле, гел елмаеп сөйләшүчән калын иренле мөлаем абзыкай. Кырык ел буе контроль эшләр тикшерә-тикшерә күзләре тәмам беткән. Күзлек диоптрийлары әллә уналтымы шунда, әллә йөз дә уналтымы, линзалары кат-кат көмеш божра гына булып күренә.

Кул кысыштык, хәл сораштык.

— Әйбә-ә-әт! — дидем мин.— Миңа ни бары таза гына, нык кына бер аяк кирәк. Бирүчесе табылса, мин аңа менә шушы тәти кул таягымны тоташ алтынга манып, асылташлар белән бизәп, бүләк итеп бирер идем.

Мәхмүт ага нәкъ шушыны гына уйлап килгән диярсең, киң елмаеп:

— Ә миңа әйбәт күрә торган бер генә күз бирүче булса, мин аңа ике аягымның берсен хәзер үк бирәм! — дип, ботына шап иттереп сугып та алды.

Шаян малайлар кебек шаркылдап көлештек тә, икебез дә бик шат, бик канәгать булып аерылыштык. Әйтерсең лә ул миңа аяк, мин аңа күз биргән.

# Дифгат Сирай

## Биеграк кураенə

Мин шагыйре Шишкин якларының,
Шишкин йөргән җирләр миңа
таныш.
Искә төшүгә үк, күңелемдә
Дулый башлый дулкынланып арыш.

Мин шагыйре Шишкин якларының,
Шишкин туган җирдә мин дә туган.
Искә төшүгә үк, күңелемдә
Шаулый башлый чайкалышып
урман.

Мин шагыйре Шишкин якларының,
Күңелемдә һаман урман, арыш.
Шишкин эзләреннән үз урманым,
Арышымны бүген эзләп барыш;
Кайчак өскә кайгы ишелсә дә,
Килеп кинәт сарылса да сагыш,
Иң беренче булып йөгереп чыга
Юатырга мине урман, арыш...

...Мин шагыйре Шишкин якларының,
Шишкин йөргән җирләр миңа
таныш.
Биегрәк күренә шуңа урман,
Биегрәк күренә шуңа арыш.

●

Чалып екты диңгез дулкыны
Ялтырап торган ташлар өстенә...
Ул ташларны дулкын шомартып,
Кертқән икән күзгә төсенә.
Тормыш дулкыны да шундый бит,
Кешеләрне иги, эшкәртә.

Шомарта ул кайсын,
Кайсының
Күңел кылын бары нечкәртә...
...Чалып екты диңгез дулкыны,
Мамык түгел икән таш өсте.
Ә шулай да барыбер елмайдым,—
Бигрәк якты иде баш өстем.

●

Кар туздырып җилләр йөри,
Җил күңелне җилкетә.
Җилләр булып исәр идем,
Җилләрне соң ни көтә? —
Кар туздырып йөргән җилнең
Җитмәстер тыны купкә.
Җилләр булып исәр идем,
Тынармын дим... Өркетә.

## Ни җитми?

Иңләгән бар бик күп үзәннәрне,
Тирбәткәндер яшел дулкыны.
Рәхәтләнеп ятып аунар өчен
Җитми барыбер авылым болыны.

Коенган бар бик күп елгаларда,
Назлагандыр суның көмеше.
Рәхәтләнеп колач җәяр өчен
Җитми барыбер авылым инеше.

Йөргән бар бик күп басуларда,
Җилкеткәндер тургай моңнары.
Рәхәтләнеп җырлар сузар өчен
Җитми барыбер авылым кырлары.

●

Елмаеп таңнар ата,
Мине дә таң елмайта;
Аяз күкләр, ак болытлар
Күңелдә нур уйната.

Моңаеп таңнар ата,
Мине дә таң моңайта;
Агач шавы, кош сайравы
Күңелдә җыр кузгата.

Таңнарга карап кемнәр
Елмаймый-моңаймыйдыр?!
Таңнар күк булсаң иде,
Алар бит... еламыйдыр?!

●

Балачагым үтеп бетмәгәндер...
Каршысына басты утлы киртә.
Шуны сүтә-сүтә үсмер чагым
Һәм яшьлегем үтте.
Гомер үтә...

## Яңа капка

Җил аударды бәреп капканы,
Баганасы, ахры, чергәндер.
Түбәләренә күпме кар суы,
Яңгыр суы төшеп сеңгәндер.
Башта әби, аннан әнием
Килен булып шуннан кергәндер.
Шатлыклар да, кайгы-хәсрәт тә
Шуннан кереп-чыгып йөргәндер.
Үтте шушы капка аркылы
Әткәемнең «соңгы туе» да.
...Җил аударды иске капканы,
Әби ауган көнне урынга.

Оста килде. Баганаларның
Яңалары төште чокырга.
Баш калкытып әйтте әбием:
«Элеккедән тизрәк утыра!
Җилен әйтәм әле, җиленә
Сокланамын сизгер булганга;
Яңа капка аша чыгасым
Килгән иде соңгы юлга да...»
...Җил аударды иске капканы,
Яңасы да инде каралган:
Һич арынып тормый яңгырдан,
Һич арынып тормый карлардан...

# Мәгъсүм Хуҗин

# МАЙ КОЯШЫ — ЯШЬ КОЯШ

хикәя



Рәхимә кухняда чәй әзерләп йөри иде. Китапка ябышкан иренә:

— Сабит,— дип эндәште. Назлы тавыш Сабитны китабыннан аерды, ул кухняга керде. Рәхимәнең стакандагы дарулы суны болгатуын күреп:

— Әллә авырыйсыңмы, әнисе?— дип, хатынының җилкәсенә кулын салды.

Рәхимә даруын эчкәч кенә җавап кайтарды.

— Авырмыйм. Болай гына, баш авыртмасын өчен генә эчәм.

— Авыртмаган башка...

— ...тимер тарак булмас.— Рәхимә пар бөркеп утырган чәйнеккә үрелде:— Нурсабах кибеткә киткән иде, ул керсен дә чәй эчәбез,— диде.

— Нигә миңа әйтмәдең кибеткә чыгарга? Нурсабах лекциясенә ашыгадыр ич.

— Минем сиңа сүзем бар иде.

— Әйт соң. Без кызыбыздан сер яшермибез ич.

— Сер түгел, ир белән хатын арасындагы сүз.

Бу гаиләдә шундый гадәт: кунакка барсалар да, өйдә чакта да, уртадагы урын — Нурсабахка. Табын янына да шулай утыралар алар, һәм кыз ана белән атага як-якка авышырга-егылырга ирек бирми торган уртак тотанак була.

Хәзер дә ир белән хатын өстәлнең баш-башына утырдылар.

— Көн матур булачак бүген,— диде Рәхимә, якты тәрәзәгә ымлап.— Май кояшы, яшь кояш... Бүген мин җиңәргә тиеш, кояш минем җиңәчәгемә алдан ук шатлана, миңа туры карый. Мин җиңәм, Сабит, мин!

— Кемне җиңәсең?

— Белмим. Бәлки үземнедер.

— Әллә минеме? Алай булса, минем үз сүземә бетәшкән кеше икәнемне онытма. Мин җиңелергә яратмыйм. Шуңа күрә сабантуйларында да көрәшмим. Синең белән ярышырга бөтенләй дә исәбем юк. Димәк, сүз дә көрәштермик.

— Ялгышасың, Сабит. Без гел көрәшеп яшибез.

— Һәм гел мин җиңәм!— дип шаяртмакчы булды Сабит. Әмма Рәхимәнең сүзне шаяртуга бордырмас өчен дәлиле бар икән.

— Без синең белән бер-беребезнең күңеле кителмәсен, бер-беребезне тагын да бәхетлерәк итү өчен гел көрәшеп яшибез.

— Алайса гел мин җиңеләм икән...— диде Сабит, сузып кына. Һәм шактый вакыт тынып, хатирәләргә бирелеп утырды. Аннары, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, әкрен генә әйтеп куйды.— Мин үземне синең белән яши башлаганчы да бәхетле идем дип саный алмыйм.

— Юк, изгелек дигәндә гел син җиңәсең!— Рәхимә өстәл аркылы иренең кулын учларына алды.— Синең белән яши башлаганчы мин дә болай бәхетле түгел идем. Ә өмет зур иде.

Алар әңгәмәне очларга өлгерә алмадылар — балкып-очынып, шәрран ярып, Нурсабах кайтып керде. Менә ул — безнең май кояшы, дип сөенеп куйды Сабит, кызын күргәч.

— Ә-ә, көтәсезме?!— диде кыз сумкасындагы ашамлыкларны өстәлгә бушатып.— Көтеп алган ризык тәмлерәк була ул.— Нурсабах, эти-әнисенә авыз ачарга да ирек бирмичә, сүзне бүтәнгә борды.— Хөббәтне эрләп вакытым узды, шуңа озаграк тордым. Җаным ла, сакалмыек баскан, күзләре тонган, җитмәсә, киеме сәламәнең дә сәләмәсе. Нигә әче таңнан исерек син, дим. Эндәшми. Егерме тиенең юкмы, ди. Илле тиен бирдем. Ашханәгә барып тамагын ялгасын әле. Эти, дим, эти, син күрән пинжәгеңне барыбер кимисең, Хөббәткә бирик шуны, йөрмәсен адәм көлдереп, безнең йортның данын төшереп.

— Ни бит, миңа пинжәк җәл түгел, әмма Хөббәт сау-сәламәт кеше. Үзе эшләп тапсын,— дип өстәмәкче иде Сабит, тик кызының үтенеченә каршы килә алмады (бүген ул күндәм!):

— Әнә, караңгы бүлмәдәдер,— диде.

Сабит бу сүзләрне әйткәндә Нурсабах пинжәкне күтәреп чыгып бара иде инде. Кинәт ул, ишекне дә япмыйча, кире борылды.

— Әни, әни, баскыч төбендә Акбай көтеп калды, колбаса кисәгеме, котлетмы бир әле шул йомшаккайны сыйларга.

Озакламыйча әйләнеп тә керде Нурсабах.

— Хөббәт абый рәхмәт әйтте, ярый әле Нурсабах сеңлем бар ди, бер син мине кешегә санап сөйләшәсең ди, мескенкәй. Акбай да рәхмәт әйтте, башын селкеде. Эти, эти!

— Әү, әү, кызым!

— Бүген синең белән киногa барабыз, яме?

— Ни бит...

— Барабыз, дим ич! «Татарстан» кинотеатрына, «Тәһран-43» фильмын күрсәтәләр. Мин билет алып куям, сәгать өчкә шунда киләсең.

— Ярар алайса...— Ни булды бүген Сабитка, иртәдән үк һәр боеруга күнә дә тора.— Ә соң, әниең?

— Әниемең тегүчегә барасы бар. Кичен минем башка эшем күп. Аннары минем синең белән барасым килә. Син Тәһран конференциясе турында күп укыгансың бит, миңа да аңлатып барырсың.

— Мин тегүчегә сәгать өчтә килергә ышандырган идем шул,— диде Рәхимә, зәңгәр күзләре белән иренә текәлеп. Тик шунда күзе тарттымы, уң кашы сизелер-сизелмәс кенә сикереп куйды, ә тулы чокырыннан чәй бүлгәндә чәе читкә чайпалуын ире күрмичә калды.

Кулмәк дигәндә хатын-кызның күңелендә кино кайгысы буламы соң, дип уйлап алды Сабит.

— Сезнеңчә булсын, алайса,— дип, ансат кына килеште.

Күр әле, күптән булганым юк икән ич минем «Татарстан» кинотеатрында! Фойены матурлаганнар, тамаша залын да баскычлап эшләгәннәр. Тыштан гына без студент чактагыча шыксыз кыяфәтен саклый. Соңгы тапкыр кайчан булган идем соң мин монда? Онытылган. Шулай да нигә читләтеп уза идем икән мин бу кинотеатрны? Югыйсә, кино карарга яратам ич. Ә-ә, Гаршия белән соңгы тапкыр очрашканнан соң кергәнем юк икән минем бу кинотеатрга. Кызык, баштарак Гаршияне

искә төшермәс өчен керелмәгәндер, аннары читтән узарга күнегелеп киткәндер инде.

— Әти,— дип беләгемне кыса төште Нурсабах,— мин мороженый алып килим әле. Сиңа кирәкмиме?

— Озаклама, тамаша залын ачтылар.

Ә Гаршия белән монда очрашу сәер генә булган иде...

...Стипендия алгач, мин туп-туры киногa йөгердем. Булачак фильмнар исемлеге эленгән белдерүне эзлим. Таныш йөз! Таныш кына түгел, минем өчен кадерле... Әйе, Гаршия! Безнең күзләр очрашты. Тик без бер-берсбезгә ташланмадык, баш кагып та исәнләшмәдек хәтта. Кирәк бит, урыннарыбыз аралык аша гына туры килде. Мин Гаршиягә сүз кушарга телим, тик телем әйләнми. Бәлки, очрашыйк, аңлашыйк, дип язып бирергәдер. Блокнотымның бер битен ертам, кулымда — каләм, әмма... нигә кирәге бар аңлашуның?!

Кинодан без бергә чыктык.

— Исәнме, Сабит,— диде Гаршия, кешеләр төркеме тарала башлагач.

— Әйбәт,— дидем мин.

— ...Укуың, тормышың?

— Әйбәт,— дидем мин.

— ...Эти-әниләрең, туганнарың ничек яши?

— Әйбәт,— дидем мин.

— ...Мин кияүгә чыгарга җыенам.— Гаршиянең бу хәбәрендә, каршы төш син минем бу теләгемә, дигән ялвару сизелгәндәй булды. Шулай да ул:— Мин алдашмыйм. Чынлап та кияүгә чыгам. Офицерга. Диңгезче,— дип, хәбәренә төгәллек кертте.

— Бик әйбәт,— дидем мин.

Тормышта кабатланулар була, әмма алар беркайчан да бер-берсенә тулысынча охшамый, бөтенләе белән тәңгәл килми. Менә, бу юлы да Гаршия белән минем урыннар янәшә туры килде. Ләкин бу юлы инде минем янымда кызым утыра. Аннары без инде теге чактагыча яшьләр дә түгел. Тормыш дигәнең яшьлеген гомере буена сакларга хыялланган Гаршиянең дә килеш-килбәтен шактый йончыткан. Бу үзгәрешләрне мин фойеда ук күргән идем.

Кызык, бергә яшәгән булсак, картлык чалымнары килер идеме икән аңарга? Ул бит яшьлеген беркайчан да җуймау турында хыяллана иде. Матур омтылыш бу, һәм мин аның моңа ышануына соклана идем. Миндәге олыгаюны ничек бәяли икән Гаршия? Кайсыбыз күбрәк үзгәрде икән? Минем белән бергә үткәргән вакытларын хәтерлиме икән ул? Әгәр хәзер Гаршия белән яшьлеккә кайтып карасаң, ә?! Тик минем кайтасым килми.

Чыгышлый мин Гаршия белән тагын янәшә туры килдем. Нурсабах мине култыгымнан ычкындырды, арттарак калды.

— Исәнме, Сабит!— Гаршиянең тавышы нык, бу көтелмәгән очрашудан каушавы сизелми иде.

— Әйбәт,— дидем мин.

— ...Ничек яшисең?

— Әйбәт,— дидем мин.

Кешеләр сирәгәеп, арабыз ачылгач кына мин Гаршиянең йөрешенә игътибар иттем. Гәүдәсе калынайган, шулай да нәфислеген җуймаган, аңардан хатын булу, ана булу матурлыгы бөркелә иде. Кыз чактан аның җиңел атлавы гына сакланып калган иде.

— Минем синең белән сөйләшәсем бар иде,— диде Гаршия, миңа таба борылып.
— Сөйләшик соң,— дидем мин (я ходай, бүген мин көне буена «әәгә «җә» дип торырга тиешмени соң!) һәм бездән артта калып килүче Нурсабахка карадым.
— Кызыңнан шикләнәсеңме әллә?
— Юк,— дидем мин кырыс кына.— Кызымнан да, хатынымнан да сер яшермим.— Дорфа әйттем, чөнки безнең гаиләдәге дуслыкны шик астына алырга мин берәүгә дә юл куймаячакмын.— Сөйләшәсе сүзең бар икән һәм әңгәмәдә кызымның катнашмавын телисең икән, син инде вак-төякне сылтау итмә.— Әмма бу тупаслыгым да Гаршиягә тәэсир итмәде.
— Кызың үзеңә охшаган.
— Әйе, барлык әйбәт яклары үземә охшаган!— дидем мин, мактанып ук.
— Ә начар яклары хатыныңамы?— Гаршия, нечкә кашларын уйнатып, мыскылламакчы булды.
— Минем баламның начар яклары юк!— дидем мин.
Кызым мине көтеп тора иде, әмма ул миңа китәргә кушып ым какты һәм кулын болгады.
— Әти, син кал, мин кайта торам,— диде Нурсабах, ә карашы минем җилкә аша Гаршиягә төбәлгән иде.— Сине көтә бит ул апа.
— Әйдә, сине троллейбуска озатып куям.
— Кирәкми, әти.— Кызымның зур түгәрәк күзләрендә иркәләнү чагылды.— Мин бәләкәй түгел инч.
Һәм мин (бүген ничәнче тапкыр инде!) тагын көндем. Нурсабах саубуллашкандай итеп кулын селтәде һәм, җилкәсен тутырган куе чәчләрен биетеп, троллейбус тукталышына таба китте.

— Әйдә, утырыйк әле,— диде Гаршия, ридикюль бавын беләгенә киеп.
— Ресторанга кереп утыра алабыз.
— Юу-ук, аулаграк урын булсын!
— Алайса, үзең сайла. Син шәһәр үзәген миннән ким белмисеңдер. Мин кая барырга да риза. Гомумән, мин бүген юаш кеше, кем ни әйтсә — шуңа күнәм.
— Монысы минем файдага икән.— Аннары Гаршия сәер-серле елмаеп өстәде:— Әмма ахыры хәерлегә булсын, юаш юанайса, усаллыгы давылдан битәр...
Алар кечкенә бакча почмагындагы артсыз эскәмиягә килеп утырдылар.
— Мин эзләп килгәч, сүзне дә мин башларга тиештермен,— диде Гаршия һәм ридикюленнән юка төргәк алып янына куйды.
— Ничек? Безнең очрашу очраклы түгелмени?— Сабит әсәренеп Гаршиягә борылды.
— Очраклы очрашуны да оештырып була бит. Ярар, анысы әһәмиятле түгел. Хатын-кыз хәйләсе бераз катнашты, шул гына.
— Мин хәйлә тозагына эләкми идем, югыйсә.
— Димәк, үзең әйткәндәй, бүген соңрак торгансың. Мин, яшьлек чытлыгына бирелеп, алдарга теләсәм, хәтерлисеңме, син миңа: Гаршия, алдашма, мин йокыдан синнән алданрак тордым, дия идең.
— Булгандыр.
— Күзләреңдә елтыр ут кабына, шушы сөйкемле коңгырт кашларың маңгаеңа үрмәли иде синең андый чакта.
— Бүген мине эзләп килүеңнең сәбәбе алдаша белә-белмәвемне ачыклау түгелдер, шәт.

— Әлбәттә,— Гаршия кулына төргәкне алды һәм, Сабитка туры карап, кинәт сорап куйды.— Әйт әле, син мине ярата идеңме?

Сабит карашын яшермәде, күзләре генә акрынлап кысыла, кысыла барды.

— Белмим,— диде ул.

— Бу җавап түгел.

— Яратмаганмын.

— Рәхмәт. Алдашмавың өчен. Менә болар — синең хатларың,— диде Гаршия, кулындагы төргәкне ридикюленә салып.— Хатларыңда синең ичмасам бер генә дә «яратам» дигән сүзең юк. Әмма син мине ярата ала идең.

— Миңа бергә булырбыз кебек тоела иде. Без бит якыннар идек, һәм гаилә кору, тормыш итү өчен шул якынлык җитә дип уйлый идем мин...

Гаршияләр Казанда яшиләр иде, ә авылда әнисе ягыннан туганнары бар. Кечкенә чактан ук җәйне авылда уздыра иде Гаршия. Пөхтә киенеп кайтыр иде дә, авыл балалары белән әвәрә килеп, кояшта каралып, ефәк киемнәренең төсен уңдырып, уку елы башланыр алдыннан гына шәһәренә китәр иде.

Сабит унынчыны бетергән җәйдә дә кайтты Гаршия, ул чакта медицина училищесының ике курсын укыган, буйга җитеп килә торган кыз иде. Кайтыр алдыннан Гаршия Сабитка хат язган иде. Мәхәббәт сүзләре дә, серле ымлаулар да юк иде анда. Быел авылда озак була алмам, институтка документларыңны илткәндә, сиңа ияреп китәрмен, дигән иде Гаршия. Әмма шушы хәбәргә дә Сабитның башы күккә тиеп йөрде. Шулай булмыйча соң, кызлардан беренче хат алуы бит!

Гаршия кайткан көнне кичке уенга алар бергәләп төштеләр. Уеннан соң, Шушма ярына утырып, ак таң атканын күзәттеләр, Гаршия, Сабитның күкрәгенә башын куеп, хыялга чумды...

— Мәрхәмәтсез син, Сабит...— Гаршия урынына кире утырды, йөзен учлары белән каплады, башы тезләренә иелеп төште.— Бу сүзләреңне шул чакта, мин синең күкрәгеңә сыенып ак таң каршылаганда, әйткән булсаң соң.

Гаршия озак үкседе, аннары тын гына елады һәм елавыннан кинәт кенә туктап калды.

Сабит финанс-экономика институтында укый башлагач, алар һәр якшәмбедә очрашалар иде. Тик Шушма буендагы кебек таңнар кабатланмады инде. Һәм бер очрашуга Сабит килмәде. Шуннан соң ел ярым чамасы узгач кына, «Татарстан» кинотеатрында урыннары янәшә туры килеп, өзек-төтек сүз алыштылар...

— Мин синең мәхәббәтең гомер буе бөредә калыр, гомер буе чәчәк ата алмас, дип уйладым. Шушма буенда... син миңа... кагылырсың дип көткән идем. Карышмаячак идем...

— Һе!

— Әйе, синең мәхәббәтең бөредә генә калган икән. Ялгышмаганмын мин.

Сабит бүлдермәде.

— Көйле чыкмады минем тормышым, Сабит. Ә синең белән бәхетле булачак идем мин. Шуны белер өчен генә эзләп таптым мин сине.— Гаршия озак кына сүзсез торды, кул аркаларын алмаш-тилмәш сыйпап утырды.— Балаларым да юк минем. Беренче иремнән малаем туган иде. Унике яшенә җиткәч, әтисенә китте. Унсигез яшенә чаклы ай саен акча җибәреп тордым, алимент ягъни.

— Алимент түләп кенә ата да, ана да булу мөмкин түгелдер.— Сабит кесәләрен капшады һәм бүген беренче сигаретын кабызды.

— Алар миннән алимент сорамадылар. Үзем җибәрә идем. Әмма

акчаларымны кире кайтара тордылар. Малайны гаепләмим, нишлисең, ир заты, әтисе ягын тартты.— Гаршия тагын тын алды.— Икенче ирем бер җилкуар булып чыкты. Җитмәсә, үтә кысмыр, тиенгә беткән бәндә инде. Малайга җибәргән акчаларның кире кайтуына очынып шатлана иде. Балтик буена туристик путевка белән баргач танышкан идек. Ә ял иткәндә кешеләрнең барысы да яхшы, начарлык ерак яшеренә ялда... Нигә син берни сөйләмисең?

Сабит җилкәләрен генә сикертте.

— Беренче ирем белән аерылышкач, ялгыз торган чакларымда, син килер дип, ишекне бикләмичә йоклый идем. Хәзер дә ишегем биксез кала. Ахры, соңдыр инде...

— Соң. Хәер, иртәсе дә булмады бугай.

— Була ала иде, син мине чынлап ярата ала идең! Һәм синең мәхәббәтеңне мин үзем үстерергә тиеш булганмын.

— Минем бит бу өлкәдә гыйлемем юк,— диде Сабит, мыскыллавын төгәл сиздереп.— Тәҗрибә аз.

— Мәхәббәт, беләсең килсә, ихтыяҗ ул. Шуңа күрә кеше яратудан, сөюдән-сөелүдән туймый.

— Килешәм.— Сабит сигаретын сүндермичә генә икенчесен кабызды.

Гаршия Сабитка усал итеп карады, боерып:

— Үзең турында сөйлә! Мин барысын да белергә телим,— диде.

— Эшлим. Бухгалтер. Төзелештә. Әйбәт яшибез. Хатыным, кызым һәм мин. Теге чакта араны өзеп дөрес эшләгәнмен. Үкенмим.

— Синең кызың үзеңә охшамаган. Бу турыда мин сиңа кинотеатр янында ук әйтергә теләгән идем. Мине ташлап китәсеңне сизеп, тыелып калдым. Синең белән сөйләшәсем, яшьлегемә кайтасым килгән иде. Күңелемне бушаттым. Синең кызың үзеңә...

Сабит Гаршиянең тел төбен төшенә башлады, аның сүзләрендә явызлык тойды.

— Син миңа начарлык эшләмәкче буласыңмы? Шулай итеп күңелеңне бушатырга җыенасыңмы?

Гаршия туры җавап бирмәде.

— Нигә бүген миңа бер тапкыр да исемем белән эндәшмәдең? Әллә исемемне оныттыңмы?

Сабит тагын, тагын эндәшмәде.

— Синең кызың үзеңә охшамаган...

— Рәхимсез дә икән әле син! Күрәсең, синең чит балага гына түгел, үз балаңа да ана була алмавыңны Шушма буенда ук сизгәнмен мин. Син элек тә — әле генә көн була идең дә, шунда ук төнгә әйләнә идең. Әйе, ана булу өчен йөрәгеңдә мәрхәмәт яшәргә тиеш, хәтта кайнап яшәргә тиеш ана мәрхәмәте.

— Нигә дөреслектән качарга?— Гаршия бая елап түккән көчен мәкер чәчеп кайтармакчы була иде. Үз көчсезлеген яшерергә теләгән хатын моны дөрестән дә ансат кына эшли ала.— Син дә, миңа өйләнмичә, асыл кош тотмагансың. Синең кызың үзеңнеке түгел...

— Минем кызым!— дип сикереп торды Сабит, ихтыярсыздан кизәнеп. Шөкер, кулы Гаршиянең йөзенә бәрелмичә тукталып калды. Шулай да кулын, буялганга санап, кулъяулыгына сөртә-сөртә ашыгып китеп барды.

— Сугасың калды, Сабит... Хәер, андый җәза гына аздыр миңа... Мин бит, мәхәббәтемә кайтырмын дип, бәхетемне әзләп килдем сиңа... Сугарга иде...

Сабит Гаршиянең сөйләнүен ишетмәде, бакчадан чыгып, кешеләр арасына кереп югалган иде инде ул.

Нурсабах синең кызың түгел, дигән сүзне беренче ишетүем иде. Шәт, соңгысы да булыр бу. Тик миңа аны яшьлегемдә якын күргән кеше авызыннан ишетүе авыр булды. Яшьлегемнең чирәмле сукмагында очраткан кешенең шулай ямьсез булып әйләнеп кайтуына минем хәтта ышанасым килми иде.

Әмма чынлыкта шулай булды.

Хатыным Рәхимәнең иртән җиңү-җиңелү турында сөйләвенең һәм кызым Нурсабахның мине кинога барырга кыставының серенә мин хәзер генә төшендем. Димәк, хатыным һәм кызым белән алдан сөйләшеп, очрашуны Гаршия үзе оештырган. Бу кадәресе инде Гаршия тарафыннан ким дигәндә әрсезлек, әдәпсезлек. Димәк, бу хәйләгә юл куюда Рәхимә белән Нурсабах үз көчләренә ышанганнар. Ачуланмыйм мин аларга. Бәлки алар шулай гаиләбез ныклыгын тикшереп карарга теләгәннәрдер. Ачуланмыйм.

Ә син, Гаршия, ялгышасың. Нурсабах — минем кызым. Моны Нурсабах көн саен искәртә. Мин китап укыганда яки каршыма очраганда, ул минем я чәчләремнән сыйпый, я колагымнан тарта да:

— Әти, әйт әле, син мине яратасыңмы?— ди.

— Институт тәмамлыйсың, тиздән инженер булачаксың, ә үзең һаман бәләкәйләр кебек,— дип, туры сүздән тайпылам мин кайчак.

— Әти кеше олы кызын күбрәк яратырга тиеш, бик беләсең килсә!— дип, туры җавап көтә миннән Нурсабах.

Я, шуннан соң нәрсә дияргә тиеш булам инде мин...

Институт тәмамлап төзелешкә эшкә урнашкач, мин трестның тулай торагында яшәдем. Аннары иске йорттан бер бүлмә бирделәр. Уңайлыклары юк, кухнясы, коридоры һәм башкасы ике хуҗага уртак. Мәж килеп яшибез шунда күрше әби белән.

Атна буе командировкада булып, кичен соң гына кайттым һәм, йомырка тәбәсе кыздырмакчы булып, кухняга чыктым. Газны кабызып җибәрүем булды, кемдер чалбарымнан тартты. Борылып карасам — зәңгәр бантиклы кечкенә кыз. Мин аның белән сүз башларга да өлгермәдем, ишектән кәстрүл тоткан хатын килеп керде.

— Кызым, кызым, абыйны борчыма,— диде ул һәм миңа карап:— Сез гафу итегез инде,— дип өстәде һәм шунда ук зәңгәр күзләрен читкә яшерде.

Әмма кечкенә кызның үз нияте булган икән.

— Мин борчымыйм, мин абыйга «Исәнме!» генә әйтмәкче идем.— Кыз кулларын чәбәкләп, сикергәләп:— Мин Нурсабах исемле,— дип мактанып та алды.

— Исемең матур икән,— дип аркасыннан сөйдем мин аның.

— Минем әнием Рәхимә исемле. Ә синең исемең ничек?— диде бала һәм миңа кулын сузды.

— Сабит,— дидем мин, аның белән күрешеп. Һәм, кызның әнисенә карап, танышу билгесе итеп, башымны кактым. Яңа күршем Рәхимә дә шул хәрәкәтне ясады. Ут яктысында да аның зәңгәр күзләре төсен җуймый, болай да якты күзләре тагын да нурланып ялтырый иде.

Әмма Нурсабахның кыюлыгы моның белән генә бетмәгән икән әле. Аның балалык хыялы без — олылар — башка да китермәгән нәрсә тирәсендә йөргән икән.

— Син миңа әти булырсың, яме,— диде Нурсабах, күзләрен мөлдерәтеп, һәм чалбарымнан тарткалап, миңа аңга килергә дә ирек бирмичә:— Я инде, әйт, буласыңмы?— дип кабатлады.

Көтелмәгән сораудан мин каушап калдым. Бу халәттә күпме булганымны хәтерләмим, тик Рәхимәнең кулыннан төшкән кәстрүл тавышына гына айнып киттем. Рәхимә, Нурсабахны кочагына кысып, үз

бүлмәләренә кереп китте. Эчтән бер тавыш та ишетелмәде. Яртылаш ачык калган ишекне бераздан соң гына тышкы яктан мин ябып куйдым.

Яңа күршеләр, фатир алыштырып, бүген генә күченеп килгәннәр икән. Рәхимә ире белән аерылышкан, һәм алар фатир бүлешкәннәр, ә минем иске күрше әбием тол калган кызы белән аларның фатирына кергән. Сәфәрдә булып, мин бу үзгәрешне белмичә калганмын.

Рәхимә ире белән күптән аерылышканмы, Нурсабах үз этисен әллә бөтенләй хәтерләмиме — болары минс кызыксындырмады. Нурсабах ул чакта бакчага гына йөри иде әле. Беренче очрашудан соң атна чамасы күрмәдем мин Рәхимә белән Нурсабахны. Алар миннән кача идеме, бу кадәресен дә белмәдем, тик мин алардан качмадым. Нигәдер сагындым мин Нурсабахны. Болай, качышлы уйнагандай яшәп булмый иде. Нурсабахны сагынуыммы, әллә Рәхимәнең якты күзләре тынгы бирми идеме,— мин аларның ишеген шакыдым. Әйе, Гаршия көткәнчә ачык ишекне каерып ачып түгел, бикле ишекне ачтырып кердем. Кердем дә:

— Нурсабах, мин синең этиең булам,— дидем.

Бала, уенчыкларын ташлап, минем кочагыма сеңде.

— Эни, эни, Сабит абый — минем эти дип әйткән идемме мин сиңа? Әйткән идемме!— диде Нурсабах һәм минем битләремне-чәчләремне сыпырды.— Әйттем бит, эти, име?..

Бу кичне Нурсабах «эти, эти» дип тәкелдәде, мин «кызым, кызым» дип кабатладым.

Моңа инде күп вакытлар үтте, әйткәнемчә, Нурсабах быел институт тәмамлый. Әйбәт яшибез, хәзер фатирыбыз да яңа. Мәхәббәтебезне Нурсабах тулыландыра. Моны туганнарыбыз да, дусларыбыз-танышларыбыз да аңлый, моны һәркем белә. Гаршиядән башкалар...

Сабитны хатыны белән кызы бергәләп каршыладылар. Рәхимә якты күзләрен тутырып Сабитка карады һәм, иренең җилкәсенә йомшак кына кагылып, кухня ягына узды.

— Эти, эти! Әнигә яңа күлмәк килешәме?

— Әниеңә зәңгәр төс бик килешә, кызым. Гомумән, әниебезгә барлык нәрсә килешә.

Нурсабах этисенең колагын тартып куйды.

— Эти, син мине яратасыңмы? Мин бит синең олы кызың! Олы кызын күбрәк яратырга тиеш эти кеше!

— Яратам.

Нурсабах тагын бөтерелеп килеп җитте дә Сабитның чәчләрен тузгытты.

— Эти, эти, син мине яратасыңмы? Мин бит синең кече кызың да. Кече кызын күбрәк яратырга тиеш эти кеше!

Көн саен кабатлана торган бу изге уенны Рәхимә елмаеп күзәтә иде.

— Яратам, кызым!..

Бер-береңә ягымлы булу чыннан да иң арзанга төшә икән бит кешеләргә, моның өчен күтәрергә-төшерергә дә, үтенергә-ялварырга да кирәкми: бары тик ягымлы гына бул син, ә ягымлы булу синең үзеңә генә бәйле, синең үзеңнән генә тора.

— Эти, эти!

— Әү, әү, кызым!

— Бүген көн нинди матур, ие бит! Май кояшы, яшь кояш. Әйе бит, эти!

*1981*

# ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

## Виктор Кочетков,

рус шагыйре

### Хәрбиләр зиратында уйлану

Бәлки, мин дә шушы каберлектә
ятар идем...
Алар туфрак, ә мин исән... исән...
Кичер, илем!
Йөрәгемне дәһшәт уты телә
искә төшкәндә:
Дон җилләре шомлы улап исте
минем өстән дә.
Яраланган килеш ятып калдым
боз-кар эчендә,
Мин — юк инде хәзер дусларым һәм
семьям өчен дә.
Һуштан язган хәлдә калдым шулай
яр читендә.
Фашист автоматын тойдым шулчак
мин битемдә.
Куркыныч төш булып эзәрлекли
күргәннәрем минем.
Мең газаплар үтеп, исән калдым,—
кичер мине, илем!—
Җиңү көнен якынайту өчен,—
кичер мине, илем,—
мин җанымны бирә алмый калдым —
каным бирдем.
Басып торам тып-тын каберлектә,
мең-мең уйлар кичәм...
Алар — үлемсезләр! Кичер, илем,
Ә мин... исән...

●

Тайга.
Урман.
Чыбык-чабык чыртлый:
әллә берәр җәнлек уздымы...
Күңел ойый. Шундый-шундый сәер
хәрби ракетодром тынлыгы.
Нарат кәүсәләре иелгәннәр.
Тып-тын. Эссе.
Урман төш күрә.
Егерменче гасыр,
хәвефләрең
булса иде бары төш кенә.
Антенналар күктән тавыш эзли,
аптыраган сыман шом юкка...
Егерменче гасыр,
кагыла күрмә,
тия күрмә шушы тынлыкка!

Күзләрендә — мөлдерәмә бер моң:
болан карап тора читлектән.
Мин түгелме
фашист коллыгында
шушы болан кебек интеккән?
Һаман ишетәм әле җаным аша
искән бозлы җилләр тавышын.
Тик мин генә шулай аңлыймдыр күк
болан хәлен, болан сагышын.
Маңгайларга түгел, күңелләргә
сугыш тирән сызды эзләрен,
әнә шуңа боланныкы кебек
уйчанлана кайчак күзләрем...

**ИЛДАР ЮЗЕЕВ** тәрҗемәләре

## Андрис Веян,

латыш шагыйре

# Шәфкатьле бул, вакыт, ашыкмачы...

Шәфкатьле бул, вакыт, ашыкмачы!
Кай арада изге төн үткән?
Очып киткән тургай — күренми дә...
Чәчтек кенә — урыр чак җиткән.

Шәфкатьле бул, вакыт, ашыкмачы!
Якты айны болыт капласын,
Коеп яуган яңгыр asларында
Атласын да кешең, атласын.

Шәфкатьле бул, вакыт ашыкмачы
Гөлләр назлы сулыш алганда,
Юраганда бу тынгысыз җаным:
«Кем мин җирдә? — диеп,—
Ни алда?»

Шәфкатьле бул, вакыт, ашыкмачы,
Тузганактай тузгып бетмәче,
Агымсулар булып югалмачы,
Искән җилдәй узып китмәче!

Шәфкатьле бул, вакыт, ашыкмачы!
Тәмамларга әле иртәрәк —
Сабыр итсен әле төн карасы,
Каршыласын ал таң иркәләп.

Шәфкатьле бул, вакыт, ашыкмачы!

## Уртак булсын

Бер кабымлык икмәк уртак булсын
Эштән соңгы тыныч табында.
Юл табылса — икәү атлыйк шуннан,
Икәү эзлик — җуйган чагында.

Уртак булсын учак ялкыннары,
Биек күкләр, җирнең һавасы...
Уртак бүлик тозны... Газапларның
Уртак була күрсен дәвасы.

Төннәр безгә түшәк бүләк итәр...
Уртак булыр күргән төшебез,
Буराннарда калып туңулар да,
Яңгырларда калып күшегү —

Уртак булыр! Икебезгә бүлеп
Күтәрербез гөнаһ йөген дә.
...Димәк, таудай кайгы җиңел булыр
Таш шикелле —
Сулар төбендә.

## Кайтып төштем...

Кайтып төштем. Туган йортымда мин.
Яз сулышы иркен тугайда.
Эч серләрем сөйләр идем, әнкәй,
Таба алмыйм сине һичкайдан.

Ишетермен күк ишкәк тавышларын
Сыкы баскан шомырт яныннан,
Чумар идем бәхет дәрьясына...
Тик нишләргә белмим кайгымнан.

Кайда соң син? Өлгермәдем лә мин
Бар уемны сиңа сөйләргә.
Ә син курка идең, улыма, дип,
Авырлыклар килгән көннәрдә

Яшәмәсме куркак куян сыман —
Эз чуалтып, качып, дерелдәп,
Тап булмасмы кыек сукмакларга
Барган, йөргән, торган иләндә?

Мәхәббәт һәм курку... Мин оялдым
Син назлаган чакта кочаклап.
Эчтән үксеп елавыңны синең
Сизмәгәнмен икән ул чакта.

Теләсәм дә сине юатырга
Вакыт табылмаган нигәдер.
Килдем бүген синең яныңа мин —
Ә каршымда менә — тын кабер...

Еллар алды куе чәчләремне,
Һәм аларны назлап сыйпаган
Куллар да юк... Мин пышылдыйм бары:
«Кичерә күр берүк, хуш, анам...»

Һаман сиңа урап гел кайтырмын
Китсәм дә мин ерак-еракка...
Туфрагыңа бүген чәчәк куям,
Учларыңдай йомшак туфракка.

## Коперник һәйкәле янында

Туктатты да беркөн Кояшны ул,
Карамакчы булып үзәгенә —
Сизеп алды кинәт: Җир әйләнә!
Билгесезлектә ул йөзә генә!

— Күктә адашкансың!— дип әйттеләр.
Ул елмайды — күзләрендә чаткы:
— Юк, хәзер һич мөмкин түгел инде
Яратуы Җирне минем чаклы!

Кулларында аның чәчәк иде...
Һәм белде ул — Җир гел әйләнәчәк!—
Мәңгелектә әйләнгән бу Җирдә
Булачак ул, әйе:
Ул һәм чәчәк...

ЗӨЛФӘТ тәрҗемәләре

# Наталка Никулина,

украин шагыйрәсе

## Чулпан йолдыз

*Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»нә багышлап*

Бу юлларның авыртулы газабында яна йолдыз,
Бу юлларның яктысыннан да яктырак яна йолдыз.
Бу юлларның ачынулы авазыннан
Еллар булып җиргә туган яңа йолдыз.—

Шагыйремнең палачлары астыра алмый,
Иң дәһшәтле үтерүче аттыра алмый.
Ә кайдадыр бер кыз яши Чулпан булып...
Күз яшьләре — йолдыз. Ләкин атыла алмый...

Һәр көн саен биеклектә көн тудыра.
Үз канынnan тере сүзләр кем тудыра?
Яңа таңнар хәбәр итә кыз исеме;
Йолдыз булыр шагыйрьләрнең чын җисеме!

●

Сират күперләре кичтем — дөнья булгач,
Башкаларга оҗмах җирдә — тәмуг күрдем;
Җитте вакыт, һәм мин әйттем үз-үземә:
«Татлы хисләр бакчасына тагын кердем;
Өзелмәгән әле сазның соңгы кылы,
Түгел әле мин җиһанның соңгы колы,
Кара көйсен үләннәрем, суксын яшен!
Күзләремә килеп җиткәч, кипсен яшем...
Аҗагандай сызыла да күктә өмет —
Мин теленәм, мин терелəм, әле яшим!»

## Франческа

*Ә ул тәмуг җиле ялны белми,*
*Күңелләрне айкалдырып караңгылык əзли,*
*һәм җәзалый, һәм газаплый, рәхәт чигә.*

Данте. «Тәмуг»

Очып бара. Сумаладай кара чәчләр
Актарылып ага-ага йөзенә төшкән...
Әй карыша сылу тәне юха утка!
Янып барган чәчәк кебек бөгәрләнеп
Җәза ала. Гаебе зур: бер минутлык
бәхет эчкән...

Беркем белми... Сабый күзләр ялваралар
Зәңгәр күккә — бөек көчкә!
Якты кояш һәм кошларның пар канаты
Өнди аны сөйгәненә... Тик бер кичкә
Алар бәхетле булганнар!
Аһ, гөнаһлы Франческа!
Җәзагыз зур — тәмугта сез
Бергә булырсыз мәңгегә...

Кызык кына:
Җирдә булса — бәхет дип аталыр иде!
Мәхәббәттә — һич ярап булмый тәңрегә!..

●

Метеоритлар җирне яралыйлар.
Ә йөрәгем минем һәр мизгел
Кыштырдыймы нидер, кемдер пышылдыймы —
Гел сискәнеп тора. һәр изге
Урын ала миндә табылдыктай,
Мин кайгыртам аны. Күкләргә
Күтәрәсем килә канат куеп,
Алла булсын диеп күпләргә!

Чөнки... метеоритлар... яралыйлар...
Шуңа кирәк минем күкләр дә...

●

Бу сүзнең әлегә көе юк.
Бу әле бары тик сүз генә;
Чын көй ул бәгырьдә яралып,
Өлгереп җиткәч бер өзелә.

Бушлыкка сан бетә — яшь белән,
Кан белән тулыша да җаным,
Мәк булып кызарып ачыла,
Сулырга ни хакы бар аның?!

Һәм моны сүз белән кабатлап,
Тел белән аңлатып булмастыр...
Бу эштә бары тик табигать —
Чын җырчы, чын рәссам, чын мастер!

...Чараң юк мәк булып өзелми —
Күңелең җыр белән тулгач бер...

●

Мәхәббәтсез мин — юк, ансыз яши алмыйм.
Барлыгымны биләде бу мәҗүси яз.
Аккошым бул элеккечә, китәм диеп,
Канатларың җилпесәң дә хәсрәтем аз
Булыр кебек. Тик була күр янәшәмдә.
Дулкынлана агачларның кайнар суты —
Чәчәкләре яфракларга ярәшелгән...
Я яшь Лада [1] баш очымда такыялар
Үреп миңа кидерергә әзер тора.
Мин корбаны була алсам мәхәббәтнең!
Күңелемдә әйтелмәгән нәзер тора...
Зәңгәрлектән кояш нуры учларымны
Өтеп ала... Шашып чәчәк ата болын!
Әле берни искәрмичә, җәйрап чаба
Табигатьнең бүз баласы — нәни колын...
Әйдә, боер! Нихәл итим — бу язда мин —
Мәхәббәттә үзем теләп синең колың!..

●

Әкияттәге кебек... Кызык икән
Үз-үзеңә кайту. Башка дөнья.
Серле әверелүләр, хисләр белән
Яши башлау әле яңа гына.
Горур болан яки арсланның
Элеккечә, ләкин сүзләр белән
Нәкъ кешечә сөйләшүен телим.
Һич булмаса,
Мин аларның тәрҗемәсен беләм.
Талның салынып төшкән бәдрәләре
Иркәләнеп кәүсәсенә сарыла.

---

[1] **Лада** — борынгы славяннарда мәхәббәт алиһәсе

Гаҗәпләнәм: бу бит синең кулың
Сөйлә, диеп иренемә кагыла...
Тыпырчына кыргый хыял күңелемдә
Әкият булып яши алсам иде мин дә!

## Шәхси сүз

Бер җыенып әйтәлермен микән
Миндә булган хыял-мизгелләрне;
Вакыт-вакыт уйны узып киткән
Хәтер торышына сизгерләнеп? —
Мин бер кызкай, толымнарым саклап! —
Утка керәм, керәм солдат булып.
Разведкада, окоп, госпитальдә —
Экраннарга күчәм салмак булып...
Йөзеп кенә барып томан аша
Шау чәчәкле бакчаларга керәм.
Үзе азат иткән азат җирдә
Полкташым-бакчачыны күрәм.
Аның белән бригадирны эзләп
Басуларны иңләп очабыз без.
Йөземле җир — һәйкәл аңа бүген;
Ал мәкләрне барып кочабыз без.
Һәм өчәүләп тезләнәбез барып
Башын түбән игән көнбагышка.
Ә бакчачы-артиллерист дустым
Борып куя аны көнбатышка.
Аксыл җитен чәчле укытучы —
Черниговның әле яшь кәләше,
Кара күзле әзербәйҗан кызы,—
Туйга килмәгәнгә үпкәләшеп,
Уитменча сылу бер ханымга
(Аның үз сере бар!..) зарланалар.
Ә ул шаян, зәңгәр күзен кысып:
«Җырлыйбызмы?» Барсы җанланалар.
Ап-ак хата. Зәңгәр эңгер булып
Днепрга яңгырап җыр тарала.
Уң як ярда — белоруслар, сулда —
Украина. Опор.[1] Һәм торалар
Чыршы, нарат зәңгәр күккә карап.
Такыялы, чиккән күлмәк кигән
Карпат гуцуллары — Балтиканың
Сагынылган кунаклары килгән.
Гәрәбәле, комлы ярларына
Шагыйрь-диңгез өнсез моңын яза...
Тота алмау хәтер мизгелләрен
Минем өчен һаман да бер җәза.
Әйтә алдым микән барсын җыеп,
Әйтә алдым микән барсын диеп,
Сезнең хакта шушы җырны язам...

**АСИЯ МИНҺАҖЕВА** тәрҗемәләре

---

[1] Опор— Карпаттагы елга исеме.

## Анатолий Бик,

мари шагыйре

### Җил

Тәрәзәмне чиртә җил,
Ул кайдан килде икән?
Кайда булып иркә җил
Нәрсәләр күрде икән?

Җил күктә болыт куа,
Җил тарый тирәгемне,
Исемеңне әйтеп, гүя,
Юата йөрәгемне.

Мин дә җитез җил сыман
Канатлы булсам иде,
Таратсам иде томан,
Дулкыннар кусам иде.

Ләйсәннәр булып кайтып
Мин җиргә төшәр идем,
Исемеңне синең әйтеп,
Туктаусыз исәр идем.

●

Аңлый алмыйм: ник сөймәдем икән куптән,
Нигә соң мин күптән гашыйк булмаганмын?
Күпме көннәр, күпме еллар әрәм үткән,
Мин аларны үз-үземнән урлаганмын.

## Миклай Казаков,

мари шагыйре

### Урман юлында

Тын урманга, иркен болынга
Кояш сибә баллы нурларын.
Җитез чаба җиңел машина.
Матур да соң, урман, юлларың!

Оча сыман юлны тутырып —
Күксел «Волга» шундый тиз бара.
Шофер янына чөнки утырып
Җитен чәчле гүзәл кыз бара.

Үр менелде. Күлне уздылар.
Зур куаклык — күлнең бу ягы.
Кабинага гүя сузыла
Чикләвекнең куе куагы.

Тәрәзәдән кинәт сузылып
Бер чикләвек шунда өзде дә,
Әйтте шофер, сөйгән кызының
Күзләренә карап, тиз генә:

«Куш чикләвек! Бу — туй билгесе!
Ничек үскән тулы-тук булып!»
Кыз кызарды алсу гөл төсле,
Кыз кабынды кинәт ут булып.

Ләкин әйтте: «Юкны юрама...
Алга кара! Юлың бормалы...»
Ишетелгәндәй булды җыр аңа —
Якындагы туйның җырлары.

Ә юл матур, юл киң, юл рәхәт!
Кайнарлыгы чиксез сулышның.
Куш чикләвек, сиңа зур рәхмәт,
Сер әйтергә бүген булыштың.

Кыюсызга ярдәм иттең син,
Рәхмәт сиңа, халык йоласы!
Уйлыйдыр кыз: «Нигә үпмисең?
Беләбез бит — туйлар буласы».

## Семен Вишневский,

мари шагыйре

### Юл өстендә яткан таш

«Ни эшең бар кеше эшендә,
Тыгылма син, карап үт тә кит,—
Таш ятмый бит юлың өстендә,
Әгәр ятса — атла читләтеп...»

Шулай диләр кайбер дуслар да.
Мин ышансам әгәр аларга,
Тиеш булам бик күп чүп-чарга
Тик күземне йомып карарга.

Шундый булса әгәр уебыз,
Эшебезгә шулай карасак,
Куркыныч бар: узар юлыбыз
Ташлар белән күмелеп калачак.

## Борис Данилов,

мари шагыйре

### Мең ел яшисе килә

Тыңлый күңел, яхшы күрә күңел:
Бал кортлары очып узалар.
Алар тими, алар пуля түгел,
Бар да якын, бар да үз алар.
Куркып көтми күк күкрәвен күңел,
Һич куркытмый яшен утлары,—
Торган җирем ут утравы түгел,
Гүләмиләр сугыш туплары.
Җир сөрәбез. Йөрәк һәм күңелләр
Куанышa: — Тавыш күп! — диләр.
Алар трактор, алар танк түгелләр,
Шытымнарны таптап үтмиләр!
Җил уйната яшел дулкыннарны,
Күңел суза тыныч таң җырын.
Үтерер өчен безнең шул көннәрне
Сиптермәбез кургаш яңгырын.
Зәһәр уттан күңел туйган инде,
Күп яуды ул минем башыма.
Үз исемемне мин дә уйган идем
Рейхстагның соры ташына.
Һәм уйлыйм мин: шуңа яшәү ямьле,
Шуңа матур мари кырлары,
Чишмәләрнең суы шуңа тәмле,
Шуңа дәртле урман җырлары.
Ашкынуым шуңа чиксез минем —
Килә кырдан муллык ташыйсы!
Аруны мин эштә һич сизмимен...
Мең ел килә җирдә яшисе!

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәләре

## Сафуан Әлибаев,

башкорт шагыйре

### ҮЗ ДИҢГЕЗЕМ

●

Җәйрәп яткан суларның да икән
Бер, тиң түгел гадәт, холыгы...
Һәр кемнең дә була үз диңгезе,
Ярсулары була, тымыгы.

Кемнәрнедер тарта ташкын сулар,
Көч-хәленнән тайган чагында:
Үз ташкынын тыймак була кемдер,
Чәчрәп чумып салкын агымга.

Тәгәрәшеп яткан фәрештәдәй,
Күпләр ярда вакыт уздыра;
Кайнар дөнья кайсыларның тәнен,
Кайсыларның җанын кыздыра.

Берәүләре киткән Ак диңгезгә,
Каспиена киткән, Аралга.
Хәерлегә булсын!— Ак уй белән
Юлым төште минем Карага.

Язмыш миннән байтак сынау алды,
Бутаган юк акны карага.
Кара диңгез!
Зәңгәр күзләреңә
Хаклымындыр туры карарга.

### Асылташлар эзли бер кыз

Яр буеннан бер кыз килә,
Яланаяк, яланбаш,
Сыгылдырып буй-сыннарын,
Эзләп йөри асылташ.

Күзләрендә асылташлар
Чагылып та киткәндәй;
Нәфис тәнен назлый-назлый
Нурлар гына үпкәндәй.

Чәчкәйләрен тарата җил,
Җилбер-җилбер эндәшә;
Аякларын чут-чут үпкән
Дулкыннардан көнләшәм.

Асылташлар еш очрамый,
Ярларда алар сирәк;
Ә таптыңмы, нур-чаткыдан
Дертләп тә китә йөрәк...

Яр буеннан бер кыз килә,
Күпме җирләр узгандыр?
Асылташны кемгәдер ул
Бүләк итәр булгандыр.

Аның белән асылташлар
Эзләшеп үтәр идем,
Иң асылы үзең, диеп,
Алыр да китәр идем.

Вак ташта эзләр калдырып,
Китканче ерак-ерак!..
Үкенечле булмас иде,
Чыксак та диңгез урап.

Ничек кенә тыярга соң
Йөрәгемнең ялкынын?
Дулкынлана күңелләрем,
Очар булам талпынып.

Күңелләрем синең янга
Ашкынудан арымый,
Очар идем, юлның ерак
Булуына карамый.

Әллә нигә болганчыклы
Уйларыма бикләнәм:
Килер идем әллә кайчан,
Көтәреңә шикләнәм.

Безнең кабат очрашуга
Кайчак күңел ышанмый.
Ак дулкыннар, акчарлактай,
Талпына да оча алмый...

## Әйтче, дулкын

— Нигә шулай шаярасың
Әйтче, дулкын?
— Шаян җилдә яралганга
Шаян холкым.

— Ераккамы син барасың,
Әйтче, дулкын?
— Бик еракка, җаннарыма
Нурлар тулсын!

— Нигә гелән сикерәсең,
Әйтче, дулкын?
— Тып-тын калсам, мине көтә
Салкын упкын.

— Нигә шулай йөгерәсең,
Әйтче, дулкын?
— Ярны барып бер үбәргә
Насыйп булсын!..

## Әллә нинди чагы күңелемнең

Әллә нинди чагы күңелемнең
Кайсы вакыт сабыр бигерәк,
Гүя белми ярдан ашуларны,
Тып-тын гына ята изерәп.

Әллә нинди чагы күңелемнең,
Үтә түзем, үтә инсафлы:
Төпләрендә үзем ача алмаган
Асылташлар бардыр ничаклы.

Әллә нинди чагы күңелемнең,
Өнсез генә давыл көткәндәй,
Моңсу гына йөзгән болытлардан
Ачылгач та балкып киткәндәй.

Әллә нинди чагы күңелемнең,
Үтә сизгер — җилдә тын калмый.
Шаулатмагыз берүк...
Диңгез сымак,
Бер дуласа, бик тиз тына алмый.

Күңелемнең әллә нинди чагы...

Әкрам Әйлисли

# ОФЫКТАГЫ ҖЫЛЫ УРМАН

ПОВЕСТЬ

## I



Олы юл чатыннан алып үз капкаларына чаклы Кадыйр авылның бер егете белән кайтты. Әллә кай арада гына, бер-берсен куышып, тыкрыклардан йөгерешеп чыккан малайлар койма буена җыелып та өлгерделәр.

Кадыйр капканы сак кына ачып керде, айванга[1] кадәрле өч баскыч араны бер генә сикерде. Ишек тә бикле түгел иде. Димәк, Солтанат өйдә. Менә ишек ачылды, бусагада Солтанат күренде.

Озак еллардан соң бу беренче күрешү иде. Ләкин алар арасында исәнләшү дә, кул бирешү дә булмады. Йөзгә-йөз килеп, бер хәрәкәтсез басып тордылар. Хатын — гүя салкын стена, ир — гүя корыган агач.

Күпмедер вакыт үткәннән соң гына Кадыйр сүз башлады.

— Исәнме, Солтанат... Менә... кайттым...

Хатын керфеген дә селкетмәде.

— Кайткансың,— диде ишетелер-ишетелмәс кенә.— Ходайга шөкер!

Солтанат бусагага баскан. Кадыйр аның каршында, айванда. Чемоданының авырлыгын да онытып, һаман күтәргән килеш басып тора.

Бераздан гына Кадыйр, исенә килеп, чемоданын идәнгә куйды. Солтанат та, кузгалып, аңа юл бирде. Ул арада инде малайларның кыюраклары ишегалдына ук кереп килә, кайсылары кызыксынуын тыя алмыйча, койма башыннан үрелеп карый иде. Кадыйрның кайтып төшү хәбәре бөтен авылга таралып өлгергән, күрәсең — аның элекке дусты, шофер Касыйм, «ярты» кыстырып, шатлыгыннан балкып, ихатага килеп керде. Ул исе китмичәрәк торган Кадыйрны каты итеп кочаклап алды, битеннән үпте. Аннары яшь пәрдәсе томалаган күзләрен Солтанатка төбәде, чөнки Кадыйр да бу минутта аны бөтенләй күрмәгән шикелле Солтанатка карап каткан иде.

Бераздан алар, стенага сөялгән зур яссы ташны кузгатып, шуңа утырдылар. Ә Солтанат, ишек янагына сөялгән килеш, басып тора бирде. Зур булып ачылган күзләре ниндидер билгесез әйберне эзләгән сыман әле җиргә, әле шешәгә, әле Кадыйрның чемоданына текәлә, аннары карашы еракта бик еракта күренгән Кура урманы өстендә туктала. Ул кымшанып куйгач кына, Кадыйр аның моңсу-сүрән күзләрендә ниндидер тере очкын уянганлыгын искәреп алды. Солтанат коридордан су чүлмәге алып чыкты да: «Су алып кайтам»,— дип китеп тә барды. Шундый итеп китте, әйтерсең лә, бер чүлмәк су булмаса, җирнең астыөскә киләчәк.

Солтанат күздән югалуга, Кадыйрның дусты шешәгә ымлап күз кысты, тамак кырып, кулын кулга ышкыды (элек алар, чибәр кыз күргәч, нәкъ шулай күз кысышып алалар иде дә нәкъ шулай тамак кыралар иде, нәкъ шулай кулны кулга ышкып куялар иде...). Касыйм аракы салырдай нәрсә эзли башлады, шунда гына малайларны искәреп алды. Җәһәт кенә аларны ишегалдыннан этеп-төртеп чыгарды да, якын-тирә-

[1] Айван — терраса.

дә беркем дә калмагач, капканы ябып, аягы белән генә этеп, астына кирпеч кыстырды һәм Кадыйр янәшәсенә килеп утырды.

— Нигә сөмсерең коелды?— Ул, гаҗәпләнеп, дустына карады.— Бар инде, стакан апчык!

Кадыйр селкенмәде дә. Ярты литрлы банка белән чүмечне Касыйм үзе коридордан кереп алды, аракыны тигезләп бүлде.

— Әйдә, тоттык!— дип Касыйм банканы күтәрде.— Эчеп җибәр — кеше булырсың! Мин хәзер китәм.

Аның тизрәк олагуын теләгәндәй, Кадыйр бер сулышта эчеп бетерде дә Касыймның кесәсеннән чыккан чикләвек төшләрен авызына тутырды.

Аннары Касыйм кузгалды, сукмактан капкага кадәр тын гына килделәр, аерылышыр алдыннан гына сүзгә җай чыкты.

— Нишләп болай соң әле син?— Касыймның ник озак кайтмый тордың дип сорарга теләвен Кадыйр бер сүздән аңлап алды.

— Бөтенләй кайтмаска уйлаган идем.

— Ташлап китеп булмый идеме?

— Кайтырга җыенганым да булмады.

— Кайларда югалып йөрдең соң?

— Белоруссиядә.

— Өйләнденме?

— Өйләндем.

— Балаң да бармы?

— Бар.

— Шома гына ычкындыңмы?

— Ничек?

— Ну... Адресыңны белмидер ич?

— Белә...

— Балаң ничәү?

— Икәү.

— Алимент түләрсеңме?

— Белмим әле.

Касыйм бүреген салып, башын кашып алды, Кадыйрның үтүкләнгән чалбарын, ак күлмәген, галстугын күзеннән үткәрде, соңыннан гына йөзенә күтәрелеп карады.

— Мине берни дә аңламый дип уйлама, Кадыйр, юл арыткан сине, йоклап ал. Ике баланы читтә калдырып кайту уен түгел. Күренеп тора, Солтанат та кайтуыңны өнәми. Әкренләп җайланыр... Синме соң бу, Кадыйр! Ачуланма инде миңа... Алыштырып җибәргәннәр сине, билләһи!

Кыска буйлы Касыймга дустын үбәргә үрелү өчен аяк очларына басарга кирәк булды. Аның хискә бирелүен сизеп, Кадыйр башын ия төште. Касыйм аның муеныннан кочып алды, җылый-җылый, кәлә-кәлә Кадыйрны яшькә чылатып бетерде. Күз яше аша елмаеп, китеп тә барды.

Буш шешәне Кадыйр ботинка очы белән читкәрәк этәрде, аннары, иелеп алып, ихата түрендәге куаклыкка томырды. Айван буйлап арлыбирле йөренә башлады. Аяк астында торган банка белән чүмечне дә стена кырыена куйды. Чемоданын почмакка илтеп урнаштырды. Әле бая гына Касыйм белән икесе утырган ташны үз урынына куйды. Банка белән чүмечне яңадан алып иснәп карады да тәрәзә төбендәге сукыр лампа кырыена каплап куйды.

Тагын айван буйлап йөренә башлады. Айван коридор һәм зур бүлмә озынлыгында. Коридорга керә торган ишек ачык, ә тәрәзә бикле иде. Кадыйр, пыялага маңгаен терәп, эчкә карады. Бүлмә бик пөхтә җыештырылган. Идәннең бер яртысына — палас, икенче яртысына брезент җәелгән; стена буенда иске тимер караваT тора, кабартып куелган ике

мендәр чигүле ак япма белән капланган, көзге янындагы самавыр да шундый ук эскәтер астында утыра, бүлмәнең кояшка караган ягында, тәрәзә төбендә гөлләр...

Кадыйр тәрәзәдән китеп, ачык ишек төбендә тукталды. Коридор караңгы иде, әчтә ни барлыгын күз иялэшкәнче шәйләрлек тә түгел — әнә җиз таз, куна тактасы, иске чүлмәк, ванна... Күпме тыелып торган Кадыйр шушы кадерле әйберләрне күргәч чак үксеп җибәрмәде: йөрәге кузгалды, Солтанатка әйтәсе күңелендә кайнаган сүзләрен ул иске чүлмәккә, җиз тазга, ваннага карап сөйли башлады.

— Кайтуыма шатланмадың, белергә дә теләмисең. Ярый. Барысы да булды инде, кыйный идем шул сине, каты бәрелә идем, онытмагансың. Төннәрен әчеп кайтып, таңга кадәр йокы мазасы бирми идем үзеңә. Рәнҗеттем шул сине, булды! Дөнья яктысы күрсәтмәдем сиңа, Солтанат, беләм! Менә, кайтып төштем да, бусагаң төбендә торам. Атна буе кайттым мин сиңа!.. Ярый, синең өчен чит булыйм да ди, бөтенләй чит кешегә дә бит якты чырай күрсәтәләр, чәйгә утырталар!.. Ә син?! Бер генә тапкыр күтәрелеп карасаң икән, бәлки мин бөтенләй үзгәргәнмендер, бәлки мин бөтенләй бүтән кешедер — күпме еллар үткән бит инде, Солтанат!..

Кадыйр үзенең җылавын сизеп алды. Иренен әче тоз яндырмаса, җылавын ул мөгаен, сизмәгән дә булыр иде... Үз-үзенә ачуы килгән ир, тиз генә кульяулык алып, бит-күзләрен сөртте, яңадан ишеккә таба борылды.

— Шуны бел, Солтанат, барыбер кермим өеңә.— Бармак янап, ул шулай әйберләргә кычкырды.— Бусагаңнан атлап керәсем юк... Керәм икән, ир түгел мин, чүпрәк. Димәк, тамчы да намусым калмаган. Кешечә кыланмыйсың икән, юньләп «исәнме» дип тә әйтмисең икән, бу йортта минс күрмәссең. Синнән тора: теләсәң, калам, теләмәсәң, китәм. Китәм! Китәм! Китәм!..

Ул, каты-каты басып, тагын айван буйлап йөренә башлады. Әчтән һаман бер үк сүзне кабатлый торгач, күз алдына поезд килде. Ерак юллар буйлап чапкан поездның корыч тәгәрмәчләре корыч рельсларга бәрелеп бер үк сүзне кабатлады: «Китәм... Китәм... Китәм...»

Авыл өстенә кичке эңгер төште. Почмактан-почмакка атлаган Кадыйрның телендә инде икенче сүзләр: «Алты ел!.. Алты ел!.. Алты ел!..»

Ниһаять, ул, арып, култыксага таянды. Моннан өй түбәләре, биек агач ябалдашлары ачык күренә. Авыл һаман шул — бу алты ел булмаган да диярсең. Ишегалдында да үзгәреш юк. Груша агачы корыган икән — төбе генә тырпаеп калган. Өй эчендәге әйберләрне дә күңеленнән барлап чыкты — карават шул ук урында, самавыр, савыт-сабалар, пәрдәләр дә элеккечә. Юк, ниндидер үзгәреш бар бугай, ул аны бер карауда искәрмәгән генәдер. Барысын да тагын бер тапкыр хәтереннән үткәргәч, аңлап алды: брезент юк иде бит элек. Бөтен идән паласлар белән капланган иде. Лимон агачы бар иде бит әле аларның, тәрәзә төбендә, чүлмәккә утыртылган гөлләр янында лимон агачы үсә иде.

Ул тагын авыл өстенә күз салды. Чирәп түбәле йортлар. Нык нигезле, ышанычлы йортлар. Ә агачлар, тамырларын тирәнгә җибәреп, җир үзәгенә ябышканнар, кузгатып кара син аларны урыныннан! Самавыр, мендәр япмасы — барысы да авыр булып тоела, куна тактасы да, җиз таз да, ванна да моңарчы гүя бер дә кузгатылмаган. Бөтен җирдә — сулышны кыса, җанны баса торган ниндидер тораташ авырлык. Кинәт, башына суккандай, Кадыйрга бер уй килде: монда алты ел гомер үтмәгән — менә хикмәт нәрсәдә икән! Шушы тетрәнүле уйдан изелгән ир, күкрәге белән култыксага ятып, сулышсыз калгандай, кулларын салындырды. Аның инде бөтенләй бүтән кеше икәнен аңламас Солтанат, аң-

лый алмас, чөнки ул үзе һаман да элеккечә калган. Кагылмаган монда алты ел гомер, кагылмаган...

Кадыйр авыл артындагы офыкка, кичкә эңгер җәелгән урман сызыгына карады. Урман артындагы Кура елгасы моннан күренми иде. Ул турыдагы өем-өем болытлар кызгылт төскә манчылган. Бая, Солтанат ул якка карап торганда, болытлар юк иде әле.

Кадыйр ачудан, көчсезлегеннән чак елап җибәрмичә, тагын айванны иңләп-буйлый башлады. Кинәт аның башына шундый уй килде: «Солтанат елгага ташланса? Я, хода! Нигә дип кайттым соң әле мин!.. Ярый! Ничек кайтсам, шулай китеп тә барырмын!..»

Бәлки Солтанат суга дип китмәгәндер, үз өйләрендәдер, аның бит эти-әнисе бар. «Шунда киткән булса иде!.. Кая барсын соң ул үзләренә кайтмыйча?..»

Урамга чыгып, беркемгә дә күренәсе килми Кадыйрның. Бала чактан ук ятим үсте ул, ерак туганнарыннан кала беркеме дә юк авылда. Кайсылары аннан йөз чөерделәр — кемгә кирәк юлдан язган җилкуар — кайсыларын ул үзе танырга теләмәде. Бөтенләй бүтән Кадыйр иде бит ул. Элеккеге Кадыйр авылдашларын кешегә санамады: әкәмтөкәмнәр, бөҗәкләр, хәшәрәтләр... Эчеп исергәч, шул сүзләрне күзләренә карап әйтә иде: «Бөҗәкләр сез, хәшәрәтләр, әкәм-төкәмнәр!.. Кабырчыкка яшеренгәнсез дә шуышасыз. Аракы эчмисезме? Акча җыясыз! Сугышырга теләмисезме? Йөзегезне җимерүдән куркасыз! Аллага гыйбадәт кылган буласыз, ә — теге дөньяда җылы урын кирәкме! Бөрешеп катачаксыз барыгыз да, этләр кебек!..»

Тау битләренә ябышып күтәрелгән өйләр... Тамырларын җирнең үзәгенә кадәр җибәргән агачлар... Алар барысы да дөнья яралышыннан бирле шулай торалардыр кебек. Бу өйләрдә яшәүчеләргә һич тынгы бирмәде Кадыйр. Бу өй хуҗаларына гына түгел, аларның алласына да, мулласына да эләкте. Кызларына, хатыннарына да көн күрсәтмәде ул. Машинасын әкренәйтеп, кабинадан сузылып кына берәр кызның баш яулыгын тартып алу да аңа берни тормый иде. Авылның хөрмәтлесе саналган аксакал өстенә машина белән килүме, чал чәчле карчыкларның сулы чиләгенә ком сибү дисеңме, йомырка кабыгы яисә тәмәке төпчеге ташлап китүләр дә булмады түгел, булды. Көн күрсәтмәде ул берсенә дә, йодрыгын эшкә җигүдән дә тайчанмады... Кайчан гына диген — алты ел элек!..

Ул чакта малай гына булган. Алты ел. Алты ел... Алты ел...

Шушы алты ел гомергә өмет итеп кайткан иде ул, ә хәзер менә төшенеп бара: монда алты ел вакыт үтмәгән. Кешегә дә санамыйлар бит аны, күрешергә килүче дә юк, Солтанат та суга дигән булып качты. Алты ел гомернең монда үтмәгәнлеген тою Кадыйрның җанын чиксез рәнҗетә иде.

Бая җыелган малайлар да бүтән күренмәделәр. Кадыйрның кем икәнен өйләрендә ишеткәннәрдер. Карак, хулиган, бандит, төрмә сагынып җылый аны! Өенә якын килмәгез, ул тирәдә уйнамагыз, алмасын өзә күрмәгез. Малайларны шулай дип куркытканнардыр, күренерләр иде югыйсә.

Шул ук йортлар, шул ук агачлар. Калын кәүсәләре арасыннан ут алынган тәрәзәләр күренә. Кызык бит, бу түбә астында яшәүчеләр аның кайтып төшкәнлеген беләләр микән? Беләләр, бөтенесе дә беләләр булыр... Ярар. Килмәсеннәр, күрергә теләмәсеннәр дә ди. Тик әле генә капка янында уйнаган малайларга хулиган, угры, юлдан язган дип аның турында сөйләмәсеннәр генә иде... Өйләрендә өлкәннәрнең балаларга шулай дип әйтүләрен күз алдына китергәч, Кадыйрның көче дә, бер өмете дә калмады. Аякларының хәле китте. Тәрәзә каршына утырып, башын тезләренә куйды.

Китәр алдыннан соңгы көнен Кадыйр юньләп хәтерләми. Өенә ул исереп кайтты. Үз аягы белән түгел, Касыйм сөйрәп кертте аны. Төнлә ни булганын Кадыйр бөтенләй исеннән чыгарган. Шунысын белә: эчкән чакларында Солтанатка бигрәк тә тартыла иде ул, үбәргә, иркәләргә, сабый бала кебек итеп уйнарга ярата иде. Андый минутларда хатынының куе чәчләре аны юләрләндерер дәрәҗәгә җиткерә иде. Калын толымны сүтеп, ишелеп торган чәчләрне мендәр өстенә тарата да, куе чәч арасына йөзе белән чумып, шашып үбә, елый башлый. «Чәч исең әниемне хәтерләтә, аңлыйсыңмы, әниемне хәтерләтә. Юсаң да, юмасаң да, шул ук ис — әнием исе. Нигә алай икән, Солтанат?» Ул, аның чәчләрен үбә-үбә, тагын елый... Нәкъ менә шундый минутларда Солтанат гадәттән тыш кырыс була, аны куа, якын җибәрмәс өчен ни генә кыланмый; ачуланышулары да шуңардан чыга торган иде. Төн уртасында торып, Солтанат этисе өенә кайтып китә. Кадыйр исә, кичтән үк, я икенче көнне иртән, яисә бер-ике атнадан хатынын яңадан барып ала иде. Әллә соң армиягә китәр алдыннан булган соңгы төндә гафу ителмәслек берәр нәрсә эшләп ташлаган иде микән? Юк, хәтерли алмый, упкынга төшеп киткән ул төн. Ә икенче көн бүгенгедәй күз алдында. Кояшлы иртә. Урман юлы. Аңа үч иткәндәй, агачлар гадәттәгедән матуррак күренә: кемдер юып алган диярсең, шундый сафлык, шундый чисталык, һәр яфрак үзенә аерым җемелди. Кура елгасына, паромга кадәр алар яшелдән-яшел урман юлыннан бардылар. Кадыйрның башы авырта, күз аллары караңгылана, ә урман сокланып туймаслык, рәт-рәт агачлар шундый купшылар, шундый бәхетлеләр. Әллә инде башы чатнап авыртканга, әллә инде армиягә китәсе булганга, Кадыйр ул иртәдә шайтан кебек усал иде. Алар пышылдап диярлек, тын гына сөйләшеп бардылар — монысын ул яхшы хәтерли. Шунысы сәер — кайсы агач турында, нинди сүз әйтелгәненә кадәр ул бүгенгедәй хәтерли.

— Я, киткәнемә сөенәсеңме?

— Юк.

— Дөресен әйт, мин бит чынлап сорыйм?

— Үзең ничек уйлыйсың: сөенәмме мин, сөенмимме?

— Сөенәсең!

— Алай беләсең икән, әйтәм, барысын да әйтеп бирәм! Минем урында, Кадыйр, кем генә шатланмас икән! Сиңа түзгән хатын-кызны әйтерием. Кем чыдап торсын синең белән?! Якты көн йөзен күргәнем булдымы? Бер генә тапкыр булса да өйгә кешечә кайтып кергәнең булса иде. Гел исерек, гел йодрыклар белән!.. Өйдә дә тормыш юк, урамга чыксаң да, кеше күзенә күренергә оят... Китәсең менә, кем дә булса озатырга килдеме? Синнән котылганга шатланалар гына... Чын күңелеңнән әйтеп кара: шундый ирдән котылу сөенечме, сөенеч түгелме?

Шушы коточкыч авыр сүзләрне дә ул тын гына, ярым пышылдап кына әйткән иде бит... Хикмәт — тыныч әйтүдәмени, аның сүзләре Кадыйрның йөрәген чәнечте.

— Ярый. Кайтмам, курыкма. Иң беткән кеше булам, әгәр әйләнеп кайтсам!..

— Үз-үзеңне бетермә... Кирәкми... Кайта күрмә, Кадыйр! Алла исемен кушып сорыйм — кайтма! Әйбәт җирләр күп бит. Берәр җирдә төпләнеп калырсың, өйләнеп, балалар үстерерсең. Миннән ирек сиңа, тик кайта гына күрмә!

Ул бу сүзләрне карт агач кәүсәсенә сөялеп әйтте, Кадыйр тешен кысып барды барды да, икенче агач турына җиткәч, кырт борылып:

— Борчылма, кире кайтмам,— диде.

Паромга кадәр алар сүзсез генә бардылар. Аерылышыр алдыннан әйтелгән сүзләр Кадыйрның әле дә колагында.

— Кайтмыйм, белдеңме! Сүземдә тормыйм икән — ир түгел, чүпрәк, иң соңгы хатын-кызга сана!

— Үз-үзеңне сүкмә, Кадыйр... Кайта гына күрмә. Ир бул — сүзеңне үтә.

Инде паром кузгалырга тора, Кадыйр әле һаман Солтанаттан аерыла алмый.

— Берәр сүз әйт инде ичмасам!

— Ни әйтим соң?

— Берәр җылы сүз әйт! Әйт инде...

— Уңышлар телим сиңа,— диде Солтанат.— Исән-имин калырга язсын.

«Кайт» дип барыбер әйтмәде...

Кадыйр хатирәләре белән бүгенге арасында тәмам арып йокыга талды. Төшенә әллә нинди чытырманлы урман керде. Дөресрәге — урман да, юл да, паром да шул ук иде... Солтанат та нәкъ элеккегечә, тик эч турысы гына кабарып, күзгә бәрелеп тора. Агачка сөялгән дә шәлен һаман аскарак тарта. Нигә соң әле ул һаман ул вакыттагы Солтанат урынына бүгенгесе пәйда була? Кадыйр яңадан урманны, паромны күз алдына китерде... Кинәт ул сикереп торды. «Солтанат авырлы иде бит! Балабыз булырга тиеш иде!» Кадыйр тәрәзәгә килеп, шул баланы күрергә теләгәндәй, караңгылык эченә текәлде.

## II

— Гөлгәз апа! Гөлгәз апа!

Солтанат капка каршында тора. Гәүдәсе калынайган, битендә кара тутлар. Айванда да, ишегалдында да беркем күренми. Баскыч янында, өрергә кызыгып, көчек бөтерелә. Аның тирәсендә тавыклар нидер чукыйлар.

— Гөлгәз түти!— дип тагын эндәшә Солтанат.

Ишегалды түреннән хатын-кыз тавышы ишетелә.

— Хәзер, кызым, хәзер! Өйгә керә тор!

Солтанат ишегалдына үтә, бераздан куаклар артыннан кулына чүлмәк тоткан Гөлгәз түти күренә.

— Утырып тор, кызым,— ди ул.— Бер-бер хәл булдымы әллә?

Гөлгәз түти айван каршында яткан кәҗә тиресен алып баскычка җәя.

— Карап-карап торам да, соңгы аеңа кергәнсең икән инде. Күп тә үтмәс — котылырсың да. Утырып тор, Солтанат, утыр, баланы тынычсызлыйсың.

— Рәхмәт, Гөлгәз түти, хәзер кузгалам мин. Йомышым шул иде, Гөлгәз түти, Сонаны бер-ике төнгә куна җибәрмәссең микән?

— Сонаны?— дип, Гөлгәз түти бераз уйланып тора.— Барыр да ул анысы... Янында аңлый торганрак, дөнья күргән хатын-кыз булса, әйбәтрәк түгелме, диюем. Синең бит әле бу — беренчесе. Әнкәңне нигә чакырмыйсың?

— Булдыра алмый шул, ничә көн инде урында ята.

— Авырыймыни? Мин каршы түгел, Сонаны алып кит алайсам, әнкәң янында икенчерәк булыр иде. Авыру булса да, үз бәгыре... Үз өеңдә стеналар да җылыта, ди.

— Әтидән кыен, Гөлгәз түти.

Гөлгәз аңа уйчан күзләрен төби.

— Больницага барсаң, ә? Анда әйбәт карыйлар, ди. Көнгә өч тапкыр ашаталар, бушка барсы да, синнән бер тиен дә алмыйлар...

— Анда бармыйм, Гөлгәз түти. Өйдә тудырам. Үтәр әле. Үлеп китмәм бит! Үлсәм дә... Миңа кырыемда кеше булу кирәк. Тулгаклый башласам, Мөнәвәрә әбигә йөгерергә...

— Ярый алайса, кызым. Бар, кайт син, кайт, аякларыңа көч китермә. Мәктәптән кайту белән кызны җибәрермен. Бар, ятып торырга тырыш, сиңа бик кузгалырга ярамый хәзер...

Кадыйр киткәнгә ай ярымнар үткәч, төнлә белән Солтанатны тулгак тота башлады. Тик кендек әбисен чакырырга туры килмәде. Ничек бала тапканын ул хәтерләми дә калды. Күзләрен ачса: янәшәдә Сона тора, ә караватта, мендәр кырыенда, марляга уралган бала ята, җилкәсе зәп-зәңгәр — үле туган бала. Сонаның елап торуын күргәч тә Солтанат тавыш чыгармады, күзләрен генә йомды. Аның керфек арасыннан тын гына аккан күз яшьләрен бала биләгән марля кисәге белән Сона сөртә башлады.

Шул ук көнне, кичке шәфәкъ төшкәч, ни үле, ни тере Солтанат, төрелгән баласын алып, зиратка китте.

Кабер казучы инде үз эшен эшләгән, бәләкәй генә кабер янында, биленә таянып, Солтанатны көтеп тора иде.

— Менә монда куй! Үзең төшерергә тиеш. Җайлырак кыймылда син!

Димәк, Коръәндә шулай әйтелгән: баласын кабергә ана үз куллары белән төшерергә тиеш. Бу бәләкәй кабер өстенә таш та куеп булмый инде. Бер айдан, ике яисә өч айдан мондый каберләр җир белән тигезләнә, бәлки бу да Коръәндә алдан күрелгәндер. Ә кабер тирән казылган, төбенә кул чак җитә.

— Ни көтәсең инде,— дип кычкырды кабер казучы.— Төшер әйдә!

Тагын кычкырмасын бу дип, Солтанат тизрәк иелде, баласын кабергә төшерде. Тураеп баскач, ул караңгы кабер төбендә, баласы белән янәшә генә уч төбе кадәр кояш нурын күреп алды.

— Кулларын күкрәгенә кушырып куй!

Солтанат, иелеп, сабыйның кулларын күкрәгенә куйды.

— Бер уч туфрак ташла!

Солтанат анысын да эшләде.

— Булды хәзер. Читкәрәк китеп тор!

Ул күндәм генә буйсынды, кабергә зур булмаган яссы таш куеп, өстенә туфрак төшерә башлагач, кабер казучыдан йөзен читкә борды. Җир куенында, яссы таш астында баласы белән бергә уч төбе кадәр генә кояш яктысы да калгандыр кебек тоелды аңа...

Берничә ай үтүгә кабер җир белән тигезләнде. Әмма ул кичне, шәфәкъ нурларын, уч төбедәй кояш яктысы белән янәшә күмелгән баласын Солтанат беркайчан да хәтереннән чыгара алмады.

Бәләкәчен күмгәннән соң Солтанат урамда да, чишмә янында да күренмәс булды. Ләкин күп тә үтмәде, шул ук авыл урамында, шул ук чишмә янында бөтенләй бүтән Солтанат пәйда булды: кычкырып сөйләшә, яңгыратып көлә, һәркемнең хәлен сораша. Әлеге яшь, сүзчән Солтанат кирәк-кирәкмәгән урында да үзенең этисе йортына кире кайтуын һәркемгә ачылып сөйли иде. Ир йортыннан ата йортына кайту әллә ни зур бәхет түгел әлбәттә, аның Кадыйр белән араны тәмам өзүенә шатланганын авыл халкы аңлый иде билгеле. Кемне дә булса чәнчеп, гайбәтен сатарга яраткан авыл ирен озаткан Солтанатның шатлыгына кагыла алмады...

### III

Кай арада төн куерган соң әле? Якты йолдызлар астында йокыга талган авыл үзе дә серле бер төш, хыял кебек: өйләр юк, бары күләгәләр генә. Күктә йолдызлар җемелди, җирдә бакалар сайрый, шул тавышлардан зеңгелдәгән төн эчендә җирдәге бакалар саны кара күк йөзенә тезелгән йолдызлар санына тигездер сыман.

Кайдадыр еракта сузып-сузып эт улаганы ишетелә. Аның кызганыч тавышы йөрәккә иңә, караңгылыкка авыр дәһшәт сала.

Кадыйр, лампа яндырып, идәнгә куйды, баш астына чемоданын китерде дә төренеп ятты.

Авыл читендә, кинәт шау-шу кузгатып, этләр өрергә тотынды, аларга башкалары кушылды. Кадыйр торып утырды, агачлар арасыннан шәйләнгән капка ягыннан күзен алмады. Менә капка шыгырдап әкрен генә ачылып, әкрен генә ябылды. Кем кергәнен Кадыйр агач астыннан күрә алмый иде, ул, бер сүз дә дәшмәстән, тын гына көтеп утыра бирде. Этләр һаман өрә, бакалар беравыздан кычкыра... Аяк тавышын ишетмәсә дә, шунда ук күреп алды ул аны. Агач астында Солтанат басып тора, бер кулында кувшин, икенче кулында туфлие.

— Кер, Солтанат, курыкма! Мин монда утырганга карама, кер!— Кадыйрның тавышы кызганыч, ялынулы булса да, Солтанат һаман кымшанмады.— Кереп ят, Солтанат. Мин монда кунам, айванда. Кереп ят, алай кыланма.

Солтанат, бер-ике адым атлап, тагын тукталды.

— Йоклыйсыңдыр дип уйлаган идем...— дип, айванга күтәрелде, култыксага сөялеп басты.

— Курага барган идем, суга ташланырга дип... Нигә кайттың син, Кадыйр?! Нигә?! Алты ел буе нинди рәхәт булган иде. Кайтып кердең дә... кая барырга хәзер, башымны кая куярга...— Ул елый-елый күз яшьләре аралаш сөйли иде.— Сүз биргән идең бит, адәм актыгы булам кайтсам, дип ант иткән идең... Миңа нишләргә соң инде хәзер, Кадыйр?!

Ул һаман кымшанмыйча пальтосы өстендә утыра, ә Солтанат теге вакыттагыча тын гына көточкыч сүзләр сөйли.

— Кара төнгә кадәр мин елга ярында утырдым. Йорт-җиреннән куылган сукбай кебек урманда йөрдем. Очрамады бит шунда бүресе дә, котырган кабаны да... Суга ташланырга уйлаган идем... Әти кызганыч... Сырхаулап тора... Бер көн йөрсә, өч көнен ятып үткәрә. Үлеп китсә, күзен йомдырыр кешесе дә калмый бит. Әти булмаса, Курадан кайтып керәсем юк иде. Кайтмый идем!

«Минем якка күз дә салмый, күралмый ул мине. Бер генә тапкыр күтәрелеп карасын иде, аңлар, минем инде башка кеше икәнлегемә ышаныр иде...» Әмма Солтанат аңа әйләнеп тә карамады, ул якка башын да бормады, аның карашы төн белән кушылган иде.

Бакалар кычкыра, этләр өреп куя, чиста күк йөзендә йолдызлар җемелди. Ниһаять, Солтанат, караңгылыктан аерылып, аның ягына күз салды, Кадыйрга сүз башларга шушы бер караш җиткән иде.

— Урманга киткәнеңне белдем мин,— диде ул.— Үзеңнекеләрдә куна калырсың дип уйлаган идем.

— Булдым мин анда. Өч мәртәбә килдем капкага... Хәзер дә шуннан килешем. Авыру янына ничек барып керим? Син кайтканны ишетмичә калмагандыр, барыбер монда җибәрер иде. Анда кунуымны өнәп бетерми ул. Төнлә үлеп китәрмен дә, куркудан йөрәгең ярылыр, ди. Картны жәлләсәң иде, Кадыйр, ул бит сиңа гел яхшылык кына кылды. Авыру ул, аягына баса алмас инде. Китәргә иде сиңа! Болай тыныч кына дөнья куялмас ул...

Солтанат, бүлмәгә үтеп, лампага ут элдерде, ишекне эчтән бикләп куйды; аннары ут сүнде, тагын янды. Солтанат, кабат чыгып, коридор идәненә брезент җәеп, урын-җир хәстәрләде дә, кереп, эчтән ишеген бикләде. Тәрәзәгә килеп, Кадыйрга эндәште:

— Урын җәйдем анда, бар, ят! Айванда туңдырыр. Лампаны да ал.

Кадыйр, лампаны алып, коридорга кергәндә, Солтанатның уты сүнгән иде инде.

— Солтанат,— дип эндәште ул бераздан.— Бер нәрсә сорыйсым бар иде синнән.

— Ят инде, Кадыйр, берни дә сорама миннән.
— Юк, әйт әле, нишләттем мин сиңа? Теге, аерылышасы төндә? Әйт әле, Солтанат? Аннары ятарсың, комачауламам сиңа.
Киенгән килеш кенә яткан Солтанат караңгы түшәмгә карап, тын гына уйланды, аннары борылып:
— Ни эшләгән булсаң, шуны эшләдең инде,— диде.— Нигә аны хәзер кузгатырга. Син шуны бел: китмисең икән — менә тере килеш күрәм димә! Синең хатының булалмыйм мин беркайчан да!
Кадыйр ишеккә килеп:
— Мин бик каты эчкән идем,— дип, пыялага иренен терәп әкрен генә дәште.— Берни дә хәтерләмим, ышанасыңмы? Ул төндә нишләгәнемне белергә тиеш бит инде мин.
Караваt такталарын шыгырдатып, Солтанат торып утырды.
— «Ул төндә, ул төндә!» Башка төннәр турында нигә сорамыйсың, ә?! Ун, унбиш көн алдагыларын? Мин интегеп ята идем, җиденче ай киткән иде бит. Син миңа нәрсә әйттең шул чагында, Касыйм барында җитмәсә! Хәтереңдәме? «Кыз туса, үтерәм. Шушы кулларым белән буып, бәдрәфкә ташлыйм!» — Синең сүзләр. Карындагы баламны куркыттың! Тулгак башлану белән, мин аңымны җуйдым, ә күз алдымнан кул китми! Зур, йонлач кул... балама таба сузыла! Карыйм, я хода, бу бит синең кул! Син идең ул, Кадыйр! Аңга килсәм, зәп-зәңгәр минем бәләкәчем, үлгән... буып үтерелгән... Күземне йомдым, ә колагымда синең сүзләр. Исеңә төшердеңме, Касыйм барында әйттең! Әгәр син булмасаң, исән кала иде минем улым... Күмдем... Белеп тор, Кадыйр, шул көнгә кадәрлеләре барысы да кичерелгән иде... Синә озаткач, урманда әйткәннәремә үкенеп тә йөргән идем. Саташкан чагында сине күргәч, балам үле тугач, барысы да киселде. Шул көннән башлап, инде менә ничә еллар буе синең кайтмавыңны сорап ходайга ялварам...
Солтанатның тавышы шунда өзелде, ул мендәренә йөзтүбән капланып ятты да изелеп йоклап китте.

Аның бу сүзләреннән тетрәнгән Кадыйр, чишенеп, утны кысыбрак куйды да урынга сузылды. Бер уйсыз, бер хәрәкәтсез бик озак ятканнан соң кинәт кенә үзенең кызларын хәтеренә төшерде. Еракта, салкын якта калган бәләкәй генә, шундый ягымлы ике кызы бар бит аның. Зурысына дүрт яшь. Кадыйр аңа Ләйлә дип исем куштырды. «То мой мама так зовут! Ай, аллах, волос как пахнут, как у мой мама пахнут!» Икенче кызы әле бәләкәй, аңа нибары яшь ярым. Солтанат исемле. Аның чәченнән дә әнисен хәтерләткән хуш ис килүен тели иде Кадыйр, ләкин бәләкәй булгангамы, андый ис җитми иде әле аның чәченә. Бәләкәй кызын әлеге ерак һәм салкын якта Солтаненок-Сатаненок дип йөртәләр иде, аларча ул бәләкәй шайтан була инде. Ул чынлап та шайтан-кызчык иде, шундый да наян, шундый да хәйләкәр, шук иде. «Солтанат, малышка мой, крошка мой!» Шушы исемне биргәндә, кайчан да булса бәләкәй Солтанатын ташлап, ерак җирләр аша бөтенләй башка, зур Солтанат янына кайтып төшәсен башына китерде микән ул?..
Солтанатны ул уятып тормады, җавабы да әзер, аклана да ала иде югыйсә. «Хәтерлә әле, Солтанат, минем хакка исеңә төшер, алай түгел иде бөтенесе дә. Мин кыз бала туудан түгел, кешеләрдән курыктым! Мин аларның ачуын китерә идем, дөресен әйткәндә, каты кылана идем, алар соң, алар да бит минем баштан сыйпамадылар. Тавыгын урласалар — Кадыйр. Печән яндырсалар — Кадыйр. Билгес түтинең паласын онытмагансыңдыр? Районнан милиция чакырттылар, эт китерттеләр. Бөтен кешене клуб каршына тезделәр, арада егермеләп ир, утыз ук булмаса... син анда идең бит, хәтерлисеңме?..
Этка нәрсә, иснәнеп йөргән булды да, туп-туры миңа, пинжәктән

каптырып та алды. Ә мин, җүләр, бурларны тотарга өйрәтелгән этләр була дип шул көнгә тиклем ышанып йөргәнмен. Монда да ялган икән. Колагына пышылдап өстергәч, белде ул кемне тотарга кирәк икәнен. Биш ай утырып чыктым... Билгис түтинең паласын күргәнем дә булмады югыйсә. Менә шуннан соң мин үземә эт өстергән кешеләрдән курка башладым. Балага узганыңны белгәч, гел бер уй кайнады башымда: кыз туса, үсеп җитеп кияүгә чыгар да, бөтенләй чит кешеләргә бил бөгеп, берәр кабәхәтнең аягын юып торыр! Җәфалап бетерәчәкләр бит аны миңа үч итеп! Шуларны уйлый-уйлый чак акылдан язмадым».

Солтанат белән ул шулай күңеленнән сөйләшеп ятты, ә күз алдыннан еракта, салкын якта калган таза йорты китмәде. Хезмәт итә торган часте белорус шәһәрчегендә тукталган чакта танышты ул Марина белән. Соңыннан аны бүтән якларга күчерделәр. Өйләнешү турында сүз дә булмаган иде. Ә бер көнне Маринадан балабыз булачак, дигән хат килеп төште. Үзенең биниһая зур хәрби грузовигын йөрткән белорус шәһәрчегенә Кадыйр кош теле кебек кенә хат җибәрде: «Здравствуй, Марина! Если будит девушка, назави Лейла. Другой прозба нет».

Хезмәт срогын тутыргач, ул дүрт тәүлек буена вокзалдан китмәде: иртәдән кичкә кадәр перронда йөреп, Кавказ ягына агылучы күпме поездларны озатып җибәрмәгәндер... Аннары ул, хәрби грузовиклар колоннасына утырып, теге шәһәрчеккә кайтып төште. Аның өчен кадерле булган исем кушылган кызы — Ләйләне күргәч, ул бу шәһәрчектә гомергә торып калды. Монда бит аны яраталар. Егетләргә бик баш бирергә яратмаган Марина да чибәр, акыллы кыз иде...

Салкыннар еш булса да, елның ун аенда яңгырлар явып торса да, кайчан да булса моннан китеп бару уе Кадыйрның башына да кереп карамады. Дөрес, җылы Кура буйларын, җылы күген, җылы урманнарын ул вакыт-вакыт сагынгалап куя иде... Хәер, монда да урманнар, елгалар бар. Ә кешеләр кайда да бер инде ул... Кадыйр аларның кайчандыр бөҗәкләр, кара еланнар, әкәм-төкәмнәр булуын тәмам оныткан иде инде...

Күпмедер вакыт үткәч, күңелендә нидер кузгалды да таудан тәгәрәгән таш кебек һаман кызурак, һаман кызурак убылып төшә башлады. Юк, аның карашында кешеләр яңадан бөҗәккә, еланга, әкәм-төкәмгә әйләнмәделәр, кинәт кенә алар бөтенләй чит-ят булып күренә башладылар. Бөтенләй икенче төрле йөриләр, икенче төрле сөйләшәләр: чит юллар, чит йортлар, чит агачлар... Пыскак яңгырлы көндә юл буендагы зиратны күреп алгач, Кадыйрны коточкыч бер курку биләп алды, үзенең самосвалында моннан мең мәртәбәләр үткәне бар иде бит югыйсә, әмма мондый тетрәнүне кичергәне юк иде әле. Ул, күзләрен кыса төшеп, машинаның тизлеген арттырды, шушы караңгы көзге көндә кемдер аны тотып алыр да шушы чит каберлеккә тереләй күмеп куяр кебек иде.

Кичен Марина аңа беренче тапкыр шундый сорау бирде:


— Сиңа ни булды, Кадыйр?

— Берни дә булмады, Марина, берни дә...

Ул чакта китү турында уйламаган иде әле, китәсе килү теләген үзе дә белмәгән иде. Каядыр бик еракта җылы урман, җылы сулар агып ята, җылы карашлы хатын яши... Анда, бик еракта әнкәсе күмелгән зират бар... Ә монда үлеп, янәшәдәге зиратта ятасы килми иде Кадыйрның!

— Ничиво, Марина, чесная слова, ничиво... Устал... У мне галава балит...

Шул көннән соң аны тәмам йокы басты — я хода, күпме йокларга мөмкин адәм баласы! Әйтерсең аның өчен бу якты дөнья йөзендә ма-



*Т. Хажиәхмәтов рәсеме.*

шина да карават кына калды. Һәр кичне бакчадан балаларны алып кайткан Марина аны гел йокыда килеш күрә иде. Шулай итеп ун көн үтте, унбиш көн... Бер кичне Кадыйр торып утырды да, йокыдан шешенгән күз кабакларын Маринага төбәп:

— Хачу уехат, Марина! Не магу. Прасти. Хачу уехат,— диде.

Ул, аякларын асылындырып, бөкрәйгән килеш утыра. Кызчыклары идәндә уйный иде. Марина, үтүген тотып, катты да калды.

— Күңелем сизгән иде аны, теге көнне үк... Ә балалар нишләр, Кадыйр?! Бусы бәләкәй инде, ә Ләйлә?.. Ул бит синең өчен җанын бирергә әзер. Әтисез үссеннәрме?!

Бүтән ул турыда сүз кузгатмадылар. Тагын шулай дәвам итте: карават — машина, машина — карават. Күңелен басып торган сагыш үтеп тә китәр иде, бу йокының да чиге килер иде... Ләкин Марина көтә алмады. Беркөнне эштән кайтуга, Кадыйр өстәлдә өр-яңа зәңгәр чемодан күрде. Чалбарлары, юып үтүкләнгән күлмәкләре өстендә куертылган сөт, ит банкалары, берничә пачка печенье ята. Марина иренең майкасын үтүкләп салды да чемоданны ябып куйды. Чөйдәге пальто кесәсеннән нидер барып алды.

— Менә билет,— диде гаҗәпләнеп торган Кадыйрга.— Станциядә билет сатучы таныш миңа. Поезд сәгать унда китә, балалар кайтканчы кузгалырга кирәк. Күрше Верага әйттем, аларны бакчадан алыр...

Перронда сүзсез генә басып тордылар. Поезд инде кузгала башлады, Кадыйр әле һаман берни аңышмыйча тора. Марина аның кулыннан тотып вагонга таба әйдәкли башлады.

— Бар, кит, Кадыйр. Болай булмый! Яшәү түгел бит барыбер!..

Марина аны соңгы тапкыр үпте. Калтыранган иренен тешли-тешли, ераклаша барган поезд артыннан карап калды.

Күпме тырышса да, Кадыйр йокыга китә алмады. Ишек катына килеп таптанып торды. Пыяла аша эчкә күз салып, сулышын тыеп кына торганы тартып карады... Яңадан урынына барып ятты. Сине алыштырып кайтарганнар дип, Касыйм дөрес әйтә. Элеккеге Кадыйр, ятим бала сыман, ишек катында болай торыр идемени! Тибеп кенә ватып ачар иде... Ватты да ди, шуннан нәрсә була? Кулын артка каерасың да... Нәрсә, әллә хатын-кызга көчең җитмиме? Һаман шул Касыйм котыртып йокы мазасы бирми, иблис малай! Кадыйр аның тавышын ишетмәс өчен утны сүндереп, башыннан ук бөркәнеп ятты. Һәм шунда ук ул Кура елгасы төбенә төшеп китте. Су астында күзне чагылдыргыч кояш яктысында Кадыйр сабый бала күреп алды. Баланы күрсәтергә дип ул, Солтанатны эзләп, суүсемнәр арасында чорналып йөзде дә йөзде. Ул да, балыклар да, суүсемнәр дә шундый шат иде. Тирә-юньдә барысы да бии, күңел ача: «Малай туды! Малай!»... Кадыйр кояш нурына чумып йөзә, янәшәдә балыклар ялтырап китә. Балык кебек шома, көмешсу тәнле нәни малай да шулар арасында. Кадыйр аның тәпиеннән тотып алды, өскә алып чыгарга иде исәбе, кинәт Солтанат юкка чыкты... «Солтанат! Кайда син, Солтанат!»...

Ул уянганда, инде көн туган, ачык ишектән кояш нуры айванга агылып тора иде. Бүлмә ишеге дә ачык, анда да кояш нуры тулган. Тәрәзә төбендә ипи, сыр кисәге, чәй һәм шикәр савыты куелган. Су кайнату һәм чәй пешерү өчен ике чәйнек тора. Кадыйр бүлмәгә кереп чыкты, ишегалдына күз салды... Су чүлмәге элеккеге урынында, ә Солтанат үзе беркайда да юк иде.

Капка төбенә йөк машинасы килеп туктады. Касыйм инде, бүтән кем булсын.

— Тордыңмы?! — дип кычкырды Касыйм капканы ачып.— Заправка ягы ничек? — Ул баскыч төбенә килде.— Районга председательне

алып барам. Әйдә минем белән, сиңа эш урыны да белешербез. Районда хәзер машиналар муеннан. Нигә болай соң әле син... ни тере, ни үле... Солтанат өйдәме? Әй, Солтанат, чык әле!

— Кычкырма, өйдә юк ул.

— Килешә алмадыгызмыни әле? Ташла, хатын-кызны белмисеңмени! Боргаланырга яраталар. Кайтыр, кая китсен ул!..

Кулын кесәсенә тыгып, Касыйм айван каршында йөренде.

— Бармыйм дисең инде? Ярый алайса, ял ит, хуҗалыгыңны кара. Синең урында булсам, беренче эш итеп мин арык казыр идем. Тиздән җәй җитә, суны япсалар, бөтен ишегалдыңны басачак. Бу агач төбен шайтаныма олактыр! Агач аралары да йомшартылмаган. Мин соңгарак калырмын, председательне киңәшмәгә алып барам. Син монда борыңның салындырма, бөтенесе дә тәртиптә булыр. Күптән киттеме? Белмисең? Кайчан китте — белмисең, кая китте — белмисең. Әтисенәдер, кая булсын бүтән! Куркытып, аяк астында җәймә итәргә телидер. Ә син нык тор, без — солдатта булган кешеләр! Кайтыр! Ничек кенә кайтыр әле!..

Кадыйр ипи белән сыр ашады, бер стакан чәй эчте. Эшне нәкъ Касыйм әйткән тәртиптә башлап җибәрде. Арыкны тирәнәйтеп, кырыйларын ныгытты. Төш җиткәнче агач төбе белән маташты. Көн уртасында Солтанат кайтып керде. Капка төбендә үк курыкынган йөз белән туктап калды, аннары тын гына килеп агачка сөялде дә:

— Әйберләремне алырга килдем,— диде.— Әти дә риза. Ә син кал! Өй, бакча — синеке. Эшләсәң, җимеше дә булыр. Өйдә бар да син киткәндәгечә, палас кына... Бер паласны сатарга туры килде. Кешеләрнекеннән ким түгел хуҗалык, аллага шөкер, өйләнерсең, гомергә буйдак булып йөрмәссең бит инде. Тол хатыннар да бар, кызлар да буа буарлык. Кыз кешегә өйләнсәң дә була, әнә бит син нинди... кыяфәтең бар, тагын да яшәреп кайткансың, димме... Алтын сәгатең, балдагың сандыкта, мин кагылмадым. Күлмәкләремне генә алам да... Үзеңнеке үзеңә булсын. Яшә тыныч кына.

Шулай диеп, ул күләгә сыман кереп китте. Кадыйр агач төбендә басып калды. Ярдәм эзләгәндәй, әле генә казып чыгарган корыган агач тамырына, аннары баш түбәсендә кыздырган кояшка күтәрелеп карады. Төенчек тотып чыккан Солтанат, шикләнеп кенә аның ягына карый-карый, сукмак буйлап капкага таба китте. Кадыйр тагын каршында яткан агач тамырына, тагын кояшка күтәрелеп карады. Хәле китеп, бер уйсыз, бер хәрәкәтсез озак басып торды... Кинәт бөтен тәненә ниндидер бер кыргый көч иңә башлады—шушы калын тамырлы агач төбен җир читенә алып ыргытырлык, гранат агачын бер талпынуда суырып чыгарырлык көч! Агач нәрсә — кояшны тартып төшерер иде күктән! Иң биеккә менеп кунаклаган да оятсызларча карап тора дөньяга, алты ел эчендә ник бер чите кителеп төшсен!..

Тамырлы төпне ул алып ыргытмады, агачны да суырып чыгармады. Тешләрен шыкырдатып, йодрыкларын йомарлап, күккә карап торды да торды. Аннары, атылып, бүлмәгә керде, кычкырып, брезентка ауды да, үз-үзен йодрыклап, кул аркасын, брезентны тешләп умыра-умыра бәргәләнә башлады.

## IV

Кадыйр костюмының яңа икәнен дә белә, күлмәге дә чиста, ботинкалары да ялтырап тора, галстук тагып тормаганын да хәтерли, тик менә маңгае күпкәнлеген, күз төбе кара янып чыкканлыгын гына уена да китереп карамады. Маңгае сызлап торганын сизде ул, карават тимеренә бәргән булгандыр инде, ә күз төбе кара янып чыкканлыгын да

белгән булса, беренче очраган кешенең үз-үзен тотышына сәерсенмәгән дә булыр иде.

Бая тыныч кына эшләп ята иде бит, кояшка да ул кадәр ачулы түгел иде, Солтанат килеп китмәгән булса. Йөз ел буе шушы ихатада арык чистартып, йөз ел буе кояш нурын тәненә сеңдереп яшәр кебек иде. Кояш җылыткан җир исен ничекләр генә сагынган иде ул. Солтанат килеп китү белән, өенә атылып кереп, брезентны ерта-ерта идәндә бәргәләнгәннән соң ул инде монда яши алмасын тәгаен аңлады. Монда аңа сулар һава калмаган икән шул.

Кадыйр, өр-яңадан киенеп, маңгае күпкәнлекне дә, күз төбе кара янганлыгын да тоймыйча, урамга чыкты.

Әнә, сатучы Аршад йорты. Ун яшьләрдәге малай өй каршында сигарет сатып утыра. Кадыйр үз кыяфәтенең нинди икәнен белгән булса, бу маңка малайның тупас сөйләшүенә ачуы да килмәгән булыр иде мөгаен.

— Син Аршад малаемы?

— Әйе.

— Әтиең һаман сату эшендәме?

— Әйе.

— Күпмегә сатасың тәмәкене?

— Нигә ул сиңа? Барыбер акча түләмисең бит!

— Түләмәсемне каян белдең?

— Белмәскә! Кадыйр бит син! Бөтен кеше белә!

Менә син нинди икәнсең, сатучы токымы: лавкадан ике адымда гына тәмәке сатып торасың, җитмәсә өрәсең! Әйе, монда берни дә үзгәрмәгән икән. Аршад һаман шул — адәм актыгы: бөҗәк, хәшәрәт!..

Кадыйр малайга тибеп җибәрүгә, як-якка сигаретлар чәчелде. Башта имәнеп калган малай, ашыга-ашыга күлмәк итәгенә товарын җыя башлады. Тиз генә капкасыннан кереп шылды да койма аша кычкырырга тотынды.

— Ычкынган! Бур! Бандит! Белмиләр дисеңме? Билгис түтинең паласын урлаган Кадыйр бит син!

Урам тын, лавка янында да беркем юк иде, Аршад ялгызы ишек төбендә утыра. Кадыйр шешенгән йөзен күз алдына китерсә, бу чирләшкә бәндәнең ничек каушап калуына сәерсенмәс тә иде.

— Әй, Кадыйр! Исәнме, туган, исәнме! Сине танырлык та түгел! Ул киемнәр! — безнең райторгтагылар кебек! Нишләп моңарчы күренмәдең? Кичәдән бирле кайтканыңа... Күршеләр бит, керергә уйлаган идем дә, борчымыйм дидем. Әйдә, үт! Кер, утырып җибәр! Нәрсә эчәсең, аракымы, әллә...

Кадыйр Аршадка карамыйча гына:

— Кабарга бармы? — дип сорады.

— Менә сыр, бүтән әйбер юк, күреп торасың. Теләсәң, суган алып киләм, печенье табарга була.

Кадыйр дәшмәде. Аршад шешәне ачты, астан стакан алып, тутырып салды, печенье чыгарды, башлы суганны учында гына сытып, прилавкага куйды. Кадыйр күтәреп эчте дә, печенье белән суганга игътибар да итмичә, Аршадка төбәлде.

— Кабарга бармы?

— Менә бит сыр, печенье...

— Анысын күрәм мин. Тегесен чыгар, түрәләр өчен дигәнен. Аңладыңмы?!

Аңламыйммы соң. Яхшы хәтерли ул Кадыйрны. Тавышы да, карашы да, йодрыклары да үзгәрмәсә үзгәрмәс икән. Минут та үтмәде, прилавкада ярты тавык, яңа пешкән чүрәк, тозлы яшелчә суы пәйда бул-

ды. Кадыйр барысын да сыпырып куйды. Яңадан ярты стакан гына эчте дә калган аракыны ашыкмыйча, үзенә бер тәм белән шешәсеннән җиргә агызды. Башланган «Аврора» пачкасы һәм шырпы кабын прилавкадан алып кесәсенә тыкты. Икенче кесәсеннән акча чыгарып, Аршад алдына ыргытты да бер сүз әйтмичә чыгып китте.

Аршад, акчаны алып, кесәсенә салды. Калган сөякләрне берәмтекләп җыйды, Кадыйр аракы түккән урынга туфрак сипте — исе дә калмасын. Ул киткән якка карап, бөтен гәүдәсенә сузылып, бер төкерде дә кибетенә кереп китте. Бу вакытта инде Кадыйр чәйханәдә, нард уенын карап торучылар арасында иде. Килеп керүгә үк, ул уен сөякләрен уйнаучыларның кулларыннан тартып алды һәм, шалтырата-шалтырата, тирә-юненә масаюлы караш ташлады.

— Кем уйный минем белән?

Уенны төгәлли алмый калган ике егет аңа рәнҗеп карап куйдылар. Өстәлне түгәрәкләп алган җан атып торучыларның да, ефәк пинжәк, кыйммәтле төрек папахасы кигән таза гәүдәле чәйханә хуҗасының да күзе аңарда иде.

— Ну, кем уйный?

Чәйханәгә җыелганнарның күбесе бер-берсенә охшаган яшүсмерләр иде. Арадан берсе генә күзгә ташланыбрак тора: Кадыйр буйлы, җилкәгә бераз киңрәк тә булыр. Аның карашы да бүтәннәрнеке сыман түгел, шулай ук куркыныч, көчле кешемени соң бу, килеп керүгә, бөтен чәйханә тынып калды дигән сыман, күзләре белән үлчәп, сынап карый. Ниһаять, такта артында утыручылардан берәү тавыш бирде:

— Кил, уйныйбыз.

Кадыйр аның каршысына утырды:

— Нәрсәгә уйныйбыз?

— Нәрсәгә телисең!

Кадыйр борылып караштырган булды, күзләре чәйханә хуҗасының затлы папахасына тукталды.

— Әнә, Хәйбулла папахасына!

— Җүләр сатма! Мин сине чынлап та уйнарга телисең дип торам,— дип егет, иренен турсайтып, такта артыннан күтәрелде.

Кадыйр уен сөякләрен тагын шалтырап алды.

— Ну! Хәйбулла папахасына кем уйный?

Барысы да Хәйбуллага карап куйдылар. Чәйханә хуҗасы ишетмәмешкә салышып йөри бирә. Ниһаять, баядан бирле сынап караган киң җилкәле егет Кадыйр каршысына килеп утырды.

— Мин уйныйм. Шундый шарт белән: кем оттыра...

— Кем оттыра, шул папаханы ала да әнә тегендә! — дип, Кадыйр урам якта торган чүп кәрзиненә ымлады.— Откан кеше рәхәтләнеп көлә. Барамы?

— Килештек!

Уен шундый кызып башланды, нард тарихында күрелмәгән уен иде бу. Алты ел инде кулына нард тотканы булмаган Кадыйр, әлбәттә, бик тиз җиңелде. Ул торды, әле һаман да ишетмәмешкә салышып, горур гына йөргән Хәйбулланың папахасын ике дә уйламыйча йолкып алды да чүп кәрзиненә томырды.

Ләкин беркем дә көлмәде, хәтта елмаймады да, иң гаҗәбе шунда: чәйханә хуҗасы аның бу кыланышын бөтенләй сизмәгән дә кебек иде. Папахасын барып алды, кагып, башына киде дә сабыр гына Кадыйр каршына килеп басты.

— Син һаман шул икән: җүләр идең, җүләр булып калырсың да.

— Аның каравы син башка. Намусыңны очсыз бәяли башлагансың,— дип Кадыйр аның папахасына ымлады, борылып, монда әлек тә

еш булган кешеләрне эзләде.— Сез үзгәргәнсез. Сез дә... Син дә... Бөтенегез дә үзгәргән. Тик барыбер кабәхәт булып калгансыз! Бөҗәкләр, әкәм-төкәмнәр, хәшәрәтләр!..

Аннан соң кызмача Кадыйр урам буйлап китте. Менә авылның үзәге: китапханә, медпункт. Аны ерактан ук искәреп, медпункт һәм китапханә ишеген эчтән бикләделәр. Кадыйр идарәгә сугылды. Анда кәгазенә иелеп нидер язган учетчик кына утыра иде. Кадыйр керүгә, ул, күз сирпеп кенә алды да тагын кәгазенә иелде.

— Кайттыңмы? — дигән булды.

— Кайттым.

— Кайткансың икән, исәнләшик. Утыр, сөйләп җибәр, кайда булдың, ниләр күрдең?

Шунда гына ул күтәрелеп карады, әмма Кадыйр чыгып киткән иде инде. Зур коридорның бер ягына авыл советы, икенче ягына почта урнашкан, икесенең дә ишекләре бикле. Кадыйр бер-ике тапкыр тибеп карады да кире конторга керде. Ишекле-түрле йөренде, тәрәзәгә килде, ә учетчик шулкадәр гамьсез утыра ки, битарафлык короле диярсең.

— Карале, Мисир! Син бит элек салырга ярата идең?

— Эш андамыни?! Эчәсең килә икән, турыдан бәреп әйт, нигә бутыйсың...

— Эчәсе килә, Мисир! Бармы синең?

— Юк.— Битарафлык короле башын калкытырга кирәк санады.— Кесәдә бер тиен юк. Акча булса, оештырабыз аны...

Кадыйр кесәсенә тыгылды.

— Акча бар миндә, тап әле, Мисир.

Дөньяның иң гамьсезе ашыкмыйча гына торып тәрәзәгә килде.

— Егет, кил әле монда! — дип, ул китапханә ишеге төбендә китап тотып торган малайга эндәште. Малай йөгереп килеп тә житте. Кадыйр кесәсендә аунаган бөтен акчасын чыгарып салды.

— Күпме тора соң ул хәзер?

Мисир көлеп җибәрүдән чак тыелып:

— Менә сиңа мә! — диде.— Карт ишәк тегермән юлын сорасын инде...

Ул, кирәк кадәрлесен санап, шуңа тагын бер тәңкәлек өстәде дә малайга тоттырды.

— Аршадка йөгер, улым. Бер литр ал, берлеге үзеңә булыр. Китабыңны монда калдыр, кайткач алырсың. Тиз бул: бер аягың монда, икенчесе тегендә булсын!..

Соң иде инде, караңгы урамнар буйлап чайкала-чайкала, Кадыйр атлады. Каршысына каяндыр Касыйм калкып чыкты.

— Кая китеп олактың син! — дип мыгырданды ул, Кадыйрның йөзенә фонар уты төшереп.— Бөтен авылны урап чыктым, җир тишегенә кереп югалдымыни! Тәмам булгансың син. Кайда эчтең, ә? Бер сәгатькә тәкатең калмаган идемени?! Сөйләшкән идек бит. Хатын анда ни генә пешермәгән. Кешечә бер утырырбыз дип уйлаган идем, ничә елдан соң. Карарга чирканыч сиңа! Кайтып ят син. Иртәгә утырырбыз, көндез. Иртәгә ял минем.

— Син, Касыйм бар...— дип көчкә әйтә алды Кадыйр.— Бар, кайт. Үзең генә утырып аша. Күзгә тыкмале бу фонареңны!

— Солтанат кайтмадымы?

— Кайтса, кайтмаса, синең эшең юк. Пылавыңны аша.

— Син кая хәзер?

— Мин? Үзем беләм... Синең эшең түгел, аңладыңмы?

— Беләм мин кая барганыңны,— дип, Касыйм аны никадәр үгетләргә тырышса да, Кадыйрның үзсүзлеген җиңә алмады.— Бар алайса, кадалып кит, кара аны, анда тавыш чыгара күрмә. Картның хәле начар, ярты ел инде урыныннан тора алмый.

## V

Бераздан Кадыйр авыру карт кырыенда басып тора иде инде.

— Әткәй! Мин бу, Кадыйр. Киявең синең. Танийсыңмы мине?

Кадыйр, тамак төбеннән һәр сүзен этеп чыгара-чыгара, бар көченә кычкырып сөйләде.

— Шатланмыйсыңмыни? Шатланырга хәлең юкмы? Үлә күрмә, әткәй! Үлмә! Бүтәннәр китсен! Әнә алар күпме!

Карт аның кайтуына шатланган иде, я хода, ничекләр генә шат иде әле! Күзләре ялтырый башлады. Ул, Кадыйрны кочакларга теләп, калтыранган кулларын сузды. Кадыйр иләнгә тезләнде, карт аның башын кочаклап җылый башлады. Кадыйр үзе дә үксеп җибәрүдән чак тыелып күзләрен читкә алды һәм почмакка бер йомарлам булып сыенган Солтанатны шунда гына искәрде.

— Әнкәй кайда соң? — дип сорады ул.

— Юк инде ул, улым,— диде карт, шул чак үкси башлаган Солтанат елаудан тыелып шым булды.

Тып-тын калдылар. Үлгән кешене хәтерләү идеме бу, әллә сөйләшер сүзләре юк идеме?..

— Ярый, әткәй, кичер инде мине, ә кызыңны мин алып китәм.

— Алып кит, улым, алып кит! — Картка шунда ук җан керде.— Мин каршымыни... Синең хатының синең өеңдә торырга тиеш. Мин аңа күпме әйттем.— Ул инде хәзер бөтенләй сәламәт тавыш белән сөйли башлады.— Ал син аны, улым, алып кит, ходай бәхет бирсен сезгә!.. Ә миңа нәрсә... бүген-иртәгә өзелермен. Сезнең тормышыгыз көйләнсә, миңа да үлү җиңелрәк булыр...

Карт башын мендәргә куйды. Хәзер инде ул тыныч кына түшәмгә карап ята иде. Я хода, шушы сукырая барган кечкенә күзләрдә күпме яктылык бар!..

Бераздан карт, урыныннан күтәрелеп, терсәкләренә таянды.

— Нишләп терәлеп калдың? — дип, ул шундый итеп әйтте, Солтанат ишеккә таба капылт кузгалганын сизми дә калды. Ул инде ишек төбендә көтеп тора, ә Кадыйр әле һаман, нидер әйтергә теләгәндәй, картның яктылык чәчеп торган кечкенә күзләреннән аерыла алмый иде. Шулай озак вакыт үткән кебек булды, инде бөтенесе дә әйтелгән иде, тик бер генә сүзе калган иде, карт аны Кадыйр ишеккә житкәч, артыннан кычкырды.

— Улым! Син бу агуны әзрәк эчәргә тырыш!.. Кирәкми, улым, кирәкми!

Яңа чыккан чиста ай яктысында авыл җәйрәп ята. Шушы чиста яктылыкны ерып, алдан Солтанат бара. Зур яулык астына күмелеп, кулларын күкрәгенә кушырып, тын гына атлый. Ай нурына күмелгән урам буйлап үзеннән алда сүзсез генә барган шушы хатынга чиксез рәхмәтле иде Кадыйр. «Кеше булып калдың, әткәй каршында мине битәрләмәдең, акыллы син Солтанат, әткәй каршында оятка калдырмадың, беренче булып үзең кузгалдың».

Урам буш, тәрәзәләрдә утлар яна, идарә янындагы биек баганада радио сөйли. Ай нурына чумган бу урамнарга, таш юлларга, бу йолдызларга радио тавышының бернинди дә катнашы юк иде. Арган тын

урам буйлап зур йозак астында йокыга талган чәйханәне, кибет турысын, Аршад өен дә үттеләр. Кайдадыр этләр өреп куйды, туктаусыз бакалар сайрады.

Солтанат капканы да сүзсез генә ачты. Айванга күтәрелеп, коридорга кергәч кенә ул култыксагa сөялде. Кадыйр коридордагы, аннары бүлмәдәге утларны кабызды.

— Бар, йокла,— диде ул тыныч кына.— Курыкма, ят. Мин монда, коридорга ятам. Ишекне бикләмә, ишетәсеңме. Бикләсәң — ишекне ватам.

Солтанат бүлмәгә кереп китте. Кадыйр аның артыннан ишекне сак кына ябып куйды. Костюмыннан гына кичәге урынга ятты һәм шунда ук йоклап та китте. Төшендә ул Кура елгасы буендагы очсыз-кырыйсыз урманны күрде. Елга төбендә бүген тоташ караңгылык иде. Тынны буа торган салкын караңгылыкны ертып, никадәр өскә калкырга теләсә дә, булдыра алмады Кадыйр. Кул-аяклары нәрсәгәдер чорналды, гүя ул балыкчы ятьмәсенә эләккән иде. Соңыннан аңлады: ятьмә түгел, Солтанатның чәчләренә уралган икән. Бик тирәндә ул тагын зәпзәңгәр тәнле үле баланы күрде. Кадыйр аңа карый алмады, куркыныч иде, тизрәк өскә, өскә калкасы иде... Тик менә аның муенына уралган чәч толымы җибәрми, буа, сулышын кыса иде.

Кадыйр сикереп торды, ул чынлап та суга төшкән кебек манма тиргә баткан иде. Уралган чәчтән котылырга теләгәндәй, башын селкеп куйды. Бераздан ул урыныннан торды, аяк очына басып, ишеккә килде. Солтанат мендәргә башын куеп бөгәрләнеп ята, кырыенда лампа яна иде.

Кадыйр кымшанмыйча озак басып торды. Аннары, караваттан одеал алып, Солтанатның өстенә япты. Аннары нигәдер одеалны яңадан урынына алып куйды, пинжәген салып, Солтанатның йокылы гәүдәсен җайлап кына төрде. Лампаны сүндерде. Вакыт күпме икәнен чамаларлык түгел иде. Ай болытлар астына кергән, яңадан беркайчан да яктырмас кебек бөтен дөнья куе караңгылыкка чумган иде.

Әмма яктылык тагын кайтты бу дөньяга. Иксез-чиксез урманнарны, Кура елгасын яктыртып, тагын кояш күтәрелде. Солтанат бүлмәсенә дә кояш өлеш чыгарган. Коридордагы урын-җиргә дә, кичә чемодан торган урынга да, куертылган сөт һәм ит банкалары куелган төшкә дә якты нурлар сузылган...

Солтанат Кадыйр ябынып яткан одеалны тышка чыгарып селкеп керде дә караватка җәйде, аннары түшәкне кагып шунда ук кертеп куйды. Кадыйр яткан мендәрне дә кагарга инде көче җитмәде, нигәдер хәле китте...

Мендәрне кочаклап, ул бүлмәгә керде, карават кырыена тезләнде дә, үксеп, күз яшьләре белән мендәргә капланды:

— Бәгырем минем!..

Азербайҗанчадан **МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ** тәрҗемәсе

## Сергей Воронин

# ЧИГИРИКАНДРА ИТӘГЕНДӘ

хикәя



Юк, егет аңа ялгышып кына да сөям дип әйтмәде. Ә кыз үзе бу турыда сорарга курыкты,— егетнең үпкәләве бар. Бу хакта сорау — икеләнү билгесе. Ә икеләнергә нигез бар идеме соң? Егет кыз янына дөм караңгы төннәрдә дә килеп чыга, төнге тайга аша япа-ялгызы сигез километр араны узып, ауган агачлар, тирән чокырлар, шаулап аккан сулар аша үтеп, берничә сәгать аның белән булып, шул юлдан яңадан кайтып китәр өчен. Яратмаса, йөрер идемени! Кыз шулай уйлады. Егетнең бер тапкыр да ярату турында уйлап карамавы аның башына да килми иде.

Килеп җитәренә километр чамасы калганда кыз аны күреп ала, кантарланып каткан елга бозыннан аның каршысына йөгерә. Үзәннәрдә инде караңгы төшә, күктә кызгылт шәүләләр хасил була, төнгә каршы суык көчәя бара. Сузылып яткан елгада да, аның ярларында да шылт иткән тавыш юк. Шундый тынлык, колаклар томалангандай тоела. Һәм еракта-еракта, агарып яткан кар өстендә бер карамчык-нокта күренә. Ул! Бу карамчык фәкать ул гына булырга мөмкин! Һәм кыз бар көченә аңа каршы йөгерә. Зур киез итекләре йөгерергә комачаулый, муенына шуып төшкән яулыгы астыннан җирән чәчләре ачыла. Тыны бетеп, йотлыга-йотлыга салкын һава сулый кыз, йөгереп килеп, сөенечтән, дулкынланудан күләргә тотына. Көлү егеткә аңлашылмый, ул йөзен җыера. Ә кыз моны күрми, егетне култыклап ала да янәшәсеннән атлый, буй ягыннан ул егеттән калышмый, бәлки әле калкурак тыр да. Суык аның бит алмаларын, борынын кызарта — кыз аларны бияләе белән уа, кыска керфекләрен бәс сарган,— болай да кысыграк күзләре тагын да кысыла төшә. Юк, кызны чибәр дип булмый иде. Ә егет чибәрләрне генә ярата, шуңа күрә аның сөйләшәсе, сүз ишәйтәсе килми, ул дәшми.

Кышлау текә кыялы Чигирикандра дигән биек сопка итәгендә урнашкан. Кыя күләгәсендә утырганга, аны хәтта көндезләрен дә табуы кыен, ә караңгыда инде бөтенләй күренмәс була, һәм аның кечкенә тәрәзәсеннән саркып чыккан сукыр ут яктысына атлау бик рәхәт.

Кышлау эче май кебек җылы. Егет кerә-керешкә Шураны кочагына ала. Һәм шактый вакыт кызны үзеннән ычкындырмый. Бераздан соң гына тирән йокыга тала, кызның аңа сокланып карап утыруын, кашларыннан, чәчләреннән сыйпавын, бите белән аның битенә кагылуын һәм тигез сулышын, йөрәк тибешен тыңлавын күрми, сизми ул. Йокысын туйдыргач, кабат үз отрядына чыгып китә. Һаваның нинди булуына да карамастан чыгып китә. Кыз аны озата бара, һәм бер дә көтмәгәндә — бу инде берничә тапкыр кабатланды — үз уйларына җавап биргәндәй, көләргә тотына. Кәкре нарат янында алар аерылышалар. Бу бик уңайлы урын. Моннан Шура әле байтак вакыт китеп баручы Василийны карап тора.

— Икенче килгәндә иртәрәк килергә тырыш, ярыймы,— ди кыз.

— Ярый,— ди егет һәм тизрәк китәргә ашыга. Очрашып күрешкәннән соң аның шулай һәрвакыт тизрәк китәсе килә.

Атна тулганда егет тагын килеп чыга. Бу танышлык бик уңайлы булып чыкты, бер нәрсә өчен дә җавап бирәсе юк, дип уйлый ул. Алар арасында киләчәк турында да сүз чыкканы юк. Һәм нинди дә булса киләчәкнең булуы мөмкин эш тә түгел. Тайга... Ә соңыннан алар өйләренә таралачаклар.

Яз җиткәндә тикшеренү эшләре тәмамланып өлгерде. Ике арадагы мөнәсәбәт тә шушының белән өзелергә тиеш иде, әмма аларга өйгә бер поездда кайтырга туры килде. Бу Василийга ошап бетмәде, шул сәбәпле юлда Шурага ул әллә ни игътибар итмәскә тырышты; булган — беткән, барысы да тайга ешлыгында калган,— шуңа күрә преферанстан аерылмады. Кыз аңа комачауламый иде. Сүз катмады, бәйләнмәде, үз тормышы белән яшәде. Егет аннан канәгать иде — акыллы кыз, барысын да аңлый, дип уйлады. Кызның мөстәкыйльлегенә, арада берни дә булмаган кебек кылануына хәтта үпкәлисе дә килде. Бу егетнең горурлыгына бераз көч килүдән иде, ә гомумән алганда ул аннан бик канәгать, мәсьәләнең шулай ансат кына чишелә баруына шат иде...

Вакыт-вакыт ул кызның күзләре белән очраша һәм — шунысы гаҗәп — кыз аңа ачык йөз белән елмаеп карый. Бары бер тапкыр гына аның карашында нииндидер томан пәрдәсе күрде ул — кыз нәрсә турындадыр уйлана иде, ахрысы, әмма анысын да төгәл генә әйтеп булмый, бәлки шулай тоелгандыр гына.

«Шулай берни өчен дә борчылмый микәнни?» — дип уйлады егет һәм ничек танышуларын исенә төшерергә тырышты.

Ул контроль нивелировкадан кайтышлый төнгә калды һәм кыз яшәгән шушы кышлауга килеп юлыкты.

— Сәлам, геологиня!— диде егет.— Моңсу түгелме соң?

— Моңсу шул,— диде кыз.

— Сиңа моңсу булмасын дип килдем бит менә.

— Яхшы булган.

Кызның сүзләреннән аның эченә җылы йөгергәндәй булды. Кулларын угалап, янган мич каршына чүгәләде.

— Чәй эчермәссеңме?

— Хәтта тамагыңны да туйдыра алам. Эшчеләр монда бoҗыр тоткаинар иде.

— Кара син аны, ә! Ярыйсы яшисез икән.

— Зарланган юк.

Кыз өстәлгә эскәтер сыман бер нәрсә җәйде, һәм зәгыйфь шәм яктысында арлы-бирле йөренгән хуҗабикәгә егет игътибар беләнрәк күз салды... Юк, кызны чибәр дип булмый иде, шуңа егерме алтыларга хәтле ялгызы утыра торгандыр да... Тагын бер елдан егерме җиде тулачак, ә анда инде утыз...

— Димәк, килеп чыгып сиңа мәшәкать ясамадым?

Кыз иелде дә егетнең күзләренә карап алды:

— Уйлаган идем аны,— диде ул тыныч кына һәм көлеп җибәрде.

— Нәрсә уйлаган идең?

— Күзләрең коңгырттыр дип. Ерактан алар кара булып күренә.

— Ерактан гына бит ул. Син аларны якыннан кара.— Егеткә аның белән җиңел иде. Һәм уйлап куйды — әгәр теләсә, кыз әллә ни карышып тормаячак. Тикшереп карау өчен аның кулына үрелде. Кызның кулы зур һәм саллы иде, бу хәл аны бераз суытып җибәрде.— Ну, боҗырлар бар дигән идең түгелме соң?

— Өстәлдә.

Егет өстәл янына килеп утырды, ашарга кереште. Аннан чәй эчте. Аннан соң тәмәке тартты.

— Килеп чыкмаган булсам, син инде бу вакытта йокларга да ятыр идең, шулаймы?

— Бәлки шулайдыр.

— Ят алайса.

Кыз өреп шәмне сүндерде дә чишенергә кереште. Эшчеләр йоклаган стена артыннан гырылдау ишетелде. Тимер мичнең кызарган стенасыннан бүлмәгә алсу яктылык тарала, шушы яктылыкта күз тора-бара кышлау эчендәге бөтен нәрсәне аера башлады. Василий Шура чишенгән якка карды. Кыз анда юк иде инде, димәк, яткан.

— Ә миңа кая ятарга? — дип сорады ул.

Кыз дәшмәде. Егет киемнәрен салды да кыз янына килде.

— Ай-һай, салкын икән идәнең,— диде, аннан одеал астына үрмәләде. Кыз читкәрәк тайпылып, урын бирде. Һәм шулвакыт егет аны кочагына алды. Кыз бу юлы да берни әйтмәде. Моны күреп, Василий аны кинәт үз ягына әйләндерде, шул мизгелдә кызның куркынудан зурайган күзләрен, ачынулы елмаюын күрде. Ләкин кыз монысына да чыдады, дәшмәде...

Күпмедер вакыт үткәч, нәрсәгәдер ачуы килгәндәй:

— Нигә аны беркемем дә булмады дип, баштук әйтмәдең? — дип сорады Василий.

— Беркемем дә булмады,— дип пышылдады кыз.

— Хәзер инде үзем дә беләм,— диде егет, тагын да ачуы кабарып.

— Ә нигә синең ачуың килә?

Егет җавап бирмәде.

— Ә мин аның шулай буласын алдан ук белдем,— диде кыз, тавышында елмаю сизелде.

— Монысы ни дигән сүз тагын?

— Чөнки мин сине килеп кергәч үк ошаттым...

— Кызганыч, алданрак белгән булсам,— диде егет, көлемсерәп, һәм баягы ачуы сүрелгәнен сизде. Бу хәл өчен берниндн җаваплылык булмаячагын ул шунда аңлады.— Син мине бик гаҗәпләндердең әле.

Шул көннән кыз янына ул ял көн саен килә башлады. Бераз вакыт үткәч, кыз аның отрядын куып җитте, тагын бергә булдылар. Аннан кыз арткарак калды, егет аның янына барып йөрде.

Көннәрдән бер көнне кыз:

— Ни әйтсәң дә, Чигирикандра — гүзәл җир ул! — диде.

Кызның ни әйтергә теләгәнен ул шундук аңлап алды: бу сопканы мактау түгел иде, әлбәттә, сүз аларны якынайткан кышлау турында бара. Әмма егет әлеге фикергә кушылмады, дәвам иттермәде.

Поездда соңгы көн барганда ул гомумән кызга якын килмәскә тырышты. Кырынды, әйберләрен җыеп чемоданга тутырды, китап-журналлар укыштырды, йоклап та алды һәм түземсезлек белән поездның, пыяла гөмбәзле вокзалга килеп кереп, тукталуын көтте. Һәм шул минут аларны бәйләп торган соңгы минут булачак, аннан соң икесе дә ирекле һәм үз юлларыннан китәчәкләр.

Менә поезд да туктады.

Перронда җылы, кояшлы иде, кайберәүләрне чәчәкләр белән каршылыйлар, кая карама көлү, шаян сүз, шатлык, үбешү-кочаклашулар.

— Менә шул,— диде Василий һәм кызга бер дә исе китмичә киң итеп елмаеп карады, гүя ике арада берни булмаган һәм булырга да тиеш түгел. Аннан кызга кулын сузды: — Хуш!

— Сау бул! — диде кыз, егетнең кулын кысып, аннан бөтен төс-битен, канатларга охшаган кашларын, матур маңгаен, сөекле күзләрен, үзен үпкән иреннәрне карашына сыйдырырга, исендә калдырырга теләп, текәлеп торды. Һәм шулвакыт эчендә нәрсәдер тетрәнеп китте,— кыз көлеп җибәрде.

Егет тагын нәрсәдер әйтергә кирәген, менә шулай берни әйтми-нитми китеп бару яхшы түгеллеген аңлый иде, ләкин кирәкле сүзләр табылмады, ул китеп барды.

Кыз аны кеше арасына кереп югалганчы карап торды, аннан соң гына үз юлына борылды, тизрәк, тизрәк өйгә, картлар янына кайтырга кирәк. Алар әле кызларының кайтып төшкәнен белмиләр дә бит. Ул юри хәбәр итмәде — болай яхшырак, болай аңа җиңелрәк, чөнки картларның каршыларга килеп аны күрүләре, барысын да аңлаулары бар. Егет белән икәүдән-икәү калганда аңа ничек авыр икәнен әле яшерергә була, ә эти-әни алдында бу мөмкин түгел. Картларны нигә борчырга? Аларның аңламаулары да бар. Һәм аңлатып та булмаячак. Гаепләләр юк! Шулай да алай саубуллашмаска иде аңа... Кызганыч... Кызганыч... Кыз тиз-тиз атлап урамнан бара, һәм кая гына карамасын, күз алдында салават күпередәй аллы-гөлле төсләр биешә...

Егет өенә кайтып керде. Аны күреп, анасы елап җибәрде. Улы аны күкрәгенә кысты, тынычландырырга тырышты, ләкин үзендә элекке кайтулардагы кебек зур шатлык тоймады. Кичен ресторанга кереп утырды — тайгада мондый кич турында хыяллана иде — тик ресторан да аңа элекке кайтулар ләззәтен бирмәде. Бераз утыргач, өенә кайтып китте,— ресторан ябылырга әле байтак бар иде. Өйдә дә үзенә урын таба алмый интекте. Нилектән бу? Аңламады.

Иртән әле кафе ярыйсы гына иде, ләкин көндезләрен аны ниндидер салкын ялгызлык урап алды. Урамга чыкты, анда да ялгызлыктан котылыр әмәл чыкмады. Һәм шунда исенә нигәдер Чигирикандра килеп төште. Хәтерендә шул кыя итәгендә үткәргән кыш яңарды. Кояш анда соңарып кына төшә, ул башта югары күтәрелергә тиеш, аннан соң гына нурлар суыкта ялтырап яткан очлы ташларны, кыя төбенә сыенган кечкенә өйне яктырталар. Түбәдән ак төтен күтәрелә. Монда һәрвакыт тынлык хөкем сөрә. Җилләр анда керми. Әйе-әйе, ул анда күп төннәрен үткәрде һәм бервакытта да җил сызгырганын ишеткәне булмады... Чигирикандра исенә төшкәч, уйлары Шурага ялганып киттеләр, кызның каршыга йөгереп килүе, зур киез итекләренең сөртенүе, муенга шуып төшкән яулыгы һәм, көндез туры килсә, җирән чәчләренең уттай янып торуы күз алдына килеп басты. Кыз аңа кулларын суза һәм рәхәтләнеп көлә. Кая карама кар җемелди. Алар култыклашып зур кыя төбенә сыенган җылы өйгә таба атлыйлар...

Шунысы кызык, яратты микән аны кыз?.. Әлбәттә, ошавын егет аңа ошый иде,— бу хакта кыз үзе әйтте... Әйе, ошый иде! Егет поездда аның белән үзен артык коры тотуы өчен үкенеп куйды. Шунда бераз йомшаграк булса, нәрсә булган. Өйләнергә йөрмәгәч, араны тизрәк суытасы, кызны ераклаштырасы килгән иде. Аларның киләчәк турында сөйләшкәннәрен хәтерләми ул. Ләкин барыбер үзеңне аның белән йомшаграк тотасы калган, бигрәк тә перронда, саубуллашкан чакта. Әйе, йомшаграк тотасы... Алай кырт кисмәскә иде...

Ярый әле аңарда кызның адресы калган. Ул аны Чигирикандрада ук биргән иде. Василий алырга да теләмәде.

— Нигә?— диде.

— Кирәге чыгуы бар, мәсәлән, суга бата-нитә калсам, өйгә язарсың.

— Ә син батма, ул чакта язасы да булмас.

Кыз Литейныйда тора иде. Өйне ул тиз эзләп тапты. Квартираны да. Һәм кнопкага басты. Ишек шундук ачылып китте, гүя аны монда көтеп торганнар. Ишектә кыз күренде, көлә иде.

— Син нәрсә көләсең?— дип сорады егет.

— Ә мин киләсеңне белдем.

— Ә нигә килергә тиеш идем соң мин?— диде егет, һәрвакыттагыча кызның көлүен өнәмичә.

— Чөнки мин сине яратам!

Һәм бу Чигирикандра дигәндәй яңгырады.

Русчадан **СОЛТАН ШӘМСИ** тәрҗемәсе

# АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

**Марсель Зарипов**

# КЕМДЕР ОТА, КЕМДЕР ОТТЫРА

Крестьян тормышының бөтен баскычларыннан үтә-үтә, кетүчелектән ВАСХНИЛ академигы дәрәҗәсенә күтәрелгән, көчле рухлы, якташ галимебез Ефим Федотович Лискунның бер томлык сайланма хезмәтләрен кабат укып чыктым. Революциядән соң атаклы «тимирязевка»да озак еллар буена кафедра мөдире булган Ефим Федотович хәзер дөньяда юк инде, әмма аның фикерләре, авыл хуҗалыгы шактый алга киткән бүгенге көннәрдә, аеруча кыйммәтле.

Лискун иң якты хыялларын авылның киләчәгенә багышлаган. Артта калган Россия яхшы фермалар күрмәгән, ә иген басуларының байлыгын исә сәүдәгәрләр чит илгә озату ягын караганнар.

Беренче Бөтендөнья сугышы алдыннан Россия чит илгә ел саен алты йөз — тугыз йөз миллион пот икмәк, кәрпә, түп, азык үләннәре сатып яткан. Ачлыктан-хәерчелектән интеккән Россия шулкадәр азыкны каян алган соң? Бу — әлбәттә, аның үзеннән артканы түгел, ярлы крестьянның авызыннан өзеп, ятимнәр өлешенә кереп, эшче гаиләләрен ачлыкка дучар итеп җыелган ясаклар яки халыкның, аптыраганнан, мәҗбүрән саткан икмәге бу. Югыйсә, бичара крестьян каһәрләнгән ул тормышының очын очка ничек ялгасын? Аңа бит кием-салым да, керосины-тозы да, кадагы-чүкече дә, дирбияләре-фәләннәре дә кирәк, акча кирәк! Җиде кат тиресен суелдырып, кан тирләрен тамдырып өлгергән икмәк әнә шул сәбәпле елгыр сәүдәгәрләр кулына, аннан тагын да арырак, чит илгә үк китә барган.

Лискун, гасабиланып, бу сәүдәнең мәгълүматлары турында: «Ә безнең сыер-малкайлар, бер пот печән генә ашаса да, чит илгә сатылган икмәк бәясен бише белән кайтаралар,— дип яза.— 1913 елда Россия Германиягә бөртектән, кәрпәдән, майлы үсемлекләрдән торган 760 миллион пот терлек азыгы сата. Моңа ул алтынлата 655 миллион сум акча ала. Димәк, туклану берәмлегенең бер килосы 5 тиенгә сатылган. Без әле моннан тыш, немец алпавытларының дуңгызларын симертү өчен, 405 мең пот тәмләткечләр, 444 мең пот шикәр комы да озатканбыз. Бу азыкларны үз терлегенә бирсәң, дуңгыз итенең потын, хәзергечә 8 сумнан, сөтнең потын 60 тиеннән генә санасаң да, без ел саен 1,5 миллиард сумны чит илләргә түгел, үз ихтыяҗларыбызга тота барган булыр идек»...

Хәзер безнең илдәге терлек-туар, кош-корт, элекке белән чагыштырганда, искиткеч күп. Колхоз-совхозларда һәм дәүләт карамагындагы башка предприятиеләрдә савым сыерлары гына да утыз миллионга җитә. Танасы-бозавы, кәҗәсе-сарыгы, аты-дуңгызы килеп кушылса, бу сан ике йөз илле миллионга якынлаша. Әле шәхси хуҗалыклардагы мал-туар күпме? Авыл хуҗалыгы продуктларының өчтән берен генә кырчылык бирә, калганы — терлекчелектән кергән байлык.

Тормыш үзе якташыбыз Лискун фикеренең хаклыгын раслый. Файда күрәсең килсә, басу-болыннар биргән бөртекне, печәнне, кәрпәне, түпне, тамыр азыкларны чимал хәлендә сатарга ашыкма икән. Син аларны мал-туарга ашат, иткә, сөткә, йомыркага, майга әйләндер! Шул хакыйкатьне аңлаган кеше, терлек азыгы әзерләргә иренүгә караганда, күп мәртәбәгә отачак.

Бу кагыйдә хәзер безнең барыбызга да биш бармагыбыз кебек таныш, тик кайбер җирдә, терлек тагарагына ни әләкте шуны салып, хуҗалыкның бөлгенлеккә төшүен дә күргәлибез.

Сорау куйыйк: ашлыкны, печәнне, силосларны, кибәк-көрпә, түп кебек калдык-постыкларны, минераль һәм биологик тәмләткечләрне ничек итеп сөт-каймакка, ит-майга әйләндерергә? Комбайннан чыккан бөртекләрне бодаен — бодай, арышын — арыш, солысын — солы, арпасын арпа көенчә фермага илтә барсаң, биш тиенлек куян, бер тәңкәлек зыян гына килеп чыгачак. Иренмичә генә, шушы бөртекләрдән ләззәтле кушылма ясарга кирәк. Бөртекләрне болгатып ашату отышлы. Төрлелек арткан саен, азык та файдалырак була бара, дүрт тоннасы бишкә әйләнә, өч мең литр сөт саудырган сыер дүрт меңне бирә башлый.

Казан янындагы «Кощак» совхозының оста савымчысы Вера Долгова 1983 елның кыш башында җитмеш бер көндә һәр сыердан меңәр литр сөт алды. Шәп. Әмма ул бердәнбер генә түгел. Бер атнадан соң «1000»ле саны ферма мөдире Борис Ермолаевның куен дәфтәренә үк кереп кунды. Борис — совхоз стипендиясе алып, югары белемгә ирешкән менә дигән мөдир.

Кышның җитмеш сигез көнендә аның фермасындагы сыерлар меңәр литр сөт биргәннәр икән, хуҗаның ниндилеге турында артык сөйләүнең кирәге дә юк! Январь, февраль, март айлары — сөт чоры түгел. «Кощак»лыларның бу вакытта да җәйге муллык белән яшәвенә сокланырга гына кала. Совхозның уңган савымчылары һәр сыердан елга биш мең литр алуга якынлашып киләләр. Шул ук вакытта бу терлекчеләргә тудырылган шартларны да телгә алмый ярамас, чөнки бирердә башка җирдә, нәкъ алар кебек үк тырышсаң да, мөмкинлеге булмау сәбәпле, хезмәтең җилгә очып бетә. «Кощак»та терлек азыгы кытлыгының ни икәнен дә белмиләр — моннан да әйбәтрәк шартны кайдан табасың?!

Совхоз директоры Нәгыйм Бариевич Вәлиев:

— Терлекчелектә «сөт чоры», «сөтнең кимегән чагы» кебек сүзне телгә алырга да түгел,— дип аңлата. Үзе шәфкатьле, үзе бик таләпчән бу директор совхозны унбиш ел буе җитәкли инде.— Мал-туар үзе теләгән азыкны туйганчы ашарга тиеш. Шуны бирмәсәң, ит тә, сөт тә көтмә инде!

Директорның бер җөмләдә әйтелгән бу таләбе — гаять зур мәшәкать, әлбәттә. Совхозның терлек азыгы әзерләү цехы җәен ике смена буе эшли, кышын — иртәдән кичкә кадәр. Инде тагаракларда ниләр барын да карыйк: силос теләгәнчә салына, бишәр килограмм печән, унар килограмм махсус «бавырсаклар». «Бавырсак»ны яшел үләнгә төрле тәмләткечләр кушып ясыйлар икән. Бу азыклар елга ике мең ярым тонна тотыла. Моннан тыш бөртек белән саламны болгатып ясаган өч йөз тонна концентрат әзерлиләр. Күбрәк салам алына, ә бөртек — хуш ис чыгарыр өчен генә. Тагын биш йөз илле тонна витаминлы печән оны тарттырып куялар. Шушы азыкка тиенгән сыерларның күпме сөт бирүен әйттем инде, бозаулар исә, унбиш-унсигез ай эчендә, биш йөз килограммга җитә. Азык әзерләү цехы ике йөз мең сумга төшкән, тик сөт һәм ит белән бу чыгымны тиз арада каплап та куйганнар.

Сүзгә бирелеп китеп, иң мөһимен онытмыйк: мондагы азыкта бөртекләләр биш-ун проценттан артмый. Бу сан алда кирәк булыр әле.

«Кощак» совхозы сыерларның ике йөз еллар элек Михаил Ломоносовның туган ягы булган Архангельск тирәсендә чыгарылган холмогор токымлысын асрый. Алга берьюлы берничә максат куелганда, терлекнең нинди токымын асрарга икәнен ачыклап тотыну ифрат мөһим. Безнең хуҗалыклар бит бер ядрә белән ике куян атуга кызыгып кына калмыйлар, өчне үк әләктермәкчеләр: сыер аларга сөт тә бирсен, итләч тә булсын, нәселен дә үрчетсен!

Татарстанның Башкортстан чигендә «Восточный» совхозы бар. Берничә ел элек монда айршир токымлы, сөт өчен генә асрала торган, чит ил таналары кайтарттылар. Сыерларның бу токымы унсигезенче гасырда чыгарылган, туган җире — Шотландиянең Айршир графлыгы. Токымның исеме дә шуннан алынган икән. Биргән сөте елга, уртача, дүрт мең — дүрт мең ярым литрга җитә, сөтенең майлылыгы — дүрт, дүрт ярым процент...

Инде килеп, шушы чит ил «уңганнарының» безнең җирдә нинди уңышка ирешүләрен карыйк. 1982 елда көтүдәге һәр сыердан уртача алты мең сиксән өч литр сөт сауганнар. Майлылык — дүрт бөтен йөздән унике процент. Әлеге сөтнең никадәр икәнен төгәлрәк күз алдына китерү өчен, чагыштырып үтәргә дә мөмкин: безнең республикадагы һәр сыер уртача, майлылыгы өч ярым процент булган ике мең өч йөз алтмыш бер литр сөт бирә. Айршир токымлы бер сыердан елга ике йөз илле килограмм атланмай алганнар, ә гадиеннән — өч мәртәбә кимрәк, сиксән дүрт кенә.

Әмма ләкин айршир сыерларыннан да көненә өчәр чиләк сөтне саф һава сулатып кына савып булмый, һәр литр сөт алу өчен, аларга бер килограмм азык ашатырга кирәк. Бу — елына алты тонна аксымлы, аминокислоталарга бай булган, витаминлы азык дигән сүз. Шундый запасың булмаса, Шотландиядән яки Швециядән генә түгел, җәһәннәмнән алып кайтсаң да, сыер сөтне күп бирмәячәк.

Язучы шөгыле, кайда гына булсаң да, кешеләр белән, аларның нинди ысулларга таянып эшләве белән кызыксынырга мәҗбүр итә. Мине терлекчелектәге фидакарьлек, борынгы бабалардан килгән бу һөнәргә тугры хезмәт итүчеләр сокландыра. Әле генә телгә алынган «Кощак» һәм «Восточный» совхозы терлекчеләренең үрнәген РСФСРның башка якларында да күрү бигрәк тә куанычлы.

Тула янында, Новомосковский районының Ленин исемендәге колхозында, уналтынчы председатель Василий Стародубцев эшли башлагач, хуҗалыктагы сыерлар, элекке мең ярым урынына икеләтә артыграк саудыра башлаганнар. Тагаракка азыкны шул күләмдә һәм шушы ук составта салганда, сөтнең артмаячагын да аңлаганнар. Савым сыерыннан, генетик мөмкинлеге булдыра алган кадәр сөт алу өчен, аны төрледән-төрле азык белән туйганчы ашатырга кирәк. Ә генетика һәм селекция күрсәтүенчә, безнең сыерлар, әйбәт тәрбияләнгәндә, сөтне биш-алты мең литрдан киметмиләр.

Ленин исемендәге колхозда, минемчә, игътибарга алып сөйләрлек тагын бер нәрсә бар. Ул да булса — фуражга калдырылган ашлыкны эшкәртү, җир биргән муллыктан терлекләргә ләззәтле сый әзерләү. Колхоз бу максат өчен, ярты миллион сумга төшереп, завод салдырган. Димәк ки, басу белән ферма арасын тоташтырып торучы яңа тармак барлыкка килгән. Кыйммәткә дә төшкән ул. Тик шунсыз мөмкин түгел икән. Нишләмәк кирәк, комбиазыкны, алма яки груша кебек, агач ботагыннан гына алып булмый. Терлек-туарга, кош-кортка дигән азыкны, көч һәм чыгымнарны кызганмыйча, махсус әзерләргә туры килә. Дөрес, барын да санарга кирәк, әмма саранланырга ярамый. Терлек-туар азыгыннан кысып калган тиенең, икенче яктан, сумнарга әйләнеп, җилгә очачак.

Шулай да, сыер-сарык азыгын әзерләү өчен, ярты миллион сумга төшереп, аерым завод салдырган колхоз председателенә мин шикләнебрәк карадым. Стародубцев агай, мөгаен, акчаны саный белмидер, көн саен бурычка сорап, банк буенда йөридер, дим.

Шикләнүемнең нигезе дә бар, андый хәлләр шактый еш очрый, әмма бу очракта мин, бәхеткә каршы, ялгышканмын. Председатель Стародубцевтан халык көче белән табылган акчаның, бер генә тиенен булса да, җилгә очыртырдай кеше тумаган әле! Ленин исемендәге колхозда уңганнар, пенсиягә чыккач, йөз егерме сум ала. Мондагы балалар бакчасы бушлай эшли. Йөзү бассейны бар. Болар — акчаны җилгә очырумыни?! Стародубцев, йөз кызартып, ник бурычка сорап йөрсен?! Колхозның үз акчасы муеннан! Кирәк икән, ул үзе финанс министрлыгына акча биреп тора ала!

Комбиазык заводының чыгымнары үзкыйммәтне күтәрә күтәрүен. Димәк, Ленин исемендәге колхозда җитештерелгән продукция бик кыйммәткә төшәдер, дип уйларсыз. Бөтен хикмәт тә шунда — бу колхозның сөте, Союз күләмендә караганда, иң арзан сөт. Центнеры — уналты сум.

Чөнки колхозның һәр сыеры елына биш мең ике йөз килограмм сөт бирә. Хуҗалык мең бер йөз баш аклы-каралы сыердан алтмыш мең центнерга якын продукция ала. Һәр центнерын утыз ике сумнан сатканда, сыерлар сигез йөз мең сум акча кертә дигән сүз. Бу — иттән дә, бөртеклеләрдән дә, гомумән, башка тар-

маклардан алына торган табыштан артык. Колхоз бөртеклеләрдән ярты миллион сум җыя, иттән — тагын шул чама. Бер савым сыеры исә елына мең сум табыш бирә. Акча суга торган машина диярсең, әлләһи!

Туланың Ленин исемендәге колхозында бөртекле фураждан ничек файдаланулары, яшь бозауларга, бәләкәй дуңгыз балаларына, симертелә торган терлекләргә, буаз малларга ниләр ашатулары ачыклана төшсен өчен, мин укучыны хуҗалыкның «аш-су әзерләү бүлмәсе»нә чакырам. Рәхим итеп карагыз, өйрәнегез, кирәк икән, файдаланыгыз!

Колхозның телгә дә, эшкә дә бик чая экономисты Татьяна Александровна Михеева, исәп-хисап машинасына төрткәләп алды да, мондый саннар тезеп китте. Без дә куркып калмыйк әле, үзебезне математика телен аңларга күндерик, бу авазлар яңгырашының үз матурлыгы бар.

1982 елның унбер аенда комбиазык заводының тәп-төгәл технологиягә нигезләнеп эшләүче бүлгәләү-болгату казаннарына 1377 тонна (32,3 процент) арпа, 1129 тонна (26,5 процент) бодай, 171,1 тонна (10,1 процент) викалы солы кушылмасы, 10,1 тонна (0,2 процент) борчак, 102,3 тонна (2,4 процент) кукуруз, 126,7 тонна (3 процент) бөртек калдыкларыннан ясалган бавырсак, 69 тонна (1,6 процент) печән оны, 49,5 тонна (1,2 процент) чүпрә, 21,1 тонна (0,5 процент) балык оны, 83 тонна (1,9 процент) түп бавырсагы, 310,8 тонна (7 процент) соя кабыкчалары, 639 тонна (15 процент) аксымлы-витаминлы өстәмәләр, 60 тонна тоз, 6,3 тонна акбур, 14,5 тонна фосфор салынган.

Терлек азыгын тиешле дәрәҗәсенә җиткереп әзерләүче һәм шуның рәхәтен күрүче хуҗалыклар күпме соң? Кызганычка каршы, гомум күренеш шактый фәкыйрь шул әле. Сатып алу бәяләре күтәрелгәнче, безнең хуҗалыклардагы сөтбикәләр, начар хуҗалар кулында, сөт-май муллыгы тудырудан бигрәк, йортҗирне бөлгенлеккә төшерүче җәфаларга да әйләнә алуларын расладылар. Ел әйләнәсендә аларның һәрберсе икешәр йөз сумга кадәр өстәмә чыгым таләп итә иде. Ил күләмендә исәпләп карасаң, бу малкайларыбыз елына дүрт миллиард сум зыян гына китерә иде.

Күзгә күренеп торган файдасы булгач, тулалыларда һәм аларга охшаш башка колхоз-совхозларда фураждан комбиазык ясаучы махсус цехларның эшчәнлеген, РСФСР Әзерләүләр министрлыгының бу өлкәдә ниләр башкаруын өйрәнергә кирәк. Алдан ук әйтеп куйыйк, мондый заводларны салу бик авыр бара, булганнарын да мактарлык түгел. Ашлык исә теләсә ничек тарттырыла да маллар тагарагына агылып кына тора. Стародубцев кебек, үз заводын салдырган председательләр башка хуҗалыкларның фуражын да ләззәтле комбиазыкка әйләндереп бирергә мең риза. Ник шулай булмасын — завод кадәр завод тик тә тора бит! Чама белән, илле чакрым ераклыктагы төбәктәге колхоз-совхозлар ихтыяҗын рәхәтләнеп үтәргә мөмкин, ә шуннан да арыраккa ташый башласаң, кызыгы китә, бәясе нык күтәрелә. Юк, Тула өлкәсендә бу заводны файдаланырга теләүче аз. Ел буена башкаларга нибары мең тонна чимал эшкәрткәннәр. Мөмкинлек дәрьясыннан — бер тамчы.

* * *

Шул ук вакытта илдәге терлек-туарга бирелә торган азыкның кырык миллион тоннага якыны тагаракка бөртек килеш салына икән. Гап-гади болгату алымы белән генә дә бу ашлыкның чиреген, ягъни ун миллион тоннасын, янга да калдырырга мөмкин булыр иде. Юк бит, алай итмибез. Ник, ни сәбәпле? Чөнки аңа өйрәнмәгәнбез, ирендерә...

Беренче карашка, Әзерләүләр министрлыгының комбиазык ясый торган заводлары җитенкерәми. Мөмкинлек булса, колхоз-совхозлар, ашлыгын элеваторга тапшырыр иде дә, әзер комбиазыкны төяп кенә китеп барырлар иде. Менә шәп булыр иде!

Әмма, комбиазык әзерләү индустриясе өлгертә алмый дип кенә терлекләрне туендыруда теләсә нинди башбаштаклыкка юл куярга да ярамый бит инде. Тирәндәрәк яткан хәлләрне күздән кичерик.

Хәер, алары да әллә ни төптә түгел. Иң әүвәл эшкә битарафлык, ваемсызлык күзгә ташлана. «Ярамаган тагын!» янәсе. Химик тәмләткечләр җитмәвенә салыну да дөрес түгел, чөнки алардан башка гына, җиренә җиткереп, болгатып бирсәң дә, азык ләззәтлерәк һәм нәтиҗәлерәк килеп чыга. Комбиазык предприятиеләренең, терлекләр санын арттыруга караганда, күп тапкырлар акрынрак салынуы үзе дә: «Мал-туар күп булсын да фуражы килеп торсын, ә аны ничек ашатсаң да барыбер инде»,— дигән ялгыш караштан туа.

Дөрес, соңгы елларда мондый заводларны салуда алга таба китеш бар барын. 1971 елда, әйтик, РСФСРның Әзерләүләр министрлыгы карамагында йөз дә унҗиде зур завод һәм ике йөз дә сигез технологик яктан шактый искергән көчсез генә предприятие бар иде. Хәзер ике йөз дә кырык дүрт завод эшли, бәләкәйләре алтмыш дүрткә калган. Терлек азыгы әзерләү индустриясенә миллиард сумнан артык акча тотылган, монда тәүлегенә, элек илле ике мең тонна азык әзерләнсә, хәзер туксан биш мең тонна эшкәртелә башлаган. Тагын кырыклап зур завод төзелеп ята.

Үсеш, алга китеш бар, әлбәттә. Тик фермалар, ит, сөт, йомырка җитештерүче фабрикалар, азык җитештерүгә караганда тизрәк арта. Хикмәт шунда, азык булдырырга бер министрлык алынган, терлекләр өчен исә Авыл хуҗалыгы министрлыгы җавап бирә. КПСС Үзәк Комитетының 1965 елгы март Пленумыннан соң әле әллә ни күп вакыт узмаган. Шул арада терлекчелекне индустрияләштерү, концентрацияләү һәм специальләштерүдә кайсы гына өлкә зур-зур эшләр башкармады?! Ә терлек азыгы әзерләү буенча кайда ныклы база бар? Анысы, кызганычка каршы, юк шул.

Унынчы бишьеллык азагында РСФСРда ике йөз туксан сигез дуңгызчылык фабрикасы, йөз алтмыш җиде мөгезле эре терлек комплексы, мең дә утыз алты — сөтчелек, биш йөз туксан ике кошчылык фабрикасы бар иде инде. Сөйләтсәң, саннар әйтә дә бирә! Бер савым сыерының хәзерге тимер-бетон абзардагы торак урыны гына да ике мең сумга төшә. Димәк ки, бу төр комплексклар салуга миллиард ярым акча тотылган. Симертү фабрикаларына да шул ук чыгым киткән, соңгы унбиш ел эчендә ел саен — егерме сигез миллиард данә йомырка, миллион тонна кош ите бирердәй фабрикаларга сигез миллиард сум акча тотылган. Әле гадәти фермаларга күпме киткән!..

Комбиазык индустриясен үстерү исә бер миллиардка төшкән. Монысы да аз түгел, тик ике якның чыгымын рәттән куеп карасаң, аерма шактый күренә. Авыл хуҗалыгы һәм Әзерләүләр министрлыклары, кулга-кул тотынып эшләүче оешмалар, бер үк олы юлдан атлыйлар, әмма беренчесе шактый кызу элдертә, икенчесенең адымнары салмаграк.

Мал-туар фабрикалары яңгырдан соң калкып чыккан гөмбәләр кебек ишәя бара, комбиазык әзерләргә тиешле предприятиеләрне салу исә КамАЗ, БАМ, Себер гидростанцияләрен төзү вакытына тиң торырлык елларга сузалар.

Бернича мисалга тукталыйк. Смоленскиның Починки төбәгендә 1977 елда салына башлаган завод биш ел эчендә төзелешкә бүленгән акчаның нибары өчтән бер өлешен генә үзләштерә алган. Калинин өлкәсендәге Максатиха заводын төзү мәйданында 1979 елдан бирле эш бара, үтәлеш графигы унҗиде — алтмыш җиде процентлар тирәсендә тирбәлә. Иркутскидагы Тайшет заводы тугыз елдан бирле салына, Вологда өлкәсенең Шекснадагы заводын төзү дә 1977 елда ук башланган иде, очы-кырые һаман күренми әле.

«Камгэсэнергострой» берләшмәсе автомобиль ясаучы җиде заводтан, ярты миллион кеше яшәрлек шәһәрдән һәм Түбән Кама ГЭСыннан тыш, КамАЗ тирәсендәге төбәктә, авыллар өчен дә ике йөз миллион сумлык эш башкарды. «Татэнергострой», «Татнефтестрой», «Татсельстрой» оешмалары тагын күпме төзеде: юллар, клублар, торак йортлар, терлек абзарлары... Кама аръягында йөз мең баш сыерга исәпләнгән тимер-бетон комплекс бар. Ит, сөт, йомырка җитештерүче яңа фабрикалар гына да әүвәл, нигездә, игенчелек белән шөгыльләнгән бу яклардан ел саен йөз егерме сигез мең тонна комбиазык таләп итә башлады. Анысын әллә кайлардан ташырга кирәк иде инде. Төбәкнең елына алты йөз тонна комбиазык бирәчәк үз заводы унберенче бишьеллыкның уртасында, КамАЗ эпопеясының ун-

дүртенче елында гына, әле анда да мең төрле җитешсезлеге һәм эшчеләре өчен торагы-фәләне юк көенчә генә, тапшырылды.

Ни белән аңлатыла соң бу? Гадәттәге ваемсызлык — бары шул гына. «Менә безнең терлекләр — ә азыкны Әзерләүләр министрлыгы бирсен, кетәбез!» — дигән, ялгыш фикер нәтиҗәсе бу.

Шул ук вакытта, үз заводын һаман салып өлгертә алмаучы Вологда өлкәсе ел саен читтән өч йөз мең тонна комбиазык кайтара, Әзерләүләр министрлыгы аңа әллә кай тарафлардан, мең бәясенә төшереп, эшелон арты эшелон куа. Терлекчеләр, артык кыйммәткә төшкәнгә күрә, бу азыкка шатланырга да, кайгырырга да белмиләр.

Ямән гадәт тиз таралучан. Комбиазыкны читтән ташыту, Әзерләүләр министрлыгы шәфкатенә ышанып яту, минем уемча, бүгенге крестьян күңелен шул кадәр көчле биләп алган ки, РСФСР Авыл хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы колхоз-совхозлар көче белән булдырылган заводлардан күбрәк файдалану турында уйлап та карамыйлар. Куәтен кая куярга белми утырган андый заводлар РСФСР күләмендә ике мең ярымга җитә. Заводларның техникасында да, технологиясендә дә әллә ни зур аерма юк, үзгәлек шунда гына: дәүләтнекеләр тәүлекләр буе әйләнә, колхоз-совхозларныкы сәгатьтән-сәгатькә генә эшләп ала. Мәскәү янындагы колхоз-совхозларның әзер азыкны дәүләттән көтеп утырырга күнегүләре шул дәрәҗәгә җиткән, алар хәтта үзләрендәге заводны эшләтеп тә карамыйлар, егерме җиде цехның нибары берсе көлтерәп утыра, ул елга бары тик унбиш мең тонна азык тарттыра. Мал-туарга бирелә торган азыкның дүрт йөз мең тоннасы бөртекләтә, заяга диярлек, ашатыла.

* * *

Хәер, бүгенге заман крестьянына фураж тарттыру тегермәннәре-заводлары белән җәфалануның кирәге бар микән соң? Уйлашыйк, исәпләп карыйк!

Илдә кырык меңнән артык колхоз-совхоз бар. Шуларның һәммәсендә фураж бүлеп торучы икешәр генә кеше тотсаң да, сиксән мең эшче көч дигән сүз. Ел буена җитәрлек фураж шактый озын юл үтә: басудан ындыр табагына кайта. Мәгълүм ки, кешеләр ындыр табагында нәкъ кырмыскалар кебек әвәрә киләләр. Бихисап көч түгелә. Һәр хуҗалыкта ындыр табагы берничә дә булырга мөмкин. Басудан кергән ашлыкны бу ысул белән тиешле сыйфатка күтәрү чыгымнары, җилгәрү, киптерү агрегатларына тотылганнарын да кушып санаганда, дүрт миллиард сумнан артып китә. Мондый байлыкны дәүләткүләм өр-яңа элеваторлар, махсус киптерү агрегатлары салуда файдалансаң, алар коеп яуган яңгыр астында җыелган чеп-чи ашлыкны да киптереп, сортларга аерып, шул ук вакытта калдык-постыгыннан комбиазык та ясап бирә алыр иде. Аннары орлыгын да, терлек азыгына дигәнен дә теләсә кайсы якка озатып ятып була.

Хуҗалыкларның эше ындыр табагында гына да бетми бит әле. Терлекләр өчен калдырылган фуражны ләззәтле комбиазык хәленә китерү — осталык һәм уңганлык таләп итүчән бик нечкә хезмәт. Сыерларыннан елына алтышар мең литр сөт алучы, иткә дигән үгез-бозауларын бер ел эчендә дүрт центнерлы итеп симертүче, дуңгыз баласын сигез-тугыз айдан колбасага озатучы, булдыклы терлекчеләр мал-туарга әзерләнә торган азыкны меңгә төрләндерәләр, тарттыралар, илиләр, аңа әллә ниләр кушып бетерәләр... Тереклек иясе үссен, зурайсын, көрәйсен өчен, аңа аксымнан тыш аминокислоталар да кирәк. Терлек азыгы әзерләүче технологтан мәшһүр ресторан пешекчеләрендәге уңганлык сорала.

КамАЗ янындагы «Новотроицкий» совхозы терлекчеләренең хайван азыгын ничек әзерләүләренә игътибар итик. Бик тырыш амбарчы Надежда Захарова һәркөнне иртән фураж складын ачып җибәрә. Ярдәмчеләре бер кучтән — бер чиләк, икенче, өченчеләреннән тагын шулкадәр үк ала-ала, тарттыргычка бодай, арпа, арыш, солы ташый башлыйлар. Азык әзер, янәсе. Шул фуражны тагаракларга салып чыгарга тагын кеше кирәк әле. Үзебез, эшче көчләр җитми, дибез. Адәм

баласының хезмәтен шулкадәр вакларга, кадерсезләргә өйрәнеп беткәнбез дә яман гадәтебездән котыла алмый интегәбез.

Мин — авыл кешесе, үзем шәһәрдә торсам да, тамырларда крестьян каны тибә, авыл тормышы җанга якын. Шуңа да карамастан, якты көндәй ачык бер хакыйкатьне әйтми кала алмыйм: ындыр табагында җырлый-җырлый тау-тау ашлык көшелләре эшкәртеп яту, гәрчә ул безнең күңелгә бик матур яклары белән сеңгән булса да, шактый искерде. Аңа алмашка хезмәтнең отышлырак, нәтиҗәлерәк алымнары килде. Ник әле агымга каршы йөзеп азапланырга? Киресенчә, яңа агымның көченнән мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга кирәк! Бар иде заманнар: чабагачлар, иләкләр, агач көрәкләр белән эшләдек, аларны сугу машиналары, веялкалар, сортировкалар алмаштырды; соңыннан ындыр табаклары тулысынча механикалаштырылды. Үсеш, алга китеш шуның белән тукталды, дип карарга ярамый. Яңа чор хезмәтнең тагын да камилрәк ысулларын тудырмасмыни?!

Бер уйласаң, мин авыл кешесенең күңеленә шулкадәр якын, аннан башка колхоз-совхоз тормышын хәтта күз алдына да китереп булмас тоелган бу мәсьәлә турында артык пошынып сөйлим, бугай. Ашлык җыюның үзәгендә, сортларга аеруда, орлык бүлеп куюда, колхозчыга бирүдә, сатарга яки фуражга күпме калдыруда кем катнаша? Уңыш өлгергәч, авылга барып карагыз. Анда Әлмәт нефтьчеләре, Түбән Кама нефтехимиклары, Чистай сәгатьчеләре, автомобиль җыючылар, тегүчеләр, пешекчеләр, энергетиклар, галимнәр һәм студентлар, шәһәрнең әле тагын әллә нинди һөнәр ияләре «мәж» килә. Хәзер үк, халыкның кырык процентлабы авылларда чакта, шул күренешкә тап булгач, без, демографлар уенча, авыл кешеләренең тагын ун-унбиш проценты шәһәргә күчкәч, ике меңенче елларда, нишләрбез икән? Телибезме-теләмибезме, күп кешеле ындыр табакларыннан баш тартырга туры килер, мөгаен. Мондагы эшне исә тулысынча элеваторларга тапшырырга һәм эшкәртелгән ашлыкны орлыкларга, шул исәптән, колхоз-совхозларга да кабаттан өләшеп чыгарга мөмкин лабаса! Һәрьяклап механикалаштырылган элеваторларда көчле машиналар белән коралланган бер кеше ындыр табакларындагы меңнәрчә кешене алмаштыра алыр иде.

Фураж өчен файдаланыла торган ашлыкның катлаулы юлын гына күздән кичерсәң дә, аны, басудан ындыр табагына китереп тормыйча, турыдан-туры комбиазык заводына илтүнең никадәр отышлы икәненә инанасың. Бер завод мәгълүм бер төбәкне тәэмин итәрлек булсын иде! Аның киптерү агрегатлары, складлары да җитәрлек санда салынсын. Әзер терлек азыгын, хуҗалыклар соравы буенча, җибәреп кенә торыр иде ул.

Әзерләүләр министрлыгы заводлары хәзергә бу эшне үз өсләренә алырлык түгелләр. Алар аз. Күпсанлы ындыр табакларын алыштырырлык хәлгә җиткерү өчен, аларны, кимендә, икеләтә арттырырга кирәк. Хуҗалыклар үзара берләшсә, уртак заводлар тирәсенә тупланса, РСФСРдагы фураж өчен калдырыла торган утыз-кырык миллион тонна фуражны күмәк көч белән туклыклы азык итеп тарттырырга-болгатырга алынсалар, ничек шәп булыр иде бит!

• • •

Бик ерак киләчәктәге яңалыкларның да башлангычы бүгенге ыгы-зыгыда беренә. Такы-токы, калдык-постык ризыклардан бәләкәй фабрикалар эшләп чыгарган ләззәтсез азык терлекчелеккә әллә ни бирмәвен аңлагач, табыш алырга омтылу теләге авылларда «Колхозаракомбиазык» дигән берләшмә тудырды. Кубаньда колхоз-совхозларның фуражга дигән ашлыгын эшкәртеп бирергә алынган шундый берләшмә председателе Владимир Васильевич Быков миңа:

— Моннан җиде ел элек, теләктән башка, бер нибез дә юк иде,— дип сөйләп китте.— Хәзер уналты заводыбыз бар. Елга җиде йөз туксан мең тонна азык бирәбез! — Ул миңа үз оешмаларының схемасын да сызып бирде.— Шул җитәрме?

— Эшегезнең нәтиҗәсе нинди дир бит?..

Быков, тел төбемдәге шик-шөбһәне сизмәмешкә салышып, дәвам итте:

— Әле шуларга ясалма сөт чыгара торган ике заводны да кушсаң...

— Шуннан ни була?

Мин аның бу хакта күбрәк сөйләвен тели идем, шуңа күрә үзем, кыска сораулар биреп, сүздән читтәрәк тордым.

— Тагын тәмләткечләр белән чүпрә заводы, ит калдыкларыннан һәм сөяктән он ясый торган өч завод бар әле безнең. Автоколонна булдырдык. «Кирәк!» — дип, авыз ачарга да өлгермисең, өеңә, әй, ялгыш әйтәм, фермаңа илтәбез дә бушатабыз...

Ниһаять, Быковка сөйләүнең тәме йөгерде. Инде һичнинди сорау бирүнең дә кирәге калмаган иде.

— Ризыкның тәме ашаганда гына беленә, дигәндәй, без бу нәрсәнең файдасына әле яңа гына төшенеп киләбез. Ит калдыкларыннан һәм сөяктән он ясый торган тагын өч завод салсак, эремчек суы әзерләүгә кирәкле сөт порошогы предприятиесен көйләп җибәрсәк, безнең эшләр тагын да җайланачак әле! Хәзергә проектын гына төзеп азапланабыз — үзебезнең микробиологик каротиныбыз булачак! Заводларыбыз, дәүләтнең бу төрдәге һәр предприятиесендәге кебек үк, өч сменага көйләнгән. Инде үзгәртеп корулар да башланды, яңа фикерләр туа тора. Куәтебез тагын утыз процентка артачак. Мәйханә киләбез, тәүлек сәгатьләре генә җитми башлады...

Ягымлы кеше җаныңны бер күрүдә үк билəп ала. Быков та миңа бик ошады. Кай ягы белән? Мөгаен, эшенең бөтен нечкәлекләрен белеп торуы шулай тәэсир иткәндер. Кабинетында сөйләшеп утырганда да ул кәгазьләр актарып тормады, һәр сүзне, һәр мәгълүматны ул үз җаныннан, зиһененнән суырып ала сыман иде. Гәүдәгә зур да түгел ул. Райкомның элекке секретаре буларак, ул эшкә муеннан чумарга өйрәнгән, башкаларга да тынгылык бирми.

Кубаньдагы хуҗалыкара яшь индустриянең ничегрәк эшләвен күз алдына китерү өчен, бүлгеч һәм болгаткычларганиләр салынганын карыйк. 1982 елның алты аенда монда эшкәртелгән терлек азыгына илле ике мең йөз дә җитмеш өч тонна бодай, утыз җиде мең дүрт йөз сиксән алты тонна арпа, унтугыз мең сигез йөз унсигез тонна кукуруз белән солы, унбиш мең ике йөз егерме җиде тонна соя белән борчак, егерме тугыз мең биш йөз кырык тугыз тонна аксымлы-витаминлы тәмләткечләр, илле мең тоннадан артыграк күләмдә түп, итле-сөяклебалыклы он, ширбәт, чүпрә кебек нәрсәләр салынган...

Берләшмәнең баш технологы Виктор Васильевич Устимченко бу калькуляцияне дә шактый кырыс тәнкыйтьли әле. «Терлекләр ихтыяҗын истә тоту түгел бу, бу — киресенчә, мал-туарны үз теләкләребезгә җайларга тырышу»,— ди, ризасызлык белдерә...

Сүз дә юк, Кубаньдагы кебек берләшмәне булдыру бик авыр. Бу якта да тормышның башка мәшәкатьләре җитәрлек. Терлек азыгы әзерләүне юлга сала алмауга мең-миллион аклану табарга мөмкин, тик кубаньлылар эшне яхшырту турында уйланганнар һәм юкны бар иткәннәр, киләчәккә тагын да зуррак планнар коралар.

Берничә хуҗалыкның күмәк көче белән ашлыктан гына түгел, авыл хуҗалыгы продуктларының калдык-постыгыннан да терлек азыгы әзерли торган индустрия булдыру — һәрьяклы хуплауларга лаек адым. Дөрес, Кубаньдагы башлангычка матур гына теләкләр белдерәсе килә: әйтик, хуҗалыкара заводларның складлары юк. Колхоз-совхозларны амбар тоту мәшәкатеннән коткара алмаганнар; коеп яуган яңгыр астында җыелган чи ашлыкны кабул итеп торырдай киптерү җайланмалары да — әлегә якты өмет кенә... Тик хәзергә бер нәрсәне, һичшиксез, отышлы икәнен билгеләргә кирәк: хуҗалыкларның күмәк көче белән салынган бу заводлар Әзерләүләр министрлыгыннан аксым, аминокислоталар, төрле тәмләткечләр кебек өстәмәләрне бераз алса да, дәүләт чималын эшкәртүдә, аңа шактый җиңеллек китерә.

Авылның үсеше, анда төрледән-төрле фабрикалар, комбиазык заводы манаралары барлыкка килү — техника прогрессы билгеләре генә түгел, бу — хуҗалыкны яңача җитәкләү, яңача фикер йөртү галәмәте дә. Комбиазык заводы, дәүләтнеке булса да, аны берничә хуҗалык берләшеп салып куйса да, ул — янгын сүндерү

сараеның каланчасы гына түгел. Кыйммәтле төзелеш ул. Аның артыннан әле тагын мең төрле яңа мәшәкать килә. Чәчү әйләнешең ничек көйләнгән? Терлек азыгына кирәкле бөртеклеләрең җитәрлекме? Конвейерыңнан чыккан азык туклыклымы?..

Бүгенге заман, басулардан җыелган ашлыкны, болыннарда үскән печәнне һәм башка байлыкларыңны терлек азыгына әйләндергәндә, шактый нык уйлау таләп итә. Дөрес әзерләнгән азык кына сөенечле нәтиҗәләргә китерә.

Соңгы ун ел эчендә терлекчелекнең шактый алга китүе, ә игенчелектә шуңа тиң торырлык үзгәрешләр ясадыкмы соң? Аксымны мул бирүче кузаклы культуралар чәчү, симертү өчен бик файдалы каротин дигән матдәгә бай витаминлы печән оны җитештерү арттымы? Дөресен генә әйткәндә, телгә алып сөйләрлек яңалык сизелми. РСФСРда дәүләткә сатылган кузаклылар елга — миллион тоннага җитәр-җитмәс. Аңа ихтыяҗ исә өч-дүрт тапкыр артыграк. Печән онын һәр хуҗалыкта ясыйлар, әмма ул фуражга өч-дүрт процент чамасы гына эләгә.

Комбиазык индустриясен торгызу белән генә дә, әгәр аның казаннарына салынырга тиешле бөртеклеләрең булмаса, мәсьәлә хәл ителми.

Кавказының кояш нуры белән өретелгән Кубань, Дон, Ставрополь кебек төбәкләре, сүз дә юк, башлыча, бодай, дөге, кукуруз игү буенча дан тоталар. Моннан тыш бары терлек асрау белән генә шөгыльләнүче, ягъни азык туплауда, Әзерләүләр министрлыгы шәфкатенә генә ышыкланып яшәүче төбәкләр күпме?! Бу җәһәттән, Ленинград һәм Мәскәү өлкәләре терлекчеләрен аерып алып күрсәтергә мөмкин. Зур ике башкаланы туендырып торучылар буларак, алар дәүләттән комбиазыкны, үзләре тапшырган ашлыкка караганда, күбрәк сорыйлар. Әле саткан бөртеклеләре нинди икәненә дә игътибар итик. Бодай. Бодайның да терлек азыгы өчен кулай булмаган көчле сорты. Арыш һәм аз гына арпа белән солы.

Бу якларда үскән көчле бодай турында берничә сүз әйтеп үтәргә кирәктер, мөгаен. Җилемлелеге егерме өч процентган да ким булмаса, мондый төр бодайдан күпереп торган ак күмәчләр пешерәләр. Күмәчкә яраклы бодайны бездә Тәньяк Кавказ, Кубань, Оренбург, Омск, Саратов, Ульяновск өлкәләрендә, Ставрополь краенда, Алтайда уңышлы игәләр. Кара туфраклы төбәкнең Воронеж, Липецк, Курск, Тамбов якларында, кара туфраксыз тирәлекнең Рязань, Орел, Псков, Мордовия, Мари АССР басуларыннан җыелган көчле бодайның сыйфаты исә шактый кайтыш.

Безнең Татарстанда үскән ул бодай оныннан куелган әче камырдан тәмлетәмле пешерә башласалар, иң уңган хуҗабикәләр дә оятка калачаклар. Әле: «Яңа уңыш бодаеннан тарттырган он иде дә бит, каһәр суккан тегермәнче башкасы белән бутаган, ахры»,— дип, аклану эзләп азапланырлар. Гел шулай: я тегермәнчеңе, я ирен, я чүпрәне гаепләргә ашыгалар. Әмма ул җитешсезлек гәрәбә кебек бодайның үзендә. Шул ук көчле сортлы бодай да безнең якларда җилемлелекне уналты процент чамасы гына җыя ала, күмәчкә дигән бодайның исә җилемлелеге, кимендә, егерме бер процент булырга тиеш.

Унынчы бишьеллыкта РСФСРда җыелган көчле бодайның чиреге генә күмәч пешерергә ярарлык булган. Әзерләүләр министрлыгына нинди бөртек бирсәң дә, әйбәт комбиазыкка алмаштырып алырга мөмкин дигән ялгыш фикернең терлекләр һәм кош-кортлар башына таш булып төшүен чамаламаганнар. Малларга туену өчен файдасыз бодай артык дәрәҗәдә күп бирелә, ул бөтен фуражның яртысын диярлек алып тора. Иң кирәкле ризыктан саналган кузаклылар исә елданелга кими генә бара. Әзерләүләр министрлыгы заводларын әйткән дә юк, хәтта колхоз-совхозларның үзләрендәге комбиазык цехларында да кулга ни эләксә, шуны тарттырып-болгатып тик яталар.

• • •

Мин, кайта-кайта, Стародубцев колхозының комбиазык заводы турында уйланам. Бу тирәдә андый предприятие башка юк, шуңа да карамастан, Стародубцев терлекләренең рәхәттә яшәвен күреп торсалар да, колхоз заводына: «Безнең

бөртекләрне дә туклыклы азыкка әйләндереп бирегезсәнә!» — дип, үтенеп килүче юк. Завод кешеләре хәтта: «Без сезгә хезмәт күрсәтергә каршы түгел»,— дигән хәбәр дә таратканнар. Юк, килүче күренми. Әллә Стародубцевка түләүдән аны артык баетып җибәрүдән шикләнәләр? Монысы, әллә нәрсәгә үч итеп, туны мичкә ягу кебек бит инде.

Бу сәер хәл бер Тулада гына да түгел. Татарстандагы хуҗалыкларда, мәсәлән, фураж өчен, миллион тоннадан артык ашлык калдырыла. Соңгы елларда комбиазык әзерләүче дәүләт предприятиеләренә ярдәмгә КамАЗ янындагы аграр зонада яңа завод сафка басты. Әлки, Апас, Чүпрәле, Зәй, Лениногорск, Минзәлә, Мөслим, Балык Бистәсе, Тәтеш, Тукай, Чирмешән районнарында, әллә ни көчлеләрдән булмаса да, хуҗалыкара заводлар бар. Бу очракта сүз заводлар турында түгел, аларның нәрсә җитештерүе хакында барырга тиеш, әлбәттә. Кызганычка каршы, мактанырлык нәрсәләр юк дәрәҗәсендә. Складлары булмаганга, колхоз-совхозлар әйбәт чималны заводка бирмиләр. Заводларга ындыр табагы калдыклары, амбардан арткан-порткан бөртек кенә эләгә. Ә заводтан әйбәт комбиазык көтәләр, анысы туклыклы да, тәмле дә, арзан да булсын диләр. Шул рәвешле, көтеп алган байлык чыганаклары яңа югалтуларга гына китерә. Хуҗалыклар да фураж мәшәкатеннән котылмадылар, заводлар да әллә ни отмады. Терлекчеләр, сөенечен-көенечен бергә кушып: «Комбиазык — шул ук безнең бөртек инде ул, сыйфаты гына начаррак»,— дип офтанырга мәҗбүрләр. Бөтен җегәренә эшләп алмый интегеп ятучы җитмеш җиде предприятиедән тыш, районнарда тагын егерме ике агрегат бар. Октябрь районының «Комбайн» колхозында нәкъ Стародубцевныкы кебек завод инде менә ун ел тик тора. Татарстандагы бу төр предприятиеләрнең бер сменада тарттыру мөмкинлеге — ярты миллион тонна, алар исә моннан ике ярым тапкыр азрак эшлиләр.

Әзерләүләр министрлыгы биргән азыкны, мең бәясенә төшереп, җәһәннәм ераклыгыннан барып алырга атлыгып торалар, үзләре башлап йөрергә иренәләр. Гаҗәп хәл: эшкә тотынмас борын ялкауланырга кайдан өйрәнеп алганнар соң?

Ни өчен крестьян шулкадәр файдалы заводларны өнәп бетерми? Отышы күз алдында ялтырап ята бит: чыгым да, көч тә азрак китә — бусы бер; ашлыкны да, ил күләмендә санасаң, егерме миллион тоннасын, янга калдырырга була — ике; шул ук рацион белән ит, сөт, йомырка җитештерү егерме процентка арта — монысы иң мөһиме.

Сүзем буш яңгырау гына булып калмасын өчен, Татарстаннан читкәрәк китеп, мисаллар эзләп карыйк. Мин Кубаньның Тимашевскидагы хуҗалыкара комбиазык әзерләү заводын яхшы беләм. Заводның директоры Геннадий Васильевич Гладунец — агрономлыкка әзерләнгән белгеч. Башта ул колхозда эшләгән, хәзер җир биргән байлыкка нигезләнгән производствоны җитәкли. Ул сәер итеп:

— Мин элек зур уңыш турында хыялландым, хәзер аны ясыйм,— диде.

— Уңышны ясап буламыни?

— Ике өлеш ашлыкка бер өлеш өстәмәләр кушабыз. Гел фураждан гына торган азыкка караганда, туклыклырак, нәтиҗәлелеге егерме-егерме биш процентка артыграк азык килеп чыга. Терлеккә чиста бөртек ашаткан хуҗалыклардагы тиресне өр-яңадан басуга илтеп чәчәргә мөмкин бит!..

— Отышыгыз күпме инде?

— Башка — баш, тоннага — тонна!

Бу кеше шактый еллар кырлар киңлегенең юмартлыгына ышанып яшәгән, сөргән, чәчкән, уңыш көткән, табигатьнең шәфкатен дә, кырыслыгын да кичергән. Хәзер исә, бер карасаң, өр-яңа тармакта эшли, әмма аның эшкә иҗади мөнәсәбәте игенчелектәге уңышларны завод конвейерында икеләтергә мөмкинлек биргән. Джонатан Свифт, кеше, гомере буе, бер сабакта ике башак үстерергә омтылып яшәячәк, дип язганда, минемчә, ике башаклы үсемлекне басудан көтеп ятучылар турында гына уйламагандыр. Уңышны икеләтә аласың икән, аңа нәкъ кырда гына ирешергә димәгән бит!

Тимашевскидагы завод халык төзелеше ысулы белән салынган. Дөрес, ... юньнән җыелган ярдәмче хуҗалык вәкилләре «Севкавэлеваторстрой» дигән рәми бер подразделениегә берләштерелгәннәр. Буп-буш җирдә кузгалып киткән те-

зелештән, ике ел үтәр-үтмәстә, завод калкып чыккан, терлек азыгы әзерли башлаганнар. Халыкның, тырышкан табар, ташка кадак кагар, дигәне шулдыр инде ул! Ялкаулар азык юклыкка сукранып, аклану эзләп ята бирсеннәр!

Без Гладунец белән, сигез катлы заводның лифтына утырып, өскә күтәрелдек, аннан җәяүләп кенә аска төштек. Заводның унике линиясе дә гөрләп эшләп утыра. Директор:

— Әле болай гына эш бетмәс бетүен,— ди.— Хәзергә монда безнең биш көнлек чеби ризыгыннан башлап, биш потлы дуңгызларга да ярардай азыклар әзерләнә...

Тимашевскидагы завод һәртөрле мактауларга лаек булса да, аның мәшәкатьләре дә җитәрлек икән әле. Мин Кубаньда чакта, бу якның зур уңыш җыеп алган бәхетле көннәре иде. Дәүләткә дүрт миллион тоннадан артык икмәк сатылган. Әмма әлеге завод дәүләт чималын эшкәртеп ята. Нәрсә бу, колхоз-совхозларның үзләрендә фураж өчен калдырылган ашлык юкмыни соң? Әле бу чорда ук алай булмаска тиеш иде бит. Монда крестьянның беркатлы хәйләсе генә яшеренгәндер, мөгаен: башта, дәүләткә мөмкин кадәр күбрәк ашлык сатып, рапорт бирә, аннары, Әзерләүләр министрлыгын «кыса» башлый. Төбәк ота, чөнки ашлык сату планын үтәгән. Министрлык та бөртеклеләрне кабул итүдә җиңеп чыккан, комбиазык программасын башкарырга атлыгып тора ул.

Тугызынчы бишьеллык белән чагыштырганда, унынчы бишьеллыкта сатып алынган ашлык йөз дә унбер процент, ә аны кабаттан хуҗалыкларга өләшү йөз дә унөч процент тәшкил итә. Концентрат рәвешендә киредән сатып алу — йөз алтмыш процент. Татарстанда, мәсәлән, шушы ук дәвердә дәүләткә ашлык сату ундүрт процентка артты, ә аннан концентратлар сатып алу сиксән сигез процентка җитте. Ашлык сату Кубаньда, Донда, Ставропольдә, Төньяк Кавказ республикаларында, кара туфраклы зонада да артты, тик дәүләттән килә торган комбиазыкка булган ихтыяҗ да үскәннән-үсә бара. Краснодар, Ставрополь крайлары, Ростов өлкәсе, дәүләткә бөртеклеләр сатуны сизелер-сизелмәс кенә арттырган хәлләрендә, дәүләт элеваторларыннан ала торган концентратларны уннан ике, уннан бер мәртәбәгә күбәйттеләр. Кубань ел саен миллион ярым тонна бөртекне яңадан сатып ала.

Илтәләр дә кайтаралар, саталар да үзләре сатып алалар, бирәләр дә кире сорыйлар. Бу алыш-биреш терлек азыгының сыйфатын яхшыртуга илтсә, хуҗалыклар терлек тукландыру хәсрәтеннән тулаем котыла алса, аптырамас та идең. Кызганычка каршы, азыкның сыйфаты шул ук бөртеклеләргә бәйле булып кала бирә һәм дәүләт элеваторыннан алынган азык хуҗалыкта кабаттан тукландыру таләп итә, махсус цехлар ачалар, белгечләр билгелиләр. Күпме көч исраф ителә?!

Тагын да мөһимрәге бар әле: колхоз-совхозлар иген иккәндә дә, аны дәүләткә сатканда да, үз фермаларының теләген искә алмыйлар. Терлек азыгы рационындагы бөртекнең унбиш-егерме процентын витаминлы печән оны белән алмаштыру файдалырак булыр иде. Мондый он өчен үстерелә торган үләннәр уңышны, башаклыларга караганда, ике тапкыр артыграк бирүчән. Өстәвенә, аларның туклыклылыгы да бөртеклеләрнекеннән кайтыш түгел. Печән онының каротинга бай икәнен дә исәпкә алсаң, комбиазык заводларының бу яшел ризык белән һичшиксез тәэмин ителергә тиешлеге ап-ачык. Яшел азыкта каротинның күплеге чык тамчыларының шифасыннан килә, диләр. Халык җырлары да иртәнге чыкны бер дә юкка гына мактамыйлар.

Декабрь ае иде. Мин РСФСР Әзерләүләр министрлыгында утырам. Берничә көннән банк, ел белән исәп-хисапны түгәрәкләп, барлык эшләрне ябып куячак. Ел бетәргә ике атна вакыт калган, яшел витаминнар буенча план тутыру өчен йөз мең тонна печән оны җитми. Бу чорда печән чаба алмыйсың, яшел он тарттыру агрегатлары күптән тынган, бу төр азыкның килер юлы ябык. Шуңа күрә, аны алмашка, ашлык ташырга тотындылар. Сәнәк урынына — көрәк, иләк урынына — чиләк...

Терлек азыгының кырык-кырык биш процентын бөртеклеләр тулыландырып тора. Хәтта күши торган хайваннарга да ашлык бирәләр. Бу — гомер-гомердән кил-

гән гадәтне бозу, терлек азыгы өчен, иген кырларының өлешенә керү, печәнлекләрнең абруен төшерү.

Дөрес, РСФСР хуҗалыкларындагы печән тарттыручы уналты мең йөз алтмыш тугыз агрегатның һәммәсендә дәүләт заказы бар, әмма ул бик кечкенә — һәр җайланма нибары илле тонна продукция эшләп тапшырырга тиеш. Татарстанның Актаныш районы «Коммунизмга» колхозындагы бер агрегат җәй буена мең дә ике йөз тонна витаминлы азык ясый. Алга куелган бурычтан шактый аермалы сан бит бу, ә?!

Димәк, бу эштә дәүләт тарафыннан күрсәтелгән планны үтәү генә чик булмаска тиеш иде, чөнки комбиазык әзерләүдә формализмга бирелү, ялкаулану, аның сыйфатына «хыянәт итү» хуҗалыкның үзенә үк зыян китерә. Әзерләүләр министрлыгына озатканда, тиешле таләпләргә җавап бирмәүче чимал җибәрү дә — үз-үзеңне алдау ул, ник дисәң, начар сыйфатлы бөртекләләрдән әйбәт комбиазык ясап булмый.

Татарстан колхоз-совхозлары унынчы бишьеллыкта өч йөз сиксән мең тонна витаминлы азык әзерләгәннәр, шуның утыз тугыз мең тоннасын дәүләткә сатканнар. План үтәлмәгән, аны бер ярым мәртәбә кимрәк итеп башкарганнар. 1982 елны печән билдән иде, агрегатлар туксан мең тонна витаминлы азык ясадылар. Монысы да — планда каралганның яртысы гына әле. Аның өчтән бер өлешен бөртекләләр тулыландырдылар.

Халык хуҗалыгында җирле мәнфәгатьләрдән чыгып кына эш игү чире гомуми максатка юнәлдерелгән көчне сыегайта. Дәүләткүләм омтылышка зыян китерүче иң яман күренеш бу.

Әзерләүләр министрлыгына нәрсә тапшырыла? Аның сыйфаты нинди? Гел дәүләттән алынган концентратлар хисабына көн күрүче Мәскәү өлкәсе хуҗалыклары, мәсәлән, сиксән мең тонна печән оны ясаганнар. Аның яртысыннан артыгы беренче һәм дүртенче класслы булган. План үтәлмәгәч, ашлык тапшырырга мәҗбүр булганнар, чөнки витаминлы азыкның егерме бер мең тоннасы тиешле таләпләргә җавап бирерлек итеп әзерләнмәгән, ягъни мәсәлән, брак килеп чыккан. РСФСР авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына караганда, 1982 елда дүрт миллион тонна күләмендә әзерләнгән печән онының яртысы диярлек беренче һәм өченче класслы. Ул комбиазык заводларына сигез йөз мең тонна тапшырылган, шуның дүрттән өч өлеше — һичнинди таләпләргә дә җавап бирә алмый торган бишенче класслы. Аңлашыла: хуҗалыклар яхшысын үзләренә алып калганнар, бернәрсәгә дә ярамый торганын комбиазык ясарга биргәннәр. Янәсе, Әзерләүләр министрлыгын төп башына утырталар!

Шулай, җәмәгать, авылның борынгы фәлсәфәсеннән котылулар җиңел түгел ул! Совхоз директорлары, колхоз председательләре, район, хәтта өлкә күләм җитәкчеләр дә, витаминлы азыкларны үз хуҗалыкларында калдырып торуны алга сөреп, Әзерләүләр министрлыгы үз җаен ничек тә үзе карар әле, дип фикер йөртәләр. Министрлыкның «җае» мәгълүм: колхоз-совхозлар ни бирсә, ул, шуны ук болгатып тарттыра да, хезмәте өчен, шактый хак өстәп, хуҗалыкларга кире тарата. Шуннан кемнең отканын, кайсының оттырганын чамала инде!

* * *

Иң кыены — юкны бар итү, табу, ясау, кечкенә генә авылың мәшәкатен дәүләт җилкәсенә менгезмәү. Кирәк тирәкне ега дигән әйтем бар. Хуҗалык кирәкләре, әллә нинди җитди күрсәтмәләреңне дә, дәгъваларыңны дә, ялварулы үтенечләреңне дә читкә куеп, булмаганны бар итә ала. Гадәттә, бөтен омтылышлар, әйтик, административ күрсәтмәләр дә, экономик исәп-хисаплар да, теләк һәм энтузиазм да бер ноктага тупланса, уңышка ирешү җиңел.

Миңа комбиазык әзерләү индустриясенең дәүләт күләмендә дә, хуҗалыкара да, колхоз-совхозларның үзендә дә шактый алга киткән Кубань якларында бу мәсьәләләр белән якыннан танышырга туры килде. Дәүләт карамагындагы заводларда әзерләнә торган комбиазык составында бөртекләләр дүрт процентка артыграк. Шактый зур аерма бу. Мондагы витаминлы яшел азыкның нибары өч бөтен

йөздән кырык биш процент булуы да күзгә ташланды. Соя юк. Борчак — кырыннан кешегә парикмахерлар өрдерә торган хушбуй күләмендә генә, тәм өчен генә кертелгән, ноль бөтен йөздән ике процент. Хуҗалыкара заводларда витаминлы азык сигез бөтен уннан бер процент файдаланылган, унбиш мең тонна борчак һәм соя кушканнар, бу дүрт ярым процент тәшкил итә. Дөрес, монысы да — оҗмах ашы түгел түгелен, шулай да саннар үскән, сигез — өч ярымнан, ә ноль бөтен йөздән ике процент дүрт ярым проценттан шактый аерыла!

Хикмәт нәрсәдә соң? Ни өчен терлекләр өчен иң кирәкле компонентлар элеваторга эләкми, бик уңган җитәкчеләр дә, боз сугу, яңгыр кою, юл юклык кебек мең төрле сәбәпләргә аркаланып, бу төр ризыкларны дәүләткә бирми калу әмәлен табалар да, үзләренә дигәндә, әле генә телгә алынган кыенлыкларны җиңеп чыгалар? Бөтен эш — принципта, исәп-хисабыңны нинди юнәлештә алып баруда.

Мәгълүм ки, һәр бөртекленең, һәр үләннең үз кыйммәте, үз җитешсезлеге бар. Печән оны каротинга бай, малларның үсүенә, чыдамлылыгына этәргеч бирә ул; борчак, соя, вика, люпин, рапс кебек кузаклыларда аксым, аминокислоталар күп; бодай исә җилемлелеге белән аерылып тора. Тик бу күркәм сыйфатларны бутарга ярамый. Әйтик, күмәч пешерергә кирәкле бодай терлек тагарагына чыгарып салынмаска тиеш. Терлек азыгы әзерләгәндә дә, бөртекләрне башка-баш алмаштыру — зур хата.

Кубаньда хуҗалыкара предприятие иярәре, азыкның чын асылын билгеләү өчен, чагыштырмача, коэффициент булдырганнар. Заводка бер тонна витаминлы печән оны (сүз, әлбәттә, Әзерләүләр министрлыгына тапшырыла торган түбән сортлы он турында бармый) китерсәң, тонна ярым, борчакның бер тоннасы — ике тонна, соянын тоннасы өч тонна комбиазык алырга хокук бирә. Тимашев районының Калинин исемендәге колхозы, мәсәлән, хуҗалыкара заводка сигез йөз тонна борчак тапшырган да мең алты йөз тонна комбиазык алып киткән.

Татарстан икмәк ризыклары идарәсе начальнигы Вәли Фәттахов:

— Алмаштыру гадәте бездә дә бар ул,— дип сөйли. Дәүләт предприятиеләре белән хуҗалыкларның алмаштыру мөнәсәбәтләре, билгеле күләмдә, урнаша башлаган икән.— Тик без тоннага тонна бирәбез...

— Кубаньдагыча көйли алыр идегезме соң?

— Юк инде, агайне, анысы барып чыкмас!

— Нишләп? Әллә ни катлаулылыгы юк бит инде?

— Тегеләр бит — һәвәскәрләр алар. Үзара килешәләр дә — вәссәлам! Без — дәүләт оешмасы. Закон, күрсәтмәләр...

Тормышта бернәрсә дә үзеннән-үзе генә барлыкка килми. Күрсәтмәләрсез генә туган яңалыкларга аеруча игътибарлылык кирәк, чөнки бу очракта, һичшиксез, тормыш ихтыяҗы үзе тудырган файда була. Хуҗалыкара предприятие иярәре азык составына керә торган компонентларның кыйммәтен үзләренчә бәяләп чыкканнар икән, нигә шундый ук системаны министрлыкларда да булдырмаска? Аның бик файдалы чара булачагына ышану кыен түгел. Һәр бөртекле һәм кузаклы культура, үзенең уңай һәм җитешсез яклары белән, бер-берсеннән нык аерыла. Шуңа да карамастан, элеваторлардагы исәп-хисап бары тик центнерларга гына көйләнгән. Җирдән алынган уңыш — тонна белән, ә тоннасы тәңкә белән генә санала. РСФСРның үзәгендә үстерелгән бодайның тоннасына — йөз, борчакныкына — ике йөз, карабодайныкына өч йөз сум түлиләр. Карабодай өчен комбиазык та бирәләр.

Сатканда түләнә торган акча карабодай, тары, борчак, соя кебек культураларны үстерү өчен тотылган чыгымнарга, хуҗалыкның алар өчен кичерелгән борчуларына һич тә туры килми. Председательгә дә, директорга да, район, өлкә яки республика җитәкчеләренә дә җирнең һәр гектарыннан алынган ашлыкның күләме кадерле. Монысы — аларның йөз аклыгы. Ачыктан-ачык сөйләшкәндә, нәкъ менә шуңа күрә дә күпчелек җитәкчеләр тонна артыннан куалар.

Нәтиҗәдә нәрсә килеп чыга соң? Карабодай, тары, борчак кебек культуралар акча күбрәк килә. Авыл хуҗалыгы министрлыгы аларны, мөмкин кадәр, киңрәк басуларда үстерүне алга сөрә, Әзерләүләр министрлыгы аларны үзендә муллрак тупларга тырыша, тик көткәннәрнең киресе килеп чыга. Элеваторлар карабодай

белән тарыны сугышка кадәрге күләмдә кабул итәләр, кузаклылар сигезенче бишьеллыктагы дәрәҗәдә кала бирә. Агрономнарның ашлык үстерүгә булган мондый мөнәсәбәте гөрләп чәчәк атканда, терлекчелек өлкәсендәге белгечләр нишли ала? Иң зур борчу тудырган мәсьәлә шул, минемчә.

* * *

Күрдегезме, краснодарлылар кичергән хәлләр тиз арада Татарстан, Башкортстан, Урал, Себер, кара туфраксыз яклар башына төшәчәк мәшәкатьләр турында күпме сораулар күтәрә?!

Тимашев заводының бик тәвәккәл директоры Гладунец иптәш миңа бер фикергә килердәй иптәшләр булдыру турында да, төзелеш кыенлыклары турында да озаклап сөйләде. Әңгәмә уңаенда, мәсьәләнең иң четерекле ягы, килешенгән хуҗалыклардан чимал килмәү очраклары хакында да сүз кузгалды. Хикмәтнең асылына төшү өчен, предприятие хезмәтеннән файдаланучыларның үзләрен күрергә кирәк иде. Һәм без районның «Россия» колхозына юл алдык.

Станица, үзенең асфальтлы урамнары белән үк, башка авыллардан аерыла. Бик уңайлы стадионнары бар. Колхоз идарәсенең бинасы хәтта мәрмәр белән дә бизәлгән. Председатель Владимир Григорьевич Кулик кабинетны да иркен итеп ясаткан: зур бүлмә артында тагын бер аулак почмак бар. Хәзер шундый нәрсә модага керде бит. Өстәлдә — минераль су. Әйбәт. Мәскәүдәге шактый дәрәҗәле җитәкчеләр дә мондый мәйданда өч кабинет ясау ягын чамалар иде, мөгаен. Председатель Куликның эшне шул юнәлештә алып баруын гаеп итмик. Киресенчә, колхозның мондый киң колачлы тормышын хупларга кирәк. Монда һичнинди гөнаһ та юк, барысы да — тир түгеп хезмәт итүнең сөенечле нәтиҗәсе. Дөньяда төрле хәлләр бар. Кайбер колхозлар муеннан бурычта утыра, шуның ук председателе дәүләт кредитына алган «Волга»да сиптерә. Исе дә китми!

«Россия» колхозының банкта саклана торган дүрт миллион сум запасы бар. Күктән төшмәгән бит ул — тырышлык хикмәте. Димәк, хуҗалыкның уңышлары тотрыклы. Узган 1982 елда бодайны — һәр гектардан кырык алты, арпаны — кырык, кукурузны — алтмыш җиде, сояны — унсигез, борчакны утыз центнер алганнар. Терлекләре дә тук. Мал башына егермешәр центнер исәбеннән азык әзерләгәннәр. Кирәксә, күршеләргә бирергә дә әзер торалар.

Сүз дә юк, бу — зур уңыш. Әмма Кубаньның «Россия» колхозында Тула өлкәсенең Ленин исемендәге, Татарстанның «Кощак» һәм «Восточный» хуҗалыкларындагы нәтиҗәлелек юк. Тегеләр сыерлардан елга бишәр-алтышар мең литр сава, ә «Россия»нең моңа бер савымчысы гына ирешкән. Лидия Иванова Березная гына.

«Россия» колхозы бу яклардагы башка ике йөз хуҗалык кебек үк, комбиазык әзерләүче хуҗалыкара предприятиенең бер члены булып тора. Монда бу яңалыкны фураж мәшәкатен хәл итүдәге мең дә бер хәсрәттән коткару чарасы дип, хуплап каршы алганнар. Тиешле акчаны да керткәннәр, әмма чималның иң әйбәтен, барыбер, үзләрендә калдыру ягын чамалыйлар.

Уйлыйк әле: ни өчен «Россия», хуҗалыкара заводка илтеп бирүгә караганда, фураж амбарын үзендә булдыруны кулайрак саный? Крестьянның, байлыгыны сандыгыңа салып бикла дә ачкычын ычкырыңа тагып йөр, дигән элекке кагыйдәгә буйсынуымы бу?

«Россия» председателе Владимир Григорьевич Кулик белән сөйләшкәндә, бу хакта да фикер алыштык. Ник әле болар, завод бирә торган комбиазыктан баш тартып, фуражны үзләре ясарга булганнар? Күпме өстәмә мәшәкать?!

— Болай ышанычлырак! — дип, Кулик үз күңелендәгене ачты да бирде.— Фуражга ашлык күп: йөз тонна соябыз бар, өч йөз тонна борчак, кирәк чакта, теләгән кадәр болгатабыз да фермага илтәбез. Завод белән сөйләшә башласаң, бүген кирәк әйберeңне иртәгә җибәрәләр; син бозау азыгы сорыйсың, алар кысыр сыерга да ярамый торганны төртә. Үзәккә үтәрдәй башка яклары да бар: ике мең тонна арпа тапшырдык, аңа, үзебезчә, саклык кассасына салган акчага ышангандай, өмет багладык, янәсе иң кирәк чакта гына алабыз... Аны район планына керткәннәр. Без бирдек — башкалар файдалана...

Бу җитәкченең фикеренә каршы торырлык сүз юк.

Комбиазык әзерләү индустриясе Әзерләүләр министрлыгына да, хуҗалыкара предприятиеләргә дә карый торган, әлегә, чагыштырмача, яшь тармактан санала. Әмма аның киләчәге өметле. Кубаньга Татарстан да, башка өлкәләр дә ияреп һәм, нәтиҗәдә, бер генә бөртек тә, бүлгеч-тарткычларга кереп, болгатылмыйча терлек тагарагына төшмәс. Тик, бу эшнең тәмен татыр өчен, үзара килешкән хуҗалыкларның мөнәсәбәтләрен, исәп-хисап өлешләрен ачыклап куясы бар. Һәркем үз бурычын һәм ни алачагын төгәл белергә тиеш.

КПСС Үзәк Комитетының 1982 елгы май Пленумында Азык-төлек программасы кабул ителгәч, агропромышленность комплекслары планлаштыруның мөстәкыйль объектлары итеп билгеләнделәр. Өч меңләгән трестлар, главкалар һәм башка төр конторалар бетерелеп, бу эшкә ярдәм итәрдәй агропромышленность берләшмәләре булдырылды. Районнарда гына да өч мең илле дүрт берләшмә барлыкка килде. Аларның советлары хуҗалыклар бер-берсенә бирә торган байлыкны бәяләү хокукына да ия.

Бу — зур хокук, олы бурыч. Районнардагы агропромышленность берләшмәләре артык сүз куертулардан, кәгазь күпертүләрдән башка гына, һәр хуҗалыкның иҗади мөмкинлекләрен ачу өчен, бөтен көчләрен куярга тиешләр.

Илдәге кырык мең колхоз-совхоз үзләре иккән ашлыкны ничек итеп файдалануны үзләре белгели: дәүләткә сатып, аннан комбиазык аламы ул, күршедәге хуҗалык заводына илтеп тарттырамы, үзара берләшеп оештырылган предприятие хезмәтеннән файдаланамы — аның үз ихтыярында. Биш-ун хуҗалык берләшсә, фураж ясау заводына шул җиткән. Бу эш, әлбәттә, тиз генә үтәлә торганнардан түгел. Аңа административ күрсәтмәләр бирү ысулы белән генә ирешеп булмый. Монда хуҗалыкларның теләге, ышанычы, омтылышы һәм ихтыяр көче таләп ителә.

Әмма, ничек кенә булмасын, бер хуҗалык гомум эшкә нинди өлеш кертсә, ул шуңа тиң өлешне алырга да тиеш. Фермага кирәкле азыкны сораганда, син биргән ашлык, район планы нигезендә, фәлән якка озатылды шул инде дигән язу сузмасыннар иде!

Комбиазык әзерләүгә катнашучылар, киләчәккә юнәлгән теләкләрен бик ачык белдерсәләр дә, хәзерге кимчелекләрдән зарланырга ашыкмыйлар, хәлне аңлыйлар кебек. Азыкның сыйфатына бәйле бәхәсләр әдәбияттагы мәгълүм персонажлар Иван Иванович белән Иван Никифоровичның ызгышуына охшаш.

Казанга якын гына урнашкан «Юбилейная» кошчылык фабрикасын, «Сосновоборский» дуңгызчылык комплексы хезмәткәрләре концентратларның «сыек»лыгына зарланалар. «Комсомольский» совхозында, күркәләрне үрдәк азыгы белән туендырырга туры килә, дип, «аһ» оралар. «Красный ключ» кошчылык фермасында да шундый ук хәл. 1982 елны егерме биш мең тонна азыкны Брежнев шәһәрендәге, Бөгелмәдәге, хәтта Казан һәм Октябрь Норлаты кебек ерак шәһәрләрдәге заводлардан ташыганнар. Тагын шунысын да әйтергә кирәк: бу азык тиешле таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәдә булмаган, алынган продукциянең унтугыз мең тоннасы, ГОСТ белән чагыштырганда, дәгъвалашырлык дәрәҗәдә икән. Дәүләтнең башка кайсы предприятиесендә мондый башбаштаклыкка юл куела! Зоотехникларның исәп-хисабыннан чыгып әйтергә мөмкин: терлекләргә бирелгән азыкта — сиксән бер тонна протеин, йөз егерме дүрт тонна кальций җитешми. Бу ризыкны тиешле дәрәҗәгә күтәрү өчен, «Красный ключ» фабрикасы, өстәмә рәвештә мең дә бер йөз кырык алты тонна өстәмәләр кертергә мәҗбүр булган, гомум хезмәт коллективка бер миллион ике йөз сиксән мең сумга төшкән. Ни лектән шулай килеп чыккан соң?

Чөнки комбиазык әзерләүче оешма белән терлек асраучы хуҗалыклар арасындагы элемтә шундый: азык бирүчесе соңгы нәтиҗә өчен җавап тотмый. Комбиазык әзерләүчесе җибәреп тора, алучысы ала, бөтенләй башкалар түп күрсәткечне саный.

КПСС Үзәк Комитетының 1982 елны ноябрь Пленумында КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Юрий Владимирович Андропов ап-ачык итеп

күрсәтте: политик һәм хуҗалык эшләренең үзәгендә нәтиҗәлелек өчен җавап бирү күздә тотылырга тиеш, ул, санга карап түгел, колхоз-совхоз һәм предприятиеләрнең, төзелешләрнең мөмкинлегеннән ни дәрәҗәдә дөрес файдалануларыннан чыгып билгеләнергә тиеш.

РСФСР Әзерләүләр министрлыгының чимал һәм үзләштерү бүлеге начальнигы Валентина Николаевна Карпова миңа терлек азыгы составындагы аксымда, төрле өстәмә тәмләткечләрдә бик зур ихтыяҗ барлыгын әйтте. Хәзергә тиешенчә бәры кош-кортны гына канәгатьләндерә алалар икән, ит һәм сөт җитештерү фабрикаларының таләбен «кулдан килгәнчә» генә каплыйлар. Болай булгач, кош-корт үрчетүчеләрнең эше көйләнгән инде! Ал да сип — калганы синең кайгы түгел! РСФСРдагы «Птицепром» оешмасына алты йөзләп предприятие карый. Әзерләүләр министрлыгына берләштерелгәннәрен исәпләве дә кыен. Анда дүрт меңләгән эшче азык әзерләү белән шөгыльләнә — шунысы гына мәгълүм. Санап караган идем, аларга ел саен алты миллион чамасы хезмәт хакы түләргә кирәк. Кош фабрикаларын тәэмин итәргә тиешле оешмалар баш ваталар, хуҗалыкара предприятиеләр, азыкның кирәкле төрләрен эзләп, әллә кемнәргә мөрәҗәгать итәләр, ә үзләре исә гади генә чуер ташны да, бака кабырчыгын да табып бирергә теләмиләр. Анысын гына, мөгаен, үзләре дә булдыра алырлар иде бит инде!

Үзара мөнәсәбәтләрне кем конкретлаштырып торыр, алыш-бирештә генә түгел, арзанлы ит, сөт, ашлык җитештерүдә яңа сүзне беренче башлап кем әйтер? Арзанлы азык-төлек җитештерүдәге кызыксынуны кем уятып җибәрер, аның өчен кем җавап бирер?

— Безгә бары тик башка-баш эшләү генә отышлы,— диде миңа «Россия» колхозының председателе Владимир Кулик.— Комбиазык заводлары, хуҗалыклардагы нәтиҗә турында да уйласыннар иде!

Тимашев заводы директоры Гладунец та бу фикергә кушылырга әзер иде.

Димәк, һәр ике як та үзара килешүгә бара. Эш рәсми күрсәтмәгә генә терәлеп калган. «Россия» председателе Кулик, без бу хакта сөйләшкән арада, ачыктан-ачык әйтеп салды:

— Безгә бик әйбәт булыр иде ул! — диде.— Комбиазык заводлары, бәхәсләшеп-нитеп тормастан, ике як өчен дә отышлы юлны сайласыннар!

Тимашев заводы директоры Гладунец та шул ук фикердә.

— Мин хезмәтебезнең ңамуска тап төшермәвен телим! — ди ул.

Моңа охшаш фикерләрне кәгазьгә теркәү миңа да рәхәт.

Тирәннәнрәк уйлап карасаң, гаҗәеп бер башваткыч килеп чыга, бер тирәдә әйләнеп тик йөрисең, әйләнмәнең азагы юк бит аның. Әйтик, Әзерләүләр министрлыгы, бөртекleләр сатып алуда, төп рольне уйнамый, нинди ашлыкны хуплау, терлекләргә генә кирәклесен сайлап алу, кайсын ничек бәяләү хокукы аңа бирелмәгән. Авыл хуҗалыгы министрлыгы исә, үз чиратында, комбиазык индустриясен буйсындыра алмый. Шулай итеп, төрле оешмаларның вак-төяк мәшәкатьләре гомумҗәмгыять мәнфәгатьләрен үз кубызына биетә килә.

Сүзне йомгаклар алдыннан берничә соңгы санга тукталыйм әле. РСФСРда фураж эшкәртә торган ике мең ярым фабрика бар. Алар терлек азыгы өчен калдырылган егерме миллион тонна ашлыкның барысын да эшкәртерлек куәткә ия булсалар да, бөртекләләр терлек тагарагына турыдан-туры салынып ята.

Ел әйләнәсенә терлеккә бөртек килеш ашатыла торган ашлык, ил күләмендә санаганда, кырык миллион тоннага җитә. Гади болгату ысулы гына да бу байлыкның, кимендә, чирегең, ягъни ун миллион тоннасын, саклап калдырырга мөмкинлек бирер иде.

Без шуңа ирешә алмыйбыз.

Ни өчен? Өйрәнеп җитә алмыйбызмы? Ялкаулык, ирену кебек яман гадәттән котыла алмыйбызмы? Алаймы-болаймы, ун миллион тонна ашлык җилгә оча! Бу бит — Татарстан кебек зур республика игенчеләренең ике ел буе тир түгеп тапкан икмәгенә тиң байлык!




## Мәрди Рафиков

# УРМАН ХУҖАСЫ

Көзге урман тынлыкка чумган. Җиләкле-чәчәкле аланнарда шашынып-шашынып кошлар сайраган чак узган. Агачлар оеп-изрәп утыралар. Бу тормышка шаулап килеп керү әдәпсезлек булыр сыман. Хәзер кошлар да ботактан-ботакка пырхылдамыйча, сак кына очалар. Имән кәүсәсендә тәмле ризык тапкан күксел үрмәләч кенә, кем беләндер шатлыгын уртаклашырга теләгәндәй, чыркылдап ала да, әрсез тукран агачка тукып, саңгырау аваз чыгарып куя.

Яфраклар коела. Ботакларны аралап, берничә кат талпынып алалар да, нәкъ кирәкле урынга килеп төшәләр: урман юлына келәм түшәлә. Никадәр бизәк үзендә — күзләр камаша!

Анна Ефимовна шул гаҗәеп бизәкле йомшак келәм буйлап бара. Күңеленә сораулар килә: ни өчен кешеләр язны күбрәк мактыйлар? Көзге бизәкләрне, бу тынлыкны, җанга рәхәт, тәнгә, аңа кодрәт бирүчән бу сафлыкны күреп, тоеп бетермиләрдер...

Бүген Анна Ефимовнаның ял көне иде. Башта йорт эшләрен карады. Улы белән килене кайтасы итмәделәр ахры, мәшәкатьләре табылгандыр. Көтә-көтә сабырлыгы сынгач, ул тагын урманына җыенды. Язгы кыраудан имгәнгән туйраларны карап кайта, янәсе. Ләкин бу — матур хәйлә генә, ул тын урманның бизәкле юлыннан, беркемнең комачавын тоймыйча, кичерешләрен барлап, хисләре белән серләшеп үтәргә омтыла...

И күңел! Кайчагында син артык узынып китәсең, ачы хәсрәтләрне дә татлы истәлекләр итеп тоясың. Хәтер Анна Ефимовнага Саша белән очрашу тойгыларын яңартырга ирек бирә. Хикмәт бит! Ул көннәрдән соң ни гомер узган!..

Сугыш еллары иде. Уналты яшьлек кыз хәрби госпитальдә санитарка булып эшли. Воронеж фронттан әллә ни ерак түгел. Үлем хәлендәге сугышчыларны дары исе сеңгән шинельләре белән үк китерәләр. Иреннәре генә кыймылдый, яралы каһарманнар гарасатлы җирдәге кыюлыкларын дәвам иттереп пышылдыйлар: «Алга! Атакага!..»

Берсендә япь-яшь танкистны кертеп салдылар. Туктаусыз ыңгырашмаса, тәнендә җаны бар дип уйламас та идең. Ак марлядан көбә күлмәк кидергәннәр үзенә, беренче карашка, җәрәхәтенең кай җирендә икәнен белерлек тә түгел. Кисәк саңгырау авазлар чыгара. Саташа дип уйлыйсың. Ләкин сугышчылар саташмыйлар, алар, йөрәк егәрен сизгән арада, дошманга каршы омтылалар: «Минем арттан!..» Ә Аня бу командаларны белә, андый чакта сугышчы янына барып, битеннән, маңгаеннан сыйпап, аны тынычландырырга тырыша.

Яшь танкист янында күбрәк булырга туры килә иде, чөнки бу яралы сугышчы, аңын югалткан саен, үрсәләнергә тотына, ут ачарга, кабахәт дошманны сы-

тып ташларга боера, аннары... су сорап пышылдый. Аня аңа тынычланган чагында сокланып карап тора. Пәһлеван гәүдә, киң җилкә — шинеленә ничек сыйган диярсең. Юка иреннәре һәр сугышчыны ышандырырлык итеп бирәдер команданы. Аня танкистның исемен дә белде: Александр Ануфриевич Тимошин. Саша!

Беркөнне Саша күзләрен ачты, Аняга текәлеп карады, нидер әйтмәк булды. Ләкин бу мизгел тиз үтте, хәле һаман авыр иде әле. Икенче мәртәбәдә аңына килгәч, ул Аняга елмая кебек тоелды. Кызның йөрәге сулкылдап алды, үзе дә сизмәстән, чәчләрен төзәткәләде. Өметле елмаю сизү күңелне рәхәтләндерә иде.

Берничә көннән Сашаны операциягә алдылар. Бу — батыр сугышчының операцияләргә беренче адымы гына булган икән. Хирург өстәленә алты тапкыр ятарга туры килде аңа. Соңгысында Аняның үзенә дә ашыгыч кына операция бүлмәсенә керергә туры килде. Хирург аңа сүзсез генә аңлатты: «Тагын кан кирәк!» Госпитальдә эшләүчеләр моңа ияләнгән инде. Бу юлы исә канын Сашага бирүе Аняны бәхетле итә иде.

Саша озак савыкты. Азап белән булса да тәрәзә янына килгәли башлады. Санитар кыз Сашаны бер ноктага төбәлгән килеш күрде. Госпиталь ишегалдында сәламәтләнгән сугышчыларны озаталар иде.

— Бәхетлеләр фронтка китә,— диде Саша.

— Сине дә озатырбыз. Атлый ук башладың ич инде.

— Юк, кадерлем, миннән сугышчы чыкмый инде, бу аяклар басып торырга гына.

Кешенең, күрәсең, эчке сиземләве бар. Ул үз халәтен ачыграк белә, бөтен тетрәнүләрен тоя, шуннан чыгып язмышын билгеләргә тырыша. Рухи төшенкелек булмасын өчен, андый чакта янында серне бүлешердәй, өметне ныгытышырдай кеше кирәк. Аның ягымлы сүзе гел ишетелеп торсын, санитар кыз яшь танкист өчен шундый зат иде.

Ә Саша тиздән госпитальдән китәсен, Аня белән саубуллашачагын белә иде. Ул, баш врач янында булып, аңадан фронтка җибәрүләрен дә сораган иде. Юатты гына: «Шушы яраларыңа канәгать бул! Сиңа, иптәш танкист, ял кирәк!» — янәсе.

Саша туган ягын ешрак искә ала башлады. Беркөнне ул Аняга да сөйләп утырды.

— Күрсәң иде безнең Идел буйларының матурлыгын! Текә яр башында утырасың: пароходлар йөзә, акчарлаклар чыр-чу килеп очалар. Алар бер пароходны озаталар, икенчесен каршы алалар, суга утырып, ял итәләр. Теге якның яры беленми дә. Аннан бормаланып Кама килеп чыга. Ике дәү елга киң тугайда очрашалар. Анда җиләкле болыннар, әрәмәлекләр! Ул болыннарда печән чабабыз без. Авылның иң күңелле чагы инде!

Саша, сүзеннән туктап, санитар кызга карады.

— Синең яр урманын күргәнең бармы, Аня?

— Инеш буендагы тал арасына керергә дә куркам мин, Саша.

— Ә мин яратам яр урманын.— Саша тагын туган төбәгенең бер бизәген күзаллап ахры, хискә бирелеп сөйли башлады: — Гасырлар буе талгын гына аккан Идел уңъяк ярның бөтен катлам төсмерләрен ачып төшкән, тик аларны, болай караганда, күрә дә алмыйсың. Бары да урман астында. Бөтен чокыр-ерганакларны яр урманы, аралап үтә алмаслык юкәлекләр, имәнлекләр каплаган. Кай җирдә агачлар, тамырларын ыржайтып, елга өстенә авар төсле торалар. Ярны җимерелүдән саклыйлар.

— Һәлак та булалармы, Саша?

— Булалар, илгә тугры сугышчылар кебек...— Аннары, онытылган фикерен барлагандай, әйтеп куйды.— Иделнең җимерелердәй ярлары да бар әле. Урман утыртасы иде шунда!

— Сугыштан соң инде, Саша!

Аня Александр Ануфриевичны станциягә кадәр озата барды.

— Үзеңне сакла, Саша! — диде ул.

Александр Ануфриевич елмаерга тырышты:

— Инвалидка нәрсә булсын соң?

— Алай да сакла үзеңне!
— Мин хат язып торырмын.
— Рәхмәт, Саша.

Алар шулай саубуллаштылар. Яшь танкист, култык таякларына таянып, туган ягына, Идел ярына юл алды...

* * *

Тын урман истәлекләрнең иң матурларын яңарта. Ә шулай да рәссамнар көзге урманны ни өчен гел сарыга манчыйлар? Сагыш телиләрме?

Анна Ефимовна усакларга күтәрелеп карады. Аларның бу вакытта яфраклары куе-кызыл була. Агачның итәгенә күз төшерсәң, анда кызгылт тамчылы каракош куагын, я гөлҗимеш күрәсең. Кипшергән үлән арасында энҗе чәчәкнең җимешләре очкынлана. Дүләнә һәм миләшләргә гүя ут капкан!..

Бервакыт Александр Ануфриевич Аняны агачлар арасыннан түмгәкле сазга алып чыкты. Хәйран тамаша иде анда! Балан яна. Нәзберек ботаклардан сазның кара-кучкыл суы өстенә сыгылган тәлгәшләр затлы алка кашларыдай җемелдиләр. Борынгылар кызның чәчрәп торган матурлыгын күз алдына китерү өчен балан тәлгәшләренә караганнар. Бу җимешләр урма куенында тыйнак кына, күзгә бәрелмичә генә өлгерәләр, аннары, бөтен гүзәллекләрен чәчрәтеп, үзләренә чакыралар. Кызлар да шулай түгелмени?! Аня үзе Сашаның күңелен ничек яулады соң?

Госпитальдән кайткач ук, Саша санитар кызга хат язды. Анысы җайлы гына кайтып җитү хәбәре иде. Икенче хат юксыну хисләрен алып килде...

Анна Ефимовна атлый торган юлыннан читкә каерылды, киселгән агач төбенә барып утырды. Саша белән кабат очрашуларын исенә төшерде. Илленче елларның башы иде. Воронеждан бу якка килеп төште. Саша аны очынып каршылады. Иделне күрсәтергә генә чакырган иде, бөтенләйгә үзендә калдырды.

Бу чакта Александр Ануфриевич трактор бригадасын җитәкли иде. Аңа рәхәт: өйдә табын тезеп хатыны көтә. Алар әле һаман да сөйләшеп туя алмыйлар. Аня шаянлана, кайчак көтелмәгән, сынаулы сораулар бирә:

— Теге чакта болын печәне өстенә ятып күктән бәхет йолдызыңны эзләвең турында сөйләгән идең, Саша. Әле дә булса таба алмадыңмы?

— Таптым инде, таптым,— ди Сашасы, хатынын күкрәгенә кыса.

Дөньялары түгәрәк иде. Аня бер малай да бүләк иткәч, тракторчылар бригадирының башы күккә тигәндәй булды, тәнендә сугыш яралары йөрткәнен дә онытты. Чир аны үзе эзләп тапты. Трактор ремонтлыйлар иде. Авыр өлешләрне күтәртеп алырга кул астында кран юк. Трактор рамын күчергәндә, Александр бөтен мускулларын киерде...

Аны авыр хәлдә Казан больницасына алып киттеләр. Йөрәк зарарланган иде. Анна Ефимовна ике көннең берендә Казанга чапты. Дәвалаучы врач хәлнең җитдилеген кисәтә.

Александр Ануфриевич больницада җиде ай ятты. Беренче группа бирделәр. Ир уртасы кеше өчен бик аяныч хәл иде бу — хезмәттән бөтенләйгә аерылу. Бу йөрәк кеше җиң сызганганны карап утырырга гына калды микәнни? Ир-егет яуга күтәрелер, тау кичәр, таш актарыр — ул шуңа яралган, ә эшсез утыру, гафу итегез, профессор, аның шөгыле түгел. Хәрәкәттә — бәрәкәт, диләр, йөрәк тә хәрәкәттә ныгыр. Александр Ануфриевич фикерләрне шулай үз үлчәвенә салды. Ләкин профессор да хаклы, йөрәккә ял кирәк иде. Анна Ефимовна профессорның кисәтүен, җае туры килгән саен, кабатлый торды. Бервакыт иренең сөенеч белән кайтуын белгәч тә, куанырга ашыкмады.

— Котлыйм сине — ирең урманчы булды! — диде Александр Ануфриевич. Хатыны дәшмәгәч, сәерсенеп калды, үзе китмәгәндә акланырга тотынды.—Урманны әйтәм, һавасы әйбәт, сәламәтлегем дә ныгыр. Хәтерлисеңме, мин сиңа Идел ярының шәрә урыннары турында сөйләгән идем. Ул җирләр мәңге шулай калмас бит инде. Үзебезнең урманны үстербез — Тимошиннар урманын. Иртән — эшкә!

Хезмәтне тансыклаган иде инде ул. Анна Ефимовна да иренә иярде. Урман күрү өчен түгел, Сашаның сәламәтлеге борчыды аны. Бераздан күңегә төште төшүен. Тик ире кайтмыйча, авызына ризык каба алмый иде.

Идел өстенә тагын яз килде. Калкулыкта чирәмнәр борынлады. Ак каеннар өрфия яулыкларын бәйләргә җыендылар. Александр Ануфриевич аеруча сөенеп кайтты.

— Трактор булды! — диде ул.— Кышлавык тавына урман утыртабыз.

Менә шуннан соң башланды да инде бөтен тамаша. Урманчы үзе, тракторга утырып, калку җирнең чирәмен күтәрде, туфрагын эшкәртте. Булышчылар алырга мөмкин түгел иде. Александр Ануфриевич күбрәк үз көченә ышанды. Ярдәмгә хатынын да чакырды. Идел ярына имән утыртырга ниятләп, гади генә чәчкеч ясады. Беренче буразналар сызылды, имән орлыклары җылы туфракка күмелеп калды. Тимошиннар шат, алар Кышлавык тавында яшь урман күрәләр иде инде.

Бер көнне тамак ялгарга туктагач, текә ярдан Идел өстенә карап утырдылар.

Александр Ануфриевич уйларының очын барлады бугай, ул, Иделнең сул ярында сызылып күренгән урманга ымлап, Анна Ефимовнага дәште:

— Теге яктагы наратларны күрәсеңме?

— Мин аларга гел сокланып карыйм.

— Безнең урман да шулай үсәр. Кошлары да элекке әрәмәлектәге шикелле сайрап торыр. Кешеләр җиләк, гөмбә җыярга йөрерләр.

— Шулай була күрсен инде!

Кеше, мөгаен, хыялы белән көчледер. Чөнки ул хыял аның йөрәгеннән чыга, канатлы була. Ә канатлар еракка да илтәләр, биеккә дә күтәрәләр. Бәхетсез кешедә мондый хыял була алмый торгандыр. Нурлы хыялы дөрләмәсә, Тимошиннар да урман утыртырга керешә алмас иделәр. Аның кыенлыгы никадәр!

Тигезрәк җирдә эшләве бер хәер, ә сөзәк урында трактор белән үтә алмыйсың. Әле аның кәҗә сукмак салырдай гына төшләре бар. Андый чакта ирлехатынлы Тимошиннар кулга көрәк алалар, оялар казып чыгалар да шул йомшартылган җиргә агач үсентесе тертәләр.

Мавыгып эшләгәндә ару-талу беленми, хезмәтне ярату көч биргәндәй итә. Бу Тимошиннар өчен дә шулай иде. Александр Ануфриевич бер көнне каен үсентеләре алып кайтты.

— Әллә, мәйтәм, каен аллеясы сузыйкмы, Аня? — диде ул.— Яшьлегебезне сагынган саен шунда барырбыз.

— Утыртыйк соң. Гомер юлыбызга истәлек булыр.

Олы юл буеннан башладылар. Александр Ануфриевич бер оя казыды да яшь каенны утыртып куйды. Ә үзе елмаеп хатынына карады: бусы мин, янәсе. Анна Ефимовна янәшәдә генә йомшак җиргә икенче каенны төртте. Үзе мәгънәле итеп иренә елмайды: ә бусы мин булам, янәсе, җитәкләшеп барабыз. Яшь каеннар, ике рәт булып, Иделгә тикле тезелделәр. Тирә-якны наратлар, өрәңгеләр биләде. Яр кырыйлары зелпеләр белән ныгытылды...

Идел ярына яңа яз килгән саен, утыз гектарлап урман утыртылды. Ирле-хатынлы Тимошиннар башладылар, урманчылык һәм тирә-як авылларның кешеләре ярдәмгә килде. Элек җил уйнап торган Кышлавык һәм Юрьев тауларында яшь урманнар күтәрелде. Александр Тимошин сакчылыгындагы биләмәләр меңөч йөз гектардан артты. Тәтеш урман хуҗалыгының Кариле урманчылыгында карталарны тулыландырырга туры килде. Идел ярындагы яшь урманнарны картага җитмеш җиденче квартал исеме белән керттеләр. Тимошиннарның беренче зур хезмәте кабул ителде.

Шатлык белән янәшә хәсрәт йөри, диләр. Ул кадәресен Александр Ануфриевич уйламый да калгандыр. Урманчы хезмәтенә алынуының унынчы елында, яр урманына яңа бизәкләр өстәү мәшәкате белән үз-үзен онытып йөргәндә, аның электән хәлсезләнгән йөрәге кинәт кенә тибүдән туктады. Анна Ефимовна өчен истәлекле урманы калды да юанырга улы Славик бар иде.

* * *

Урман тынлыгын бозып, саескан кычкырып үтте. Ул уйга батып утырган Анна Ефимовнаны сискәндереп җибәрде. Озаграк тукталган икән шул, тын җирдә израп үк киткән. Ул, капылт кына торды да, юлдан борылып, үзе генә белгән сукмактан баланлы сазлык ягына юнәлде.

Баланның иң матур чагы иде. Һәр җиләгенә гүя кояш нуры тулган! Анна Ефимовна түмгәктән-түмгәккә күчә-күчә балан куаклары янына ук килде, янып торган тәлгәшкә үрелде. Шунда үзе дә сизмәстән аягын чылатты. Юеш аяк киеме белән озак йөрергә ярамас, дип, ул түмгәктән-түмгәккә атлап, юлга чыкты да, өзеп алган тәлгәшен кулына тоткан килеш, авылына атлады.

Ул теге чакта, ирен җирләгәч, Кама тамагы районының Кече Мәрәтхуҗа авылында, бакча эченә чумып утырган өендә улы Славик белән икәүдән-икәү генә яшәп калды. Үстергән урманын да ташлап китә алмады, ире постына үзе басты. Аның бу уңайдан ачык фикере бар иде: Александр үстергән агачларны күрәчәк, аларның иминлеген саклап торачак, кирәксә, ярдәм итәчәк.

Иң беренче эше итеп ул авыл артындагы карт урманга барырга җыенды. Урманчы формасын киде, иңенә мылтык асты. Агачлар арасында бер үзе йөрергә күнекмәгән иде. Бәлки ул куркудан да түгелдер. Янында сүз алышырдай кеше булса рәхәтрәк. Үзеңне кыюрак сизәсең, көтелмәгән очрашуларда да югалып калмыйсың. Урманга барысы да саф һава суларга, табигать гүзәллеген күрергә генә бармыйлар. Аның байлыгына кул сузарга теләүчеләр дә очрый. Андыйлар юлга аркылы төшүне өнәп бетермиләр.

Анна Ефимовна үзе белән улы Славикны алды. Малайның шатлыгын күрсәң иде! Әнисе белән бергә әти урманын сакларга баралар. Бүредән дә курыкмыйлар, чөнки әтидән калган чын мылтыклары бар. Әнисе төзәп ата белмәсә дә, янда мылтык булгач, тыныч.

Менә алар ничә сәгать буе урманда йөриләр. Агач башында йөгерек җил уйный, ботакларны чайкалдыра. Бераз йөргәч, урман шавына күнегеп бетәсең, ят тавыш, көчсез генә булса да, колакны яра. Анна Ефимовна да урман гүләвеннән аерым гөрселдәү тавышын ишетеп алды. Малаен җитәкләп, тавыш килгән якка китте.

Анда әзмәвердәй ике ир өч имәнне аударганнар да ботарлапмы-ботарлыйлар. Мәгълүм ки, дәүләт урманы — шәхси бакча түгел. Әзмәверләр бу турыда уйламыйлар иде. Агачлар арасыннан урманчы киемендә яшь хатын килеп чыккач, бераз аптырап калдылар бугай, пычкыларын кулдан җибәрделәр. Ләкин карашлары бик тиз усалланды. Бу минутта Анна Ефимовна да ярсыган иде.

— Тимошин үлгәч, урманның хуҗасы юк дип исәпләдегезме әллә? — Ул малаен үзенә якынрак китереп бастырды.— Менә без хуҗалар! Дәүләт урманын без саклыйбыз.

Анна Ефимовна үзендәге катгыйлыкка үзе хәйран калды. Исенә «кылт» итеп иренең: «Урман каравылчысына бераз усаллык та кирәк»,— дигән сүзләре килеп төште. Менә кайчан кирәк икән ул усаллык! Имән егучылар да урманчы хатынның ярсуыннан шикләнделәр, урманнан коры кул белән китәргә мәҗбүр булдылар. Соңыннан җавап тотарга да туры килде...

Анна Ефимовна ире вафат булгач та Идел ярына агачлар утыртуны дәвам иттерде. Элеккеләре нык тамыр җибәрделәр дә, без дә күкрәп яшәргә хаклы, дигән сыман, буйга үсеп киттеләр, елга сәяхәтчеләрен таң калдырырлык булып Иделгә йөз белән күтәрелделәр: имәннәр, наратлар, каеннар... Бер сафта, рәт-рәт... Аларга нәреп яңа утырткаппары тернәкләнде. Урманчы агачларны нарасыен тәрбияләгәндәй үстерә. Орлыкларны җиргә салганчы бер кайгыра, инде алар аксыл яшел сабаклары белән җир өстенә килеп чыккач, тагын каударланып йөри: кырау алмасмы, кояш көйдермәсме? Чүп үләннәр хирысланса, нәфрәте кайный, әссе җилләр уйнаса, сары шәүләгән кебек яңгыр тели, чыклы иртәләрне көтә.

Шулай бер яза яр өстендәге тагын бер калкулыкны «яулап алды» Анна Ефимовна. Шартын китереп белгечләр белән киңәште. Барын да дәлилләп күрсәтте. Чалгы алырлык печән дә үсми иде анда, ерганаклана да башлаган иде. Бу

жирдә урман үстерү хәерлерәк. Урманчы хатынның фикере белән килештеләр. Ярдәм итәргә дә булдылар.

Яшь агачлар тамырлары белән туфракка ябышкач ук гүя урман булып яшәргә сәләтләрен күрсәттеләр. Анна Ефимовна Идел ярына килгән саен рәт аралары күзәтеп торды. Шушы биләмәгә китмәнчеләр белән килеп йөргән чаклары да бар иде. Ләкин бер көнне яшь урманын күреп чак кына үксемәде Анна Ефимовна. Анда сарык көтүе йөри иде. Бу очракта урманчыга нишләргә? Бөтен сабырлыгыңны саклап терлекләрне куалап чыгарыргамы? Никадәр хезмәтеңне, барлык сөенеч-куанычларыңны күз алдыңда юкка чыгарганда андый сабырлыкны каян табарсың да, мәрхәмәтсез белән дуамал сөйләшмичә ничек түзәсең?!

Анна Ефимовна көтүче янына очып килгәндәй булды. Ярсуыннан тыны кысылды. Ул бары тик:

— Нишләвең бу? — дип кычкыра алды.

— Ник, нәрсә булган? Ашасыннар,— диде көтүче, беркатлы булып кыланып.— Печәнен чапмыйсың бит.

— Агачларны харап иттергәнсең.— Анна Ефимовна ни кылануын да белмичә көтүче кулындагы чыбыркыны тартып алды, илаһи бер куәт белән һавага селтәнде. Көтүче баскан урынында сикереп куйды, аннары бер алдына, бер артына карый-карый, терлекләрне куаларга тотынды. Анна Ефимовна көтүне һәм көтүчене авылга тикле юыртып кайтарды. Яшь агачларны таптаткан көтүчене хөкем залында да каты гаепләде ул. Арабызда кеше хезмәтен һәм табигатьне санламаучы туң йөрәклеләр булганда, монысы да бик кирәк.

Анна Ефимовнага урман юлында андыйлар очраштыргаладылар шул. Ул бервакыт йөрәк өзгеч күренешкә тап булды. Сер түгел, каен аллеяга еш килә иде ул. Олы юл ягыннан керә дә ике рәткә җеп кебек сузылган ап-ак кәүсәле каеннар арасыннан ире белән сөйләшкән кебек Иделгә тикле төшә. Аннары каеннарның берсенә барып сөялә. Бу минутта аның ниләр уйлавын сүзсез аңлыйсың. Анна Ефимовна, каеннан сызылган истәлек аллея булмаса: «Урманымның һәр агачын тигез яратам!» — дип әйтә алыр иде. Ләкин ул ике рәткә пар-пар булып баскан каеннарын ныграк ярата шул. Чөнки бу аллея — аларның яшьлек истәлеге. Анна Ефимовна аны ире үлгәч, күз карасыдай карап, саклап яшәде, ә берсендә шашар хәлгә җитте: аллеяга исерек тракторчы килеп кергән, ничә пар каен, чылбыр астында калып изелгән.

Исерек бәндә үзе дә ерак китә алмаган икән. Аллеядагы тракторында гыргыр килеп йоклап ята. Тракторчы төп җавапны суд залында тотты. Ә урманчы хатын шаһит кына түгел иде, ул гаепләп сөйләде, урманга зыян китерүчегә каты җәза таләп итте.

Теге чакта сарык көтүеннән зарарланган яшь урманны да төзәттеләр, урманның бизәге булган истәлек аллея да яңартылды. Ләкин Анна Ефимовнаның күңеле тыныч түгел иде. Яңа ел якынлаштымы, Идел ярындагы яшь наратлыкка юл салалар. Төннәр буе, суык җилеккә үткәнче, сакларга туры килә. Андый чакта гаиләсе белән гипс рудникы поселогында яшәүче улы Вячеслав Александрович ярдәмгә чыга. Якындагы авылдан да булышырга киләләр. Ә көндез халыкка сату өчен бергәләп яңа ел чыршылары әзерлиләр.

Идел ярында гаҗәеп урманнар күтәрелә икән, аны үстерүчеләр, каравыллаучылар барлыгын онытмыйк! Яр урманында поста безнең танышыбыз, кыен язмышлы тынгысыз кеше Анна Тимошина тора.

Кама тамагы. 1982.

Мәхмүт Хәсәнов

# ОЛЫ ЯЗМЫШЛАР ЮКСЫНДЫРА...

Бүгенге проза турында сөйләшүне дәвам итеп тагын шунысын да әйтми булмый: без, татар прозаиклары, ифрат дәрәҗәдә аз язабыз. Алайса — сыйфат ягы яхшыдыр бәлки? Алай дияр идең, кайда соң зур социаль проблемаларны эченә алган, гүзәл геройларны гәүдәләндергән әсәрләребез? Үзе артыннан әйдәп барырлык, җәмгыятьнең рухи тормышына йогынты ясый алырлык, чын мәгънәсендә олы язмышларны сурәтләгән әсәрләребез кайда?

Нишләп соң әле иҗат иткән әсәрләребез тормыштан, чынбарлыктан, җәмгыять үсешеннән шактый артта кала? Ни өчен катлаулы һәм әһәмиятле мәсьәләләр соңгы елларда язылган әсәрләребезне читләтеп үтә?

Дөрес, әдипләр арасында күп язу яки язмау турында берничә төрле караш яши. Бер ишеләре: бер көн дә язмый калмаска, диләр. Икенчеләре: бары тик язмыйча булдыра алмаганда гына язарга, дигән фикерне яклыйлар... Мин үзем беренчеләр ягында. Язу эше — шул ук хезмәт ул, анда теләү-теләмәү белән санашып торырга, илһам килгәнне көтеп ятарга ярамый. Бер хакыйкать бар: илһам эшләгәндә килә. Мөмкин кадәр күбрәк язарга кирәк. Талант сыйфат белән генә түгел, күләм белән дә үлчәнә дигән А. П. Чехов. Фатыйх ага Хөсни әйтмешли: «Бәлки гел генә алтын күкәй салып тормабыздыр, ләкин корыга кытаклап йөрүгә караганда, күкәйне сала торганың яхшы».

Әдәбият дөньясында, күп язу буенча, адәм әйтеп адәм ышанмаслык феноменнар бар. Мәсәлән, XVIII гасыр Бальзагы дип йөртелә торган Ретиф де Ло Бретонн (1734—1806) 300 томга якын әсәр язган. 300 том! Бөек комедиограф Лопе де Вега (1562—1635) турында да могҗизалы сүзләр йөри. Аның гомеренең һәр көненә (туган көненнән үлгәнчегә кадәр) алтышар юл шигырь туры килә икән.

Хәер, замандашыбыз Жорж Сименонны гына алып карыйк. Бүгенге көндә ул 209 роман авторы. Хикмәт бер санда гына да түгел, ә авторның дөньякүләм популярлыгында. Моның шулай икәнлеген раслау өчен Ж. Сименон әсәрләренең сиксәннән артык телгә кабат-кабат тәрҗемә ителүе турында әйтү дә бик җитә. Бүгенге көндә аның комиссар Мегрэсын белмәгән кеше бармы икән? Тагын шунысы кызык, авторның чираттагы әсәре язылып та бетмәгән була, төрле илләрнең продюссерлары, режиссерлары, театр әһелләре, радио-телевидение вәкилләре, тәрҗемәчеләр әсәрне сорап аңа инде тынгылык бирми башлыйлар. Моны бәлки «мода» дип тә аңлатырга мөмкин булыр иде. Әмма моданың бер хикмәтле ягы бар: аны көчләп такмыйлар. Авторның дөньякүләм популярлык казануы, барыннан да элек чор, бүгенге көн сулышын дөрес тоемлауда, вакыт ритмын дөрес тотып алуда һәм сурәтләү чараларының заманга аваздаш булуындадыр.

Автор үзе болай ди:— Мин бик тиз һәм тыгыз итеп язарга тырышам. Язу стиле сюжетның үсү темпына җавап бирергә тиеш дип саныйм. Иң гади тел белән язарга тырышам. Элек роман язучылар һәр нәрсәне җентекләп тасвирладылар, чөнки ул чагында укучы бик күп мәгълүматны китаптан ала иде. Ә хәзер мондый ихтыяҗ калмады. Радио һәм телевидение укучыга яхшы гына мәгълүмат бирде, ә бу язучыны артык эштән коткара.

Бу сүзләрдә һәркайсыбыз колак салырлык фикер бар. Ә без ай-һай ла аз эшлибез икән!

Без Н. В. Гогольнең «Язучының бер генә өйрәтүчесе бар — ул аның укучысы» дигән сүзләрен бик еш искә төшерәбез. Узган елның көзендә Апас районында үткәрелгән әдәбият атналыгында бу сүзләрнең хаклыгына кабат төшенергә туры килде. Безнең бәхеткә каршы әлеге атналык укытучыларның август киңәшмәсе барган көннәргә туры килде. Районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очрашу онытылмаслык бер якты хатирә булып истә калды. Бер үк вакытта татар теле һәм әдәбияты укытучылары әдипләребез адресына җитди генә тәнкыйть сүзләре дә әйттеләр. һәр чыгышта диярлек, укучыларыбызның күңелен чын мәгънәсендә җәлеп итәрлек, аны чынлап торып уйландырырлык, дулкынландырырлык, үсеп килә торган яшь буынга аң-сабак, рухи азык, ныклы терәк, кыскасы, үрнәк алырлык әсәрләрнең торган саен азрак чыгуы турында ачынып сөйләделәр. Күпчелек әсәрләребезнең тематик диапазонының бик нык тараюы, проблемаларның вакланус, әхлакый юнәлешләрнең бик үк ачык булмавы, үзенең күңел сафлыгы белән аерылып торган татар әдәбиятының элеккеге гүзәл сыйфатларын әкренләп югалта баруы турында кайта-кайта сөйләделәр. Бүгенге көн темасына язылган проза әсәрләренең алгы планына тормышта үзенә урын яки үз кыйбласын таба алмаган вак җанлы шәхесләр, тагын да аяныграгы — иргә яки хатынга хыянәт итүче һәм мәхәббәтнең чуалчык сукмакларында адашып йөрүчеләр бирелә. Җитмәсә тагын андый әсәрләрдәге мәхәббәт маҗаралары күрсәтмә-аңлатма булырлык дәрәҗәдә бик тәмләп, бик тәфсилләп языла.

Юк, укытучылар мәхәббәткә каршы түгел. Мәхәббәт — мәңгелек тема, алар бу турыда бик яхшы беләләр, ансыз әдәби әсәр бик сирәктер. Әмма алар чын, олы мәхәббәтне шул дәрәҗәгә җиткереп түбәнәйтүгә, «заманлаштыруга» каршы. Алар кешене бөек итә торган саф, әсәрнең аерып алып булмаслык тукымасы булып кергән һәм һәрьяктан акланган, нигезләнгән мәхәббәт ягында.

Укытучылар, әдәбиятның җан азыгы булуы турында, әдәбиятның яшәешкә тәэсир көче бинииһая булуы турында ассызыклап әйттеләр. Язучының талант көче белән иҗат иткән геройлары, диделәр алар, үлмиләр, үз укучыларын табып, тормышта яшәүләрен дәвам итәләр.

Укытучыларның язучылар алдына куйган таләпләре бер: героик чорыбызга лаек замандашларыбызны сокландырырлык итеп, бөтен тирәнлеге белән күрсәтергә, гәүдәләндерергә! Без иҗат иткән геройлар, заманыбызның реаль вәкиле булу белән берррәттән, киләчәк яшь буын өчен дә нәкъ Корчагиннар, Яшь гвардиячеләр кебек үрнәк алырлык, үз артларыннан әйдәп барырлык геройлар булырга тиешләр.

Шушы ук фикерне без КПСС Үзәк Комитетының «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик тәрбия практикасы белән иҗади элемтәсе турында»гы карарында да ачык күрдек: «Совет кешеләренең яңа буынны рух һәм вакыт буенча үзләренә якын булган, сәнгатьчә ачыш дип кабул ителердәй, кешеләрнең эш-гамәлләренә тәэсир ясардай, халык язмышын чагылдырырдай уңай геройга мохтаҗ».

Әгәр дә бүген миннән, соңгы елларда чыккан иң уңышлы әсәр турында сорасалар, икe дә уйлап тормас идем, язучы Вакыйф Нуруллинның «Аккан су юлын табар» повесте дияр идем. Әйе, повесть татар совет әдәбияты өчен көтеп алынган әсәр булды. Хикмәт повестьның заман таләпләрен, бүгенге көн куйган бурычларны тоеп, катлаулы колхоз производствосын чагылдыруында гына да түгел. Соңгы елларда бу тематиканы күтәргән әсәрләр булмады түгел, булды. Әмма киң катлам укучы күңелен дулкынландырган, җанын кузгаткан әсәрнең шактый вакыт инде күренгәне юк иде шикелле. Бездә авыл темасына әсәрләр языла тора. Аларда персонажларның шәхси тормышлары да шактый киң чагылдырыла, ә менә әдәби чаралар ярдәмендә осталык белән дәвер рухын тоеп яшәүче шәхесне гәүдәләндергән әсәрләр бик аз иҗат ителә.

Повестьның үзәгендә халык мәнфәгате, кешеләр бәхете дип, социалистик җәмгыять идеаллары белән янып-көеп яшәүче, зур ихтыяр көченә һәм югары мораль сыйфатларга ия булган коммунист Булат Вәлиев образы тора. Ул колхоз председателе, фронтовик. Булат җитәкче буларак үз эшенә партия куйган таләпләр биеклегеннән карый, кылган эшләрен анализлый белә. Перспективаны күрә, күңеле белән тоя.

Булат — үз эшенә ахыргача бирелгән бүгенге көн кешесе. Ул рухи яктан чыныккан, әзләнүчән, көрәштән курыкмас һәм оптимист. Психологик яктан да катлаулы, күпкырлы характер итеп бирелгән ул.

Иң әһәмиятлесе шунда: автор төп игътибарны бүгенге көндә һәркемне дулкынландырган, беркемне дә битараф калдырмый торган проблемаларны чишүгә юнәлткән. Әсәрнең колачы да шактый киң, олы бер дәверне эченә ала. Илдәге икмәк муллыгы булдыру өчен барган зур көрәш әсәрнең үзәгенә куелып хәл ителә.

Повестьның тагын бер отышлы ягын билгеләп үтәсе килә. Әсәрдә конфликт киеренке, кискен. Капма-каршы ике фикер көрәшенә корылган бу конфликт аклана. Ахыр чиктә, әсәрнең логикасы буенча, гаделсезлек җиңелә, хакыйкать тантана итә. Райком секретаре дәрәҗәсенә күтәрелгән кара эчле карьерист Шәйхи бәрыбер фаш ителә.

Шуны да өстисе килә: Шәйхи образы турында матбугатта шактый ук каршылыклы фикерләр әйтелде. Төрле яктан җентекләп анализ ясап карагач, тәнкыйть сүзләрендә күпмедер дәрәҗәдә хаклык бар, автор әлеге образны сурәтләгәндә, чыннан да буяуларны артыграк куерткан диясе килә.

Вакыйф Нуруллинның бу әсәренә шулай киң тукталуымның сәбәбе авыл темасына язылган булуда гына түгел. Хәер, мәсьәләнең ул ягына да игътибар итмичә, әһәмият бирмичә мөмкин түгел. Чөнки бүгенге авыл турында язу торган саен авырая. Сәбәбе бер — авылда социаль-экономик процесслар тирәнәя һәм шул процесс белән җитәкчелек итүчеләрнең эчке дөньялары да катлаулана. Бу уңай белән Мәрсель Зариповның «Отышлы әйләнеш» дигән публицистик язмасындагы түбәндәге юлларны искә төшереп үтәсе килә. «Әгәр дә игенчелекне хуҗалык итүнең арифметикасы, дип санасак, игенчелек белән терлекчелекнең икесен бергә алып бару югары математикага тиң». Шәп әйтелгән бит, шайтан алгыры!

Еш кына очракларда, бүгенге темаларга багышланган әсәрләр турында сүз чыкканда: «Бүгенге көн героен беренче нәүбәттә яшь авторлар тудырырга тиеш», дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Әлбәттә, әдәбиятыбызның киләчәге — яшьләр кулында. Ләкин бер үк вакытта: безнең яшь язучыларыбыз әлеге зур миссияне кабул итәргә әзерләрме соң? дип шик белдерүчеләр дә бар.

Бу бик җитди мәсьәлә. Чөнки алмаш хәзерләү һәрбер иҗади оешма алдында торган иң зур проблемаларның берсе. Беренче карашка бу өлкәдә безнең эшләр ал да гөл сыман. Чөнки Татарстан Язучылар союзы яшьләр белән эшләү юнәлешендә үрнәк булырлык эшләр башкарды, күпләр кызыгырлык бай тәҗрибә туплады.

Чынлыкта хәлләр ничегрәк тора соң? Иң әүвәл прозага килгән яшь көчләргә күз салыйк. Кемнәр соң алар? Фәрит Гыйльми, Газиз Кашапов, Разил Вәлиев, Мәрсель Галиев, Азат Ганиев, Разим Вәлиев, Альберт Хәсәнов кебек иптәшләрне хәзер инде яшь язучылар дип булмый... Яше егермегә дә җитмәгән борын М. Шолохов «Тын Дон» кебек эпопеяга алынган, ә 22—23 яшендә инде «Октябрь» журналында романның беренче ике китабын бастырып чыгарган. Аннары хикмәт күләмле әсәрдә генә дә түгел бит. һәр гөлнең үз чәчәге дигәндәй, һәрбер яшь авторның үз тавышы, үз стиле, иҗади индивидуальлеге, үз йөзе белән килүе дә кирәк. Илья Ильф сүзләре белән әйтсәк, «барлык талантлы язучылар төрле-төрле, талантсызлар гына бер төрле яза».

Мәсьәләнең әнә шул ягыннан караганда әллә ни мактанырлыгыбыз юк кебек. Бәлки безгә яшь язучылар белән эшләүнең яңарак, үтемлерәк формалары турында уйлап карарга кирәктер. Сүз дә юк, төрле семинарлар, зона конференцияләре үзләренең бурычларын үтиләр, әмма талантларны төркемләп, «пачкалап» тудыру, һәрхәлдә, мөмкин түгел.

Югары әдәби курсларда укыганда мин үземне Константин Фединга беркетүләрен сорадым. Ул елларда аның иҗаты белән мавыккан чагым булгандыр, мөгаен. Минем Казаннан икәнлегемне белгәч, ул да бәрсүзсез риза булды. Күп дигәндә 5—6 тапкыр очрашканбыздыр, әмма чорыбызның олы әдибе белән булган ул очрашулар гомерем буена онытылмаслык якты хатирәләр булып калды.

Әле дә булса исемдә, мин аңа «Урманчы» һәм «Халисә» дигән хикәяләремне биргән идем. Беренче очрашу, танышу гомуми сүз белән үтте. Шунда ул татар халкын якын күрүен, үз итүен белдерде. Бу турыда ул бик урынлы, бик иплe итеп, безгә

кофе хәзерләгән хатыны Дора Сергеевна белән таныштырган кебек итеп кенә әйтте. Алар 1941—42 елларда Казанда булуларын, Чистайда яшәгән вакытларын искә төшерделәр. Чистайда Асеев, Исаковский, Пастернак, Тренев, Брайнина кебек әдипләрне берләштергән Мәскәү язучылары бүлеге дә оешкан булган.

Очрашканчыга кадәр Константин Александровичның биографиясе, бөтен иҗаты белән танышкан идем. Аның Татарстан хезмәт ияләренең фронттагы татар солдатларына язган хатын рус теленә тәрҗемә итүен, аны аерым китап итеп бастырып чыгаруы турында да белә идем. Ә менә аның әдәбиятта беренче адымнар ясавы да татар һәм башкорт халкы белән бәйле булуы турында ишеткәнем юк иде. Ул 1918 нче елда Петербургта татар һәм башкорт солдатлары өчен чыга торган «Салават» дигән газетада эшләгән. Әдәбиятка беренче адымнарын да шунда ясаган.

Константин Александрович белән икенчеме-өченчеме тапкыр очрашканда хикәяләр турында бик конкрет сөйләшү булды. Ул хикәядә дөрес тон табылуның әһәмиятен ассызымлап үтте. Өлкән әдипнең, әдәбият турында сүз барганда, музыкаль термин куллануы ул вакытта минем өчен шактый ук яңалык иде әле. Әмма тирән мәгънә, төпле фикер булмаса, язучы үз әсәрен ничек кенә бизәмәсен, чуарламасын, андый иҗат җимеше һичкайчан да үз вазифасын үти алмаячагын да әйткән иде ул.

Күпмедер еллар үткәч миңа Константин Александрович Фединның «Судьба романа» дигән зур фәнни хезмәте белән танышырга туры килде. Ул аны Көнбатышта романның жанр буларак яшәргә хакы бармы, юкмы дигән дискуссия уңае белән язган булган. Фединның әлеге китабында түбәндәге сүзләрне укыдым да, кайчандыр «мәгънә», «фикер» турында гәп сатып утырган чакларыбыз бөтен тулылыгы белән күз алдына килде. Менә ул юллар:

«Читателю всегда нужно главное, и только. А главное — мысль.

Читатель, то есть тот воображаемый, нужный тебе, художнику, человек, для которого ты пишешь, умнее тебя. Он догадлив, у него тонкое чутье, он быстро все понимает, и что ты ни подумаешь, что ни замыслишь, он сразу схватит. Он — высший и строжайший критик, его не обманешь пустяками и завитушками. И он живет в тебе.

Слушайся его, и будет все хорошо».

Гомумән, һәрбер әдипнең — яшьме ул, урта яшьтәме — һәръяктан үрнәк алырлык, тормышында ышанычлы терәк, өметле таяныч булырлык остазы булуы кирәктер.

Шагыйрь Ренат Харисның яшьләргә карата: «Язучыны шәхес итә торган өч нәрсә бар: профессиональ сәләт, характер һәм биография», дигән сүзләре хәтердә калган. Сүз дә юк, безнең яшьләребезнең күбесе диярлек профессиональ сәләткә ия. Аларның һәркайсы югары белемле, теоретик яктан хәзерлекле. Характер мәсьәләсенә килсәк, анысы да булыр. Тормыш — бөек остаз, чыныктырыр. Ә менә биография төшенчәсенә туктасак, монда эшләр шәптән түгел. Яшьләрнең катлаулы тормыш юлы үтеп, тормышның үзеннән алынган багажлары, әйтер сүзләре бик чамалы. Бу уңайдан, 200 ләп әсәр авторы, украин әдибе Петр Панчның: «Язучы биографиясенең беренче яртысы тормышны өйрәнүгә, дөньяны танып-белүгә багышланырга тиеш» дигән сүзләре искә төшә.

Әйе, яшь язучыларга тормышның кайнап торган урынына якынаерга кирәк. Бары тик шулай иткәндә генә хезмәт кешесенең эчке дөньясына үтеп кереп булачак. Ә инде зур гомумиләштерүләр, фәлсәфи тирәнлекләр, социаль-психологик төгәллек кебек сыйфатлар, вакыты белән үзләреннән-үзләре киләчәк, минемчә.

Беркемгә дә сер түгел, без әле күп нәрсәне белмибез. Тормыш дигән кырыс һәм мәрхәмәтсез остаз белән «син»гә күчә алганыбыз юк. Күпчелек әсәрләребездә тематик ярлылык, ваклык бар, ил һәм халык кичерешләрен шәхес кичерешләре белән берлектә тою, заман рухын ачык сиземләү, вакыт таләп иткән фикер саллылыгы юк. Икенче төрлерәк итеп әйтсәк, социаль планда киң фикер йөртү, вакыйгаларга дөрес бәя бирү, төпле анализ ясый белү җитенкерәмәү үзен адым саен диярлек сиздереп тора.

Ә бит тирә-юнебездә гаять кызыклы, катлаулы, күпкырлы һәм каршылыклы, бай һәм киеренке тормыш. Безнең дәвер — атом һәм космос чоры, әкиятләрдә генә сөйләнә торган тизлекләр, кискен үзгәрешләр заманы. Тормышыбыз көн саен, сәгать саен кешеләрнең гүзәл характерлар һәм образлар галереясын тәкъдим итеп кенә

тора. Әмма тормыш үз чиратында, әдәбият алдына да торган саен зуррак таләпләр куя. Һәм, бер үк вакытта, җитди генә төзәтмәләр дә кертә. Бу — котылгысыз процесс. Бер генә көнгә калдыңмы, үзеңә үпкәлисең.

Нишләргә соң? диган сорау тууы мөмкин. Җавап бер. Иң яхшы укытучы — тормыш үзе, совет чынбарлыгы. Тормышта үз чорыңның, үз халкыңның кайгы-шатлыклары, мәшәкатьләре белән янып яшәргә, язмышлар хәл ителгән җирдә, язарга җыенган геройларыңның уй-фикерләре, хыял-омтылышларына якын торып, үзең катнашып яшәргә кирәк.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, яшь әдипләрнең тормышка якынаю юллары бик күп. Шуларның берсе — көндәлек матбугатта якыннан торып катнашу. Газетада эшләү яшь язучы өчен файдалы. Бу турыда Константин Федин: газета — язучының дусты, бигрәк тә яшь язучы газетада эшләргә тиеш,— ди. Борис Полевой кичерәк газеталарда эшләү елларын әдәбият буенча беренче күнекмәләр алу мәктәбе дип атаса, сугыш елларында «Правда» газетасында эшләвен: Минем өчен чын мәгънәсендә университет булды, диде. В. Катаев та: «Мин әдәбиятка газета аша килдем»,— ди. К. Симонов, яше алтмыштан узуга да карамастан, үзен горурлык белән: Мин газетчы, дип атады. Һәм үзенең иң соңгы чыккан китапларының берсен: «Журналист булып калам», дип атады. Мондый мисалларны бик күпләп китерергә мөмкин.

Безнең яшьләребез күп кенә яктан шактый ук отышлы хәлдә. Янәшәбездә генә дөньякүләм масштаблы төзелешләр. Димәк, язылачак әсәрләребез өчен материал юклыктан зарлана алмыйбыз. Хәзер инде безнең халыкның бүгенгесен һәм киләчәген КамАЗлардан, илебезнең «валюта цехы» дип телгә кергән Түбән Кама гигантларыннан, Татарстан атом станциясе төзелешеннән башка күзаллавы да кыен.

«Социалистик яшәү рәвеше: яшь шәһәрләр һәм хәзерге заман әдәбияты» диган темага язучыларның Бөтенсоюз конференциясе Брежнев шәһәрендә үткәрелү үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Әлеге конференцияне алып барган Юрий Суровцев сүзләре белән әйтсәк: «Конференция темасын безгә тормыш үзе тәкъдим итте. Яшь калаларда замандашыбызның рухи дөньясындагы үзгәрешләр аеруча ачык күренә, социаль мөнәсәбәтләрнең яңа формалары аеруча ачык төсмерләнә. Ә боларның барысы да әдәби өйрәнү объекты булып тора».

...Тормыш әдипләребез алдына ифрат мөһим һәм берсеннән-берсе катлаулырак проблемаларны куеп кына тора. Чөнки ай үсәсен көн үсәбез, рәхим итеп яз гына. Тирә-юнебездә мәшһүр галимнәр, исемнәре бөтен дөньяга билгеле шәхесләр һәм иң әһәмиятлесе, иң кирәклесе — әдәбиятның төп каһарманы — хезмәт кешесе. Безгә матур үрнәкләр, бөтен илебездә киң яңгыраш тапкан әсәрләр биреп калдырган Габдрахман Әпсәләмов әйткәнчә: «Тормыш үзе шундый югарылыкка күтәрелгән, аларда совет кешеләренең уртак сыйфатлары шулкадәр көчле тупланган, алар язучы тарафыннан гомумиләштерелмичә дә әдәби әсәр герое булып керә алалар».

Күңел тетрәнми, каләм тибрәнми, ди. Бары тик замандашыбызның уй-хыяллары, теләк-максатлары белән янып-көеп яшәгәндә генә без укучыларыбызны дулкынландырырлык, аларның йөрәкләренә барып җитәрлек әсәрләр иҗат итә алачакбыз.

Расул Гамзатовның: халыкчанлык, партиялелек һәрбер язучы өчен пар канат, диган сүзләре хәтердә калган. Бу сүзләр дөньяда ике идеология кылычка-кылыч килгән бер чорда аеруча актуаль яңгырый. Әйе, художество иҗаты соңгы елларда кешеләрнең акылын һәм йөрәген яулап алу өчен кискен көрәш аренасына әверелде. Буржуаз пропаганда, нәкъ менә чикләрне «виза-рөхсәтсез» үтә торган сәнгать чаралары белән безнең кешеләргә тәэсир итәргә маташа. Дөнья тыныч түгел. Хәрби агрессияләр, экономик диверсияләр, идеологик провокацияләр турында һәркөнне диярлек ишетеп торабыз.

Йомгаклау сүзе итеп шуны әйтәсе килә: без әдәбиятны тормыш белән, ә тормышны әдәбият белән чагыштырып карап кына героик чорыбызга лаек әсәрләр иҗат итә алачакбыз.

## Фаяз Дунай

# ДӨРЛӘП АЛА ФИКЕРЛӘР...

— Чу! Кайсы тагын, ни зур бәйрәм, ни зур хәвеф булмаганда, чаңнар кага? Эшле-хисле кешеләрне бимазалап, янә бәхәс, киңәш-табыш дәгъва итә...

— Утсыз төтен чыкмас, диләр. Сәбәп-сылтаулары бардыр...

— Тәки үз каланчасына каратты бит, әй!

— Күңелендәгеи әйтә белә.

— Сабак-вәгазьләре күптән мәгълүм инде...

— Аның каравы, янып-көеп, әрнеп сөйли.

— Әннекәем, ничек зурдан купты! «Ил югарылыгыннан торып караганда, дөнья биеклегенә менеп уйланганда безнең хәлебез бер дә тынычланырлык түгел!» — ди.

— Дөрес шул. Әй, язмыш, язмыш... Тарих бабай, җавап бир әле. Нигә бездә Гомер юк, хәр Баян да юк. Аристотель, Рафаэльләр, Пикассолар, Шекспир вә Байроннар, Гете, Гейне, Бетховеннар, Гомәр Хәйям, Низамилар, Пушкиннар да, Толстойлар, Шолоховлар, Джек Лондон, Айтматов, Маркеслар... юк? Әллә син ялкау булдыңмы? Мәдәният тауларына иренеп үрләдеңме икән?

— Торып-торып бер сөальне тәкрарламагыз, улым. Бер халыкка, бер милләткә каян шулкадәр бөекләр җыелсын, ди. Нигә тегесе, бусы юк, дип, холыксыз, иркә бала сыман шыңшып-сыктап йөрү килешми.

— Тынгысыз җан кычкыра шул, бабай, дәгъвалый.

— Зыялы кеше үз халкының тарихыннан фәһемсез булмый, улым. Антик әдәбиятның мәңгелек әсәрләрен татар укучысы, я, кайчан гына уку бәхетенә ирешә алды? Яңарыш чоры, мәгърифәт чоры нурларын ике-өч гасырдан соң гына шәйли башлады татар укымышлысы. Мәдәният, әдәбиятлар үсеше мөхит-чорга, экономик-сәяси шартларга бәйле. Туфрагы нинди булгандыр да, нинди яңгырлар яугандыр, нинди җилләр искәндер — шундый гөлләр үскәндер... Ә тарихта болгар-татар бабаң узган үтә кыен, хәтәр юллар, гасырлар... Кайчандыр бабаңнар өчен ябык булган капкаларны, биклебогаулы ишекләрне күзаллап хәтерләсәгез дә, бүгенгегә шөкерана кылып, тауны тауга бәреп эшләсәгез икән. Һай, тәмәке исе сеңгән бүлмәләрдә бәхәсләшеп, низаг белән вакыт исраф итмәсәгез икән. Кадерен белсәгез, һәр талант иясе үзенең хәләл өлешен ихлас өсти торганда, әллә ни ишле-санлы булмаса да, бик тә уңган, тырыш, сәләтле безнең татар халкының да мәдәният хәзинәсе ярлы түгел, оныкларым. Аның, әнә, мең еллык әдәбияты бар дип, еш сөйлисез бит. Димәк, дөнья күзе алдында йөзегез кызарырлык түгел. Тик менә булдырыклырак булсагыз икән дә, үлгәннәрнең — каберен, исәннәрнең кадерен белсәгез икән...

— Рәхмәт, бабай!..

...һәм күңел — уйчан сәяр кош, үткәннәрне урап, бүгенгегә кайта, тагын да ары җилпи канатларын...

Дөнья буйлап батырлыкка, горур азатлыкка өндәп Муса Җәлил йөри. Әйе, «Муса Җәлил иҗаты милләтебезнең авторитетын арттырды, аның тарихи бердәмлеген ныгытты...» Азиядә-Европада төрле телләрдә Тукай авазлары ишетелеп тора. Әнә, әле яңа гына Шәүкәт Галиевнең шат куяны «физзарядка» ясап күрсәтте дә, атаклы әкиятче Андерсен бабасының мактаулы дипломын алып кайтты. Безнең җырчы-биюче егетләребез-кызларыбыз да дөнья сәхнәләренә бик кыю чыгалар хәзер...

Татар чәчмә әдәбиятының да, тел чикләрен узып, чит илләргә чыккан дистәләп әсәре бар. Һай, хәлемнән килсә мин галәмәт бер биштәр күтәрер идем дә Галимҗан Ибраһимовның, Фатих Әмирханның классик иҗат җимешләрен, Кави Нәҗми, Шәриф Камал хикәяләрен, Габдрахман Әпсәләмовның, Мирсәй Әмирнең, Фатих Хөснинең, Әмирхан Еникинең, Мөхәммәт Мәһдиевнең күренекле әсәрләрен немец, француз, испанга да, төрек-гарәп, инглизгә дә өләшеп йөрер идем. Болары да хуш булыр, шәт, дип, әнә, хәзерге яшьләрдән Разил Вәлиевнең «Яшисе килә» җыентыгын, үз персо-

нажлары кылган эшләрне белеп язучы Фәрит Гыйльми әсәрләрен дә бүләк итәргә тарсынмас идем. Укымаслар идемени?! Бу әсәрләрнең әдәби-эстетик дәрәҗәләре дөнья укучысы алдында да оялырлык түгел, идея-иманнары ныклы, миһербанлы...

Өлкән әдибебез Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестен әдәби җәмәгатьчелек Р. Гамзатовның «Минем Дагстаным», О. Гончарның «Тронка», М. Кәримнең «Озын-озак балачак» әсәрләре белән янәшә куеп, хаклы бәяләде.

Яисә, әйдәгез, беразга тын калып, «Татар прозасында балалар дөньясы» дигән юнәлештә уйланыйк, булган әсәрләрне барлап чыгыйк әле. Дистәләгән телләргә тәрҗемә итеп, бөтендөнья балалары күзенә күрсәтерлек милли бизәкле әсәрләр юкмыни?!

...Әгәр Шамил Усмановның «Памирдан радио»сы кайчандыр татар мөгаллименнән сабак алган үзбәк, кыргыз, казахта гына булса да күптән инде менә дигән фантастик кинофильм төшерерләр иде. Әле хәзер дә, җирдә һаман милли азатлык, бәйсезлек өчен көрәш дәвам иткән чорда, әсәр һич искермәгән, ул мавыктыргыч мәҗаралы һәм социалистик идеяле...

...Валентин Распутинның «Соңгы срок» әсәре буенча эшләнгән спектакльне карап утырам. Әйбәт әсәр, милли әсәр! Тик күңел төрлесен уйлап сыкрана. Аналарга, үткәннәргә гамьсез булган балалар турында Әмирхан ага Еники «Әйтелмәгән васыять»ен шактый алданрак язды лабаса! Һәм ничек кенә итеп язды әле! Дистә илләргә, дистә телләргә, инсценировка итеп олы сәхнәләргә тәкъдим итәрлек чын сәнгать әсәре!

Шәриф Хөсәеновның «Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде») драмасы да В. Распутиннан алданрак язылды. Мисалларны дәвам итәргә мөмкин. Әнә, Аяз Гыйләҗев та җиде-сигез тере язучыны бездән ким мактамый. Димәк, бик үк дәһи булмасалар да, «гомумсовет әдәбиятының югары дәрәҗәдәге авторлары белән тиң иҗат итә» алырлык әдипләр татар әдәбиятында булган һәм, шөкер, хәзер дә бар. Артык «мескен булып та калмаска», «ай, харап булабыз!» дип шәрран сөрән салмаска, үзеңнең дә, башкаларның да күңелен төшермәскә, боек итмәскә кирәктер. Аннары, безнең әле дә энә очы кадәр кимчелегебезне дөя итеп күрсәтергә әҗгырып торучы идеологик дошманнарыбыз барлыгын да онытмыйк, иптәшләр.

Дәрес, «тынычлану зарарлы!» һәм ул безнең күпчелек язучыларыбызның җанына чит нәрсә. «Мәскәүдә, Ленинградларда бара торган югары утырышларда» татар прозасы әсәрләренең «бик сирәк, анда да тематик яктан гына телгә» алынулары күңелле хәл түгел, әлбәттә. Ләкин татар әдипләренең Бөтенсоюз күләмендә макталган, хәтта артыграк та макталган мәҗлесләр дә аз түгел бит инде.

СССР яки РСФСР язучылары съездларында хәзер татар әдәбиятына багышланган махсус докладларның куелмавын да кимлеккә юрамыйк без. Җитмештән артык милли телдә иҗат итүче гомумсовет әдәбияты форумнарында бер безнең Абдулла агайны гына аерым зурлап, аның саулыгына махсус дога уку, мәдхия әйтү — килешмәстер ул.

Аннары, бусы да бар: ул югары җыелышларда катнашучы безнең вәкилләр соң үзләре авыз йомып утыралармыни? Булганны күрсәтә белү, башка милләтләрнең олы әдипләре белән аралашу, дуслаша белү җитми, күрәсең.

А. Гыйләҗев, татар әдәбияты әсәрләрен дөньякүләм һәм гомумсовет әдәбияты таләпләреннән чыгып бәяләргә, яшь әдипләрне дә шул олуг таләпләр югарылыгыннан торып тәрбияләргә, аларга: «Әдәбият эшенең көрәш һәм батырлык икәнен аңлата торырга» өнди. Күптәнге, ләкин һәрвакыт көнүзәк, сугышчан зарури чакыру бу!

...Безнең Татарстанның язучылар саны Россиядә Мәскәү белән Ленинградтан гына калыша. Көчле батальон, әлбәттә. Бары совет чынбарлыгы гына тудыра алган казаныш... Тик менә...

— Чыраеңны сытма, энем. Нигилистлык хәзер модада түгел.

— Шулаен ул шулай да... Чор прогрессыз яшәмәс, анысы. Бигрәк тә безнең социалистик җәмгыятьтә. Тик таләпчәнлекне нигилистлык белән бутамыйк әле без.

Безнең татар халкы гомер-гомергә тире эшкәртүгә, читек-кәвешләр тегәргә оста, һәвәс булган. Хәзер безнең бик күп илләргә мәгълүм җәнлек совхозларыбыз, мех комбинатлары, җитен-киез, кием-салым, аяк киемнәре, милли киемнәр җитештерүче куәтле комбинат-берләшмәләребез бар. Ш. Камалның утызынчы елларда ук язылган «Томан арты» драмасыннан тыш, шул мәртәбәле фабрика-заводларның киеренке тор-

мышын, андагы эшсөяр замандашларыбызның образларын чагылдырган бер генә әдәби әсәрне дә, хәтта урта кул очеркны да хәтерләмим мин.

Безнең татар халкы гомер-гомергә чисталыкны, пакьлек, арулык, нәзафәт-нәзакатьне олы, зарур күргән, затлы бизәнү-нәкыш әйберләрен баета торган. Хәзер безнең җирле сабын заводларыбыз гына түгел, затлы-затлы, хуш исле, матур бизәкле продукцияләрен күп җирләргә, илләргә, дөньяга илтеп сатучы куәтле комбинатларыбыз бар...

Авыр сугыш елларында күбесе авылдан килеп, татар ир-егетләре, апалар-сеңелләр куәтле моторлар, самолетлар, вертолетлар ясарга өйрәнделәр. Инде аларның уллары-кызлары, оныклары промышленность новаторлары, инженерлар-конструкторлар булып җитештеләр. Бу атаклы предприятиеләрнең дә киң капкалары күптән инде журналистлар, язучылар өчен ачык. Һәм алар матбугат, нәшрият йортларыннан ерак та түгел ләбаса!

Казан кино-фото пленкалары, Чистай сәгатьләре, Түбән Кама шиннары... Һай, барсын санап китсәң, Татарстан ирешкән казанышлар искиткеч! Һәм алар барысы да кешеләребез акылы, аларның даими хис-фикерләр көрәше белән туды, сугарылды. Ә менә шул киң мәйданнарда безнең татар халкын да белемле-һөнәрле итеп, ил, дөнья күзенә, цивилизация-мәдәният, фәнни-техник революция үрләренә күтәргән экономик, иҗтимагый-политик, социаль, рухи-психологик казанышлар татар әдәбиятында тиешле чагылыш таба алдымы әле?

— Аның каравы безнең татар әдәбиятында нефть темасы фонтан булып бәрде!

— Әйе, бу өлкәдә безнең әдипләребезнең өлеше зур, диярлек. Татар әдәбияты әсәрләрен илгә-көнгә чыгарды бу фонтаннар! А. Гыйләҗев телгә алмый узса да, Рахман Ильясның «Тирән горизонт»ыннан ук башланган бу мөһим тема тирәнәю, баю, конкретлашу юнәлешендә көчәя бара. Уңышлар сөенечле, кимчелекләр дә бар. Тик, зинһар, бик эре кыяфәт белән узып барышлый гына Ш. Бикчурин, Җ. Рәхимов иҗат иткән роман-повестьларны «хәзерге прозаның казанышлары рәтендә санавы кыен» дип, кара тамга сукмыйк әле. Дөрес, Ш. Бикчуринның, Җ. Рәхимовның бу мөһим, нагрузкалы әсәрләрендә эстетик бизәкләрне, персонажларның интеллектуаль дөньяларын баета төшәсе бар иде. Ләкин шунысы бәхәссез: тынгысыз җанлы, эшчән, булдыклы замандашларыбызны авансценага куеп, мөхит, даирәне, реаль шартларны, нефть эшенең рәтен-җаен белеп язучы, тормышның олы урамнарыннан атларга тырышучы бу әдипләр үзләренең беренче роман-повестьлары белән татар прозасының йөзенә кызыллык китермәделәр. Һәм яшьләргә дә начар үрнәк күрсәтмиләр алар.

— Соңгы дистә елда КамАЗ тематикасы бик шаулады.

— Аеруча публицистика һәм поэзия өлгерлек күрсәтте.

— Проза да калышмады.

— Ләкин иҗтимагый резонанс тудыра алган әсәрләр рус телендә дә әлегә бик аз. Татар прозасында исә Равил Вәлиевнең, Эдуард Касыймовның унбиш-егермеләп документаль новеллаларыннан тыш, игътибарга лаеклырак башка әсәр юк төсле...

— Калын-калын романнар, повестьлар басылып кына торды ләбаса!

А. Гыйләҗев «образны, зур төзелешләр белән бәйләп, мәйданга чыгару ансатрак ул, ә батырлыкны гадилектә күрә белү кыен»,— дип, уйлап җиткермичә әйтә. Гүя зур төзелешләргә бәйләнгән образларга гадилек — зарур сыйфат түгел. Зур төзелешләрне җитәкләүче яки аның чираттагы нигез-фундаментларын, стеналарын салучы эшсөярләр дә бик гади, дөньяви фани кешеләр бит. Ләкин аларның иҗтимагый офыклары, белем һәм осталык дәрәҗәләре, без фараз иткәннән дә югарырак, гражданлык вазифалары, рухи дөньялары киңрәк. Зур эшләрне бары тик олы язмышлы кешеләр, М. Горькийча атасак, гади бөекләр генә башкарып чыга ала. Һәм шушы хакыйкать әдәбият-сәнгатьтә монументаль чагылдыруны таләп итә, ул безнең социалистик реализм әдәбиятының магистраль юнәлешләрен билгели, гомер хәтердә калачак үрнәк көрәшче, перспективалы образларын тудыра. Әнә, ул төзелешләр тематикасыннан Б. Полевойның «Кыргый ярда» романын, Ф. Видрашкуның «Өметләр яры» хроникасын, таҗик әдибе Ю. Әкберовның «Нурек» романнарын искә төшереп узыйк әле... Кызганыч, татар прозасының бу биеклекләргә ирешә алганы юк әлегә. Бөтен шартлар булуга да карамастан...

— Соңгы дистә елларда тарихи әсәрләр хакында сүз-бәхәс ишәеп китте.

— Ибраһим Нуруллинның «Тукай» әсәре, Атилла Расихның «Ямашев» романы культурабыз хәзинәсенә мәгълүм өлеш булдылар. Ә «Кол Гали» драмасын иҗат итә алган Нурихан Фәттахка, чынлап та татар тарихын, культурасын сөючеләр «Нурихан Фәттах Болгар чорын өйрәнүгә күп көч салды, мөгаен, хәзер шул заман вакыйгаларыннан берничә роман бирер» дип ышанганнар иде. «Әтил суы ака торур» әсәреннән соң Бөек Болгарның ныгыган, чәчәк аткан чорын, затлы биналар корган, чуен койган заманнарын, андагы иҗтимагый хәрәкәтне, фән-мәдәният үсешен күрергә бик теләгәннәр иде.

Без «Кол Гали»дәге экономик-этнографик ситуацияләрне, тарихи драматик вакыйгаларны, үзенчәлекле образларны, акыллы фикер-гыйбарәләрне бик озак онытa алмабыз әле. Мин В. Белинскийның Вальтер Скоттка карата «ул тарихны арадашчы итеп, сәнгать белән тормышны тоташтырды» дигән сүзләрен Н. Фәттах адресына әйтүдән дә курыкмас идем.

— Прозабыз соңгы дистә елларда фәнни даирәгә күз сала башлады.

— Сез А. Расихның, Ә. Еникинең, М. Зариповның, М. Мәһдиевнең, Т. Миңнуллинның кайбер әсәрләрен күздә тотасыздыр. Әйе, бу әсәрләрдә төрле идея-максатлар өчен һәм төрлечә яссылыкта галимнәр тормышы сурәтләнә. Сөенечле тәүге адымнар болар. Тик, кызганыч, бу әсәрләрдәге галим-голәмәләрнең берсе дә зур теоретиклар да, кыю экспериментаторлар да түгел. «Таланты чикле һәм шикле булып та фәнни дәрәҗәгә ыргылган карьеристлар турында өлкән буын күп язды»,— ди әнә Т. Галиуллин. Бу, минемчә, ил әдәбиятында Л. Леоновның «Русский лес», Д. Гранинның «Иду на грозу» романнарыннан соң башланды, төрле вариант, вариацияләрдә ишәйде һәм шул агымнан безнең кайбер әдипләребез дә калышмаска тырышалар. Ләкин алдагы якты кыяларга күз салып, ихласын әйтик: илебез фәне үсешенә Татарстан галимнәре өстәгән искиткеч байлыкның, ачышларның әле киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булганнарын гына барлап чыксак та — бу өлкәдә татар прозасының хезмәте чыпчык тезеннән генәдер...

Безнең прозада әле дә персонажларны ясалма батырлыкка, ясалма матурлыкка көчләп этү тенденциясе дә яши бирә. Шуның аркасында автор реаль чынбарлыкка хыянәт итә, персонажны эволюция-үсештә күрсәтәм дип, аны ясалма ситуацияләргә ташлый, аның холкына-табигатенә хас булмаган эшләр эшләтә, логика югала.

Әйтик, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Исәнме, Кәшфи абзый» исемле якты, заманча публицистик фикерле повестенда үзе тир түгеп тапкан малның кадерен-бәрәкәтен белеп яшәргә тиешле гомерлек игенче Кәшфи-тракторчының, ялга барган җиреннән, йөз илле сумга сатып алып (!), пар ондатра күтәреп кайтуына кем ышансын? һәм бу ясалма юмартлыкның хаҗәте бармы? Чөнки су йомраны — ондатра безнең Идел-Вятка-Кама буе төбәкләрендә гомер-гомергә яшәгән. Арча, Дөбъяз, Тау ягы күлләрендә дә еш күренә ул. Кыерсытылмаган җирләрдә үрчи, ишәя бара. Таңнарда кыштыр-кыштыр камыш кисүче шул гөнаһсыз җәнлекләр яшәгән күл-сулыкларны пычратма гына! Менә шул юнәлештә Кәшфи абзый берәр эш кылса, әйтик, әнә шул күлгә солярка-бензинмы, химикатмы агызучы фәлән юньсезнең якасыннан алса яки бүтәнчәрәк, көрәшкә кыюрак керсә — укучы моңа ышаныр һәм персонаж үзе дә табигый үсеп китәр иде.

Шул ук Кәшфи абзыйның әле кияүгә чыкмаган тагын ике кызы, фәлән кадәр оныклары бар. Өстәвенә, әнә, үз җизнәсенә үк — «мишәр кияүгә» җанын-тәнен ачкан тагын бер дәртле кызы тагын бер онык «тупырдаткан». Шул гөнаһы өчен ата-анага, туганнарына күренергә ояла, курка бугай, читләшкән-үгиләгән, яшь баласы белән тулай торакта кысылып яши...

Малаеннан да уңмаган Кәшфи абзабызга, һай, кызлары, оныклары өчен борчылыр-уйлар, психологик барьерлар, хәл итәсе эшләр, күрәсе чаралар фәлән кадәр икән әле. Ләкин автор аны шул реаль чынбарлык юлыннан атлатып мәшәкатьләмәде. Кәшфи абзабыз өлкән сазау кызыннан тыш, башка балаларыннан, оныкларыннан бизгән. Аларга гаме, күңел тартымы юк аның. Ә үзе бала тансыклаган, янәсе, дәү өендә хатыны белән икәү генә яшисе килми, юк!—оныкларының да берәрсен түгел, ятимнәр йортыннан асрамага малай алып кайта... Я, шундый сәер эшләреннән соң, үзең аңла инде, укучы, Кәшфи абзаң кыланчык түгел, диген...

# ТОРМЫШ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЛСЫН!

*Дискуссиягә укучы кушыла*

«Казан утлары» журналы битләрендә бүгенге проза әсәрләре хакында бара торган сөйләшүне без, әдәбият сөючеләр, бик кызыксынып күзәтәбез, күпчелек язмаларны яратып укыйбыз. Чөнки аларда гади укучыларның да фикерләре чагыла. Ә бу үзе татар әдәбияты өчен һичшиксез файдага булачак. Киңәшү, бергәләп уйлану эшне алга җибәрергә ярдәм итә бит ул.

Әдәбият турында сүз кузгалдымы — бүгенге тормыш хакында сөйләшми мөмкин түгел. Тормыш — әдәбиятның төп җирлеге. Ә соңгы 10—15 елда яшәү нык кына үзгәрде. Ата-бабаның төшенә дә кермәгән әйберләр: радио, телевидение, газета-журналлар, холодильник, кыйммәтле мебельләр хәзерге авыл кешесенең өенә үк кереп утырды. Моңа яхшыдан бүтән сүз әйтеп булмый билгеле. Совет халкының тормышын яхшырту партиянең, хөкүмәтнең дә төп максаты бит.

Ләкин язучыларыбыз Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиевләрнең әсәрләрендә бик дөрес күрсәтелгәнчә, соңгы еллар кешесендә кайбер борчылырлык сыйфатлар да килеп чыкты. Минем шундый мисал китерәсем килә: элек хатын-кызлар уракка барганда, кеше күргәнче иртәрәк китеп, күршесе килгәнче 1—2 сутый җирне урып куярга тырыша иде. Бик күпләр әнә шулай иде. Ә хәзер, ничектер, кешенең психологиясе үзгәрде кебек. Менә шушы мәсьәлә хакында язучылар әчкәрәк кереп уйлансыннар иде. Җитеш, мул тормышта яшәү нишләп кешедә кайбер начар сыйфатлар китереп чыгара? Моның сәбәбе ни? Безнеңчә, татар прозасының әле моңа җавап биргәне юк. Язучылар бу нәрсәнең барлыгын күрсәттеләр генә әле. Без алардан тагын да тирәнрәк эзләнүләр көтәбез.

Аннан соң хәзер яшьләр мәсьәләсе бик уйландыра. Төп фикеремне әйткәнче, башта тагын мисал китерим. Элек, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләгән яшьләр матур итеп күңел ачарга да вакыт табалар иде. Кичәләр оештыралар, авыл халкы өчен үзләре оешып концертлар, спектакльләр куялар иде. Ә хәзер яшьләр белән сөйләшеп карасаң — алар: «Клубта ямь юк,— дип зарланалар,— төрле уеннар оештырылмый» — диләр. «Ә нигә соң шуларны үзегез оештырмыйсыз» дигән сорауга җавап: «Ә культура хезмәткәре нәрсәгә?»

Мондый күренеш шулай ук уйландыра. Тыштан бик актив кебек тоелган яшьләр күңелләре белән ни өчен пассив? Ни өчен алар кемдер әзерләгәнне генә кабул итәргә өйрәнгәннәр? Аларның күңелләрен нәрсә уята ала?

Дөресен әйткәндә, татар язучылары хәзерге тормышның менә шундый яңа мәсьәләләре хакында бик аз уйланалар. Безнең, мәсәлән, бүгенге авыл яшьләре турында җитди әдәби әсәр укыганыбыз юк соңгы елларда. Ә бит статистика әйтүе буенча хәзер илебез халкының бик күп өлеше яшьләр.

Татар әдәбияты һәм яшьләр темасына калгылгач, тагын шундый теләк тә белдерәсе килә. Безнеңчә, яшьләрнең иң күп өлеше әдәбиятны 10 нчы класс бетергәнче укый. Алар әдәбиятны бик бирелеп, чын күңелдән ышанып укыйлар. Әнә шуннан соң, мәктәпне тәмамлагач, тормыш белән якыннан танышу башлана. Чын яшәү башлана. Менә шунда инде әдәбиятның нинди педагог булганы яхшы ачыклана. Ул яшьләрне тормышка ничек әзерләгән? Кайбер әсәрләр яшәүне өстән генә тасвирлап, аларда ялгышрак тәэсир калдырмаганмы? Яшьләребез катлаулы һәм шул ук вакытта ямьле дә булган тормышка ныгытып аяк басарга әзерме? Сер түгел — язучыларыбыз кайчак тормышны буябрак сурәтлиләр. Нәтиҗәдә кеше — яшь кеше — аңа әзерлексез килә. Хәер, бу хакта партия Үзәк Комитетының июнь Пленумында да бик дөрес сүз булды бит.

Кыскасы, татар әдәбиятына таләпләре күп укучыларның. Аларның һәммәсе тормышка да ашар дип булмый. Теләк, ният һәрчак зурдан була инде ул...

Шулай да, әдипләребез үз укучылары сүзенә колак салмый калмас әле...

**ТӨХФӘТОВЛАР** гаиләсе,
Әгерҗе районы, Кичке Таң авылы.

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

**Геннадий Муханов**

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ СЫЙФАТЫ

Интернационализм — социалистик реализм әдәбиятының аерылгысыз бер категориясе. Хәзерге татар әдәбиятында без моның мисалларын күпләп саный алабыз. Рухи яктан бай, коммунистик идеал өчен көрәш белән тыгыз бәйләнгән кешенең матурлыгын эстетик ачып бирү бурычы ачык күренеп торган милли характерлы, максатка омтылышлы, чын граждан булып җитлеккән геройны сурәтләү юлы белән хәл ителә. Дөрес, андый геройны тудыруда схемадан, төрле сыйфатларның стандарт җыелмасыннан котылу җиңел генә бирелми.

Татар әдәбиятында андый геройлар хәзер аз түгел. Арслан Гобәйдуллин, Мирсәет Ардуанов (Г. Ахунов, «Хәзинә», «Ардуан батыр»), Зөбәеров (Ш. Бикчурин, «Каты токым»), Габитов (И. Гази, «Гади кешеләр»), Дания Дәүләтшина (М. Зарипов, «Квартирга ордер»), Әхмеров (Э. Касыймов, «Чулман — оныклар елгасы»), Бакир Галиев (М. Хәбибуллин, «Икмәк кадере»), Саттаров, Громких (Д. Вәлиев, «Сиңа тормыш бүләк итәм», «Диалоглар») һ. б. әнә шундыйлар.

Мәдинә Маликова «Казан каласы — таш кала» дигән повестенда архитектор Мәрьямнең кызыклы образын иҗат иткән. Язучы тормышының мәгънәсен иҗат белән януда күргән көчле, нык ихтыярлы хатын-кызны алга бастыра. Мәрьям шәһәр төзелеше проблемаларын хәл итүне җанына бик якын ала, кешеләргә шатлык китерергә омтыла. «Дөньяга яратылганнан бирле,— дип фикер йөртә ул,— кешелек хакыйкатьне аңларга, мәңгелекнең серләрен ачарга омтылып яши. Бу авыр һәм озын юлның очкырые күренми әле, һәм бары тик мин-минлегеннән, үз тормышыннан югары күтәрелә алган кеше генә, җирдә яшәүче башкалар белән бердәмлеген тоеп, мәңгелек хакыйкатьне аңлау юлында кешелеккә бераз гына булса да алгарак китәргә ярдәм итә алган кеше генә — бары тик шундыйлар гына бу дөньяда җан тынычлыгы һәм киләчәккә ышаныч белән яши ала».

Альберт Мифтахетдиновның «Атларны Убиенка елгасы тамагына илтү» дигән повестенда Чукотканың кеше аяк басмаган районнарын үзләштерүчеләрнең батырлыгы, никлыгы, ихтыяр көче турында сөйләнә. Көче геолог Аникей Марков һәм каюр Афанасьичка аеруча әһәмиятле документларны экспедиция начальнигының үз кулына илтеп тапшыру заданиесе йөкләнә. Алты аттан торган кәрванның елга тамагына барыр юлы бик авыр: атлар һәлак була, Афанасьич үзе чак кына батып үлмичә кала. Ләкин язучы драматизмны куертмый, хәвефле моментларны сурәтләү белән мавыгып китми. Әнә шуның белән ул «көндәлек тормышның» кешеләргә нинди бәягә төшүен ышандырырлык итеп тасвирлый. Геологлар белән бергә повестьтагы башка кешеләр — совхоз бүлекчәсенең управляющие Коля Кузьмичев, сатучы, эстон кызы Магда Апперкот, радистка Меланья да кыенлыклар аша үтә. Бу кешеләрнең очраклы хәлләрдә, беренче тапкыр гына очрашулары, әмма алар үзләрен генә кайгыртмыйлар, бер-берсенә ярдәм итәргә омтылалар. Бу әсәрдә интернациональ эстетик идеал «дөньядагы иң олы матурлык» булып алга баса.

Күләме зур булмаган «Митрич» повестенда Р. Кутуй Аниска дигән кызны тәрбиягә алып үстергән карт эшченең рухи матурлыгын күрсәтә. Ул Анискага карата үз

этисе кебек игътибарлы, аны ярата, кыз бәхетле булсын өчен бөтенесен эшли. Анисканың туган көнендә утырганда күзләреннән, бөтен йөзеннән яктылык, шатлык бөркелә. Яшьләр күп җыелган. Һәм шунда, коридорга тәмәке тартырга чыккач, ул кызы дип санаган кешесенең кемгәдер әйткән сүзләрен очраклы рәвештә ишетә: «Ә ул минем беркемем дә түгел. Митя абый гына ул. Күрше...» Митрич ялгыш кына ишетеп калган сүзләрне күтәрә алыр идеме, әмма шул чакта ишек шакыйлар. Аниска үзенә килгәннәр дип уйлый, ә анда Нюшка тора икән, Митричка кыен көннәрдә ярдәм иткән кыз. Ул хәзер дә аның янына кадерле, якын кешесе итеп килгән. Язучының шундый контраст куллануы Митричны күтәрә, Анисканың әхлаксыз, туң җанлы кеше икәнлеген күрсәтә.

Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романында карт эшчеләр татар Сөләйман Уразметов белән рус Матвей Погорельцевның дуслыгы ышандырырлык һәм дөрес итеп тасвирлана. Аларның чын мәгънәсендә туганнарча мөнәсәбәтләре сокланырлык. Һәм бу хәзерге татар әдәбиятында берләнбер мисал түгел. Төрле милләт кешеләре дуслыгының матурлыгы әллә кайчаннан килә. Аның әдәбияттагы куәтле чагылышы мисалларын Г. Ахунов, Ә. Еники, Э. Касыймов, Р. Төхфәтуллин, М. Хәбибуллин һәм башка язучылар әсәрләрендә күреп була.

Совет илендәге барлык милләтләрнең иҗтимагый мөнәсәбәтләрендә иң мөһим як булган интернационализм художестволы иҗат материалы булып кына калмады, камил, гүзәл кеше концепциясендә төп критерийга да әверелде. Г. Әпсәләмовның шул ук романында кеше матурлыгының нинди булуын, аның революциягә кадәр һәм безнең көннәрдәге үсеш юлларын күрәбез. Сөләйманның бабасы, патша заманында җанны тетрәтерлек бәетләр әйтеп йөргән сукыр скрипкачы Хәйретдин имән баскан дустын коткарган өчен генә җәзалана. Сукыр җырчының гадел һәм бәхетле кеше турындагы хыяллары Сөләйман белән Матвейга мирас булып кала, алар өчен дөньяда иң кадерле принциплар — гаделлек, тигезлек, гуманизм һәм кешеләрнең интернациональ туганлыгы.

Әдәби әсәрләрнең геройлары арасында чынлыкта илебездәге барлык милләт, халык исем-фамилияләрен йөрткән геройлар булуы бик әйбәт. Моның закончалыклы күренеш икәнлеге СССР Язучыларының VII съездында аеруча басым ясап әйтелде: «Әдәбият, милли шартлар һәм традицияләр обстановкасында эшче кешенең иҗади хезмәтен сурәтләп, советча яшәү, социалистик патриотизмның әхлакый көче, җәмгыятебездә эшчеләр сыйныфының җитәкче роле турындагы карашларыбызны киңәйтә» («Литературная газета», 1981, 1 июнь, 2 бит).

Үзбәк язучысы Р. Фәйзинең «Галиҗанәп кеше» романында тимерче Мәхкәм әкә һәм аның хатыны Мәхриниса сугыш елларында төрле милләттән булган 14 «чит» баланы үз балалары итеп үстерәләр. Бу гади хезмәт кешеләренең олы кешелеклелек хисе таң калдыра. Аларның бу адымы — изгелек яки кызгану тудырган бер очраклы хәл генә түгел, ә бәлки социалистик җәмгыятьтә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең бөтен системасы тудырган гуманизм, интернационализм кебек хисләрнең закончалыклы чагылышы. Казах язучысы М. Мәгауинның «Бер ата балалары» дигән повесте да шул темага багышланган. Ул илебезнең төрле республикаларыннан килгән ятим балаларны үз гаиләләренә алган казах колхозчылары турында шигъриятле итеп сөйли.

1976 елда «Звезда Востока» журналында Үзбәкстанда яшәүче рус язучысы Г. Марьяновскийның документаль әсәре — «Язмышлар китабы» дөнья күрде. Фактик материалларга нигезләнеп, автор Ташкентка ачлыктан, авырулардан интеккән балалар эшелон-эшелон килеп торган героик сугыш елларын сурәтли. Үзбәкстан йөз мең баланы үзенә сыендыра, тергезә, тормышка аяк бастыра. Ятим балаларның кайсы милләттән икәнлеген уйлап тормыйлар, барысына да тигез карыйлар. Романда, повестьта, документаль китапта бер үк нәрсә турында — илебезнең гүзәл кешеләре, аларның олы җанлылыгы, гуманизмы һәм интернационализмы турында сөйләнә.

Ярдәмчеллек, зур эшләрне бергәләп хәл итү совет халкына һәрвакыт хас сыйфат. Моның мисалы Э. Касыймовның «Чулман — оныклар елгасы» романында да бар. Талантлы инженер һәм галим Усман Әхмеров сыйфатлы гипосульфит алу буенча үткәргән тикшеренүләрен Эстониядән килгән коллегалары белән әчкерсез уртаклаша. Кунаклар Әхмеров ирешкән нәтиҗәләргә исләре китеп, сокланып карыйлар. Әмма

Татарстан химикларының казанышлары аларда көнләшү тойгысы уятмый. Әлеге кыйммәтле химик продукт бөтен илгә кирәк һәм алар Татарстанга аны җитештерү серләрен өйрәнергә дип килгәннәр.

Җәмгыятебез гүзәл, көчле рухлы, батыр, тәвәккәл кешеләрне күп тудырды. Д. Вәлиевнең «Сиңа тормыш бүләк итәм» дигән пьесасындагы партиянең шәһәр комитеты секретаре Гайнан Саттаров һәм А. Салынскийның «Мария» драмасындагы райком секретаре Мария Одинцова әнә шундыйлар. Аларны партия тапшырган эшне ачык аңлау, шуның хакына яшәү, кешеләр турында кайгырту берләштерә. Саттаров һәм Одинцова төзелеш җитәкчеләре белән конфликтка керүдән куркып тормыйлар; производство процессларын яхшырак аңлаганга түгел, тормышка карашлары киңрәк булганга зур белгечләрнең коры техницизмына каршы көрәш алып баралар.

Җиңү җиңел генә килми, кайчагында аның өчен гомереңне дә бирергә туры килә. Мәсәлән Саттаровның авыру йөрәге чыдамый, Излучинск шәһәренең киләчәген яклап, Мария да чак кына һәлак булмый кала. Чынбарлыкны һәм кешене үзгәртү, матуррак итү өчен көрәш аларның үзләрен дә матурайта.

Сибгат Хәким КамАЗга, аның кешеләренә багышланган «Дәверләр капкасы» дигән фәлсәфи поэмасында төзелеп килә торган гүзәл шәһәргә, заводка, гасыр могҗизасын төзүче кешеләргә сокланып карый:

**Без көн саен иске алганнарның**
**һәм сугышта исән калганнарның**
**Балалары, үтәп наказларны,**
**Сала бүген гигант КамАЗларны...**

**. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .**

**Карый алар КамАЗ түбәсеннән,**
**Шул биеклек хәтта түбән сыман,**

— дип яза шагыйрь.

Совет халыкларының хезмәттәге казанышлары матурлыгын шигъриятләштерү, ачык сизелеп торган интернационализм пафосы татар шагыйре Р. Мингалимнең «Күз карасы» һәм рус шагыйре В. Лавришконың «Узел связи» поэмаларының төп эчтәлеген тәшкил итә. «Эш көне» дигән бүлектә Р. Мингалим замандашларының эшенә сокланып карый:

**Эш көне!**
**Бар да эшли...**
**...Күрәсеңме**
**Күбәләк кенә кыз**
**Кранда**
**Авыр панельләрне**
**югары этажга күтәрә.**
**Буем җитмәс аңа,**
**үрелсәм дә**
**гөлләр бүләк итәргә.**
**Әй, сеңелем,**
**Исемең ничек, дип кычкырсам,**
**тавышым ишетелмәс үзеңә.**

Ш. Бикчурин «Каты токым» романында интернациональ хезмәт коллективын үзәккә ала. Анда шәхесләр формалаша, кешенең психологиясе хезмәттә үзгәрә, хезмәт вазифа һәм яшәү чарасы булудан бигрәк, кешенең иң беренче ихтыяҗына, канәгатьлек чыганагына әверелә бара. Совет тормышының атмосферасында ук булган бөтен яхшы, гуманистик яклар шушы кечерәк кенә коллективта кристаллаша, коллектив һәркемгә үзенең кешелек дәрәҗәсен тоярга, үз урынын табарга ярдәм итә. Элек акча җыюны гына максат итеп куйган, иптәшләрен дә, эшен дә күрә белмәгән Сәпәрбай Казахстаннан әйләнеп килүгә беренче итеп шуны сорый: «Ничә метр үтте-

гез?» Нефть эшенең бер дигән остасы Кадерматнең дөнья ачысын күп күреп бирчәйгән җаны эри. «Кара алтын» эшенә очраклы гына килеп эләккән элекке матрос Тин-Тиныч нефтьче булырга ныклап карар итә. Мотгәрәй генә, киресенчә, нефтьтән аерылып китәргә була. Нефтьче хезмәте аның тормышына әверелми, әмма ул үз бәхетенең иген кырында икәнлегенә ныклап төшенә.

Кешедә булган иң матур сыйфатлар хезмәт нәтиҗәсендә материальләшә. Һәм китапның ахырында бригадир Зөбәеровның түбәндәге сүзләре бик хаклы яңгырый: «Әбит скважина җиргә үтеп кенә калмый, катлам-катлам булып без үзебез дә ачылабыз. Шламсыз гына түгел, билгеле, ансыз булмый, бездәге чын сыйфатлар да үзен күрсәтә».

Дуслык, чын иптәшлек белән береккән кешеләр генә үз кимчелекләрен җиңә, рухи яктан сафрак һәм матуррак, инициативалырак, мөстәкыйльрәк була алалар — татар язучысы романының интернационалистик пафосы әнә шундый. Төрле милләт геройларының уртак тырышлыклары һәм максатларының чыганаклары турында аны русчага тәрҗемә иткән язучы В. Чивилихин бик матур итеп әйтә: «Язучы нинди генә телдә язмасын, совет кешесенең идеалы бер. Анда барлык чорлар һәм барлык халыклар кешеләренең иң яхшы сыйфатлары, һәркем үзенең эшләрен һәм уй-ниятләрен шуның белән чагыштырып карый. Художникның позициясе күбрәк аның шул идеалны, бөтен дөнья халыклары өмет баглый торган киләчәк кешесе идеалын ничек итеп күрүендә. «Каты токым» романының геройлары миндә шундый уйлар тудырды».

Хәзерге күп милләтле әдәбият чын кешене тасвирлап бирү өчен кешедә булган бөтен сыйфатларны — аның дөньяга карашын, хезмәткә мөнәсәбәтен, көнкүрештә үзүзен тотышын һ. б. һәммәсен бергә, бер-берсеннән аермыйча алып карый. Художестволы иҗаттагы матур кеше — ул иң элек фидакарь хезмәт иясе, идея ягыннан инанган, саф әхлаклы, белемле һәм күп нәрсә белән кызыксынучан кеше.

Татар әдәбияты һәр яктан камил кешенең нинди дә булса моделен тәкъдим итәргә омтылмый. Бу мөмкин дә түгелдер. Кешенең матурлыгы статистик исәпләүләргә, төгәл логик билгеләмәләргә сыешмый, аны берәр төрле «үрнәккә» генә сыйдырып бетереп булмый.

Совет әдәбиятының интернационализмы — художникның социалистик милләтләр белән элемтәсенең бөтен бер программасы ул. Интернационализмга юл художестволык нигезендә, Ватаныбызга чиксез бирелгәнлектә, язучы талантының, культурасының, тормыш тәҗрибәсенең, эстетик идеаллары югарылыгының хәлиткеч үсешендә ята торган барлык шартларны үзләштерү аша үтә. Күп милләтле совет әдәбияты үсешенең бөтен дәвамы аның тагын да интернациональләшүен, совет һәм бөтендөнья культурасы хәзинәсенә бик зур өлеш кертүче социалистик милләт һәм халыклар әдәбиятларының үзара тагын да якыная баруын һәм бер-берләрен баетуын кире кагылгысыз итеп раслый.

# ДЕМЬЯН БЕДНЫЙ ТАТАРСТАНДА

Совет әдәбиятын башлап җибәрүчеләрнең берсе, шагыйрь Демьян Бедный турында сөйләгәндә без аның иҗаты үзебезнең якларга бәйләнгән булу белән хаклы рәвештә горурланабыз. Ул Гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышының кырыс елларына туры килә.

...1918 елның җәе. Утлы боҗра эчендә калган яшь Совет республикасының язмышы Көнчыгыштә хәл ителгән көннәр. В. И. Ленин үзе бу фронттагы, аерым алганда Казан тирәсендәге, сугыш хәрәкәтләренең барышын күзәтеп тора. Ул фронтның Казан участогын тәэмин итүгә, анда ашыгыч рәвештә резервлар җибәрүгә өчләтә игътибар белән карауны таләп итә. Ак интервентлар белән көрәшкә Мәскәүдән, Петроградтан, илебезнең башка промышленность үзәкләреннән өстәмә көчләр агыла. Алгы сафта большевиклар бара.

Партия җибәргән кешеләр арасында пролетариатның танылган шагыйре Демьян Бедный да була. Ул 5 нче Кызыл Армиянең штабы һәм политбүлеге урнашкан Зөя шәһәренә килә.

Август ахырында һәм сентябрь башында Зөядә 5 нче армия политбүлеге органы «Гражданская война» һәм республика Реввоенсоветы председателе поездының басма органы «В путь» чыга башлый. Алар бу чорда Татарстанда чыга торган бердәнбер большевистик газеталар була һәм шунлыктан республикабызның партия-совет матбугаты тарихында күренекле урын алып торалар. Армия политработниклары һәм РКП(б) губерна комитетының Казаннан эвакуацияләнгән хезмәткәрләре белән бергә Демьян Бедный да бу газеталарны оештыруда һәм чыгаруда актив катнаша.

Мәсәлән, ул үзенең мәшһүр «Озату»ын («Как родная мать меня провожала») беренче тапкыр «В путь» газетасында бастыра. Композитор Д. Васильев-Буглай көйгә салган бу җыр тиз арада бөтен Совет Россиясенә, фронтларга тарала һәм халыкның иң яратып җырлый торган җырларыннан берсенә әверелә. Җырның тексты матур итеп бизәлгән рәсемле плакатларга басыла. В. И. Ленин заказы буенча язылган бу әсәре белән Д. Бедный яңа солдат җырының тәүге үрнәкләреннән берсен бирә. Анда Кызыл Армия сугышчысы булу хезмәт ияләренең патриотик бурычы итеп җырлана. Җырның герое, яшь крестьян егете Ваня, үзен Кызыл Армиягә бармаска өндәгән кайбер туганнарына азатлык өчен, җир өчен гадел сугышка баруын сөйләп бирә.

1918 елның 7 сентябрендә, Казан өчен хәлиткеч сугышлар башланыр алдыннан, Демьян Бедный «Казан янында» («Сәлам») дигән шигырен иҗат итә. Ул массовый тираж белән басыла һәм самолетлардан шәһәр өстенә, Казанның тирә-якларына таратыла. Ул шундый сүзләр белән башланып та китә: «Гудит-ревет аэроплан. Летят листки с аэроплана. Читай белогвардейский стан, посланье Бедного Демьяна!» Шагыйрь 3 сентябрьдә акгвардиячеләргә каршы баш күтәргән Казан эшчеләрен чын күңелдән сәламли, халыкка гражданнар сугышын көчләп таккан буржуазиянең, аның лакейлары булган эсерлар һәм меньшевикларның әшәке ролен фаш итә.

10 сентябрьдә Кызыл Армия частьлары һәм Идел флотилиясе корабльләре Казанны алалар. В. И. Ленин Казанны азат иткән гаскәрләргә котлау телеграммасы җибәрә. Һөҗүм итүче гаскәрләр белән бергә Казанга Демьян Бедный да килә. Ул «Казан» («Җиңү белән, иптәшләр!») дигән шигъри телеграмма яза һәм аны 5 нче армия штабыннан РКП(б) Үзәк Комитеты органы булган «Беднота» газетасына җибәрә. 10 сентябрь, кичке 8 сәгать 5 минут дип төгәл вакытын да күрсәтә.

Бу шигъри телеграмма бер үк вакытта Мәскәү һәм Казан газеталарында басылып чыга. Казанда чагында Демьян Бедный «Казан могҗизасы», «Сәлам, эшче иптәшләр» шигырьләрен, «Расказанское положение» дигән сатирик бәетен яза һәм җирле матбугатта бастыра. «Кызылармеец йолдызы» дигән маршын да Демьян Бедный шул көннәрдә Казан тирәсендә яза.

1918 елның 14 сентябрендә шагыйрь Казаннан китә. Әмма Казан тирәсендәге сугышлар аның хәтерендә кала. Соңрак, 1933 елның 26 сентябрендә ударник колхозчылар адресына котлау телеграммасында ул болай дип яза: «Без Кызыл Татарстанның башкаласын акгвардиячеләрдән сугышып алган чакта мин Казан тирәсендә һәм Казанда булдым».

«Почетлы кызылармеец» Демьян Бедныйның Казан тирәсендә башланган фронт юлы 1920 елның көз ахырында Кырымда, Врангель армиясенең калдыклары куылып беткәч кенә тәмам була. Гражданнар сугышы чорында аның әсәрләре 5 миллион данәдән артык басыла. Шул исәптән 1919 елда Казанда «Дурман», «Качкын Митька турында», «Хаин мирасы» дигән әсәрләре дөнья күрә.

Аның әсәрләре татарчага да тәрҗемә ителә. Мәсәлән, Фәтхи Бурнаш «Таң» газетасында аның «Ачлык патша»сын, Әбрар Сәгыйди «Эшче» газетасында «Паровозга» дигән шигырен татарча бастыра.

Алгы позицияләр янәшәсендә, кайвакыт дошман уты астында да ук язылган сугышчан гимннар, революцион җырлар, окоп такмаклары, зәһәр эпиграммалар фронттагы кызылармеецларга, тылдагы эшче-крестьяннарга гаять зур йогынты ясый, аларны көрәшкә туплый, дошманның җиңеләчәгенә ышанычларын көчәйтә. Ул чагында окопларда «Демьян Бедный үзе ике дивизиягә тора» дип сөйләүләре тикмәгә түгел. Д. Бедный әдәби иҗаты өчен хөкүмәтнең зур бүләгенә — сугышчан Кызыл Байрак орденына лаек булган беренче совет язучысы. Аңа орден тапшырганда М. И. Калинин болай ди: «Сезнең әсәрләрегез гади һәм һәр эшчегә аңлаешлы, шунлыктан алар гадәттән тыш көчле, хезмәт ияләренең йөрәкләрендә революцион ут кабызалар һәм көрәшнең иң кыен минутларында күңел күтәренкелеген арттыралар иде».

Демьян Бедныйның гражданнар сугышы чорындагы ярсулы поэзиясе үзәктә һәм урыннарда бик күп совет шагыйрьләренең иҗади формалашуына уңай йогынты ясады. Аның иҗади алымнарының йогынтысы астында татар шагыйрьләре дә совет поэзиясенә үз юлларын салалар. Мәсәлән, ул утлы елларда татарча чыгып килгән партия, совет һәм кызылармеец газеталарында («Эшче», «Таң», «Яңа көч», «Кызыл Армия», «Шәрык ярлылары»), «Кызыл Шәрык» журналында тематик юнәлештә һәм бәян итү формасы белән Демьян Бедный әсәрләренә охшаган шигырьләр, поэмалар, җырлар, такмаклар һәм мәсәлләр әллә никадәр басыла. Мәсәлән, Фәтхи Бурнашның «Мөхәммәтҗан» поэмасы, «Колчак һәм Деникин» памфлеты, Сәгыйть Сүнчәләйнең җырлары, Г. Рәфиковның «Кызыл яу җырлары», Г. Гомәрнең «Кызыл әләм, кызыл йолдыз», Сирин Батыршинның «Әнкәмә», «Авыл кызына» дигән шигырьләре һ. б. әнә шундыйлар.

Алга таба социалистик төзелеш елларында, утызынчы еллар ахырына кадәр диярлек Татарстан газета-журналларында Демьян Бедныйның төрле жанрдагы әсәрләре әледән-әле басылып тора. 1931 елда Казанда М. Крымов тәрҗемәсендә аның шигырьләр җыентыгы татарча басылып чыга.

Бөек Ватан сугышы башлангач, язмыш шагыйрьне тагын Казанга китерә. 1941 елның октябрендә, Гитлер яулары Мәскәүгә якынлашкач, СССР Язучылар союзының секретариаты башкалада калган әдипләрне Казанга китерә. Д. Бедный Казанга А. Фадеев, В. Бахметьев, Л. Ошанин, М. Алигер, П. Бровка, Я. Галан һәм башка танылган совет язучылары белән бергә килә. Д. Бедныйның олы кызы сүзләренә караганда, инде үзен онытканнардыр дип уйлаган карт шагыйрьне Казанда бик ачык күңел белән каршы алалар. Казанда Демьян Бедный Зур Галактионов (хәзерге Горький) урамындагы 17 йортта, Казан опера театры артисткасы Мөнирә Булатова квартирасының бер өлешендә яши.

«Әйбәт кенә урнаштык,— дип яза ул шагыйрь А. А. Жаровка хатында.— Азык-төлек белән өзеклекләр була, әмма без аларга бирешмибез... кайбер нәрсәләр, хәтта папирос та юнәтәм».

Казанда 1941 елның октябрь уртасыннан 1942 елның апрель башына кадәр яшәү дәверендә Демьян Бедный армый-талмый эшли. Ул зур әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге алып бара. Җыелышларда чыгыш ясый, радиотапшыруларда катнаша. Шигырьләрен Казанда да бастыра, Куйбышевка һәм башка шәһәрләргә дә җибәрә. 1941 елның 28 ноябрендә ул Казан әдипләренең гомумшәһәр җыелышында чыгыш ясый. Декабрь аенда Казан аша үтеп баручы А. Н. Толстой белән очрашу кичәсендә катнаша. Шагыйрь җирле әдипләргә һәм журналистларга практик ярдәм күрсәтә. «Красная Татария» газетасының элекке җаваплы редакторы А. И. Анушкин болай дип искә ала: «Демьян Бедный Казанга килү белән үк без аны Матбугат йортында, биредә урнашкан Татарстан газеталары редакцияләрендә күрдек. Демьян Бедный безнең актив хезмәткәребезгә әверелде. Ул еш кына «Красная Татария» редакциясенә килә,

фронт һәм тыл яңалыкларын белешә. Һәм һәрвакыт болай дип сорый иде: «Я, эшләр ничек, егетләр? Бу санга миннән нәрсә кирәк булыр?»

Зур тормыш тәҗрибәсенә һәм революцион практикага, бигрәк тә матбугатта эшләү практикасына ия кеше буларак, ул безгә иптәшләрчә киңәшләрен бирә һәм кирәк булганда шунда ук редакция заданиеләрен дә үти иде» («Советская Татария», 14 апрель, 1963 ел).

«Красная Татария»нең 1941 елгы 21 декабрь саны Кызыл Армия сугышчылары, командирлары, политработникларының — Татарстан улларының — фронттагы батырлыкларына багышланып чыга. Шагыйрь Әхмәт Ерикәй бу сан өчен «Татарстан сөйли» дигән зур шигырь яза. Шигырь газетада Д. Бедный тәрҗемәсендә дөнья күрә.

1942 ел алдыннан Совинформбюро, Кырым ярымутравына десант төшереп, Керчь һәм Феодосияне алган совет сугышчыларының героик батырлыгы турында хәбәр итә. Демьян Бедный шушы вакыйгага багышлап көнендә үк «Җиңүчеләр» дигән шигырь яза, Кызыл Армиянең бу «Яңа ел бүләген» халкыбызның зур шатлык белән кабул итүен тасвирлый. Бу шигырь «Красная Татария»нең 1942 елгы беренче санында дөнья күрә. Шул ук санның дүртенче битендә Д. Бедныйның берничә сатирик антифашистик шигыре дә урнаштырыла. Аларда шагыйрь гитлерчыларның «яшен тизлегендәге сугыш» турындагы планнарының җимерелүе турында үтергеч сарказм белән яза.

Шул ук газетаның 11 январь санында Д. Бедныйның «Гвардия» дигән шигыре басыла. Анда ул эшчеләр сыйныфының — «хезмәт гвардиясенең» совет тылындагы батыр хезмәтенә дан җырлый. Бер үк вакытта шагыйрь шәһәр циркы өчен лозунглар һәм агиткалар, тылдан фронтовикларга җибәрелә торган посылкаларга салып җибәрү өчен өндәмә шигырьләр яза. 1942 елның язында Демьян Бедныйның Казанда язылган шигырьләре «Советский писатель» нәшриятында «Безнең көч» дигән җыентыкка туплланып чыга.

Әлбәттә, Демьян Бедный тизрәк Мәскәүгә кайту теләге белән яши. Хатларының берсендә ул болай дип яза: «Мәскәүгә кайтыр көннәр әллә ни ерак түгелдер дигән өмет белән яшим мин». 1942 елның февралендә инде Мәскәүгә кайтып китәм дигәндә шагыйрь аягын сындыра. Биш атна урында ята һәм апрель аенда гына Казаннан китә. Авырып ятканда да Д. Бедный эштән туктамый. Казаннан китүенә А. А. Фадеев җибәргән телеграмманың булышлыгы тия. Фадеев шагыйрьгә «ТАСС тәрәзәләре» булдыруда турыдан-туры һәм актив катнашырга тәкъдим итә. Сугыш чорындагы «ТАСС тәрәзәләре»нең алтыдан бер өлеше Д. Бедный шигырьләре белән чыга. Шигъри коралның бөтен төрләре — мәсәл, сатирик эпиграмма, җыр, плакатлардагы үтлы юллары ярдәмендә карт солдат үз гомеренең соңгы көннәренә кадәр Ватан өчен көрәшә. 1945 елның 25 маенда ул кисәк үлеп китә.

Бөтен совет кешеләре кебек үк казанлылар, Татарстан хезмәт ияләре дә Демьян Бедный исемен хәтердә саклыйлар, революцион пролетариат поэзиясен башлап җибәрүчеләрнең берсен, куәтле талантын күп милләтле Ватаныбызның чәчәк атуына хезмәткә куйган шагыйрьне хөрмәтләп искә алалар. Казан шәһәренең Совет районындагы бер урамга Демьян Бедный исеме бирелде. М. Горький урамындагы шагыйрь яшәгән 17 нче йорт Татарстан АССРның тарих һәм культура истәлекләре исемлегенә кертелде.

**Т. НАСЫЙРОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# БЕЗ БИК ЯКЫНБЫЗ

Безнең эш бүлмәсендә бәләкәй генә бер җир шары тора. Ул безгә, уенын-чынын бергә кушып әйткәндә, глобусларның гына түгел, дөнья дигәнеңнең дә бик бәләкәй икәнлеген искә төшереп торсын өчен кирәк. Җае чыкканда без шул җир шарына бармак очлары белән генә кагылабыз да — әйләнә дөнья... Ул, чыннан да, артык зур түгел шул: бер-берсенә сыенып утырган берничә кисәк коры җир һәм Океания дип аталган тоташ бер зәңгәр материк...

Глобус-җир шары әйләнә; без дөнья гаме, илләр-халыклар язмышы турында, төркиләр белән Шумер культурасын тоташтырган тамырлар, төркиләр белән Америка индеецлары арасындагы якынлык турында сөйләшә башлыйбыз. һәм, әлбәттә, «без бик якынбыз» дигән нәтиҗәгә киләбез.

Без бик якынбыз...

Өйгә кайткач, мин гаилә архивын актарам, менә инде ничәмә тапкыр иске, саргайган конвертларны аралыйм, — башкорт даласындагы сәер генә исемле бер авылда яшәп ятарга тиешле якын туганнарның адресын эзлим. Безнең абыз-апай дөньядамы икән әле, аның балалары безне хәтерлиләрме икән?..

Без бик якынбыз: абыз-апай минем әни белән бертуган; моннан унбиш-егерме еллап элек, ул әле, үзе әйтмешли, әүхәтендә чагында, кече улы белән киленнен дә ияртеп бер кайткан иде. Менә хәзер инде адресларын да табып булмый, аралар әллә ни ерак булмаса да, хәбәрләр йөрми. Дөньяда микән син, абыз-апай? Безнең хәтерсезлеккә, үз балаларыңның каты бәгырьлелегенә рәнҗеп ятмыйсыңмы икән? Без инде шул кадәр үк күрше хакын, дуслык хакын хакламаслык, күрше янсә дус кына да түгел, кан кардәшләр булуыбызны истән чыгарырлык хәлгә килеп җиттек микәнни?..

Бәлки, бу — бүрәнә аша бүре күрү, булган-булмаганны артык купайту, хаталанудыр, алай ук хафаланырлык сәбәп-нигез дә юктыр? Шулай була гына күрсен иде! Әллә нигә бер булсын да, китапларда гына гыйбрәт өчен язылсын иде андый хәлләр!

Менә әле, Нажар Нәҗминең «Кем уйлаган»[1] исемле яңа китабын укып чыккач та мин еракта яшәүче якын туганнардан хат-хәбәр алган кебек куанулы һәм йөрәкне кысып куярлык бер хис кичердем. Ул хис бигрәк тә китапны ябып куючы битләрдәге бер гади генә җөмләдән, ишек ачылганда сискәнеп киткән лампа уты сыман, дерт итеп, тартылып-талпынып калды. Иҗат һәм шигърият турындагы, татар әдипләренә багышланган хатларын, шул рәвешле бөтен китабын төгәлләп килгәндә, «бу язганнарым... безнең әдәби бәйләнешләребезне киләчәктә тирәнрәк һәм киңрәк сыйфатта дәвам итү... теләге белән дә туган дип фараз ителсә иде»,— ди Нажар ага һәм, әлеге сүзләрен әйтер алдыннан җирлек әзерләгәндәй: «без бик якынбыз»,— ди...

Әйе, чыннан да, без бик якын шул.

Ыру-нәсел шәҗәрәләреннән дә ышанычлырак, көчлерәк һәм тирәнрәк туганлык тамырларыбыз бар. Үзгәртеп-сиплән булмый торган нык тарихи нигезләребез һәм социалистик милләтләр гаиләсендәге уртак матур язмышыбыз бар. Ниһаять, татар халкының күп гасырлы язма әдәбиятына, бай тәҗрибәсенә һәм эчкерсез ярдәменә дә таянып үскән башкорт әдәби теле һәм әдәби культурасы бар.

Бу уртаклыкны — халыклар дуслыгының мәңгелек тамырларыннан күтәрелгән шифалы сут белән совет әдәбияты дигән мәгърур агачның көчле ябалдашы арасын-

---

[1] Нажар Нәҗми. Кем уйлаган. Уфа, Башкортстан китап нәшрияты, 1983.

дагы бәйләнешне — тирәнтен тою безнең культураларыбызның бүгенге үсешенә дә этәргеч ясый. Безнең уртак җырларыбыз бүген дә дәвам итә.

«Татар теле» исемле зур җегәрле шигыре, «Юкка түгел, юкка түгелдер», «Син гомер агышларым», «Өфе юкәләре», «Сиңа тагын мин бер килэм әле» кебек ягымлы җырлары белән генә түгел, тулаем иҗаты белән Татарстан укучыларының да үз шагыйренә әверелгән Нәҗар Нәҗминең яңа китабын укыганда күңелне әнә шундый уйлар били.

«Кем уйлаган» — истәлекләр, иҗади портретлар һәм уйланулар җыентыгы. Рәсүл Гамзатов белән Кайсын Кулиев, Яков Ухсай белән Семен Данилов портретлары-мы, янсә башкорт һәм татар әдипләре иҗатына багышланган тәнкыйди прозамы,— һәр очракта заман, әдәбият һәм шагыйрьнең шәхси җаваплылыгы турындагы сүз югары дәрәҗәдә алып барыла анда. Кешелекле хисләр, чын күңелдән сөенү һәм ара-тирә яңгырап киткән борчулы ноталар да биредә анализ сабырлыгын, фикер дәлиллеген басып китә алмый; тегеяки бу мәсьәләгә шәхси мөнәсәбәт бер үк вакытта гадел һәм таләпчән булып та калырга комачауламый.

Дөресен әйткәндә, кемнең әле үз фикерен яшереп кенә объективлыкка ирешә алганы бар? Бүген проза һәм поэзиядә дә, әдәбият турында фикер йөрткәндә һәм аңа бәя биргәндә дә, аерым күренешләрне тасвирлаудан бигрәк, аларга мөнәсәбәтеңне ачык, дәлилле итеп белдерү әһәмиятлерәк була бара. Бу — «объектив» сурәтләүдән кыенрак, чөнки биредә шәхеснең үз калачасы беленә, бердәнбер «ут ноктасы» — позициясе ачыла.

Нәҗар ага менә шулай, ахыргача объектив һәм әчкерсез булып калу өчен, сүзне үзеннән, үз язмышыннан башлый. Шагыйрьнең туу чыганаклары, җирлеге-туфрагы турындагы бу сүз әлеге шул туфрак кебек үк табигый дә, саллы да. «Кем уйлаган...» дип, сәерсенәбрәк, тартынып̆рак керешеп киткән әлеге автобиографик язмалар — зур иҗат сандыгының бәләкәй ачкычы. Аларның әһәмияте соңыннан бөтен бер китапка исем булып китүләрендә дә күренә түгелмени! «Кем уйлаган...»

«Мин үземне шигърият дөньясына нинди дер бер көтелмәгән шифалы җил тарафыннан очырылып төшкән орлыктан үсеп чыккан үсенте итеп хис итәм һәм шушы орлыкның бик уңдырышлы туфракка туры килгәнен күрәм. Ул туфрак — минем туып үскән җирем, халкым һәм безнең чынбарлык. Алар белән гомерлемен дә, шигырьлемен дә»,— дип тормыш йомгагын сүтә шагыйрь. Безнең күз алдында аның бәләлык һәм үсмерчак тәэсирләрә яңара, яшьлек һәм беренче иҗат сәхифәләре ачыла. Булачак шагыйрьнең һөнәрле агайлары, тормыш һәм әдәбияттагы дуслары, остазлары, сылу Әминә, күрән алаша, туган авылы Миңеште...— һәркайсы моңсу булып, кадерле булып истә кала. «Шигърияттә дә шулай булсаң иде — үзеңчә берәү генә булып, берәүгә дә охшамасаң һәм исемең дә шулай, кешеләр күнеккәнче, ятрак булып тоелса иде...» — дип искә ала ул үзенең Миңештесен.

Шәхси тормышыннан, тәэсир-уйлануларыннан замандашлары иҗатына чыга, шәхси язмышларда чор сурәтен күрә шагыйрь. Аның автобиографик язмаларында ук безнең көннәргә дә бик якын, безне бүген дә бик борчый торган сорауларга җавап эзләү башлана.

Нәҗар Нәҗми уйланулары,— тыштан карaганда салмак агышлы, сабыр тавышлы бу «Кем уйлаган...»— үз иңендә шактый авыр һәм борчулы сораулар күтәреп торуы белән, шундый типтагы башка бер китапка да охшамаган. Дөресрәге, ул сорауларга җавап эзләү үзе күпләр инде күнегә төшкән юлдан бармый. Без бит тәнкыйтьтә генә түгел, гадәттә проза әсәрләрендә дә фикер-анализ агымының бер юнәлешен генә сайлап алырга — ахыр нәтиҗәне күргән-бәяләгән хәлдә, «шуңа ничек ирешелгән?» диган сорауга җавап эзләргә генә тырышабыз. Бу — чагыштырмача җиңел юл һәм аның тормышны, әдәбиятны аңлатуга керткән өлеше дә шул җиңеллеккә бәрабәр. Билгеле булганча, тормышта да, әдәбиятта да соңгы ноктасы куелган, тәмамланган күренешләр без теләгән кадәр үк күп түгел. Димәк, аларны тәгәлләнмәгән процесс итеп карау һәм аңлату кирәк. Хәтта кайбер талантларның китаплардан тыш гомере инде өзелеп калган булса да...

Шагыйрә Саҗидә Сөләймановага багышланган хатында гына түгел, башка бик күп урында, гомумән күпчелек очракта Нәҗар Нәҗми шушы авыр юлны сайлый. Йомылып калырдай сорауларны кире ача, темаларны ача, башкаларга да ачык калдыра. Аның уйланулары, фикерләре беркайчан

да авторитетларның киң җилкәсе артына сыенмый, шигырь кебек үк яклаучысыз, укучы белән күзгә-күз кала. Үзе борчыла: ялгыш аңламасыннар иде, ди,— шул ук вакытта ярашмый, шомартмый, мондый чакта ярдәмгә әзер торучы «түгәрәк» сүзләрдән баш тарта. Чөнки шагыйрьне зуррак борчулар били: иҗатта җаваплылык, намуслылыкны яклый, табигыйлек, бөтенлекнең җуелмавын кайгырта ул. Хәтта «чын шигырь әнә шул Александр колоннасы кебек үз авырлыгы, үз һәлмәклеге белән торырга һәм яшәргә тиеш»,— дигән сүзләрендә дә күпме борчылу! Уртә кул шагыйрьләрнең әрсезлеген, бик тиз үрчүен, бер-берсен яклашуларын, ниһаять, әдәби процесска бәя һәм тон бирергә маташуларын күреп әрни аның күңеле. «Йөзсез яшәү мөмкинме соң? Мөмкин түгел,— әй яшиләр!»

Шушы җитди мәсьәләләрнең асылына карап Нәҗәр Нәҗми иҗат һәм тәнкыйть принциплары, талантны тану-бәяләү критерийләре турында катгый фикерен белдерә. Ул җиңел генә «төзәтелә» торган әсәрләрне, оригиналь булыр өчен генә «мөгез» чыгаруларны чын талант җимешләреннән кискен аерып куя, әдәби күренешләрне бәяләгәндә фасонына карап кына бер чыбыктан сөрүче тәнкыйтькә каршы чыга. «Нигә әле без талантларга бәя биргәндә әзрәк «фәстерергә» куркабыз?.. Сәнгать ул, табигать шикелле, тигезлекне белми һәм белергә дә теләми...» дигән сүзләр, хәтта беркадәр «фәстерү» булганда да бик урынлы һәм актуаль кисәтү булып яңгырый.

«Кем уйлаган...» — чын талантның табигатен аңлау һәм аңа мөнәсәбәт турындагы китап. Нәҗәр аганың «Шагыйрь шигырьдән шигырьгә туа» дигән канатлы сүзләрен раслагандай, әдәбияттагы талантлар юлы турындагы фикер дә бу хезмәттә сәхифәдән сәхифәгә үсә, ачыклана бара.

Башкорт шагыйре Хәким Гыйләҗевка багышланган иҗат портреты язучының үсешен күзәтү җәһәтеннән аеруча гыйбрәтле.

«Күп очракта әдипләребез кем булуларын үзләренең нинди мәктәп, нинди институт бетерүләре белән бәйлиләр. Димәк, аларның язучылык сәләте... табигать тарафыннан бирелгән бердәнбер сәләт...— Мәкаләдәге кызыклы борылышларның берсе әнә шулай башлана.— Хәким Гыйләҗев, мәсәлән, язучы булмаса, бәлки аннан рәссам чыгар иде, һич тә булмаса, галимлек юлы белән китәр иде,— дип дәвам итә автор.— ...Ул төрле яклап талантлы, аның кулыннан төрле эш килә...»

Кабатланмас иҗади йөз һәм табигыйлек (Яков Ухсай), заман һәм шагыйрь гармониясе —«табигать тарафыннан яратылган кантар (глыба)» булу (Гамил Афзал) турындагы уйлануларда талантка ышаныч, талантка ихтирам мәсьәләләре кузгатыла: «Минем дә синең кайсыбер шигырьләреңне укыганда аягүрә басасым килде» (285 бит). Бу юлларда иң югары дәрәҗәдәге таләпчәнлек тә бар. Чөнки, хәтта Туфан, бала җанлы Туфан да, дип искә ала Нәҗәр ага, «күңеленә, поэзиягә ят һәм чит булган, хилафлы күренгән нәрсәләргә рәхимсез һәм принципиаль иде».

Менә шул рәвешле, иҗат принциплары һәм талант табигате хакындагы фикерләр бер төенгә килеп бәйләнә һәм бу һич тә очраклы хәл түгел. Төрле шагыйрьләр иҗатына кагылышлы күзәтүләр нечкәлеге, фикер һәм образ логикасына үтә сизгерлек, шуның өстенә җегәрле һәм йөгерек тел бу китапны укучы күңеленә тагын да якынайта.

Әлбәттә, «һәркемгә ошау мөмкин түгел, һәркемдә үз турыңда әйбәт фикер калдырыр өчен берничә катлы булырга кирәк». Нәҗәр Нәҗми анализ юлларыннан иң авырын сайлаган кебек, үз фикерләрен бәян итү өчен дә бердәнбер формага — ихлас булуга йөз тота. Китапның өчтән бер өлешен алып торган «Ачык хатлар» әлеге омтылышны тагын да ассызымлап тора. Ул хатлардагы күңел җылысы китапның соңгы битләренә таба көчәйгәннән-көчәя барып, «Ут күршеләр» дип исемләнгән иң ахыргы бүлекчәдә аеруча юмарт һәм эчкерсез гәүдәләнеш ала. Алты хат — һәркайсы берәр татар шагыйренең иҗатына гына кагылса да, нинди зур хезмәт булыр иде. Ә бит бу хатларда — китапның алдагы өчтән ике өлешендә барган сүзнең сөземтәсе, аның, башкортчалап әйткәндә, иң югары кимәле (дәрәҗәсе). Бу хатларда — талантның тормыш һәм иҗат биеклеге, гражданлык йөзе, сәнгатьнең милли асылы һәм интернациональ табигате турында уйлануларның билгеле бер «уртак ваклаучы»га китерелүе.

Менә Нәҗәр ага татар шагыйренең бер шигырен «кычкырып укый», башкаларны да

тыңларга чакыра. Барыбызга да бик таныш юллар...

**Миңа гармун, гармун җитми читтә,**
**Юлларыма ятар таң нуры.**
**Яңгырасын иде Европаның**
**Уртасында татар гармуны...**

Шигырь тулысынча укыла. Шагыйрь каләмдәшенең бер әсәре аша бөтен иҗатына, алай гына да түгел, бөтен татар поэзиясенә үз бәясен бирә сыман: «Бу... халкыңны, аның интернациональ миссиясен шундый югарылыкка күтәрү түгелмени! Ул югарылык Тукайлардан, Җәлилләрдән килә...» Тугандаш халыкның күренекле әдибе язган бу «Хатлар», аның Муса Җәлил һәм Хәсән Туфан батырлыгы турында уйланулары, әнә шундый югары бер мотивта берләшеп, безнең күңелләргә кайта.

...Сүземне бәләкәй глобустан, кайдадыр хәбәр-хәтерсез яшәп ятучы Америка индеецларыннан һәм әбыз-апалардан башлаган идем. Тора-бара, төп игътибарны китапка туплагач, укучыларда каршылыклы бер тәэсир калуы ихтимал. «Фәсоны килсен өчен генә» эшләнгән бер алым булган икән дип уйлаулары мөмкин... Юк, алай түгел! Чөнки халыкта: «Үзең таныган илен танырь, илен таныган күршесен танырь», дигән сүз бар... Ә бәлки, кечкенә җир шары һәм индеецлар турында искә төшерү дә шушы сөйләшү өчен кирәк булгандыр әле. Без бик якынбыз бит...

**САЛИХ МАННАПОВ.**

# БАЛАЛАРГА ЯҢА КИТАП

Җәүдәт Дәрзаманов исеме укучыга шактый таныш. Аның моңа кадәр басылган китаплары турында төрле фикерләр булды. Ләкин ни генә әйтелсә дә, ул китаплар Җәүдәтчә тапкырлык белән язылган иде. Аларны бала үз итте, яратты.

Бүген балалар шагыйренең яңа китабын укыйм.— «Гөлназ мәктәпкә бара». Әйбәт кыз ул Гөлназ... һәр нәрсәдән шигърият таба белә:

**Арба кайта келтер-келтер,**
**Тирбәлдереп җай гына.**
**Ә Гөлназның күз алдында**
**Уйнап кайткан тай гына.**

**Үзе кара, үзе елгыр,**
**Тояклары — тимер күк.**
**Карамасаң, кара тайның**
**Куанычы кимер күк.**

(«Арба кайта келтер-келтер»)

Гөлназ хезмәттән җанына рәхәтлек ала белә:

**Ташыйлар өчәүләшеп:**
**Мичкә белән — әтисе,**
**Көянтәләп — әнисе.**
**Ә Гөлназ йөри гелән**
**Нәни чиләкләр белән.**

**Әй сибәләр, сибәләр —**
**Түтәлләр тиз кибәләр!**
**...Күмәк эшләү күңелле,**
**Әллә шулай түгелме!**

(«Бакчада»)

Әйе, шулай... Аның шулай икәнлеген шагыйрьнең «Кирәк», «Чүкеч, пычкы, балта, ышкы», «Пехтә була, матур була», «Эш беткәч», «Печән өсте» кебек әйбәт шигырьләре раслап тора.

Әле шуның өстәвенә бик әйбәт, олы җанлы кыз да ул Гөлназ. «Тукталышта» исемле шигырьдә бу фикер бик матур, төгәл әйтелгән. Чыннан да «гаҗәп хәл бит: чумып карга йөри ялгыз кара карга». Җирдә кыш салкыны, ә ялгыз карга аптырагач «Итек башын татып карый, сумка бигән тартып карый». Гөлназыбыз аны күмәч белән сыйлый. Һәм кисәтеп куярга да онытмый:

**Якын килдең,**
**Назландың да...**
**Төрлесе бар**
**Кызларның да.**

Мәсьәләгә конкретрак якын килик. Беренче бүлек «Уенчыкларым» дип аталган. Уенчык булгач, уенчык инде ул: туп, бөтерчек, машиналар, һ. б. 11 шигырь тупланган бу бүлектә укучы 3 әйбәт шигырь белән очраша. Ә калганнары? Калганнарын мин шәхсән кабул итә алмадым. Ни өчен?

Беренчедән, ул шигырьләрдә авторның фантазиясе чикләнгән. Моның иң отышлы мисалы —«Сәяхәт» шигыре. Җәнлекләр вагонга төялеп үзләренең туган җиренә китә. Ак аю, юлбарыс, жираф, бolan, бөркет, фил, кабан, бүре, дельфин, куян... Тик аларның берсе дә үзенә генә хас сыйфаты белән ачылмаган. Җитмәсә яңадан шул ук вагонга төялеп, бөтенесе дә авылга кайта.

**— Урра! Кайтып җитәбез!— дип,**
**Бөтенесе шатлана.**

Юк инде, Җәүдәт туган. Болай булмый ул. Биредәге җәнлекләрнең һәрберсе үз җирендә калырга тиеш иде. Паровоз (ә, бәлки, электровоз) малайны гына авылга алып кайтырга тиеш иде.

Икенчедән, әлеге шигырьләр кытыршы тел белән язылган. Менә бу юлларны кайсы бала абынмый укый алыр икән:

**Әйдә, икәү уйныйк, Алмаз,**
**Миңа — КамАЗ, сиңа — МАЗ.**
**Башта ташын илтеп ташлыйк,**
**Ком озакка чыдамас.**

. . . . . . . . . . . . . .

**Аннан авылга барырбыз**
**Тырма, сабаннар салып.**
**Безнең шулай уңганлыкка**
**Шаккатсын әле халык.**

(«Машиналар»)

«Курчаклар», «Тәгәрмәчләр» дә шундыйрак тел белән язылган.

Өченчедән, шагыйрь үзе дә сизмичә вакыт-вакыт балалар телен оныта. Бала чал чәчле картка охшап кала. «Нидер эзләнә күңел», «Үз-үземне тиргәп куйдым, озак уйлап яттым дип», «Син дә булыш, тик утырма, игълан язып куя тор». Кемгә ничектер, әмма минем үземә шушы рәвешле фикер йөртүче бала очраганы юк.

Икенче бүлекне укыйбыз. Бу бүлек күләме белән зуррак. Ул 17 шигырьне үз эченә алган. Әйбәт шигырьләр җидәү. Кайсы шигырьләр? «Бәйрәм», «Юлда», «Сәгать туктагач», «Тукталышта», «Циркта», «Пөхтә була, матур була», «Эш беткәч».

Бу бүлек шактый оста тел белән язылган. Беренче бүлектәге кебек тел көрмәкләнеп туктап калулар монда бөтенләй юк диярлек. Әмма бу бүлектә шагыйрьнең яңа кимчелекләре күзгә бәрелә.

Биредә шагыйрь үзе дә сизмичә, кемнедер кабатлый башлый.

**Чәчләрен дә үрде,**
**Юды битләрен дә,**
**Гел елмаю тора**
**Ирен читләрендә.**

. . . . . . . . . .

**— Ботенесен үзе**
**Эшләгән бит, кара!**
**...Соң, бүгеннән башлап**
**Ул мәктәпкә бара.**

Әдәбиятта мәгълүматлы укучы шунда ук Бари Рәхмәтнең атаклы «Уңган кыз Сара» шигырен искә төшерер. Шул ук ритм, шул ук интонация.

Аннары кайбер шигырьләргә күпсүзлелек килеп кәрә. Җәүдәт юллар саны артыннан куа башлый һәм шигырьне кайдан башларга, кайда нокта куярга кирәклеген оныта. Бер генә мисал — «Циркта» шигыре. 20 юллы шигырьнең алдагы 8 юлын сызып ташлау берни тормас иде. Чөнки алар буш юллар. 48 юлдан торган «Тискәре һәм... тылсымлы хәрефләр» шигырендәге ике генә куплет көтелгән эффектны бирә.

**«Менә Гөлназ «а» хәрефен**
**«у»га илтеп ялгады.**
**Ялгады да карурманда**
**Ерак адашып калды.**

. . . . . . . . . . . . .

**«У»ны «а»га кушкан иде,**
**Эш тапты бит үзенә:**
**Күлмәкләре бик каралган,**
**Шул ташланды күзенә.**

Миңа калса, китаптагы иң отышлы бүлек — соңгы бүлек «Җәйгә ял». 21 шигырьне эченә алган бу бүлектә 15 әйбәт шигырь булу моны раслап тора.

Бу бүлектә мин шагыйрьнең көчле яклары белән очраштым һәм аңа булган ихтирамым үсте. Шагыйрь «балалар шигы[illegible] олылар да укый торган әйбәт шигырь булсын» дигән принциптан чыгып эш итә. Балалар шигырендә олылар лирикасы матур

ачыла һәм, басым ясап әйтәм, балаларча бик матур ачыла.

Лепер-лепер кул чәбәкли
Усаклар, әбәк уйнап —
Ромашкалар, дулкын-дулкын,
Куыша алан буйлап.

(«Саумы, җәй»)

Давыл тынды, җил тынды,
Диңгез тынлыкка чумды.
Ахрысы чабып арган,—
Дулкыннар чикте ярдан.
Чикте чыклар калдырып,
Кабырчыклар калдырып.

(«Диңгезне сагындырсын»)

Диңгез бүген уянган,
Бүтән төскә буянган:
Ачуыннан каралган,
Чал чәчләре таралган —
Өсте гел күбек кенә,
Чын кораблар чайкалалар
Уенчык кебек кенә.

(«Диңгез ачулана»)

Бу юлларны кайсы гына бала, кайсы гына өлкән кеше яратып кабул итмәс микән?

Җәүдәтнең көчле ягы да шунда: ул үзе олыгайган саен, сабыйлыгын югалтмыйча, бик матур рәсемле шигырьләр яза белә. Табигать матурлыгы, җир, кешеләр матурлыгы турында язылган шигырьләре әйбәт шигырьләр бәйләмен тәшкил итә. Мин аның шул якка ныграк басым ясавын теләр идем. Бүгенге көндә кешелеклелек, матурлык турында язылган шигырьләр күбрәк сорала. Киләчәктә дә шулай булыр. Намус дигән олы төшенчә беркайчан да искерми.

Рецензиянең иң соңында шуны да искәрми үтә алмыйм: китаплар чыгаруга һаман да җиңел карыйбыз әле. Шагыйрьләр сан артыннан куа. Рецензент та, редактор да таләпчәнрәк булсалар, укучыга тагын да әйбәтрәк китап барып ирешер иде.

Шагыйрь Җәүдәт Дәрзаманов алдагы китапларын балалар күңеленә кош итеп очырганда үзенә таләпчәнрәк булсын иде.

РӘШИТ БӘШӘРОВ.

# ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

## ХАТЛАР УКЫГАНДА

«Соңгы китап»ның «Каргалы һәм «Дәүләкән» өлешләре «Казан утлары»нда басылып чыккач, укучылардан журнал редакциясенә, шулай ук үз адресыма шактый гына хатлар килде. Димәк, укучылар әсәрне кызыксынып укыганнар, битараф кала алмаганнар, фикерләрен әйтәсе, мөнәсәбәтләрен белгертәселәре килгән. Бу күңелле факт. Укучы сүзен ишетү һәрвакытта кызыклы һәм файдалы ул.

Редакциядәге иптәшләр белән сөйләшкәннән соң, минем шул хатларга җавап бирүем кирәк табылды. Мин менә шул вазифаны хәлемнән килгәнчә үтәмәкче булам... Болай «хәлемнән килгәнчә» дип әйтүем берәүне дә гаҗәпләндермәсен, чөнки әсәрнең үзен язуга караганда аны шәрехләү һәм аңлату автор өчен һәр вакытта читенрәк. Кайчагында «аңлату» урынына бутау да килеп чыгарга мөмкин. Бу — язу эшенең бер ачылып җитмәгән сере булса кирәк. Әгәр сүз роман яки повесть турында барса, мин бәлки хатларга җавап бирүне кирәк тә тапмас идем, һәркемнең әсәрне үзенчә аңларга хакы бар, дип ансат кына бу эштән котылган да булыр идем. Әмма сүз бит истәлекләр турында бара. Ә истәлек исә — ул чынлыкта булганны язу... Бу очракта инде укучы күңелендә берәр төрле шик, сорау яки теләк белдерәсе килү туа икән, моны игътибарсыз һәм җавапсыз калдыру мөмкин түгел. Истәлекләрнең эчтәлеген тәшкил иткән фактлардагы дөреслек сакланырга тиеш, дөреслекне бозарга ярамый, аны тулыландырырга һәм ачыкларга гына ярый. Кыскасы, әнә шул исәпләрдән чыгып, мин укучы хатларына җавап рәвешендә үземнең кайбер фикерләрем белән уртаклашуны кирәк таптым.

Хатлар ике төркемгә бүленә: бер төркеме әсәрнең «Каргалы» өлешенә, икенче төркеме — «Дәүләкән» өлешенә карый. Миңа да шулай итәргә, ягъни һәр төркемгә аерым-аерым тукталырга туры киләчәк. Әмма барлык хатларда уртак бер нәрсә бар — бу турыдан-туры әсәрнең исеменә кагылган мәсьәлә. Башта шуңа тукталырга рөхсәт итәрсез.

Һәрбер хатта диярлек сорау, гаҗәпләнү, ризасызлык белдерү: ни өчен «Соңгы китап»? Хәтта бер яшь укучым «Татарстан яшьләре»ндә «Соңгысы булмасын!» дип язып та чыкты. Кыскасы, исемне яратмаганнар. Журналдагы иптәшләр дә аны алыштырырга кушканнар иде, ләкин мин бүтән исем таба алмадым — шулай «соңгы...» булып китте ул. Исем табу, бигрәк тә әсәрнең эчтәлегенә яки рухына туры килгәнен табу җиңел эш түгел. Күрәсең, ул үзенә бер осталык сорый торгандыр инде. (Әнә Европа язучылары исем табарга бик осталар.) Баштарак мин дә истәлекләремә туры килердәй (ә ни өчен туры килергә тиеш?) исемне озак эзләдем, таба алмадым, табылганын — ошатмадым, яңа түгел, оригиналь түгел,— ни сәбәптер гел бүтәннәр кулланган исемнәрне хәтерләтәләр иде. Шулай азапланган чакта кинәт кенә күңелемә «Соңгы китап» дигән исем килде. Бик бәхәсле исем булуына карамастан, мин аны китапның башына язып та куйдым. Яхшырагы, кешегә ошардае табылса, алыштырырмын дип тә уйлаган идем, ләкин, әйткәнемчә, үземне канәгатьләндерерлек бүтәне табылмады, китте шулай...

Билгеле, укучыларның күбесе аны бик туры мәгънәсендә, ягъни бу абзый соңгы әйберен язган, башка инде язмаячак икән дип аңлаганнар. (Һәрхәлдә, куплэрнең күңеленә, чынлап та бу соңгысымы, дигән шик килмичә калмаган булса кирәк.) Әлбәттә, һәрбер язучының соңгы әсәре була, хәтта язылып бетмичә өзелеп калганы да була — моны истән чыгарырга ярамый. Әмма бу әле язучы үзе, үз теләге белән язудан туктады дигән сүз түгел. Һәм мин дә алай кырт кисеп куймадым. Гомер бул-

са нигә язмаска?! Язу ул минем өчен хәзер бердәнбер юаныч.

Ләкин шулай да «соңгы...» дигәнне ничегрәк аңларга соң? Әдәбият дөньясында күптәннән бер традиция яшәп килә: һәрбер язучы гомеренең ахырына таба үзенең күргән-кичергәннәрен язып калдырырга тырыша. Моны истәлекләр яки мемуар әдәбият диләр. Менә мин дә соңга калыбрак булса да шул эшкә керештем. Моңа инде дүрт-биш ел вакытым китте, тагын күпмегә сузылыр — үзеп кенә әйтә алмыйм, әмма үземнең үткәнемне язып чыгуым беренче һәм соңгы мәртәбә булачак. Китапның исемен әнә шул мәгънәдә аңларга да кирәк. Ихтимал, бу исемдә минем күп нәрсәне соңга калып искә төшерүем дә, онытылган, терелтеп булмый торган югалтулар да, гомернең инде шактый чикләнгән булуы да чагыла торгандыр. Нишләмәк кирәк, язу — күңел эше, китапка исемне дә күбрәк ул куша!

Инде хатларның үзләренә килик. Менә аларның «Каргалы» өлешенә караганнары... Бу хатлардан күренгәнчә, әсәр тулаем укучыларда кызыксыну тудырган булырга тиеш. Башкортстан җирендә Каргалы дигән бер авыл барлыгын, анда үзләрен «төмән» дип йөрткән халык торганлыгын укучы әдәбиятта моңарчы күренмәгән яңа бер нәрсә итеп кабул иткән булса кирәк. Күп кенә хатлардан моны ачык сизеп була. Һәм бу аңлашыла да — узган заман укучыны һәрвакытта кызыксындыра, бер авыл мисалында да ул халыкның тарихын һәм язмышын күрергә тырыша. Ә бит кайчандыр башкорт җирләренә күчеп утырырга мәҗбүр булган төмән, мишәр, типтәр авыллары аз түгел — Каргалының якын тирәсендә генә дә алар дистәләп. Килгән еллары һәм юллары бер булмаса да язмышлары бер — шушы бәрәкәтле туфракта үзләренең яңа ватаннарын тапканнар.

Ләкин хатлар минем үземә дә күп кенә яңалыклар китерде. Безнең авыл һәм минем нәсел тарихы белән яхшы ук таныш кешеләр бар икән. Алар үзләренең белгәннәрен язалар, минем истәлекләргә нидер өстиселәре яки нәрсәнедер төзәтәселәре килә, кыскасы, чын ихластан миңа ярдәм итәргә телиләр. Шуларның берсе Сәгыйт Хәнәфи улы Еникеев. Ләкин ул безнең Каргалыдан түгел, ә Чакмагыш районы Яңа Бәшир авылыннан... Бу авыл да Каргалы белән берүк вакытта диярлек (ике генә ел соңга калып) Темников өязеннән башкорт җиренә күчеп утырган. Күчеп килүчеләрнең дә күпчелеге Еникеевлар икән. Шулай итеп, Башкортстанда Еникеевлар яшәгән ике авыл барлыгы билгеле булды — югыйсә, мин бер Каргалы гына дип йөри идем. Ләкин бу ике авылдагы Еникеевлар бер тамырдан түгел, Яңа Бәширдәгеләр — князь Тениш токымы, ә Каргалыдагыларның нәсел очы Күлдәш морза — алар арасында бер нинди туганлык бәйләнеше юк, дип яза Сәгыйт Хәнәфиевич. (Тенишнең да, Күлдәшнең дә Еники исемле уллары булган — бер үк фамилия менә шуннан килеп чыккан.)

Шулай ук Сары Кылыч белән Темников та бер үк кала түгел икән; татарлар корган Сары Кылыч 1365 елда җимерелгән, шуннан соң яңа шәһәр — Темников Сары Кылычтан күпмедер читтәрәк, Мокшы елгасы буена салынган... Менә шундый өстәү-төзәтүләр кертә Сәгыйт Хәнәфиевич мин язганнарга. Ул үзе архивларда күп утырган, иске документлар белән танышкан, аннары бабайларның борынгы җирләренә дә барып кайткан — билгеле, аның сүзләренә колак салмыйча булмый.

Сәгыйт Хәнәфиевич хәбәр иткән яңа бер нәрсәгә тукталып китмичә ярамас ахрысы... 1767 елда Екатерина II указы белән яңа уложение (законнар җыелмасы булса кирәк) проектын төзү өчен Зур комиссиягә депутатлар сайлау үткәрелә. Барлыгы 564 кеше сайлана, һәм шулар арасында 27 татар да эләгә. Бу татарлар арасында Әюп Еникеев дигән бер морза да була. Менә шушы кеше әле Петр I заманында ук урман кисәргә куылган татарларның хәлләрен җиңеләйтүне үтенеп «Әби патшага» берничә мәртәбә мөрәҗәгать итә. Үзенең мөрәҗәгатьләрендә ул җәен-кышын урман кисәргә һәм чыгарырга мәҗбүр ителгән халыкның бу авыр эштән бик интегүен, тәмам бөлгенлеккә төшүен, күпләрнең урманда имгәнүләрен, үлеп тә калуларын, карап эшләтүчеләрнең бик рәхимсез кылануларын, чак кына ризасызлык белдергән өчен дә бик каты җәберләүләрен яза. Кат-кат язуга карамастан, нәтиҗәсе, әлбәттә, бик кечкенә була — эш өчен түләүне генә беркадәр арттыралар[1] (Атлыга көненә — 16 тиен, җәяүлегә 10 тиен түләү «сыйлар.)

[1] «Лашманчылык» дигән исем белән тарихка кереп калган һәм 150 ел давам иткән бу чукынмаган татарларны мәҗбүри эшләтү бары Александр II вакытында гына туктатыла.

Әюп морзаның «Әби патшага» язган мөрәҗәгатьләрендә башка шикаятьләр дә җитәрлек. Җөмләдән берсе: аеруча зур җинаять эшләгән бәгъзе татар җәзадан котылу өчен тизрәк чукына торган булган. (Шундый «льгота» булган икән ул заманда.) Әмма үзенең тиресен саклап калыр өчен генә чукынган бу кеше соңыннан үз милләттәшләренә һәртөрле әшәкелек эшли, җәбер-золым күрсәтә торган булып киткән. Татарлар менә шундый мөртәтләрдән үзләрен химая кылуны сорап, рус патшасына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булганнар. Гыйбрәтле факт. Әюп морзаның прошениесендә дә шул хәлләр язылган.

Шулай ук миңа Ленинградның Салтыков-Щедрин исемендәге мәшһүр китапханәсендә эшләүче, фәннәр кандидаты Игорь Васильевич Сахаровтан да берничә хат килде. Ул минем әйберне, билгеле, укый алмаган, әмма аның хакында ишеткән. Быел мин Ленинградка баргач, без очрашып сөйләштек тә. Игорь Васильевич күптәннән татар морзаларының тарихын өйрәнә икән. Тенишевлар, Еникеевлар һәм башка фамилияләр турында шактый материал туплаган. Һәр фамилиягә карата картотека да төзегән. Бу картотекаларны караган чагында минем күземә бер нәрсә чагылды: күп кенә фамилияләрнең шәҗәрәсендә «Еники» исеме очрый (мәсәлән, «Кудашев, сын Еникия» дип язылган) — күрәсең, заманында шактый таралган исем булгандыр инде... И. В. Сахаров — тарих белән махсус шөгыльләнүче кеше, әзләнүләрнең юлын-ысулларын да яхшы белә, миннән дә ниләр белүемне төпченеп сорашты — кыскасы, татар журналында басылган бер истәлекнең рус галименең дә игътибарын җәлеп итүе, башта әйткәнемчә, бездә халыклар тарихы белән кызыксынуның никадәр көчәйгәнен күрсәтсә кирәк. Ул миңа да ярдәм итәргә әзер торуын белдерде. Аның әйтүенә караганда, барлык Еникеевлар да бер тамырдан, бер кешегә — Биханга барып тоташа. Кем хаклы — әйтә алмыйм, әмма бик борыннан килгән фамилияләр татарларда аз түгел. Ләкин аларның берсе дә тикшерелмәгән һәм өйрәнелмәгән. Элегрәк заманнарда аңлырак бабайлар үз нәселләренең шәҗәрәсен белгән кадәр төзеп калдырырга тырышкан, тик кызганычка каршы, аларны җыючы да, саклаучы да булмаган — күптән югалып беткәннәр. Хәлбуки, татар халкының шактый катлаулы, четерекле тарихын өйрәнү өчен шәҗәрәләрнең, башка чыганаклар белән бер рәттән, әһәмияте зур булырга тиеш, минемчә.

Килгән хатлар арасында шулай ук аерым кешеләргә кагылганнары да бар. Хәтерлисездер, «Каргалы» өлешендә Әхмәт-Солтан Терегулов турында да беркадәр язылган иде. Бу — Каргалыдан чыккан, Уфада зур чиновник булган кеше. Менә шуның хакында Түмән шәһәреннән нефтьче-геолог Үзбәк Ишаев миңа түбәндәгеләрне хәбәр итә: Әхмәт-Солтан Терегулов губернатор канцеляриясендә чынлап та зур урын билгән; берәр җирдән пар атта кайтканда аңа дугадагы кыңгырауларын бәйләмичә калага шаулатып килеп керергә рөхсәт ителгән. Ә ваграк чиновникларга рөхсәт ителмәгән, алар кыңгырауларын бәйләп, тавыш-тынсыз гына кайтып кергәннәр, имеш. Хәер, бусы бер деталь генә, ә иң мөһиме менә нәрсәдә: Уфа охранкасы большевик Цюрупаны тотып ябарга җыенгач, Әхмәт-Солтан аны үзенең өендә яшереп тота. Алай гына түгел, охранканың эзләвен бөтенләй ялгыш юлга кертеп җибәрә. Революциядән соң Цюрупа Уфадан киткән чагында Терегуловка аның большевикларга ярдәм итүе турында язу да биреп калдыра. Бу — мөһим факт. Ләкин Үзбәк Ишаев аны кайдан белә? (1927 елда туган кеше.) Язуына караганда, аңа бу хакта әнисе ягыннан ага тиешле Йосыф Еникеев сөйләгән икән. Ә бу Еникеев егерменче еллардан алып комсомол булган кеше, Әхмәт-Солтан аңа авылдаш кына түгел, кайсыдыр яктан әзрәк кардәш тә икән, ләкин ул комсомол булгач, элекке чиновник абзасына кырын карап йөргән булса кирәк. Менә шуны сизгән Әхмәт-Солтан энекәшен тынычландыру өчен, үзе аңа барып, чиновник чакларында революционерларга ярдәм итүен сөйләгән һәм Цюрупа биреп калдырган әлеге язуны да күрсәткән...— Шулай яза миңа Үзбәк туган Ишаев. Минем моңа ышанасым килә, чөнки беренчедән, Әхмәт-Солтан Терегулов хакында андый сүзне беренче генә ишетүем түгел, икенчедән, аңа революциядән соң да Уфада тыныч кына яшәргә һәм эшләргә мөмкинлек биргәннәр. Бу инде тикмәгә генә булмагандыр.

Хатлар эченнән тагын бер көтелмәгән кеше килеп чыкты. Бу — Дәҗҗал Терегулов. Отставкадагы подполковник Хәснулла агай Хәбибов миңа әнә шуның хакында язган. Дөрес, кайчандыр бик күп еллар элек бу хәтәр исем минем дә колагыма

керәп калган иде. Ләкин шуннан соң бүтән ишетергә туры килмәде.

Хуш, кем соң ул — Дәджал Терегулов? Туган җире безнең Каргалы, туган елы — 1896, чын исеме Әхмәтҗан. Атасы Хөсәен агай — учитель, Каргалыдан китеп, күп еллар Троицкида укытып торган. Калган балалары барысы да шунда туганнар. Яшь егет Әхмәтҗан Терегулов 1913 елны Казан художество училищесына укырга кергән,— димәк, ул заманда татар башы белән махсус уку йортына керә алыр өчен аның җитәрлек сәләте булган. Ләкин беренче герман сугышы башлангач, 1915 елны аны армиягә алып, хәрби мәктәпкә укырга җибәрәләр. Әхмәтҗан Ржевтагы прапорщиклар мәктәбен бетереп чыга, фронтка китә, башта рота, аннары батальон белән командовать итә. Ул бик кыю, бик батыр йөрәкле кеше була. Һәм бик шәп оратор да булган икән. Февраль революциясеннән соң ул солдатлар комитеты белән җитәкчелек итә, ә Бөек Октябрь революциясе булгач, үзенең батальоны белән большевиклар ягына чыга. Нәкъ шушы дәһшәтле көннәрдә ул дини әкиятләр буенча безгә мәгълүм «Дәджал» дигән куркыныч исемне үзенә алган да булса кирәк. Деникинга каршы сугыша. Башкорт бригадасының командиры булып, Петроградны Юденичтан сакларга бара. Күрсәткән батырлыклары өчен исеме язылган кылыч белән бүләкләнә. 1919 елны Әхмәтҗан Хөсәен улы Терегулов Коммунистлар партиясе сафына кабул ителә. Сугышлардан соң Башкортстанда күпмедер вакыт военком булып тора. 1924 елны Казанга килә, шәһәр милициясенең начальнигы була... Вакыт уза, замана үзгәреп тора, «Дәджал» кебек кешегә дә төрлесен татырга туры килә... Аннары ул 1938 елны Казанның юридик институтын бетереп чыга. Озак та үтми Ватан сугышы башлангач, Дәджал тагын фронтта, бу юлы инде ул снайперлар хәзерләүче полк белән командалык итә. 1946 елны фронттан кайта, үзе тәмамлаган юридик институтта укыта, 1967 елны Ленин ордены белән бүләкләнә, Союз дәрәҗәсендә пенсия ала, сиксән яшен тутырып, 1977 елны дөньядан үтә.

Дәджал Терегуловның без әйләнеп кенә узган биографиясе әнә шундый. Дәртле, ялкынлы кеше булган, рәссам булырга хыялланган, аның урынына сугыш кәһарманы булып киткән, бик тиз югары күтәрелгән һәм кинәт түбән дә төшкән, янәдән күтәрелгән, яшәгән, картайган...— Революция елларында мәйданга чыккан күпләр өчен бу таныш язмыш, ә Дәджал кебек тынгысыз җаннар өчен бигрәк тә.

Әмма шушы урында Дәджал Терегуловның бертуган энесе турында да, бик кыска гына булса да, әйтеп китмичә булдыра алмыйм. Мин аны һич уйламаган, көтмәгән җирдән таптым. Дәджал турында минем тагын кайбер нәрсәләр беләсем килә иде. Ләкин кемнән сорашырга? Кайбер борынгырак кешеләргә дә шалтыратып карадым. Дәджал дигән исемне ишеткәннәре бар, ләкин үзен ачык кына белмиләр. Ахырда башлап хат язган Хәбибов иптәшкә мөрәҗәгать иттем. Ул миңа килеп, Дәджалның бер туган энесе Казанда тора бит диде һәм адресын да бирде. Баксам, ул кеше урам аша гына торган минем күршем булып чыкты. Менә ничә ел инде мин аны һаман күреп йөрим, алай гына да түгел, без аның белән бер мәҗлестә дә утырганыбыз бар. Әмма кем уйлаган аны Дәджал браты дип?

Безнең шәһәрдә яшәүчеләрдән дә күпләр бу кара чәчле, һәрвакыт үз алдына елмаебрак йөрүче, ягымлы тавышлы кешене белергә тиешләр. Ул бит Казанда яхшы танылган, исеме таралган врач-невропатолог Али Хөсәенович Терегулов була. Аңа күренүчеләр, киңәшен тыңлаучылар, дәваланучылар, билгеле, аз түгелдер. Әмма аның бөтен уен коралларында шактый чибәр уйнавын һәм үзе дә музыка язуын бик сирәкләр генә белә торгандыр. Миңа да Али Хөсәеновичның пианинода үз көйләрен уйнап күрсәтүен тыңларга туры килде. Нәрсә дим, белгеч булып хөкем итә алмыйм, ләкин аның «Уйлану» һәм «Хыял» дип аталган, ничектер классик романсларны хәтерләткән музыкасын чын ихластан яратып тыңладым. Хирургларның скрипкада уйнауларын мактап яза торганнар иде. Менә рәхим итегез, бездә дә бар икән андый врачлар!

Дәджалның рәссамлыкка кабилияте булган, энесе Али (Габделвәли)нең музыкага зур сәләте бар, димәк, нәселдән килә торгандыр инде бу... Аталары Каргалы төмәне, ә аналары кем? Шуны сорагач, Али Хөсәенович: «Әнинебез саф башкорт кызы»,— диде. Бер ана кулында һәм бер ата карамагында җиде бала үскәннәр.

Али Хөсәенович үзен бик бәхетле кешегә саный. Һәм моның бик җитди нигезе дә бар икән. Ул Ватан сугышын хәрби врач булып, исән-сау уздырган, ә менә сугыш беткәч, илгә кайтыр алдыннан чак-

чак кына үлмичә калган. Германия өстеннән очкан чакта безнең У-2 самолетын ниндидер бер явыз мылтыктан атып төшергән. (Пуля моторына тигән.) Летчик белән бер врач шунда ук һәлак булган, Али Хөсәеновичның аяк-куллары, кабыргалары сынган, башы яраланган һәм госпитальдә үндүрт тәүлек аңына килә алмыйча яткан. Шулай да врачлар аны үлем тырнагыннан тартып алып калганнар. Хәзер инде аңа 80 яшь — чынлап та, үзен бәхетле санарга хакы бар икән шул!

Күпме алар — менә шулар кебек гыйбрәтле язмышлар?!

Килгән хатларда тагын әле башкалар турында да язалар, ләкин мин монда барысын да санап чыга алмыйм, чөнки сүз бик озынга китәчәк. Әйткәнемчә, укучылар минем истәлекләрне үзләренчә тулыландырырга телиләр — моның өчен аларга, билгеле, бик зур рәхмәт!.. Тик хикмәт шунда: истәлек дигән нәрсә ул асылда кешенең үзе күргән, үзе кичергәннәре турында язылган әсәр, аңа бөтен ишеткәннәрне дә сыйдырып бетерү мөмкин түгел (яки бик кирәкләрен генә сыйдырырга мөмкин), шул сәбәпле хатларда язылганнарның барысын да мин файдалана алмыйм икән, укучыларым моны аңларлар һәм гаеп итмәсләр дип ышанам.

«Дәүләкән» өлеше басылып чыккач килгән хатлар да укучыларның әсәрне шулай ук кызыксынып кабул итүләрен күрсәтә. Хатлар төрле яктан һәм төрле кешеләрдән... Минем өчен, мәсәлән, мәрхүм Хәмит дусның ерак Әндиҗан өлкәсендәге бер кышлакта яшәүче сеңелесе Фәридәдән һәм Уфадагы улы Әсгатьтән хатлар алу бик күңелле булды. Алар минем истәлекләр турында ишеткәннәр, бик кызыксынганнар һәм журналны сораганнар — мин, билгеле, аларның икесенә дә «Казан утлары»н җибәрдем. (Фәридәнең язуына караганда, безнең журнал ул торган кышлакка да барып чыккан, ләкин ни сәбәптер юлда аның күп битләре ертылып беткән булган.) Шулай ук Дәүләкән райкомының элекке беренче секретаре иптәш Тартыковтан килгән хат та мине куандырды. Дәүләкәнне яхшы белгән, үзе дә аның турында зур очерк язган кешенең сүзе һәм кайбер төзәтүләре минем өчен, әлбәттә, бик әһәмиятле иде. Янә Алабугадагы Маһинур ханым Фәйзуллинаның бала һәм кыз чакларын исенә төшереп язган бик мәгънәле, җылы хатын алу да күңелле булып калды... Хат язучыларның барысын да санап чыгу кирәк микән? Алар арасында истәлекләр язуның нәрсә икәнен бик яхшы белгән Сәйфи ага Кудаш та, тарихны һәм телне бик әйбәт белүче Йосыф абзый Гәрәй дә, барысын күрергә, укып барырга өлгерүче журналист М. Садыйкова да (Уфадан), тагын укытучылар, укучы яшьләр, пенсионерлар да бар. Һәркайсы диярлек әсәргә карата җылы сүзен әйткән, рәхмәтен белдергән — цитаталар китереп тормасам да, шөт ышанырсыз... Мин аларның һәрберсенә аерым-аерым җавап язарга вакыт арттыра алмадым, шул сәбәпле менә хәзер форсаттан файдаланып, миңа хат язган барлык укучыларыма тирән рәхмәтемне белдерәм.

**ӘМИРХАН ЕНИКИ**

# БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Сорау:**

*Бүгенге әдәбияттагы реалистик һәм шартлы алымнар турында Сез ничек уйлыйсыз, ул алымнарны үз иҗатыгызда ничек кулланасыз?*

**Илдар Юзеев:**

*Бала чакта эти миңа ак бүрек алып кайтты. Башка малайларда да бар андый бүрек, бернис белән дә аерылып тормый. Шулай да берклнне минем шул ак бүрегем малайлар алдында дан казанды.*

*Укытучы абый-апалар мәктәп сәхнәсендә театр куйдылар. Без, малайлар, билгеле инде, бүрекләрне дә салмыйча, иң алда, сәхнә янын-*

дагы идәнгә тезелеп утырдык. Икенче пәрдә башланыр алдыннан, укытучыбыз — «артист» Язит абый сәхнәдән генә минем ак бүрегемне сорап алды да югалды. Пәрдә ачылды. Акгвардеецлар, җырлый-җырлый, авыл халкыннан талап алынган казларны йолкалар. Карыйм: акгвардеец киемендә Язит абый кулындагы каз — минем ак бүрек! Мактанып, күрәсезме диеп, малайларга төртәм. «Кит аннан, нинди бүрек булсын, каз ич ул!» диләр тегеләр. Күпме генә тырышсам да, малайларның ышанасылары килмәде. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә икеләнеп калдым. Соңыннан, Язит абый «каз»ны минем башка чәпәгәч кенә, аның минем бүрек икәненә ышандык. Шул көннән соң малайлар минем үземә түгел, бүрегемә бер чакрымнан сәлам бирә торган булдылар.

Әдәбиятта шартлылык дигәндә, мин шул вакыйганы искә төшерәм. Әдәбият — тормышның нәкъ үзе түгел, ул — чынбарлыкның чагылышы. Ә аны дөрес чагылдыру өчен, язучы шартлы алымнар кулланмый булдыра алмый.

Мин теоретик түгел, шунлыктан, үз тәҗрибәмнән чыгып җавап бирергә уйлыйм. «Тынлык белән сөйләшү» поэмасын язарга мине тормыштагы бер факт этәрде.

...Бер мәктәпнең унынчы класс укучылары 1941 елны мәктәпне тәмамлаган егетләр — фронтовиклар белән очрашырга уйлыйлар. Аларны эзли башлыйлар һәм очрашу көнен дә билгелиләр. Ә очрашуга бер егет тә килә алмый: аларның барысы да Ватан сугышында корбан булган икән!

Бу материал прозаик кулына тап булса, ул шушы вакыйгадан да, бәлки, хикәя язган булыр иде. Поэма язганда, тормыш факты бөтенләй төшеп калды. Әсәрнең алымына ярашлы рәвештә, мин символик образга — Тынлыкка мөрәҗәгать иттем. Балалар әлеге корбаннарның символы — Тынлык белән очрашалар. Бер минут Тынлык, Хиросима Тынлыгы, Гамьсез Тынлык, Җир-ана, Бала телгә килеп, сөйли башлыйлар.

Романтик рухтагы әсәрләр язганда, миңа еш кына символик образлар уйлап табарга туры килә. «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасында Фазылҗанны үз артыннан иярткүче бәндәне — Төн кешесе итеп алдым. «Онытылмас бәет» драмасында Ак Әби, Ак бабайларга контраст итеп, Кара әби образын бирдем. «Кыр казлары артыннан» драмасындагы Борынгы кеше, «Сандугачлар килгән безгә» моңсу комедиясендәге Тимер кеше — символик характердагы образлар.

«Мәңгелек белән очрашу» трагедиясендә исә жанр, геройлар, тел-стиль, сюжет — барысы да фантастик алымга буйсынган, Кешелек алдында торган иң зур проблема: Җирдә, Күктә, Суда сугышны булдырмау, Җирне, Күкне, Кешене саклап калу, Узган, Бүгенге, Киләчәкне бер ноктада очраштырырга омтылу — әнә шундый алымны таләп итте.

Минемчә, шартлы, символик, фантастик алымнарны куллану язучыга катлаулы реалистик чынбарлыкны масштаблырак, гомумиләштеребрәк, аның фәлсәфи асылын бер фокуска туплабрак бирергә ярдәм итә. Әмма һәр язучының тормышны чагылдыру өчен үз алымнары бар. Югарыда күрсәтелгән чараларда мин кулланган алымнарның кайберләре генә...

Язучы нинди генә шартлы алым кулланмасын, укучыларын ышандырырга тиеш.

Укучылар, тамашачылар минем ак бүрекләремне каз итеп кабул иткәннәрме, юкмы — анысы алар иркендә...

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

# СӘХНӘДӘ КАМАЛ I ДИСӘЛӘР...

Рус һәм азербайҗан сәхнәләреннән кайбер үрнәкләр алган татар театры үз нәүбәтендә башка халыкларның иҗат коллективлары формалашуга да ярдәм итте. Башкорт, үзбәк, казах, төркмән һәм таҗик театрларын оештыруда татар артистлары зур хезмәт күрсәттеләр.

Габдулла Камал (сәхнәдә — Камал I) татар театрының бер вәкиле буларак, башка төрки халыкларның театрларын оештыру өчен күп көч куйды. Ул үзе иҗат иткән һәрбер образның эчке хасиятен, фигылен аңларга тырышты, бер вакытта да отышлы образ белән мавыгып, спектакльнең ансамбленә хыянәт итмәде, киресенчә, аны булдырырга тырышты. Безнең театрыбызда үзен генә күрсәтергә тырышкан артистларыбыз да булмады түгел. Г. Кариев мәктәбен үткән артистлар бу «авыру» белән чирләмәделәр. З. Солтанов, Г. Мангушев, К. Тинчурин, Б. Болгарский, Г. Болгарская, Н. Таҗдарова, Н. Арапова, Ф. Ильская һәм бик күп башка артистлар сәхнәдә бербөтен ансамбльдән чыкмый яшәделәр. Бу сыйфатлар Камал I гә дә хас иде.



*Рәсемдә (уңнан сулга): Камал I, Фәйзулла Туишев, артистлар Газиз Монасыйпов, Нуретдин Ахунов.*

Габдулла Камал — Галиәсгар Камалның бертуган энесе. 1893 елның 15 октябрендә Казанда вак сәүдәгәр гаиләсендә туа. Абыйсы тәэсирендә булса кирәк, «Сәйяр» труппасының спектакльләренә йөри. Артистларның уенын мавыгып карый һәм Г. Кариевның тәкъдиме белән 1912—1913 елгы сезонда үзе дә «Сәйяр»да артист булып эшли башлый. Бу чорда аңа абыйсы пьесаларындагы геройларның барысын да иҗат итәргә туры килми, чөнки ул әле яшь һәм тәҗрибәсе азрак була. Камал I рус һәм дөнья классикларының әсәрләрендә дә уйный. Мәсәлән: «Сәйяр» тарафыннан 1913 елны куелган «Мәкер һәм мәхәббәт»тә Президент, «Мөсибәте Фәхретдин»дә Мәхмүт бәк, 1914 елны «Яшенле яңгыр»да Дикой, 1915 елда «Гөнаһсыз гаеплеләр»дә Муров, 1916 елда «Ревизор»да Осип, «Җинаятьче гаиләсе»ндә Монсиньор (монахлар башлыгы), 1917 елда «Трильби»дә рәссам Тофи һ. б. Камал I солдатка алынып берникадәр вакыт труппада булмый. «Кояш» газетасында (1916 ел, 28 февраль, № 924) язылган хәбәргә караганда, артист сугыш мәйданыннан яраланып кайтып озак вакыт госпитальдә ята, гаскәри хезмәткә яраксыз дип табылып, хәрби хезмәттән бөтенләй азат ителә. Газетада аның «Сәйяр»га кайтканнан соң «Ревизор» спектаклендә катнашачагы турында әйтелә.

Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендә Камал I Президент ролен уйный, шунда аның көчле драматик рольләрне башкара алу сәләте ачык күренә. «Сәйяр» 1914 елның 21 мартында А. Островскийның «Яшенле яңгыр»ын сәхнәгә куя. Спектакльнең режиссеры рус труппасының артисты Загорский була. Г. Кәрам

үзенең бер мәкаләсендә: «Артистлар анық өйрәтүеннән күп истифадә[1] иткән булсалар кирәк. Чөнки бу көнгә кадәр уйналган татар пьесаларында мондый иттифак[2] вә интизам[3] күренми иде»,— дип яза.

1915 елның 18 декабрендә А. Островскийның «Гөнаһсыз гаеплеләр» спектакленең премьерасы була. Бу пьеса — ике-өч еллар элек Гайшә Терегулова тарафыннан тәрҗемә ителгән булса да, сәхнәгә кую өчен артистлары җитмәгәнлектән, «Сәйяр» аны яшь көчләр үсүгәч кенә сәхнәгә куя ала.

Бу спектакль турында матбугат та югары бәя биреп, артистларның үз рольләрен тирәннән аңлап, зур игътибар һәм җаваплылык белән эшләүләре турында яза.

«Гөнаһсыз гаеплеләр»... шундый осталык белән уйналды ки, Казан сәхнәсендә бик сирәк әсәр болай нык тәэсир калдыра алгандыр»,— дип яза Шәһит Әхмәдиев «Йолдыз» газетасында[4]. Бу спектакльдә Г. Кариев — Дудукин, К. Тинчурин — Незнамов, Б. Болгарский — Галчиха, Габдулла Камал — Муров, Г. Болгарская Кручинина рольләрен башкаралар.

Ә «Яшенле яңгыр»да Камал I башкаруында Дикой тупас, кыргый, деспот холыклы кеше, кара искелекнең вәкиле булып гәүдәләнә.

Беренче империалистик сугыш елларында провинциаль театрларның репертуары сай фикерле, эчтәлексез комедияләр, водевильләр белән тула, ә классик драматургия сәхнәдән кысрыклана. «Провинциаль театрларның хәзерге эшендәге үзенчәлеге шунда ки, аларның репертуарыннан Островский бөтенләйгә төшерелеп калдырылган»,— дип язды «Театр и искусство» журналы. Башкала һәм провинциаль театрлар репертуарларыннан Островский төшереп калдырылган бер вакытта «Сәйяр» труппасының Островскийга мөрәҗәгать итүе, әлбәттә, татар театры тарихында горурланырлык күренеш.

Тәҗрибәсе арткан «Сәйяр» 1916 елның март аенда Н. В. Гогольнең «Ревизор»ын сәхнәгә күтәрә. Бу комедиянең дә режиссеры артист Загорский була. Бу театр алдына яңадан-яңа иҗади бурычлар куя. һәм алар уңышлы гына үтәлә дә. Аерым образларның бирелүендә бу бик ачык күренә. Камал I бирәдә Осип ролен ихлас мавыгып иҗат итә. Нәтиҗәдә бу образ бик җанлы һәм ышандырырлык итеп башкарыла. «Бу оста артистыбызны быел сәхнәдә күрүебезгә бик мәмнүн булдык. Үз кадерен үзе белә торган иренчәк, шапшак Осипны Камал максатка бик якынлашып, матур вә көлдергеч итеп уйнады. Зарланып килгән хатыннарны ул, бер дә ашыкмыйча гына, салкын канлылык белән генә, якаларыннан эләктереп ишек артына чыгарып куйды. Бу күренеш бик табигый, дөрес һәм көлке булып чыкты»,— дип язды «Аң» журналы (1916 ел, 10 март саны).

1916 елның 20 гыйнварында «Сәйяр» Н. Нәримановның «Надиршаһ» исемле трагедиясен әзерли. Бу трагедия үзенең үткен фикере, теле һәм калку образлары белән артистларга дәртләнеп эшләргә мөмкинлек бирә. Спектакль аша артистлар шаһ һәм әмирләрнең мәкерлелеген, комсызлыгын фаш итәләр. Г. Кәрам «Аң» журналында артистларның уенына карата:

«Ул (Кариев) гайрәтле юлбасар Надирны да, яхшы йөрәкле, әмма вәсвәсәле шаһны да гаять дөрес вә тулы итеп иҗра[5] итә алды. Габдулла Камал башта тәхеткә наил[6] булган Хөсәен ханны ничек дөрес вә аңлап тәшхис[7] итә алса, соңгы пәрдәдә Надиршаһның якыны вә гаять акыллы вәзирләреннән булган Мирза Мәһдине дә бик хакыйкый вә мәгънәле бер рәвештә күрсәтә алды»[8],— дип язды.

«Сәйяр» 1917 елның 19 гыйнварында тамашачыларга С. А. Найденовның «Ванюшин балалары» дигән драмасын күрсәтә.

«Ванюшин балалары» ап-ачык тенденцияле пьеса булу белән бергә, зур мәүзугъка[9] язылган әһәмиятле бер әсәрдер. «Ванюшин балалары» русларда гына түгел, бездә дә бар һәм бик күп алар. Гаилә эчендә япандагы үлән кебек ялгыз үскән, үз язмышына тапшырылып тәрбия ителгән балаларның барысына да «Ванюшин балала-

---

[1] Истифадә — файда.
[2] Иттифак — ансамбльлек.
[3] Интизам — тәртип.
[4] «Йолдыз», 1915 ел, 20 декабрь.
[5] Иҗра — иҗат.
[6] Наил булу — ирешү.
[7] Тәшхис итү — тудыру.
[8] «Аң», 1916 ел, № 24.
[9] Мәүзугъ — тема.

ры» дилэр. Бу спектакльдэ Константин ролен уйнаган Камал да беренче ролен тигез генэ алып барды» [1],— диелэ рецензиядэ. Дөрес, спектакльлэргэ язылган бу рецензиялэрдэн генэ чыгып Камал I рольлэрен ничек башкаруы турында тирэн фикер йөртүе читен. Лэкин шунысы ачык: бу рольлэр аның киң пландагы иҗат кешесе икэнлеген күрсэтэлэр. Труппага ярдэм итү максаты белэн ул 1918 елның көзендэ М. Мутин белэн Астраханьга барып чыга. Биредэ ул атаклы азербэйҗан артисты Хөсэен Гарэблинский белэн очраша һэм Астрахань татар труппасы артистлары белэн спектакльлэрдэ катнаша. Алар бергэлэп А. С. Сухово—Кобылинның «Кречинский туе», Ф. Шиллерның «Юлбасарлар», аннан тыш «Надиршаһ», «Яшь гомер», «Банкрот» кебек эсэрлэрдэ уйныйлар. Сэхнэдэ Камал I, дисэлэр, гадэттэ, зал шыгрым була.

Башкорт театрының элекке режиссеры Мөкэррим Мэһдиев «Театр турысында» исемле китабында Камал I хакында түбэндэге сүзлэрне яза: «Колчак тар-мар ителгэч, Омский сэяси бүлеге каршында эшлэгэн труппа кире кайтарылып эшкэ башлый. Труппа Бөгелмэдэ вакытта, артист Камал I чакырылып алынды. Уфадан Г. Саттаров, Мөслимевлэр, Чилэбедэн Ш. Шамильский, И. Элмэшевлэр кушылды. Баш режиссер итеп Камал I билгелэнде. Труппаның составы зурайгач, репертуары да артты. Галиэсгар Камал эсэрлэре, Гафур Колэхметовның «Ике фикер», «Яшь гомер» дигэн эсэрлэре бик күп куелды. «Ике фикер» эсэрендэ Кызыл фикер ролендэ — Г. Казанский, Кара фикер — Камал I, Даут ролендэ — И. Элмэшев, кыз ролендэ М. Мирвэлиева уйный»,— дип яза.

Гэрчэ Камал I Уфада вакытлыча эшлэсэ дэ, Уфаның культура тормышында матур эз калдыра. Г. Кариевнең шэкерте буларак, ул остазының реалистик традициялэрен дэвам итэ. Чорның талэбенэ җавап бирердэй классик эсэрлэрне сэхнэлэштерэ.

Без бу репертуардан Камал I нең Уфа сэхнэсендэ асылда «Сэйяр» репертуарын кабатлавын, Кариевнең реалистик традициясен алып килүен күрэбез. Ягъни Кариев шэкерте В. Мортазин-Иманский тарафыннан Стэрлетамакта 1920 ел башында оештырылган башкорт труппасы 1922 елны Уфага күчеп килгэнче үк инде Уфа тамашачылары демократик татар драматургиясендэ тэрбиялэнгэннэр дигэн сүз. Камал I Уфадан киткэч, аның эшен бераз вакыт Нури Сакаев дэвам итеп 1920 елның сентябрь аенда Уфа сэхнэсендэ беренче мэртэбэ М. Фэйзинең «Галиябану» драмасын куя [2]. Бу спектакльдэ Галиябану ролен — Маһирэ Мирвэлиева, Хэлилне — Г. Казанский, Исмэгыйльне Ш. Шамильский башкаралар.

Төркстан фронтының политик бүлеге каршында берничэ труппа төзелэ. Бу труппаларның эшенэ В. М. Фрунзе, В. В. Куйбышев аерата эһэмият биргэн һэм ярдэм күрсэткэн. Шундый фронт труппаларының берсенэ Камал I җитэкчелек итэ.

1920 елның көзендэ Төркстан Наркомпросының театр бүлеге тарафыннан Ташкентта үзбэк һэм татар труппаларын төзү һэм ныгыту чарасы күрелэ. Шулай итеп, белемле, тэҗрибэле артист һэм режиссер Габдулла Камал үзбэк театрына профессиональ театр культурасын алып килэ.

Камал I 1921 елның октябрь аенда исэ Оренбургның «Шэрык» исемендэге театрында баш режиссер булып эшли башлый. Ул «Хезмэткэ мэдхия», «Хөкемдэ хаталык», «Җиңел хезмэт», «Тормыш уен түгел», «Революция», «Мэкер һэм мэхэббэт» пьесаларын куя. Лэкин декабрь аенда бу театр бинасы яна. Габдулла Камал Урта Азия реввоенсоветы карамагындагы агитпоезд белэн юлга чыга. Труппа составында Фатыйма Камалова да була. Труппа төрле шэһэрлэрдэ «Көнче ир», «Галиябану» пьесаларын куя. Ниһаять, төрле авырлыкларны баштан кичереп труппа Ташкентка килеп җитэ. Монда татар артистлары К. Маркс исемендэге труппада эшли башлыйлар.

Шул вакытларда Камаллар гаилэсендэ зур бэйрэм була. 1922 елда аларның кызлары туа. Кызларына Гэүһэр дип исем кушалар. Бүгенге көндэ Гэүһэр Камалова — РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы.

Габдулла Камал соңгы елларында Татарстан радиокомитетында эшли. 1933 елның җэендэ, абыйсы Галиэсгар Камал вафат булганнан соң, бары бер генэ атна яшэп кала.

**ХӘСӘН ГОБӘЙДУЛЛИН.**

---

[1] «Кояш», 1917 ел, 19 январь.
[2] «Шэрык ярлылары». 1920, 26 сентябрь.

Сибгат Хәким

# АККОШ КҮЛЕНДӘ САГЫШ, МОҢ...

Туфан турында истәлек язу читен, бик читен. Я яз, я язма. Аны фәлән төштә очраттым, күрдем дип кенә үтеп китеп булмый. Туфанны бүлгәләп булмый. Ул бер бөтен. «Зур шәхес, зур язмыш» дигән сүзләрне Туфанга карата курыкмый кулланырга мөмкин.

Исемнәр — утраулар. Татар әдәбияты исемнәр — утраулардан тора. Син аларга әллә ничә тапкыр якынаясың, һаман серле алар. Тукай — ачылып бетмәгән аерым утрау. Татар әдәбияты катлау-катлау. Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал... Бер катлау. Йөзендә берөзлексез Тукай шәүләсе сизелеп торган буын. Аралар якын. Тукай кайдадыр якында басып тора. Такташның ялкыны-шәүләсе төшкән икенче катлау — Туфан, Җәлилләр буыны... Өченче катлауга Туфанның еллар аша үзенең мәһабәт шәүләсе ятты шикелле. Катлаулар калын, нык. Һәр буын үзенә лаек буын үстергән. Мин Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирханнан кала шул буын язучыларының барысын да күреп калуым белән бәхетле. Татар әдәбиятының бөек бер чорын күреп калдым. Әдәбиятка алып кергән хис тә шулардан йоккан горурлык хисе булгандыр. Мондый буыннарның койрыгына тагылсаң да ярый. Тагылдым, Җәлилләр, Кутуйлар, Туфаннарга тагылдым.

Туфанның тормышы турында уйлый башлау белән, илнең төрле төшләрендә кинәт учаклар кабынды. Шул учаклар янында иелеп утырган, кулына куен дәфтәре тоткан юлчыны күз алдыма китердем. Идел, Кама буйларында, Урал таулары итәгендә, Урта Азия чүлләрендә, Себер далаларында кабынды ул учаклар.

Туфанның миңа бүләк иткән бер китабында: «Синең «Учак» янындагы кичләрдән бирле дәверләрне бергә кичкән елларыбызның бер истәлеге бу шигырьләр сиңа, Хәким» — дип язылган. Шул учаклардан башларга булдым бу истәлек язмаларымны.

Үз гомеремдә Туфан белән бергә ике учак яктык. Берсе Бөек Ватан сугышы алдыннан, 1938—39 елларда, Казан артында, Өнсә авылы кырында. Кайчан да булса Туфан белән Өнсәгә барып чыгармын дип уйлаганым юк иде. Бу очракта мин иярттем, минем яшьлек ияртте Туфанны. Ә минем үземне — мәхәббәт. Өнсә авылы читендәге медпункт, яшь кыз сәбәпче. Ул да шигырьләр яза. Минем егет чак. «Совет әдәбияты» журналында эшләп йөргән чак. Безне шигырь таныштырды. Ял көннәрендә Арча поезды белән Бөрелегә чаклы барам да аннан урман эченнән җәяүләп китәм. Бу сигез-ун чакрым ара минем өчен берни түгел. Авыл малаена юл — шигырь, юл — җыр ул. Иртән эшкә дә кайтып өлгерәм. Күп таптадым мин бу ике араны. «Пар ат»ны шул медпунктта яздым. Берсендә Туфанны ияртгем. Авыл, халык, Сабан туе дисәң, Туфанны тиз кабындырып була. Танылган шагыйрь, миннән күп олы, семьялы... Туфан — юл кешесе. Юлга аны төнге икедә уятсаң да җыенып чыгып китә. Әйбәт ягы шул: акча сорамый, машина, ат сорамый, ашарга сорамый. Туфан — бала. Дөньяга килгән, яратылган, миңа шул җиткән, шуның өчен бу тормышка рәхмәт дигән кебек яши бирә...

Июнь ае. Арыш серкәдә. Сабан туйлары вакыты. Өнсәгә без арыш араларыннан кичке эңгердә генә барып кердек. Без авылдан чыккан кешеләр. Һаман шул табигать тарта. Туфанның учак ятканын шунда белдем. Кырда учак ягу турында ул сүз

кузгатты. Ләкин бер шарт белән, шушы кечне истә калдыру өчен икебез дә «Учак» дигән шигырь язарга булдык. Мин үз «Учагым»ны яздым.

Юл буенда ялгыз бер ут яна,
Кем ял иткән анда, кем яккан!
Туктап мин дә шунда чыбык салдым,
Аерылуы кыен учактан...
Ташлап китәр идем, бик кызганам,
Сүнәр көйрәп торган күмере.
Яңадан соң аны кем тергезер
Дәвам итсен өчен гомере.
Шигырь итеп яздым сине, учак,
Син күпмегә кадәр яшәрсең!
Тиз сүнәрлек булсаң, мин янында,
Кабызырмын, миңа дәшәрсең.

Учак — шигырь, учак — гомер. Озак янармы ул? Туфанның иң күтәрелгән чагы. «Зәңгәр бүре» авторы. «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Бибиевләр» авторы. Такташ та түгел, Маяковский да түгел. Үзе баскычлы. Хабуллар, Чапыйлар традицион шигырьгә сыймыйлар, эре сөякләләр. Рифмалар чатлы-ботлы, шигырьдән төртеп чыгып торалар. Шигырьләр калын тавышлылар, Хабул сыман җырланудан бигрәк, сөйләү өчен язылганнар. Җөмлә-фразлар халык теленнән ишетелгәнчә шигырьгә салынган. Образлар Уралның үзенә тиң. Мартеннар арасында Минап, Хабул шикелле кешеләр кирәк. Туфан поэзиягә иске традицияне бозып килеп керде. Урал тудырган бердәнбер татар шагыйре. Урал Туфанны тудырды, Туфан — Уралны. Уралдан «пролетар шагыйре» исемен күтәреп йөргән тагын кемнәрдер бар иде. Алар «Урал эскизлары» фонында юкка чыкты. Урал хәтле Уралны үзенеке итте Туфан. Шагыйрьләр Тамбовтан, Оренбурдан, Уралдан дип йөртелә башладылар.

Учак янында Туфан шул елларын искә төшерде, Уралын сагынды. Шигырь телгә килде.

Кара сыер тесле кара төнне
Кемдер суйды:
Ялкынлы кан китте бугаздан.
Домналар ул,
Вулкан уянган күк
Йолдызларга пожар сузалар.

Ул «пожар»ның шәүләсе Өнсә кырларына төште, минем кечкенә «Учак» бөтенләй югалып калды. Туфан күктән йолдызларны эзләргә ярата: Җидегән, Казык йолдыз... Өнсә күгендә ай.

Тәрмә...
Таш коймада сакчы кебек
Ай йөренә
Себер күгендә.
Айлар үтә,
Айлар үткән саен
Ристан гомерен сүтә бу тәрмә...

Учакны туктаусыз актара, болгата, эзли. Нәрсә эзли?

Аякта ботинка. Башта кепка. Озын чәч-ял. Гомергә ябык. Гомергә «суык аяк», гомергә «Брамат». Өнсә кырында безнең учакның көйрәп күмерләре калды. Минем яшьлекнең башы. Туфан гомеренең уртасы. Ул «Учак» картая төшкәч, тагын минем «Таныш әянкеләр»гә килеп керер.

Күбәйде миндә дә тутлар
Сездәге тутлар кебек,
Ул тутлар учакта сүнеп
Бетмәгән утлар кебек...

Бу юллар соңыннан, күп еллар узгач туган шигырь юллары. Алда минем әле туй тора. Өнсәдән — туйга!

1939 елның 31 декабре. Минем «Пар ат»ның Казанга кергән елы. Яшь шагыйрь Хабра Рахманның «Чәчәк ява» җыентыгы белән поэзиягә юл ачкан елы. Яшь шагыйрь Әгъзам Камалның «Чәчәк сатучы кыз»ы дөньяга килгән ел. Никздәр оптимизм: шигырь китаплары «Чәчәк»тән башланып китә. Тагын ике оптимист яшь шагыйрьне онытa алмыйм: Вәдүт Мифтахов һәм Мансур Гаяз. Вәдүт Питрәчтән, «Марс» колхозыннан килеп йөри. Гаяз — Бөрәңге районыннан. Өметлеләр, талантлылар. Татар поэзиясенә җиң сызганып эшләргә, иҗат итәргә килүчеләр. Хабра Рахман 1941 елның көзендә Мәскәү янында барган каты сугышларда һәлак була. Әгъзам Камал 1941 елда Балтик буеннан чигенгәндә яраланып үлә. Батальон комсоргы Мифтаховның атакада гомере киселә. Мансур Гаяз да Ватан өчен гомерен бирә. Җылы, йомшак күңелле лириклар, оптимистлар. Һәркайсының тавышын ишетәм, елмаюларын хәтерлим. Кайберләренең архивымда һәлак булыр алдыннан язган хатлары ята. Архивта яткан хатлары белән үзләрен күргән кебек очрашам. Хат кәгазьләренең саргылт төсе уйларымны ерак елларга, фронтларга алып китә. Күп иде алар, татар әдәбиятының булачак алмашы. Минем туй алды кешеләре, минем буын...

Үзенең мең еллык борынгы традициясенә таянган, Октябрь белән рухланган, зур идеаллар белән дәртләнгән татар әдәбиятының бу чоры, өлгергән шушы чоры, минем яшьлекнең туена үзенең олы вәкилләрен җибәргән чоры күңелдә озак сакланыр. Канат куелган әдәбият. Бер иңбашыннан Горький сөеп сыйпаса, икенче иңбашыннан Фадеевлар сөеп сыйпаган әдәбият. Рус һәм Көнчыгыш әдәбиятларының зур вәкилләре белән эш иткән әдәбият — Такташларның поэмалары шулар исеме белән кабынып биек күтәрелгән. Туфаннары чүлләр аша Гафур Голәмнәргә ашкынган. Җәлилләре, соңыннан авыр язмышларында шулар рухы кирәк буласын тойган шикелле, Александр Фадеевлар, Павло Тычиналар белән дуслашканнар. Киң колачлы, интернационалист әдәбият. Арага зур борчулар килеп керсә дә, сау калган.

Туй көне дә аның ниндидер күз ачкысыз буранлы көн иде. Әллә бу туйлар гел шулай буранлы көннәрдә була микән. Бала чакның кышы, каты бураннары, атлар, кыңгыраулар минем туй көнне хәтердән яңадан бер тапкыр дулап, чыңлап узды. Минем бөтен язмыш Тукай белән бәйләнгән ахры. Туем да Тукай урамында, нәкъ Мехчылар клубына каршы йортның капкасыннан керергә кирәк. Буранда тапмаслар дип капка төбендә үзем басып тордым. Бернинди шартларда да күңелен төшерми торган шат йөзле Кутуй буран эченнән килеп чыкты. Башны куртка якасына тыккан, үз дөньясына чумган Туфан күренде. Муса Җәлил Әминә ханым белән көлешеп узды. Җәүдәт Фәйзи җитди иде, чөнки мин аның шул көнне Тукай клубында үткәрелергә тиешле иҗат кичәсен боздым. Маннур: «Кутуй бармы?» — дип сорады да, кире китәргә теләп, капка төбендә тәмәкесен тартып, уйланып торды... Туй алдыннан шул турыда бер подвал мәкалә язып, «Кызыл Татарстан»да бастырган Гази Кашшаф түрдә. Янында баҗасы Әхмәт Исхак. Йөзендә һәрвакыт җиңел юмор сызыклары беленеп торган Мирсәй Әмир. Тагын кемнәр? Күп иде. Арада Фатих Кәрим генә юк... Тышта буран котырды, шомлы буран. Мәҗлеснең башында Кутуй, ул һаман сөйли, сүз бирә, тыштагы буран белән ярыша кебек. Туфан һәрвакыттагыча дәфтәрен, авторучкасын чыгарып, бернәрсәгә исе китмичә яза. Туфан дип эндәшкәч, бер күтәрелеп куя да тагын онытыла. Тиз арада язып ташлаган экспромтлар яңгырый. Өчесе өч характер. Муса да характеры белән тыныч кеше. Ләкин ул кинәт шаркылдап көлеп җибәрә. Муса...

Җәен Кабан күле артындагы лагерьга солдатлар белән очрашырга бардык. Муса, мин, әлеге туйдагы яшь кыз очраштык, шигырьләр сөйләдек, кичкә табарак кайтырга чыктык. Җәй, болын, сукмак. Настроение әйбәт, күңел күтәренке. Арада яшь кыз. Күрәсең сүз белән мавыкканбыз, болытның өскә килгәнен сизми дә калганбыз. Кара болыт, яшенле болыт. Йөгерәбез. Яшь кыз алда, Муса уртада, мин арттa. Муса кызның туфлиләрен ике кулына күтәргән килеш йөгерә. Ике туфли яшен яктысында ике шәмгә охшап китә. Кара болытның нәкъ каршына, хәвефле яшеннәрнең эченә йөгерәбез... Муса шул күренешне туйда көлә-көлә искә алып үтте. Көлке дә, гаҗәп сәер дә. Сугышның якынлашканын белгерткән шомлы күренеш иде бу. Якынлаша. Мин, запастагы офицер, хәрби сборларда моны күңелем белән яхшы тоя идем. Бу туй —

сугыш алды туе. Шатлыклы да, үкенечле дә. Тышта буран дулый. Шыксыз декабрь бураны дулый, Туфан кәлми дә, елмаймый да... Минем «Пар ат» ул туйдан кире чыкмады... Соңгы очрашу. Язмыш безне Бөек Ватан сугышы алдыннан махсус очраштырды шикелле. Яшьлек белән соңгы очрашу. Фронтларга таралдык. Мин ул туйдагы настроениены соңыннан, инде язмышлар ачыклангач, шигырьдә әйтеп бирергә теләдем.

**Минем сугыш алдындагы туйда**
**Хәсән Туфан туйны ярды соң!**
**Бар тавышка: «Ачы, ачы!»— диде,**
**Сизгән кебек ачы язмышын.**
**Муса Җәлил аннан басты торып:**
**«Шампанский, Хәким, ач элек...»**
**Ачтым... «Ачы»,— диде, шуннан бирле**
**Яна йөрәк, яна ачынып.**
**Тукайдагы тәрәзәләр минем**
**Тавышыннан Гадел Кутуйның**
**Торды зыңлап, соңгы кенемәчә**
**Тик ачысы калды ул туйның.**
**Туйдагыча кабатланды бар да,**
**Кабатланды «ачы», чиратлар...**
**Колагымда тавышлары яңгырый,**
**Бер-берсеннән ерак зиратлар...**

Кутуй белән Мирсәй Әмир туйда бүләк иткән кул сәгате фронтта кинәт туктап калды, күңелгә шик керде, борчу керде. Иптәшләр кайда, кемнәр бар, кемнәр юк?

...Икенче учакны 1960 елларда Тымытык янында, Ык буенда яктык. Туфан белән Әлмәт, Лениногорск якларында күп булдык. Әлмәтнең шаулаган чагы. Нефть кузгаткан шау-шу. Әлмәттә язучыларның иң күтәрелгән чоры. Гамил Афзал, Сәҗидә Сөләйманова, Рафаэль Төхфәтуллиннарның иҗатта кайнаган чагы. Кайчакта шулай хезмәттәге энтузиазм белән әдәбияттагы энтузиазм ничектер бергә кушыла, кешеләрнең күзгә күренеп талантлары ачыла. Казан үзе шул якларга омтыла. Туфанны, мине юлга чакырган нәрсә дә шул нефть, шагыйрьләр шәһәре — Әлмәт. Көндез семинарлар, кич клубларда очрашулар. Гәрәй Рәхимне без узып барышлый яшьләр семинарыннан тартып чыгардык шикелле. Ә Ыкта нәрсә калган? Ыкка җилкендерүче кеше ата балыкчы Мәхмүт Хәсәнов иде. Октябрь, җилсез, йомшак, җылы. Ык әрәмәләре тартты безне. Мәхмүт борчакны күп сипсә дә, балыгы әллә ни эләкмәде, әмма җәелеп, тулып яткан Ык үзе, болыны, бай табигате безне ниндидер хыялый, шигъри дөнья эченә алып керде. Мәхмүт безне балыкка гына дип алып килгәндер. Әмма мин аңа шушында очраштырган өчен эчемнән рәхмәт укыйм. Ике учак арасында еллар, нинди еллар, нинди вакыйгалар. Мин дә шактый күргән кеше, Ватан сугышын узган кеше. Туфан миңа караганда да күбрәк кичергән, күбрәк татыган тормышның ачысын. Тормышта зур тетрәүләрдән соң шундый бәхетле минутлар була, ул минутларны табигать эчендә ялгыз калып яңадан бер тапкыр кичерәсе килә. Дуга сугышыннан исән чыккач, мин кыр уртасында дөньяга шулай гаҗәпләнеп карап тордым. Мондый тын урын да бар икән җирдә! Сугыштан соң Арча белән Әтнә арасында бәрәңге утыртып ятучыларны күреп, онытылып тордым. Кешеләр гап-гади эш эшлиләр, сугышмыйлар, бәрәңге утырталар. Кинәт Ык тынлыгына юлыккан Туфанга да бу сихри дөнья шулай сәер тоелгандыр дип уйлыйм. Ярлар тын. Әрәмәләр тын. Әрәмәдә гөлҗимеш, балан. Балыкчылар...

Туфан учак ягарга әзерләнде. Изге бер эшкә тотынган кебек кереште. Куак араларында озаклап йөрде, гөлҗимешләрнең, баланнарның башларыннан сыйпап үтте, алар белән сөйләште...

**Ике кулын артка куйган көйгә**
**Үтеп бара айлы аланны.**
**Иркәлисе килә аның шунда**
**Юл буенда үскән баланны...**

Иплап чыбык-чабык сындырды, бөтен шартын китереп учак якты. Күмерләре төшкәч, учакның өстенә ук иелде, бөтен гәүдәсе белән шундый иелде, утка мена-менә авар төсле иде. И актарды утны, и болгатты утны, минем хәтта кычкырасым килде: Туфан, утта янасың бит! Ахак-күмерләр эченнән нәрсәдер эзли иде ул, нәрсә эзли? Нәрсәне югалткан?

Аклы кимемен кигәндер,
Бәлки кайтыр дигәндер,
Зәңгәр карны ера-ера
Вокзалларга килгәндер,
Бәлки табылыр дигәндер...

Ык буе. Төн. Йолдызлар һәм Туфан. Галәм һәм Туфан. Эзли, интегә, таба алмый.

Әй син, йөрәк,
Сансыз йолдызларның —
Матдәнең бер җанлы кисәге!
Каян алдың сөю, сагынуларны,
Каян алдың син бу хисләрне!!

Учаклар... Өнсә кырында, Каракалпакстан чүлләрендә, Себердә. Ыкта. Күкта хисапсыз йолдызлар. Җидегән, Казык йолдыз. Шул йолдызларны ничек табарга икәнен бала чакта әнисе өйрәткән. Туктаусыз сәяхәт кылган елларында аңа шул Казык йолдыз кирәк булган.

Илдә нилар бар икән:
Юллар зәңгәр кар микән!
Һавадагы алсу шәүлә
Пожар микән, таң микән!
Илдә нилар бар икән!

Туфан иҗатында ике чор, ике биеклек. «Урал эскизлары» чоры һәм алтмышынчы еллар лирикасы. Икесе дә өйрәнү өчен кызык, икесе ике төрле стиль, алым, форма. Ике чорда да фәкать Туфан.

Туфанны мин 1931—32 еллардан бирле беләм. Күреп, укып беләм. Журналга китергән шигырьләр аның аша уза. Такташ юк. Аннан соң иң зур шагыйрь, һичшиксез, Туфан. Минем өчен күптәнге шагыйрь. Әйтерсең, дөньяның үзе белән бергә яратылган. Дөньяны туфан баскан дәвердә яратылган. Исеме күңелдә шундый хис калдыра...

Мин Көнчыгыш педагогия институты студенты. Бу институтка татар әдәбиятының шул вакыттагы бөтен күренекле кешеләре тартылган иде. Әдәбияттан тәнкыйтьче Галимҗан Нигъмәти, тарихтан Фатих Сәйфи-Казанлы, телдән — Гыйбад Алпаров, Сәләх Атнагулов, Шиһап Рамазановлар... Татарстан Язучылар союзының яртысы диярлек шул институттан. Кутуй, Сирин, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Идрис Туктаров, Гали Халит, Сөббух Рафиков, Ибраһим Салах... Чувашстаннан Хузангай, Шавлы. Безнең факультетта хәтта Үзбәкстанның яшь шагыйрьләре дә укый иде. Педагогия институты татар культурасына талантлар җитештереп торучы рухи чыганакка әйләнде. Миңа, бер авыл малаена, чын мәгънәсендә яңа дөнья иде бу. Галимҗан Нигъмәтиләргә, Алпаров, Мөхәммәтхан Фазлуллиннарга гомер буе рәхмәт укыйм.

Мин бер язучы кулыннан икенче язучы кулына күчеп, пединститутка эләккән кеше. Минем юл башында Кутуйлар тора. Кутуйлар «Дим буе»ның авторы Садри Җәлалгә тапшырды, Садри Җәлал үз чиратында рабфактан институтка озатты... Институтта иң популяр факультет — тел-әдәбият факультеты. Дәрәҗәсе зур. Әдәбиятка таләпләр зур. Галимҗан Нигъмәти безгә күбрәк Такташ белән Туфанны тәкъдим итә иде. Татар совет поэзиясенең төп ориентирлары шулар... Шулар янында Кутуйлар, Җәлилләр... Авылга ялга кайтсам, укытучылар чолгап ала: «Кави нәрсә яза? Кутуй тирәсендә нигә шау-шу? Туфан ник ишетелми!» Казанда барган әдәби хәрәкәт укы-

тучыларның сүз үзәгендә. Әдәбият белән шул хәтле нык кызыксынган башка чорны белмим. Синең бөтен язганың, адымың, хәрәкәтең укучыга мәгълүм. Шул кулны тоеп торасың, син бар, син кирәк, син үсәргә тиеш, шул кешеләрнең җылы сүзләрен акларга тиеш. Әдәбиятка кайчакта менә шушы җылы җитми кебек.

Таләпләр югары. Язучылар союзында Әхмәт Фәйзинең «Флейталар»ын укып тикшерү истә калган. Әхмәт Фәйзи инде берничә җыентык чыгарып өлгергән автор. Әдәбиятта үз исеме бар. Ләкин аңа «Флейталар» кебек поэма җитми иде әле. «Флейталар» иңрәп, елап, чыңлап туган әсәр. Ялгыз бунтарьның революцияне кабул итүе. Әхмәт Фәйзинең үз шәхесе, үз биографиясе аша узган әсәр. Маяковский белән Әхмәт Фәйзи арасында туган әсәр. Әхмәт Фәйзинең барлык калган әсәрләрен ятсынып торган поэмасы шушы «Флейталар». Яңгырашы, ритмы өзек-өзек, кисәк-кисәк, чигәсенә пистолет куйган бунтарьның сулышы кебек. Әхмәт Фәйзине чын шагыйрь итеп «Флейталар»дан соң таныдылар... Икенчесе прозада. Мирсәй Әмирнең «Агыйдел» повесте белән дә шундый ук хәл булды. Мирсәй бик күп авыл хикәяләре язган кеше. Аның да әдәбиятта исеме бар. Әмма шул исемгә әле нәрсәдер җитми. Мәсәлән, татар зиратында кабер ташына «Әдип Фатих Әмирхан» дип язылган. Монда «Әдип» сүзе артык. Фатих Әмирхан. Башка бернәрсә дә өстисе килми. Такташ, Туфан да шул килеш әйбәт. «Агыйдел» ике сүздән торган «Мирсәй Әмир» исемен тәмам раслап печать сукты. «Агыйдел» аны художник итеп танытты. Талантны талантсыздан аера белгәннәр, һәркемне үз урнына куя белгәннәр. Сугышка кадәр әдәбиятта автор чиләнеп тудырган исем генә бар иде. Шагыйрьләрдә бер орден, бер медаль. Маннур «орденлы шагыйрь». Нур Баян «медальле шагыйрь». Туфан бу нәрсәләрдән бөтенләй читтә. Тормыш, яшәү, иҗат — иң зур бүләк!

Татар шагыйрьләре берсен-берсе үстереп баралар шикелле. Гел катлаулана баралар. Такташтан соң Туфан. Туфаннан соң Җәлил. Җәлилдән соң Фатих Кәрим. Кайсы зуррак дигән сорау да туа миндә кайчакта. Бу фикер 1983 елның 15 февралендә Муса Җәлилгә мемориаль музей ачканда күңелгә килде. Алда Такташ бар. Алда Туфан бар. Алда Фатих Кәрим бар. Безнең поэзия талантларга бай да соң дип куйдым эчемнән. Җәлил башы гына әле.

Такташ. Туфан. Казанга кергәндә үк зур булып кергән бу шагыйрьләр. Берсенең артында Төркестан сахралары. Икенчесенең артында эшче Урал. Бөек Октябрь. Тормыш үзе тудырган шагыйрьләр. Зур социаль чорларның авазы, яңгырашы булып туган шагыйрьләр. Алар тормышның ихтыяҗы. Аларсыз заман тулы булмас иде. Егерме дүрт яшьтә «Гасырлар һәм минутлар». Егерме җиде яшьтә «Урал эскизлары». Давыллы чор тиз өлгерткән шагыйрьләрне. Кубесенең беренче шигырьләре матбугатта унөч яшьтә басылган. Исәнбәт, Бабич, Сәйфи Кудаш, Җәлил, Әхмәт Фәйзи... Такташ унбишләрдә дөньяга бәреп чыккан. Мин — Язучылар союзына кабул итү комиссиясенең председателе буларак еш кына шул турыда уйланам. Ник соңлап киләләр яшьләр хәзер әдәбиятка? Ун елга бер дә очрамый егерме яшьлекләр. Хәзерге мәктәпләр элекке мәктәпләрдән күп югары бит!

Ык буе. Төн. Учак. Туфан. Туфанның шагыйрьлеген күрергә теләсәң, син аны галәм белән икәүдән-икәү генә калдыр. Башка берәүләр мондый киңлектә бөтенләй югала,— Туфан үз кеше, ул галәмнеке, бергә кушыла, аңа галәм уртасында басып тору килешә, бер-берсен алар күптән беләләр шикелле. Бу яктан Леонид Мартынов белән Туфан бертуганнар. Күп нәрсә уртак. Мартыновка Такташны түгел, Туфанны тәрҗемә итәргә кирәк булган. Болар бар да учак янындагы кичке уйланулар.

Аккош күлендәге дачасында диванга кырын ятып уйланган чакларында, күңеле бер ачылып китеп истәлекләргә бирелгән чакларында, көзге тын кичләрдә янында тыңлап утырырга ярата идем. Без аның белән күптән таныш, фикердәш, күп фикерләр уртак, шуңа күрә сөйли, хисләргә бирелә. Туфанның тормышы, биографиясе белән танышкан кеше аны юлчы, сәяхәтче, мосафир дияр. Урта Азиягә сәяхәт. Туфан Союз командировкасы белән түгел, үз теләге, үз инициативасы белән чыгып китә. Унбиш көнгә, бер айга да түгел, бер елга. Тимер юлларда кара эшче. Аз-маз акча белән тагын юлга. Юлда малярия белән каты авырып, озак больницада ята. Кемнәрдер аңа булыша, дәвалыйлар, аякка бастыралар. Яңадан сәфәр. Каракалпакстан чүлләренә барып чыга. Мамык кырларында каналлар ера. Каракалпакстанның яшь

поэзиясенә дә каналлар ера. Чүлләр, халыклар... Шул хакта Туфанның менә үз шигыре: «Каплан-Кырда». Каплан-кыр — Кара Комның бер өлеше.

Каплан-Кырда сөякләр ята...
Җилләр исә мине үгетләп:
— «Чүлдә синә, кеше, ни кирәк!—
Күзен төбәп күкләргә таба,
Каплан-Кырда сөякләр ята».
Җилләр исә мине үгетләп:
— «Бөек сәнигъ Фәрһад кебекнең,
Я синдәй бер фантаст егетнең
Башкаедыр, бәлки бу сөяк...» —
Җилләр исә мине үгетләп:
— «Чүлдә сиңа, кеше, ни кирәк!»
— Су кирәк, су! Чүлдә су булсын,
Дәрья тагын Каспийга койсын!
Сахраларны гөлстан итсен,
Чүлдә миңа бүтән ни кирәк!
Күзне төбәп күкләргә таба,
Чүлдә үлгән кырыс бабалар!—
Сездән туган кыю балалар
Таш яуса да бәхеткә бара,
Күзне төбәп максатка таба!
Каплан-Кырда сөякләр ята...
Без аларны онытачакмыни!!
Без бу юлдан борылачакмыни!—
Омтылгандай Иделгә таба,
Каплан-Кырда сөякләр ята...



Туфан интернационализмы озын юлларда төрле халыклар, төрле язмышлар белән очрашканнан соң туган интернационализм, дуслык. Авыр язмышка дучар булган чакларында аны шул кешеләргә, халыкларга чиксез хөрмәте, мәхәббәте саклап калгандыр. Туфан поэзиясендә кеше аерым бер гуманлык пәрдәсенә төренгән. Туфан бервакытта да «шагыйрь»не «Кеше»дән алда куймас. Башта: кешеме ул?— дияр.

Туфан Урта Азия буйлап 1927 елда сәяхәт кылган. Ярты гасырдан соң без, сәнгать кешеләре, Каракалпакстанга юл тоттык. Туфан үзенең бара алмавына борчылып, безне озатып калды. Ләкин Каракалпакстан аны онытмаган. «Каплан-Кырда» шигыре анда кабат яңгырарга керешкән. Туфан интернационализмы бездән бик күп алда үз эшен эшләгән икән. Кайчандыр юлларында Туфанны очраткан яшь авторлар инде Каракалпакстанның, Үзбәкстанның халык шагыйрьләре булып өлгергәннәр. Олы шагыйрьләрнең язмышы башка халыклар язмышыннан аерылгысыз икән. Арган, йончыган, картайган Шагыйрь образы гел минем күз алдында торды:

Сугарган да миллион күңелләрне,
Иксез-чиксез сахра-чүлләрне,
Ул ял итә Аму-дәрья кебек,
Шул көннәрне сагына йөрәге...

Туфан инде беркайчан да кабатланмас шагыйрь, уникаль шәхес. Аның беренче шигырь җыентыгының дөнья күрүе дә нәкъ Туфанча. Үзе киткәч, Гомәр Гали, Нигъмәтиләр җыеп чыгарган китабы белән ул Урта Азия шәһәрләренең берсендә очраша. Юлда китапханәгә керә. Өстәлдә Назыйм Хикмәт шигырьләре ята... һәм Туфан. Ышанмый, бу нинди яңа Туфан? Алып карый, үз шигырьләре. Назыйм Хикмәт һәм Туфан, янәшә. Ике төрки халкының ике зур вәкиле беренче тапкыр шулай очраша. Тормышта, юкатта шушындый очрашулардан да бәхетлерәк очрашу юктыр. һәр шагыйрьнең янында шушындый тәнкыйтьчеләр басып торсын иде. Шагыйрьләре дә Туфан шикелле булсын иде. Туфан гомере буена шулай, нәшрият яки кемдер бирәү

кузгатса гына китапка алынды. Миңа калса шушы «кимчелек» аның буй җитмәс дәрәҗәсе, горурлыгы...

Туфан биографиясе өйрәнелмәгән биография. Бездән читтә, еракта аның биографиясе. Мин белгәне — Казан. Казаннан тыш? Казанда ул иҗатының башында һәм ахырында. Уртасы? Уртасы — учак...

Туфанның гомерендә бер тапкыр туктапып ял иткән урыны — Аккош күле. Ерак юл, ерак сәфәрләрдән соң арып килеп егылган урыны — шул урын. Дачасы, бакчасы. Урманнан җыеп, кешеләрдән җыеп чәчәк үстерде. «Тургай чәчәге»ннән башлап, яраткан ромашкалардан башлап, бөтен чәчәкләр дә бар аның кечкенә бакчасында. Көз җиткәч, ул аларны берәм-берәм өзеп, букет ясап, иртән Тукай һәйкәленә илтә. Балалар — мәктәпкә. Туфан — Тукайга. Һәр елны шулай. Һәр елны бер вакытта. Бер үзе. Ялгыз. Уйлары да үзе. Изгеләрчә. Авыл карты кичтән әзерләнеп, иртән изгеләр каберенә барган күк бара. Бара, басып тора, икәүдән икәү. Шунда рухы аның Тукай рухы белән тәмам кушыла сыман. Хәзер ул тыныч. Үз бурычын үтәде. Менә бит Туфан чәчәкләре каян үсеп чыга. Тукай — Туфан туфрагыннан. Җирлеге бай...

Чәчәкләр һәм песнәкләр... Кыш җитсә, песнәкләргә ул көнбагыш салып, алмагачка кәгазь тартма элә. Җилдә, буранда селкенеп тора ул тартма. Минем күңелгә шушындый олы шагыйрь болар белән артык мавыга ахрысы диган уй да килә иде кайчакта. Ләкин тормышын күз алдымнан уздырам да шунда ук уйларымнан кире кайта идем. Ялан, кырлар искә төшә, Туфан ромашкалары җилдә тирбәлергә кереша. Кышкы бураннар, ачы суыклар искә төшә...

Чәчәкләр һәм песнәкләр... Мондый күренешне тәнкыйтьчеләр элек тормыштан, көрәштән читкә китү дип аңлаталар иде. Янәсе, шагыйрь шулардан үзенә юаныч эзли. Есенин, Такташ, Туфан чәчәкләре — җирне, табигатьне — тормышны артык ятканнан яралган чәчәкләр алар.

**Агыла да болыт агыла**
**Туган-үскән җирләр ягына;**
**Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр**
**Нәрсә әйтер туганнарыма!!**
**Агыла да болыт, агыла...**
**Нәрсә әйтсен: берни белми ул,**
**Хәбәре юк минем йөрәктән.**
**Мине бары чылатып үтте**
**Кукурузлар белән беррәттән...**
**Нәрсә әйтсен, берни белми ул.**

Кешене шул кукурузлардан аерасы килми. Әйтерсең язмышлары уртак аларның. «Бу тормышка ялан аяк килдем, ялан аяк кына китәрмен». Кайчакта миңа Туфан үзе түгел, аның өчен язмышы яза кебек. Язмышы әйтеп торганны Туфан бары кәгазьгә генә терки...

Аккош күлендә көз. Балалар китә, олылар китә, таралалар. Күл буе тына. Көзге урман тына. Бөтен җирдә тынлык урнаша. Төн. Дачада бер-ике кешедә генә ут яна. Бер читтә Гомәр Бәширов уты, икенче читтә минем ут. Уртада Туфан уты. Бәшир дә, мин дә Туфанны күзәтеп яшибез. Мин тәрәзә пәрдәсен күтәреп Туфан утын эзлим. Төн уртасы узган, ул уяу, ул яза. Уты тонык кына агач араларына төшкән. Ул төнлә язарга ярата. Аның тәрәзәсендә ут сүнми торып, мин йокларга ятмыйм, уңайсыз. Туфан хәтле Туфан эшләп утырсын, син ят, син йокла. Миндә шагыйрьләр көнчелеге уяна. Алдан яту оят. Тукайны, Муса Җәлилне, Туфанны бик нык хөрмәт иткән, һәр чыгышында диярлек шуларны телгә алган балкар халык шагыйре Кайсын Кулиевнең дә шушы турыда язган «Шагыйрь уты» исемле шигыре бар.

**Замандашлар имин җырлар яза,—**
**Тәрәзәдә йөрәк уты янә.**
**Әҗәлне дә бу ут туктатырлык,**
**Куркып кача аннан бәла-каза.**
**Шагыйрь йөрәгенең якты уты**

Ап-пакь итәр төсле бу дөньяны,
Шул кояшның игелекле нуры
Гөлбакчалар итә таш кыяны.
Безнең Кәзим чәчкән нурлар да бит
Яктылыкка өнди халыкларны.
Шуннан нурлар алган туган халкым,
Шуның белән җиңгән салкыннарны.
Синең тәрәзәңә каршы гына
Туфан тәрәзәсе балкый кичен.
Рәхмәт, Сибгат, Сиңа Туфан өчен,
Ышанычлы иптәш булган өчен.
Шигъриятең, тиңдәш, гөрләп тора,
Тынгы белмәс чал Иделең сыман.
Якты өмет юллыйм:
Ерак чорга
Үз телеңдә җырлап кер син, туган.

Төн буе ике тәрәзәдә ике ут яна. Ул ут бөтен Аккош күле урманын уйландырып яна. Кайчанга, күпмегә кадәр янар ул утлар? Кайчагында мине кинәт курку ала иде...

Көз. Урман. Кичләрен аның янына керәм. Ул сузылып ятып, өстенә приемнигын куеп, кичке хәбәрләрне тыңлый. Кичке хәбәрләр, концерт. Минем шикелле ул да күбрәк халык җырларын ярата. Туфан музыкаль кеше. Ул нотаны белә, сизгер. Җәлилнең дә, Туфанның да яраткан уен коралы — мандолина. Яраткан композиторы — Сәйдәш. Яраткан җырчылары Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров. Икесенең дә теленә, моңына соклана. Бу ике төшенчәне: телне һәм моңны бер-берсеннән аерып булмый... Сөйләтәм, үзем өчен сөйләтәм. «Галия»дә укыган. Шәехзадә Бабичлар белән бергә укыган. Әдәбиятка Галимҗан Ибраһимовның фатихасын алган. Минем алда бөтен бер тарих ята. Чал тарих. Шундый тын көзге кичләрдә миңа университетның берәр егете магнитофонын күтәреп килеп чыгар төсле тоела иде. Туфан сөйләр, ул язар, истәлек калыр, китап калыр... Магнитофон түгел, култык астына папкасын кыстырып, буе-сыны, түгәрәк йөзе белән Лермонтовны хәтерләткән яшь Мөдәррис Әгъләмов урман юлыннан тиз-тиз атлый. Башта Туфанга кагыла, аннан миңа. Туйганчы яттан шигырьләр укый. Университет яшьләре белән экспедициядә Себердә булган, Уфада яшь шагыйрьләр — чордашлары белән бәхәсләшкән, хисләре күп, шигырьләре кайнар... Менә ул тагын бер ун-унбиш ел шулай туктамый, сүрелми язар шикелле иде миңа. Туфан күпме өмет баглады бу егеткә. Туфан әрнүен күргәнегез бармы сезнең? Әрнеми ул, рәнҗи. Рәнҗүе чыраена чыга аның. Талант әрәм була бит, талант... Талант халыкка хезмәт итәргә тиеш. Туфан үзе бөтен барлыгы белән халыкка төбәлгән кеше. Тукай мәктәбе шагыйрьләренең иң күркәм сыйфаты шушыдыр. Тукай үзенең иҗаты, көрәше, идеалы белән үз мәктәбенең — халыкчан мәктәбенең таза нигезен салып калдырган икән.

Татар поэзиясе бай. Шәхесләрнең зурлыгы белән бай. Туфан мин белгән шагыйрьләрнең берсенә дә охшамаган. Бу яктан татар шагыйрьләренең һәркайсы үзенә башка. Тукайга якынаерга беркем батырчылык итми. Дәрдмәнгә теләсәң дә читен. Такташка охшарга тырышучылардан кем дә калмады. Муса Җәлил безнең белән Европадан торып сөйләшә. Фатих Кәрим, Такташлар белән горурланып, алар исеменә тап төшерми поэзиягә батырларча юл ярган шагыйрь. «Фабрикант малае» дип йөртелгән интеллигент-оратор Кутуйны, Ватан сугышында «катюша»да хезмәт итеп, партия сафына кергән, бөтенләй икенче ягы белән ачылган, дөньяга шат яратылган Кутуйны гомумән икенче бер поэзиядә очрату кыен. Әхмәт Фәйзие бөтенесеннән читтә, озын буйлы, күзлекле, үзен Фатих Әмирханча тотышы белән аерым басып тора... Үзләреннән соң туган шагыйрьләрнең барысына да контраст...

Туфан берәүгә дә охшамаган. Каләме дә башка. Карасы да башка. Каләме фәкать алтын очлы. Карасы фәкать яшел. Бетсә, шул караны бөтен шәһәр буйлап эзләячәк. Башка төрле кара белән язганын хәтерләмим. Бик вак хәрефләр белән яза. Төрле шартларда яза ала. Теләсә кайда. Җыелышта, туйда, хәтта мунча ишеге төбендә чи-

ратта. Беркемгә дә исе китми, үз дөньясы дөнья. Минем түйда язып утырган шигырен мин уналты елдан соң китаплар арасыннан табып алдым...

Туфанның мин үз гомеремдә акча юк дип зарланганын ишетмәдем. Ә бит ул иң аз басылган шагыйрьләрнең берсе. Аның өчен бер генә нәрсә бар — поэзия. Фанатик. Идеалист. Акча, әйбер, җиһаз дигән барлык төшенчәләрдән ваз кичкән идеалист. Хәзер инде икенче буын белән очрашканнан соң, Туфан миңа гаҗәеп сәер кеше булып күренә. Ярабби, татарда мондый шагыйрь дә яшәгән икән. Яшәгән, бары поэзиягә, халыкка гына ышанган. «Көнем өчен түгел, денем өчен» дип яшәгән.

Аккош күлендә көз. Туфан янына керәм. Ял итеп ята. Арык, йөзе ак, чәче ак. Йокласа, уятмыйм. Уятырга куркам. Йокысы аның әллә нинди куркыныч, хәвефле. Күкрәгендә бер тавыш һаман көчәя бара, үсә, әйтерсең калын урманнар түреннән күтәрелә, бер секундка туктала, аннан кинәт эчке бер газап белән тышка бәреп чыга. Үзе дә соңыннан, котылдым дигән төсле, уф дип куя. Мин аның аяк очында басып торам. Дәшмим. Урман тын. Өй эче тын. Туфан йоклый. Йокысы баһадирларча. Йокысы да бүтән...

Мин аның янына яңа шигырьләремне укырга кергәлим. Сәгатем кинәт туктап калса, сәгатемне төзәттерергә дә алып кергәләдем. Әйтерсең ул беркайчан шигырь язмаган, сәгать төзәткән, һөнәре буенча сәгатьче. Бераү булса, бу минем эшем түгел дияр иде. Өстәл тартмасын ача. Тартмада бөтен кирәк-ярагы. Күзлеген кия, лупа ала. Сәгатьне пинцет белән актарырга керешә. Ташларын җентекләп карый. Ташларына бәя бирә. «Тиз ремонт» ясаучы сәгать мастеры. Шагыйрь-сәгатьче. Килешеп тора. Пинцет белән бик вак детальләрне әләктерә. Шигырьне сүтеп ыргыта да яңадан җыя кебек. Рифмаларын әләктереп үз урыннарына тезә сыман. Ничә сәгать төзәттердем икән. Вакыт әрәм була дими, зарланмый. Поэзиясен табып эшли. Төрле һөнәр аның кулыннан килә. Тормыш күп һөнәргә өйрәткән. Һөнәр иясе...

Аккош күлендә көз. Кайчандыр башланып та бүленеп калган сүз башланып китә. Күп фикерләр уртак, карашлар уртак. Кайчакта ул бик нык ачыла, истәлекләргә бирелә. Туфан шагыйрь, Туфан укытучы, кара эшче. Туфан көтүче дисәләр дә мин бер дә гаҗәпләнмәс идем. Дала. Учак. Туфан куен дәфтәренә вак-вак хәрефләр белән күңелендә йөргән шигырьләрен терки. Дөресрәге, күңелдә язылып барган шигырьләр... Көтүчеләр һәм шагыйрь. Мин үзем дә авылыма кайтсам болыннарда йөрим, көтүчеләр янына барып утырам, алар кайнаткан чәйне эчәм. Кыр, дала кешене җырчы итә, җырларын тыңлыйм. Дала кешене йомшак күңелле, бай рухлы итә...

Учак. Көтүчеләр. Айтматовның дала бетереп чабып йөргән дөясе — Каранары шикелле, Туфанның яраткан үгезе була. Мәһабәт үгез. Туфан сөйли:

**Язган булып утырам төннәрдә:**
**Өметләрне эшкә ашырган**
**Кыю еллар,**
**Эпослар сыман,**
**Йөрәгеңә килеп кергәндә**
**Мөмкин түгел язмый түзәргә.**
**Язып утырам. Төн. Кыш. Өермә.**
**Шактый кыю кеше шикелле,**
**Кемдер шакый тышкы ишекне.**
**— Мин өйдә юк: күңел бүген дә**
**Ерактагы туган җиремдә!**
**Бер тонналы үгез «Прометей»**
**Өйчегемнең ишеген каера,**
**Тагын миңа эштән аера:**
**Уяу икән син дә дигәндәй,**
**Хәл белергә килгән «Прометей».**
**Сагынган ул, абзарын ваткан,**
**Мөгезендә чылбыр өзеге,**
**Кеше түгел, хайван ул үзе.**
**Юлда көртка-буранга баткан,**
**Ә мин торган өйчекне тапкан!**

Тәрәзәне ватты. Тыгылды,
Күзгә карый, җиңемне ялый.
Әйтә кебек:
— Куй, Туфан абый,
Буран күмгән син киткән юлны...
Печән кирәк! Киттек, ки тунны!
Төн. Караңгы. Буран. Ферма.
Кит, «Прометей», китче, кит әле!—
Мин өйдә юк, күңел бүген дә
Туган җирдә, Тукай илендә.

Туфан миңа үзенең шомын сөйли. Мин ышанмыйм. Туфан, син хыялыңда туган шагыйрәнә бер күренешне миңа сөйлисең, дим. Ул үпкәли. Туфан үпкәләсә каты үпкәли. Ярар, дөрестер. Шагыйрь күңеле нәрсәләр генә уйлап чыгармас. Шулай дим. Үзем тәрәзәгә карыйм. Аккош күленең көзге төне шул ерак дала белән тоташа. Агачларның ботаклары ут яктысында уйный. Теге «Прометей» болыт төсле куе, моңсу күзләре белән безнең тәрәзәгә карап тора шикелле. Муенында өзгәләнгән чылбыр...

Шагыйрьлекне Туфан кебек еллар аша саклап алып барган, шагыйрь исемен бөек тоткан шагыйрьләр татарда аз түгел. Мин сугышта йөрдем, озак аерылып тордык. Ил тормышында төрле вакыйгалар шаулап узды. Әлекке Туфан белән яңадан очрашасың һәм күреп гаҗәпкә каласың. Әйтерсең, аның белән берни дә булмаган. Һаман да шул Туфан, чорның үзе кебек зур, олы. Шигырьләр тагын да тирәнәя төшкән, уйланулар күбәйгән. Шигырь юллары нечкәргән, хисләр тартылган.

Җирдәге юллар, борылмалар, шагыйрь күңелендәге юллар, борылмалар. Муса Җәлилнең бер шигыре «Юллар, юллар» дип атала. Муса Җәлил эзләре буйлап Германия Демократик Республикасында ике тапкыр булганнан соң, ул юлларның нәрсә икәнен мин аңладым. Бер сүз белән әйткәндә, кичерешләр алар. Иң кадерле, иң газаплы кичерешләр. Ә Туфан узган юллар? Туфан томнары... Кечкенә-кечкенә ике-өч том. Юллар озынайган саен, шигырь тыгызланган. Юлда йөк авыр булмасын өчен хисләрнең иң кадерлеләрен генә үзе белән алган шагыйрь. Сиксән еллык катлаулы гомер, тормыш шул җыйнак сайланмаларга сыеп беткән. Шагыйрьнең эчке борчулы, каршылыклы уйларыннан кристаллаша икән шигырь. Шигырь — шәхес үзе икән. Кечкенә-кечкенә ике-өч том. Язганнары шул кадәр? Ә язылмый калганнары күпме! Шул учаклар янында җылынып өчен янганнары күпме?

Аккош күлендә көз. Туфанны мин юлчы-мосафирга охшаттым. Мосафирлар төрле җирләрдә очрашалар. Менә хәзер безнең Аккош күлендәге утны күреп Фатих Кәрим килеп керсә. Бәй, Фатих, син исәнмени?— дип каршылар иде Туфан. Исән... Фатих мосафирдан бигрәк солдат. Кыяфәте, гәүдәсен тотышы, атлап йөреше белән солдат. Туфан тормышта идеалист. Фатих реалист. Туфан материя, матдә... Фатих материянең бүгенге чынлыгы. Туфан сугышка әлексә, санбатта яки күмү командасында хезмәт итәр иде. Фатих? Нәкъ язмышындагыча сугышчан офицер. Гомумән, татар шагыйрьләре я философ, я солдат. Икенең берсе.

Баскычка дөп-дөп басып килеп керсә? Әгәр килеп керсә... Аккош күлендә нинди бәйрәм булыр иде. Туфан аның белән бер очраша. Сугыш алдыннан. Соңгы тапкыр. Анысы да өндә түгел, төштә. Туфан миңа үзенең төшен сөйли. Казан елгасы буенда ак йорт. Туфан шул йортта авырып ята, имеш. Кыш. Салкын. Тәрәзәләр туңган. Кинәт ишек ачылып китә, ишектә бераү күренә. Башында иске бүрек. Аякта... Аякта тимер чыбыклар белән чорналган машина шины. Туфан таный: бу бит Фатих. Хәле авыр булуга карамастан, Туфан песи шикелле генә атлап барып, ике кулы белән күзләрен кыса. Таныйсыңмы, ди. Фатих сузып: «Хә-сән»,— ди. Туфанга эндәшкәндә ул «Туфан» сүзен бераз суза төшеп, йомшартып әйтә. Шул йомшартып, сузып әйтүендә аның хөрмәте, ихтирамы... Кочаклашалар. Еламыйлар. Шагыйрьләрдә генә була торган горурлык ирек бирми. Пушкин белән Лермонтовның елавын күз алдыма китерә алмыйм. Тукай кемнәр каршындадыр мескенләнкә бирелде дисәләр дә ышанмыйм. Җәлил дә еламаган. Туфан белән Фатих Кәрим дә шул бер токым. Горур токым.

Шагыйрьләр горурлыгы турында җырлар идем мин. Бөгелми, сыгылмый торганнар горурлыгы турында. Төш. Хәтта төштә дә ялымыйлар...

Туфан үзенә алмаш яңа буынны күрде. Сугыштан соң бик аз калган идек без. Сугыш алды язучыларының күбесе юк. Бөтен Союзга шаулаган әдәбият тынып калды. Зур һөҗүмнән чыккан солдатларны бәрәмләп җыйган шикелле, татар әдәбиятының да исәннәре тирәсенә башкалар әкренләп оеша башлады. Башкалар — моңа хәтле билгесезләр. Билгесезләрне тизрәк күрергә теләүдән дә кызыграк нәрсә юк. Нинди кешеләр килер икән? Төсләре, кыяфәтләре ничек? Характерлары ничек? Бер буынга күнеккәннән соң икенче буынны кабул итү сәер икән. Мин Такташ, Кутуй, Туфан төслесенә ияләшкән, күнеккән, яңалар алай булмаса... Бәлки тагын да көтмәгәнрәкләре килер. Әкренләп ишек шакый башладылар. Редакция ишекләрен, әдәбият ишекләрен. Шәүкәт Галиев. Йөзеннән үк билгеле, авыл малае. Кутуйлар кыюлыгы да юк, Такташлар бунтарьлыгы да юк. Авыл. Сугыш чоры авылы. Ат җиккән, икмәк ташыган, тыйнак, басынкы. Илдар... Монысы кызлар белән кич утырганда гармунын күтәреп урамга чыккан. Таңны каршылый. Авылның «Таныш моңнары»ннан исергән. Рәшит Гәрәй — авыл, агротехник, бригадир. Хисам... монысы окоптан. Солдат... Гамил Афзал... Бабичларны искә төшереп торыр өчен килгән. Туфан Миңнуллин... Борынгы Болгар җибәргән әдәбиятка. Галиәсгар Камалга да, Кәрим Тинчуринга да охшамаган. Күбрәк Мәхмүт Галәүгә тартым... Аннан Равилләр, Ренатлар, Рәдифләр... Болар мәктәп, университет. Авылдан бигрәк шәһәр. ФТР... Гәрәйләр, Зөлфәтләр, Робертлар — кабат авыл...

Прозада Гарифлар, Мөхәммәт, Аяз, Нуриханнар. Күп төрле талантлар. Дөресен әйтим, татар әдәбиятының яңадан шушылай күтәрелүенә, яңача ачылуына күңелемдә шик яши иде. Мин шул буынның уртасында хәзер. Күңелдә татар халкына рәхмәт хисе. Коргаксымаган икән аның рухы. Татар әдәбияты моннан соң да коргаксымаячак. Мин шуңа иман китердем. Алда тагын кемнәр? Аларны инде киләчәктә шушы бүгенге буын каршылар. Каршылау күңелле, озату күңелсез. Хәсән Туфан гомеренең азагында Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллиннар буынына үзенең бәхилләгән, ризалыгын әйтеп калдырды. Мин сезгә бәхил, диде. Димәк, тормыштан тыныч күңел белән китәргә мөмкин. Кемдер киләчәктә бу буынның йөзеннән Туфан шәүләсе әле китеп бетмәгән дисен иде...

Аккош күлендә көз. Туфан мине озата чыга. Төн. Йолдызлар. Йолдызлар даладагы учаклар кебек. Ул әле мин киткәч тә шул йолдызларга карап ишек төбендә басып тора...

**Аккош күлендә сагыш, моң,**
**Юксынып сорый урман:**
**Гасырның үзе кебек чал**
**Кайда дип синең Туфан!**
**Үзем дә эзлим, шушыннан**
**Узган эзләрен белән.**
**Чәчәкләр карый күземә**
**Туфан күзләре белән.**
**Ул юкта ромашкаларга**
**Кунмаган хәтта тузан.**
**Сыйпыйм башларыннан сөеп**
**Сыйпаган кебек Туфан.**
**Аккош күлендә сагыш, моң,**
**Юксынып сорый урман:**
**Гасырның үзе кебек чал**
**Кайда дип синең Туфан!**

*Трускавец — Казан*
*1982—83.*

# Сафуан Муллагалиев

## Үзбәкстанда кар ява

Карлар монда кунак кына —
Канат җәеп тыйнак кына,
Бәхет булып ява җиргә —
Юмартланып, уйнап кына...

Шаяра-шуклана карлар,
Алар монда кунак кына.
Мин йөрим урамнар буйлап
Туган якны уйлап кына...

## Җылытасым килә үзләрен

Өшегәннәр күктә йолдызларым,
Нурларыннан салкын бөркелә.
Кар каплаган каен, тирәкләрне...
Килмәгән шул бу кыш бер көнгә.

Ул йолдызлар, гүя, сабый чагым —
Сагыш белән тулы күзләрем...
Учларыма салып салкын төндә
Җылытасым килә үзләрен.

## Яңгыр

Асты-өскә актарылып
Болыт килә көньяклардан.
Чабыш-ярыш кыза күктә —
Очкын оча тояклардан.

Юмарт болыт чәчен тарый,
Җиргә төшкән толымнары.
Дөбердәп атлар чабыша,
Кешнәп куя колыннары.

## Туган көнем

Илләр гизеп кайттым туган якка,
Инде кабат чыгып китмәмен.
Казанымда бүген туган көнем —
Авыз иттем җирем икмәген.

...Самолетның ап-ак эзе кебек
Җирдә безнең үткән юл озын.
Казаныма кайттым — туган көнем —
Бүген күктә минем йолдызым:

Таң йолдызы сыман нурлар бөркә,
Юлларыма ява рәхмәте.—
Казанымда бүген туган көнем —
Җаным тулы бәхет-рәхәтлек!

## Мин синеке, яр

Яуган ак кар нурларында
Коена таллар.
Тармакларыннан, кар эреп,
Тамчылар тамар.
Мин синеке, яр!

Күңелләрдә дәрт кабыныр —
Эрер салкын кар.
Йөрәгемне лачын иткән
Мәхәббәтем бар.
Мин синеке, яр!

Беренче язгы яңгырда
Юыныр таллар.
Талларымны кисмәсеннәр,
Яшьләрем тамар...
Мин синеке, яр!

Һәр йөрәкнең гомерлеккә
Сөйгән яры бар.
Яфрак ярган талларым бар —
Мин синеке, яр!

Мин синеке, яр!..

*Үзбәкстан, Маргилан шәһәре — Казан.*

# Хәлил Бакиев

## Беләгемә беләзек...

Мебель цехы. Агач исе.
Өем-өем пычкы чүбе.
Балтам йөзе — үткен пәке,
Бер чапканчы үлчим җиде.

Кулым эшкә ятып тора,
Шуны тоеп җан куана,
Беләгемә беләзектәй
Йомычкалар әй урала!

Ир-егеткә җитмеш һөнәр
Кирәк дигән ата-бабам.
«Ә хатын-кыз кемнән ким?» — ди
Киң сулышлы яңа заман.

Чалбар кигәч, ничек инде
Ышкы-пычкы кирәкмәсен:—
«Тулган айдай тезкәйләрең —
Яшермә», дип, өйрәтмәгез!

Мебель цехы. Урман исе.
Өем-өем пычкы чүбе.
Егетемне янып сөйгәч
Ир-ат эше җене тиде.

— Тиз бул, тиз бул!— дия кебек
Көне буе ышкы-пычкы:
— Кулыңнан гөл тама!— диеп,
Кулым үбеп, ирем кочты.

«Билкәйләрен өзә күрмә!»
Дип елмая ир осталар.
Беләгемә беләзектәй
Уралалар йомычкалар.

## Бизәнмә, сеңел

Бизәнмә, сеңел, бизәнмә:
Эх, дип, бу сипкелләрем!
Күк йөзен әнә бизи бит
Ак йолдыз төркемнәре.

Биткәйләрең, биткәйләрең
Күктән алган өлгесен —
Ай-йолдызлар балкып торган
Кичтәй серле йөзлесең.

Бизәнмә, сеңел, бизәнмә:
Эх, дип, бу сипкелләрем!
Нурлы кояш нурсызланмый,
Бар дип тап-тимгелләрем.

Йөзкәйләрең, йөзкәйләрең
Күктән алган өлгесен —
Бер түгел, мең кояш көлгән
Көндәй көләч йөзлесең.

Бизәнмә, сеңел, бизәнмә:
Яшермә сипкелләрең!
Шул искиткеч йөзең белән
Мине бит сихерләдең.

## Үз эшенең остасы

Барган идем тимерчегә
Юк эшемне бар итеп.
«Булыш»,— дип чүкеч тоттырды,
Ташлап китәсең ничек?!

Ә үзе сандал тирәли
Дирижердай очына;
Хәйләле елмаю кунган
Мыегының очына.

Кулларымнан чаткы түгел,
Йолдыз яна башлады;
Әйтерсең, тимер чүкемим,
«Әпипә»гә басамын.

Ут бураны уйнатабыз,
Озын сүзнең кыскасы,—
Яраттырды үз һөнәрен
Үз эшенең остасы.

*Ульяновск өлкәсе,*
*Иске Кулатка районы*

# 1983 ЕЛДА «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

*РСДРПның II съездына 80 ел*


Фасеев К. **Партия — чорыбыз байрагы.** № 7.


*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карары*


**1983 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирү турында.** № 7.
**Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреатлары.** № 1.


## ПРОЗА


Баянов Ә. **Таш китап.** Роман. № 1, № 2.
Бәйрәмова Ф. **Болын.** Повесть. № 9.
Вәлиев М. **Иkенче каттагы бүлмә.** Новелла. № 3.
Галиев Ф. **Игенче язмышы.** Игенче язмалары. № 8.
Галиев Ә. **Сәяхәт.** Хикәя. № 2.
Гаффар Ә. **Бодай бөртеге һәм тегермән ташы.** Роман. № 10, № 11.
Гыйззәтуллин Р. **Читлек.** Хикәя. № 5.
Кашапов Г. **Җир җылысы.** Повесть. № 3.
Кәрами Р. **Йөрәгемне ут алган.** Повесть. № 12.
Кәримов К. **Алдавыч күз.** Кечкенә повесть. № 3.
Ларин В. **Гудок.** Хикәя. № 10.
Маликова М. **Ак давылда тал бөресе.** Роман. № 4, № 5.
Мушинский Ә. **Кайту.** Повесть. № 2.
Низамиев Р. **Галиянең бер көне.** Хикәя. № 6.
Рафиков М. **Хикәяләр.** № 12.
Сәлимҗанов Р. **Елан мөгезе.** Хикәя. № 11.
Сөләйман Б. **Абу баба.** Хикәя. № 3.
Төхфәтуллин Р. **Тигәнәк.** Повесть. № 10.
Фәизов Р. **Рөстәм ул берәү генә.** Хикәя. № 2.
Фәтхетдинов З. **Ачылган серләр.** Маҗаралы повесть. № 7, № 8.
Хуҗин М. **Май кояшы — яшь кояш.** Хикәя. № 12.
Хәбибуллин М. **Өченче вагон.** Хикәя. № 7.
Хәсәнов А. **Әбием ядкаре.** Повесть. № 10.
Хөсни Ф. **Берәү килә, берәү китә.** Повесть. № 9.
Шамов А. **Бер җамаяк сөт.** Хикәя. № 11.
Юныс М. **Юлда уйланулар.** № 6.


## ПОЭЗИЯ


Арсланов Н. **Йөрәгеннән алдым.** Шигырьләр. № 9.
Афзал Г. **Туган илдә Тукай рухы.** Шигырьләр. № 4.
Байтимеров Р. **Сигезьюллыклар.** № 8.
Булатова К. **Уйландыра, шушы уй яндыра.** Шигырьләр. № 10.
Гадел Ә. **Алпамша.** Шигырьләр. № 9.
Галиев М. **Җирдәшләрем.** Шигырьләр. № 6.
Галиев Ш. **Очты яфрак.** Шигырьләр. № 11.
Гатауллин Р. **Гомер уртасыннан хатлар.** Цикл-поэма. № 7.
Гыйззәтуллина Ф. **Дүрт кыз.** Поэма. № 5.
Гәрәй Р. **Аккаеннар — күңел сафлыгы.** Шигырьләр. № 2.
Дәүли Н. **Шаулагыз, гөрләгез, ташкыннар!** Шигырьләр. № 11.
Зөлкарнәев Л. **Ядәч.** Шигырьләр. № 4.
Измайлова Н. **Сүз.** Шигырьләр. № 3.
Кудаш С. **Сигезьюллыклар.** № 4.

Латыйп Г. Муса дисәм... Шигырьләр. № 7.
Латыйпов К. Язлар килер. Шигырьләр. № 6.
Маннапов Ш. Кешеләр эзләп барам. Шигырьләр. № 4.
Минһаҗева А. Биогамма. Шигырьләр. № 3.
Миңнуллин Р. Җир бишеге. Шигырьләр. № 2.
Мостафин К. Охшамаганнарга гимн. Шигырьләр. № 12.
Мәэминова Э. Язмышлар. Шигырьләр. № 3.
Нури З. Бу уклар кемгә тияр! Шигырьләр. № 2.
Рафиков М. Култаягым хәйләкәр. Шигырьләр. № 2.
Рәхим Г. Җирем. Шигырьләр. № 5.
Сафин Ф. Безнең гомер. Шигырьләр. № 11.
Сирай Д. Биегрәк күренә. Шигырьләр. № 12.
Туктарова В. Кыска шигырьләр. № 10.
Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. № 6.
Харис Р. Ат нярләү. Поэма. № 8.
Хәким С. Белоруссиядән башлап... Шигырьләр. № 3.
Шәрифуллина Э. Кыл уртада басып тора ана. Шигырьләр. № 3.
Юзеев И. Мәңгелек белән очрашу. Шигъри трагедия. № 1.
Яруллин Ф. Ишекләр. Шигырьләр. № 9.
Әгъләмов М. Күзгә хикмәт. Шигырьләр. № 10.
Әхмәтҗанов Рәшит. Кол Галиләр рухы. Шигырьләр. № 9.
Әхмәтҗанов Роберт. Шигырьләр. № 12.
Әхсәнов И. Кечкә тәрәзәләр. Шигырьләр. № 2.
Әюпов Х. Өй өмәсе. Шигырьләр. № 11.

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Ишморат Р. И мөкатдәс, моңлы сазым. Драматик повесть. № 5.
Фәттах Н. Кол Гали. Трагедия. № 9.

## ӘДӘБИ МИРАС

Сөләйманова С. Яңавыл хатирәләре. Шигырьләр. № 10.
Туфан Х. Карлар астыннан. Шигырьләр. № 4.

## БАЛАЛАР ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

Галиев Ш. Урам чатында булган хәл. Шигырьләр. № 5.
Мингалим Р. Өстәлеңә ак чәчәк. Шигырьләр. № 8.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Батыров К. Кырларымда калам. Шигырь. № 10.
Газизов Р. Кычыткannар. Шигырьләр. № 3.
Галиева Ф. Горурлана беләм. Шигырь. № 10.
Кәримова О. Күгәрчен. Шигырь. № 10.
Моратов Г. Йөзү. Шигырьләр. № 10.
Мөхәммәтшин Г. Җир йөрәге — игенчедә. Шигырьләр. № 2.
Рәкыйпов Р. Тал төбендә талгын су. Шигырьләр. № 10.
Хөснетдинов И. Яшен тели күңел. Шигырь. № 10.
Әхмәдиев Н. Яшелдән киенгән каен. Шигырьләр. № 10.
Әхсәнов И. Дөньяда мин. Шигырь. № 10.

## ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Афзал Г. Син гади... № 10.
Зарипов И. Туган көн. Юмористик хикәя. № 3.
Кизәнов. Тәкәббер тәкә. Шигырьләр. № 7.
Сәлимов М. Чэпэ. Юмореска. № 7.

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Бик А. Җил. Шигырьләр. № 12.
Веян А. Шәфкатьле бул, вакыт, ашыкмачы. Шигырьләр. № 12.
Воронин С. Чигирника idра итәгендә. Хикәя. № 12.

Вишневский С. **Юл өстендә яткан таш.** Шигырь. № 12.
Данилов Б. **Мең ел яшисе килә.** Шигырь. № 12.
Казаков М. **Урман юлында.** Шигырь. № 12.
Кочетков В. **Хәрбиләр зиратында уйлану.** Шигырьләр. № 12.
Муханов Г. **Әдәбиятыбызның күркәм сыйфаты.** № 12.
Насыйров Т. **Демьян Бедный Татарстанда.** № 12.
Никулина Н. **Чулпан йолдызы.** Шигырьләр. № 12.
Әлибаев С. **Үз диңгезем.** Шигырьләр. № 12.
Әйлисли С. **Офыктагы җылы урман.** Повесть. № 12.

## КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ел) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Дәүли Н. **Минутларның кадерен белик!** № 8.
Низамов Х. **Колхоз мәктәптән башлана.** № 9.
**Яңа бурычлар.** (Язучыларның анкетага җаваплары). № 12.

## АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

Бәйрәмова Ф. **Тегермәнче турында баллада.** № 3.
Галиев М. **«Кече Артек» хуҗалары.** Очерк. № 4.
Зарипов М. **Отышлы әйләнеш.** Очерк. № 1.
Зарипов М. **Кемдер ота, кемдер оттыра.** Очерк. № 12.
Тимбикова К. **Мәсүфәнекеләр һәм Пивник.** Очерк. № 3.

## УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

Абдуллин Ф. **Җылы юллар.** Очерк. № 7.
Вәлиев Р. **Көчле агым.** Очерк. № 4.
Хөснимәрдәнов М. **Себер белән Париж арасы.** № 5.

## ТАТАРСТАН АТОМ ЭЛЕКТР СТАНЦИЯСЕ ТӨЗЕЛЕШЕ — ЖУРНАЛНЫҢ ӘДӘБИ ПОСТЫ

**Әдәби постта беренче очрашу.** № 3.
Бибишев М. **«Истәлеккә шәһәр бүләк итәм».** № 7.
Кашапов Г. **...һәм башланды яңа көрәш.** № 6.
Кәтиев Р. **АЭС һәм авыл.** Әдәби постта әңгәмә. № 11.
Әмирханов М. **Тарихка кергән бер көн.** № 8.

## «АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫ

Батулла Р. **Чабак-тау.** Очерк. № 7.
Дәрзаманов Җ. **Шөгер — гомер сукмагы.** Очерк. № 6.
Кашапов Х. **Сугарулы басулар.** Очерк. № 2.
Мөэминова Э. **Бер остазның ике шәкерте.** Очерк. № 10.
Низамов И. **Күңел урталыгыннан.** № 5.
Рафиков М. **Урман хуҗасы.** № 12.
Рәшитов Ә. **Сез кемнең варислары!** Очерк. № 9.
Хисмәтуллин Р. **Республиканың көнчыгышыннан хатлар.** № 11.
Хәбибуллин М. **Елның бер көне.** Очерк. № 3.
Әхмәтҗанов Р. **«Ишегалдым яшел чирәм».** № 8.
Әһлиуллин М. **Өр-яңа мәсьәләләрне чишкәндә.** Очерк. № 4.

## ТАТАРСТАН НЕФТЕНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА

Зарипов И. **Пар канатлы яктышларым.** Очерк. № 11.
Рәхимов Җ. **Шөгернең икенче яшьлеге.** № 11.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Галиев М. **Лорка илендә.** № 1.

## БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

Вергазов А. Гомер сагында. № 10.

## СТАЛИНГРАД ЯНЫНДАГЫ ҖИҢҮГӘ — 40 ЕЛ

Рәкыйпов Ш. Горур генерал. Очерк. № 2.
Шакир С. Командарм юлдашы. № 2.

## 8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

Елизарова М. Сәламәтлек сагындагы майор. № 3.
Ихсанова Л. Юл кешесе — юлда. № 3.

## 9 МАЙ — ҖИҢҮ КӨНЕ

Хамматов Ш., Тәхау К. Фронтовик әдипләр. № 5.

## 1 ИЮНЬ — БАЛАЛАРНЫ ХАЛЫКАРА ЯКЛАУ КӨНЕ

Ишморат Р. Балалар хакына. № 6.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Бүгенге татар драматургиясе турында сөйләшү. № 7.
Мөхәммәдиев Р. Тормыш дәвам итә. № 1.
Хатипов Ф. Күңел хәзинәләрен ачканда. № 6.
Яхин А. Фикер дәлилле булсын! № 5.
Әхмәтҗанов Роберт. Җил уңаена борылма. Реплика. № 5.

## БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

Ахунҗанов И. Күңел кайнарлыгы. № 7.
Акмалов Н. Күңелне кузгатамы! № 11.
Баянов Ә. Замандашларым. № 4.
Габиди Ә. Уңышларыбызны да күләгәләмик. № 8.
Галиуллин Т. Нәфисәләр юксындыра. № 2.
Галимуллин Ф. Мөмкинлекләр бар! № 3.
Ганиева Ф. Әдәбият — ул сүз сәнгате. № 9.
Гыйләҗев А. Тынычлану зарарлы! № 2.
Дунай Ф. Дөрләп ала фикерләр. № 12.
Зөлкарнәев Ф. Чакма чакмый ут чыкмый. № 4.
Ихсанова Л. Олы максатларны онытмыйк. № 6.
Миңнуллин Т. «Күктә ни булмас». № 5.
Миңнуллин Ф. Реаль хәлләргә күз салыйк. № 10.
Нуруллин И. Илең турында уйла. № 11.
Моратов Г. Тормыш куйган сораулар. № 7.
Мостафин Р. Перспективаны югалтмыйк. № 3.
Сәхәпов Ә. Күләгәләр яктыда югала. № 6.
Төхфәтовлар. Тормыш мәсьәләләре булсын. № 12.
Хатипов Ф. Сокланам һәм уйланам. № 8.
Хәсәнов М. Олы язмышлар юксындыра. № 12.
Шәмси С. Вакыйга артында ни ята! № 5.
Шәрипов С. Әсәрнең ышандыру көче кирәк. № 10.
Әхмәтшина Ф. Кайбер теләкләр. № 10.
Дискуссиягә укучы кушыла. (Ибраһимов А., Мөхсинов Ә., Гомәрова Ф. мәкаләләре). № 9.

## ЯЗУЧЫ УЙЛАНУЛАРЫ

Д. Вәлиев. Диоген фонаре. № 5.

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

Еники Ә., Мәһдиев М., Шакир С. № 6.
Мостафин Р., Хәбибуллин З. № 7.
Рәкыйпов Ш. № 8.
Юзеев И. № 12.
Якупов Х. № 10.

## ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Вәлиев М. **Искергән акчалар тарихы. № 6.**
Галимуллин Ф. **Халатың ак, күңелең пакь булса. № 9.**
Еники Ә. **Хатлар укыганда. № 12.**
Низамиев Р. **Биеклеккә чакыру. № 4.**
Тмин. **Шигырь язарга өйрәтәм. № 5.**
Фәттах Н. **Яшь язучының бер хикәясе. № 10.**

## БИБЛИОГРАФИЯ

Ахунҗанов И. **Үзенчәлекле шигърият. № 11.**
Бәшәров Р. **Балаларга яңа китап. № 12.**
Вульфсон Г., Михайлова С. **Революцион көрәш серләре. № 6.**
Галиуллин Т. **«Тыйнак табын»га кил, укучы! № 11.**
Галимуллин Ф. **Изге ният. № 6.**
Зөлфәт. **Ак буранда туган шигърият. № 4.**
Маннапов С. **Без бик якынбыз. № 12.**
Миңнуллин Р. **Канатлы малайлар, канатлы шигырьләр. № 1.**
Мостафин Р. **Кырыс реализм. № 7.**
Мөхәммәдиев Р. **Үсеш юлында. № 2.**
Мөхәммәдиев Р. **Ихтирам. № 7.**
Сафин Ф. **Тормыштан һәм тормышчан. № 6.**
Харис Р. **Бакый Урманче альбомы. № 6.**
Юзиев Н. **Шигърияттә үз йөзе бар. № 6.**
Ягъфәров Р. **«Алтмыш арба бодай бир», № 7.**
Әхмәт Р. **Үрдә иманнар. № 10.**

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА

Дәрзаманов Җ. **Тормышка мәдхия. № 3.**
Зиннәтуллина Ә. **Кызыклы да, гыйбрәтле дә. № 3.**
Моратов Г. **Сабыр канатлары. № 3.**
Нәбиев Р. **Революция каһарманы. № 3.**

## ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Сафиуллина Ф. **Хәзинәдә ниләр бар! № 1.**

## ФОЛЬКЛОР

Садыйкова А. **Гыйбрәтле хикәят. № 1.**

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Гобәйдуллина Э. **Соңгы сәяхәт. № 11.**
Гобәйдуллин Х. **Фатих Әмирхан ядкаре. № 11.**
Енакаев Р. **Ипи-тозлы шәһәрдә. № 2.**
Мостафин Р. **Аның тел ачкычлары. № 2.**
Хамматов Ш. **Яңа документлар: Муса Җәлил кульязмалары. № 2.**

## ИСТӘЛЕКЛӘР

Мирзагилдина-Баязитова Г. **Мирсәй Әмир белән очрашу. № 2.**
Хәким С. **Аккош күлендә сагыш, моң. № 12.**

## СӘНГАТЬ

Билялов Р. Сихерле күзгедә чагылган язмыш. № 2.
Вәлиева Г. Татар келәме һәм гобелены. № 10.
Галиев Б. Төсле моң. № 8.
Илялова И. Татар сәхнәсендә тәрҗемә әсәрләре. № 5.
Исмәгыйлов Ә. Жанр аныклыгы һәм тормыш дөреслеге. № 4.
Хәйруллина Н. Җирне җыр бизи. № 6.
Шиһапов М. Театр — замана көзгесе. № 10.

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Абдуллин Я. Борылыш. № 6.
Абилов Ш. Низами һәм татар әдәбияты. № 3.
Галиев М. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән — мәгариф өлкәсенә. № 11.
Гобәйдуллин Х. Сәхнәдә Камал I дисәләр... № 12.
Госманов М. Тирән эзләр, үзәк тамырлар. № 9.
Еники Ә. Ике шагыйрь. № 8.
Казаков Е. Йөзек кашына ни язылган! № 6.
Каримуллин Ә. Тапшырылмый калган бүләк. № 4.
Михайлова С. Давылга таба. № 3.
Миңнуллин Җ. Археограф Вәли Зәбиров. № 10.
Мәхмүтов М. Бу тарихи бергәлек. № 10.
Мөхәммәдова Г. Балачак истәлеге. № 4.
Нәфиков Р. Иң бөек максат. № 4.
Рахманкулов Ш. Тукай Троицк шәһәрендә. № 4.
Сабирҗанов Г. Татарстанда культура революциясе. № 11.
Уразманова Р. Борынгы һәм яңа бәйрәм. № 5.
Хәкимҗанов Ф. «Йөзек кашына ни язылган!» дигән мәкаләгә карата. № 6.
Хәмзин К. Соңарган хат. № 8.
Шәрәфетдинов З. Халыкка аң-белем бирү юлында. № 10.

## КОЛ ГАЛИНЕҢ ТУУЫНА 800 ЕЛ

Госман Х. Ерак чыганаклар. № 9.
Госманов М. Кол Гали — халык хәтерендә сигез гасыр. № 9.
Фәттах Н. Кол Гали. Трагедия. № 9.
Хисамов Н. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының идея проблематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше. № 9.
Юзиев Н. «Кыйссалардан, хикмәтләрдән күреклерәге». № 9.

## ЗАКИР ҺАДИНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Гайнетдинов М. Бишенче ел әдибе. № 11.

## ЯРОСЛАВ ГАШЕКНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Бөгелмәнең шанлы көннәре. № 4.
Антонов С. Кызыл чех. Документаль повестьтан өзекләр. № 4.

## НӘҖИП ДУМАВИНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ганиева Р. Каршылыклы еллар авазы. № 6.

## В. В. МАЯКОВСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Маяковский В. Сул марш. Шигырьләр. № 7.

## ӘХМӘТ ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Мадьяров Н. Әхмәт Фәйзи Кырлайда. № 3.
Юзиев Н. Гаҗәеп талант. № 3.

ГАДЕЛ КУТУЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ, РИЗА ИШМОРАТКА 80 ЯШЬ

Ишморат Р. **Яшьлегебезне сагынып. № 10.**

МӨХӘММӘТ ГАЙНУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

Гайнуллин М. **Татар хатын-кыз язучылары. № 8.**
Юзиев Н. **Өч нәсихәт. № 8.**

ГАРИФ ГАЛИЕВКӘ 80 ЯШЬ

Хәйри Х. **Яңа авыл җырчысы. № 5.**

СЕРГЕЙ МИХАЛКОВКА 70 ЯШЬ

Михалков С. **Шигырьләр, мәсәлләр. № 3.**

МИН ШАБАЙНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Мостафин Р. **Кешелеклелек таланты. № 4.**

ӘМИНӘ БИКЧӘНТӘЕВАГА 70 ЯШЬ

Кукушкин Р. **Сез бик кадерле безгә... № 1.**

МӨХӘММӘТ САДРИГА 70 ЯШЬ

Садри М. **Төрле еллардан.** Шигырьләр. **№ 5.**

НИЯЗ ДАУТОВКА 70 ЯШЬ

Шәмсетдинова Ф. **Бәхетле иҗат юлы. № 9.**

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВАГА 60 ЯШЬ

Шәрәфи Г. **Ихласлык. № 8.**
Ихсанова Л. **Сәгать.** Хикәя. **№ 8.**

ИБРАҺИМ НУРУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Нуруллин И. **Киләчәккә карап. № 4.**

МӘХМҮТ ХӨСӘЕНГӘ 60 ЯШЬ

Хөсәен М. **Шинель.** Шигырьләр, җырлар. **№ 4.**

ИЛДАР ЮЗЕЕВКА 50 ЯШЬ

Ахунов Г. **Кыядагы бөркетләр. № 1.**
Игъламов Р. **Хакыйкатьне эзләү юлыннан. № 1.**

МАРС ШАБАЕВКА 50 ЯШЬ

Шабаев М. **Шигырь утым алга дәшә мине.** Шигырьләр. **№ 7.**

ХӘКИМҖАН ХАЛИКОВКА 50 ЯШЬ

Халиков Х. **Рәхим итегез!** Шигырьләр. **№ 1.**

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Гайнуллин М. **Мөхәммәт Галинең тууына 90 ел. № 3.**
Ибраһимова Ф. **Ф. Ибраһимовның тууына 90 ел. № 2.**
Ишморат Р. **Зәйни Шаһиморатовның тууына 70 ел. № 3.**
Шәрәфиев Ф. **Х. Сәлимҗановның тууына 80 ел. № 2.**

## УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

Бакиев Х. **Беләгемә беләзек...** Шигырьләр. **№ 12.**
Муллагалиев С. **Үзбәкстанда кар ява.** Шигырьләр. **№ 12.**
**Укучы сүзе. № 2.**

**«Яшь ленинчы» һәм «Ялкын» бездә кунакта. № 9.**

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Матвеев М. **«Дан биеклеге»ндә. № 2.**
Матвеев М. **Легендар танкист. № 11.**
Хуҗин М. **Батыр мәйданда чыныга. № 11.**
Шәмсетдинова Р., Дунаева Т. **Китап һәм укучы. № 11.**

## КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ — СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

**Дәрзаман Җ., Измайлова Н., Әйди Т. № 9.**
**Кукушкин Р., Латыйпов К. № 1.**
**Мансуров З., Садриев Ф., Хатыйпов Ф., Хисмәтуллин Р. № 6.**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—№ 12.**

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Вәлиева Д. **Әнәс Тумашев. № 12.**
Могильникова Г. **«В. И. Ленин портреты». № 4.**
Садыйкова Д. **Рәссам Мәхмүт Усманов. № 1.**
Садыйкова Д. **Кондрат Максимов җиләкләре. № 7.**
Садыйкова Д. **Бала бәхете сагында. № 6.**
Садыйкова Д. **«Студентлар җыры». № 10.**
Цой В. А. **Илдар Зарипов «Бәйрәм»е. № 5.**
Цой В. А. **Каһарман Камил Якуб. № 2.**
Чернышева В. **Шишкин «Алан»ы. № 8.**
Шаһиева Р. **Көчле кешеләр. № 3.**
Шаһиева Р. **Рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов. № 9.**
Фәттахов Л. **Совет властеның тәүге елларында. № 11.**

## ЯҢА ҖЫРЛАР

Закиров И. музыкасы, Вәлиев Р. сүзләре. **Бәхетем башкаласы. № 3.**

# ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

21 сентябрьдә Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Отчет докладына белән партия оешмасы секретаре Ринат Мөхәммәдиев чыкты. Ул язучыларыбызның КПСС-ның XXVI съезды, КПСС Үзәк Комитетының Пленумнары карарларын тормышка ашыруда, дөнья иминлеге сагында торучы совет кешесенә рухи азык бирүдә, аны гуманистик идеаллар яктылыгында илебезнең чын патриоты итеп тәрбияләүдә үз иҗатлары белән нинди өлеш кертүләре, әдәбиятыбызның бүгенге һәм киләчәк бурычлары турында сөйләде, язучыларның соңгы елларда язылган әсәрләрен анализлады.

Доклад буенча фикер алышуларда Г. Бәшиҗров, А. Шамов, С. Хәким, Г. Ахунов, Р. Мостафин, Л. Ихсанова, Ш. Галиев, М. Зарипов, Р. Харис һәм КПССның Бауман райкомы секретаре Ф. Габидуллин катнашты.

Яңа партбюрога Г. Ахунов, Р. Харис, С. Хәким, Г. Паушкин, И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Л. Ихсанова, Р. Мөхәммәдиев, Ә. Мушинский иптәшләр сайланды.

Язучылар союзы партия оешмасы секретаре итеп яңадан Р. Мөхәммәдиев сайланды.

### КОЛ ГАЛИ ЮБИЛЕЕ ХӨРМӘТЕНӘ

10 октябрьда Казанда, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында болгар-татар язма шигъриятенә нигез салган Кол Галинең тууына 800 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды.

Тантаналы җыелышны кереш сүз белән юбилейны үткәрү буенча республика оештыру комитеты председателе, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты. «Кол Гали — татар язма әдәбиятына нигез салучы» дигән доклад белән В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты профессоры, тарих фәннәре докторы М. А. Госманов чыкты. Аннары РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре М. М. Годенко, Башкортстан шагыйре Нажар Нәҗми, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын русчага тәрҗемә итүче филология фәннәре докторы С. Н. Иванов (Ленинград), ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов чыгыш ясадылар.

Тантаналы җыелышта Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе И. Х. Садыйков, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, Мәскәүдән, Ленинградтан, Үзбәкстаннан һәм Башкортстаннан килгән кунаклар катнаштылар.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталары тарафыннан «Кыйссаи Йосыф» поэмасы буенча һәм Татарстан шагыйрьләре, һәм композиторлары әсәрләреннән әзерләнгән әдәби-музыкаль композиция булды.

*

* *

11 октябрьда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында болгар-татар язма әдәбиятына нигез салучы, урта гасыр төрки поэзиясенең күренекле шагыйре Кол Галинең тууына 800 ел тулуга багышланган фәнни конференция булды. Аның эшендә Казан, Мәскәү, Ленинград, Алма-Ата, Уфа, Махачкала галимнәре катнашты.

Конференцияне кереш сүз белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, философия фәннәре докторы Я. Г. Абдуллин ачты.

Докладлар белән филология фәннәре докторлары Н. Г. Юзиев, Х. Х. Куроглы, С. Н. Иванов, Г. Т. Таһирҗанов, тарих фәннәре докторы М. А. Госманов, филология фәннәре кандидатлары Н. Ш. Хисамов, Ф. С. Фасеев, Ш. Ш. Абилов, У. Х. Субханбердина, Ү. И. Гыймадиев һәм башкалар чыкты.

Конференция эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, КПСС өлкә комитетының фән һәм уку йортлары бүлеге мөдре Ә. С. Миндубаев катнашты.

### Н. А. ДУРОВАГА — 200 ЕЛ

1 октябрьда Алабугада Ватаныбызның патриот кызы Надежда Андреевна Дурованың тууына 200 ел тулуны тантаналы төстә билгеләп үттеләр.

Татарстан АССР Министрлар Советы карары белән Алабуганың Садовая урамына Н. А. Дурова исеме бирелде. Бу уңайдан шәһәр хезмәт ияләре митингысы булды. Соңгы елларда Алабугада Дурова яшәгән йортны музей итү турындагы карар укылды.

Тантанада катнашучылар шәһәрнең тарихи урыннары белән таныштылар. Н. А. Дурова һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре салдылар.

Кичен шәһәрнең техника йортында тантаналы җыелыш булды. «Н. А. Дурова —

язучы, солдат, патриот» дигән темага доклад белән Алабуга педагогия институты ректоры, филология фәннәре докторы Т. Н. Галиуллин чыкты.

Җыелышта катнашучыларга Татарстан дәүләт филармониясе әзерләгән әдәби-музыкаль композиция күрсәтелде.

Н. А. Дуровага 200 ел тулу тантанасында Татарстан АССР культура министры И. Н. Алиев, КПССның Алабуга шәһәр комитетының беренче секретаре И. В. Курмашев, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре А. И. Волков, РСФСР Язучылар союзы идарәсенең консультанты шагыйрь Гәрәй Рәхим, «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Ренат Харис, язучылар Нурихан Фәттах, Нонна Орешина, шәһәрнең партия, совет, комсомол работниклары, шәһәр активы катнашты.

* * *

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советының Татарстан Язучылар союзы идарәсе белән берлектә уздырылган киңәйтелгән утырышы Ватаныбызның патриот кызы Н. А. Дурованың 200 еллык юбилеена багышланды. Анда «Н. А. Дурова — язучы, солдат, патриот» дигән доклад белән филология фәннәре докторы Т. Н. Галиуллин чыкты.

Аннары филология фәннәре кандидаты А. М. Саяпова, Алабуга шәһәренең тарих музее директоры Г. Н. Маясникова, язучы Н. Орешина һ. б. чыгыш ясады.

## БӨТЕНСОЮЗ КИҢӘШМӘСЕ

5 октябрьдә Казанның Яшьләр үзәгендә Идел буе зонасы культура һәм сәнгать работникларының Бөтенсоюз киңәшмәсе булды.

Киңәшмәдә Мари, Мордва, Татарстан, Удмуртия, Чувашия автономияле республикалары, Горький, Куйбышев, Пенза, Саратов, Ульяновск өлкәләре культура органнары һәм учреждениеләре вәкилләре катнашты.

КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев киңәшмәдә катнашучыларга республикабызның экономик, социаль һәм культура үсеше турында сөйләде.

«КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы карарларын үтәү буенча культура һәм сәнгать органнарының һәм учреждениеләренең эше турында» доклад белән СССР культура министры урынбасары Т. В. Голубцова чыкты.

Доклад буенча фикер алышуларда ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов та катнашты.

## ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ ПЛЕНУМЫ

10 октябрьдә Пресса йортының конференц-залында Татарстан Журналистлар союзы идарәсенең киңәйтелгән пленумы булды. Анда «КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы карарларын, КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Ю. В. Андропов Пленумда сөйләгән речендәге положениеләрне һәм нәтиҗәләрне тормышка ашыру буенча республика журналистлар коллективларының бурычлары турында»гы мәсьәлә тикшерелде.

Пленумда шулай ук оештыру мәсьәләсе каралды. Пенсиягә китүе уңаеннан, пленум Ш. Х. Хамматовның Татарстан Журналистлар союзы идарәсе председателе вазифасыннан азат итү турындагы үтенечен канәгатьләндерде. Татарстан Журналистлар союзы идарәсе председателе итеп «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Р. М. Сабиров сайланды.

## ШАГЫЙРЬЛӘР СЕКЦИЯСЕНДӘ

Быел Ташкентта Азия һәм Африка илләре язучылары Ассоциациясенең VII конференциясе булып узды. Тынычлык, гаделлек һәм прогресс байрагы астында үткәрелгән әлеге зур форумда, Азия һәм Африка язучылары бәйләнешләре буенча Совет комитеты члены буларак, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Гариф Ахунов та катнашты. Поэзия секциясенең 13 октябрьдә узган чираттагы җыелышында ул Ташкент очрашуында алган тәэсирләре белән уртаклашты.

Язучының иҗтимагый-политик һәм гражданлык позициясе турында сөйләде, әдәби хәрәкәтебездәге хәл итәсе проблемаларга тукталды, тыңлаучыларның күп төрле сорауларына җавап бирде.

## БАТЫРЛЫК БЕЛӘН ОЧРАШУ

16 сентябрьдә Казанның А. Алиш исемендәге Пионерлар сараенда патриот язучы Абдулла Алиш истәлегенә багышланган кичә булып узды. Бу кичә язучының тууына 75 ел тулуга багышланды.

Казан мәктәпләренең А. Алиш исемен йөртүче отряд пионерлары янына язучының туганнары, каләмдәшләре һәм яшь язучылар килгән иде.

Очрашуда танылган шагыйрьләр Нури Арсланов белән Галимҗан Латыйп А. Алишның яшьлек еллары турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар. Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин җәлилчеләрнең үлемсез батырлыклары турында сөйләде. Шагыйрьләр Р. Мингалимов, Р. Миңнуллин яңа әсәрләрен укыдылар.

Язучының хатыны Рокыя Алишева, улы Алмаз, бертуган апасы Мәрьям Булатова, бертуган энеләре Габдрахман һәм Галимҗан Алишевлар пионерларның сорауларына җаваплар бирделәр, истәлекләрен сөйләделәр.

# ӘНӘС ТУМАШЕВ

*Рәссамның 60 еллыгына*

Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган художнигы Әнәс Тумашев моннан илле ел элек сәхнә бизәүчеләр сафына баса һәм шунда ук үзен танытып та өлгерә. Аның бөтен иҗаты диярлек Г. Камал исемендәге академия театры белән бәйле. Шушы коллектив белән бергә ул яңадан-яңа уңышларга ирешә.

Әсәрнең күтәргән мәсьәләләре тирәнрәк булган саен, сәхнәне бизәү эше дә кызыклырак. Нәкъ менә шуның өчен дә Шекспирның «Чамасына күрә чарасы», Островскийның «Яшенле яңгыр», «Котырган акчалар», Лермонтовның «Маскарад», Погодинның «Баһадирлар» әсәрләренең эскизлары һәм декорацияләре сәхнә рәссамы тарафыннан үзенчәлекле хәл ителгәннәр.

Рәссамның хезмәтләрендә татар драматургиясе аерым урын алып тора. Аларның берничәсен генә санап узыйк: Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә», К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр», Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми», Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар», Г. Ахуновның «Чикләвек төше»... Күргәнебезчә, бирелә художник иҗатына хас булган социаль характердагы әсәрләр өстенлек итә. Ул спектакльләрдә куәтләре тигез булмаган көчләр бәрелешәләр һәм еш кына һәлак та булгалыйлар, ләкин аларның яхшылык, хаклык идеяләре тантана итә, киләчәк буыннарда үз дәвамын таба.

Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» исемле тарихи-революцион драмасы академия театрында күп тапкырлар куела. 1957, 1977 елларда спектакльнең художнигы Ә. Тумашев була. Бу хезмәтләрнең соңгысында ул элекке татар авылының нинди авыр шартларда яшәвен чагылдырырга омтылган. Ә мондый омтылыш бик кызык хәл ителә, ул бизәлешнең соргылт-көрән тон алуыннан, анда иске крестьян йортын һәм бөтен сәхнәне әйтерсең лә рам эченә камап алган читән тасвирлануыннан да күренә. Ләкин әлеге күренешне милли киемнәрнең якты төсләре, пьесаның төп герое Биктимер карт өенең гадилеге, пөхтәлеге ачып җибәрә.

Спектакльнең ничек кабул ителүендә рәссамның, режиссер һәм актер кебек үк, тоткан урыны зур. Әнәс Тумашев иҗат иткән декорацияләр ачык һәм аңлаешлы булулары белән тамашачыны җәлеп итәләр. Чөнки алар барлык иҗади коллективның бердәм хезмәте белән бербөтеннәр.

Рәссам озак еллар буе Татарстан художниклар союзы идарәсе председателе һәм Татар дәүләт академия театрының баш художнигы эшләрен бергә бәйләп алып бара. Бүгенге көндә сәнгать остасының иҗат көче ташып тора. Һәрвакыттагыча аны театр да, сынлы сәнгать тә үзенә тарта. Аларның икесе дә рәссам күңеленә бик якын.

**Динә ВӘЛИЕВА,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

●

**Тышлыкның дүртенче битендә:**
М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Шопениана» балетыннан бер күренеш.

**Рөстәм МАНСУРОВ** слайдлары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ